ISSN 0206-4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2013



# *Казан Универсиадага әзерләнә*


















# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

**3**
**(1085)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир,**
**Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева,**
**Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. *Хикәяләр.* ....5

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Яну дәверләрендә. *Роман-поэмадан өзекләр.* ....25

БАТУЛЛА. Туган ягым – Зәй төбәге. *Хатирәләр.* ....34

Рөстәм АКЪЕГЕТ. Күңелем – салават күпере. *Шигырьләр.* ....73

Булат ИБРАҺИМОВ. Мөкатдәс саз тынды уйнавыннан. *Шигырьләр.* ....124

ӘДӘБИ МИРАС

Газиз МӨХӘММӘТШИН. Дулкыннар җыры. *3 пәрдәлек трагедия.* ....77

«МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫНА100 ЕЛ

Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ. Гыйлем һәм мәгърифәт учагы. ....127

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Фатих КУТЛУ. Тәрҗемәчелек – заман таләбе. ....132

Ленар ШӘЕХ. Телләрнең күптөрлелеге – бөтен дөнья байлыгы. (*Халыкара ПЕН-клубның Кырым конференциясе*) ....136

ПУБЛИЦИСТИКА

Фәрит ХАТИПОВ. Агымсуда электр ташкыны. ....141

ХӘТЕР

Рәфикъ ЮНЫС. Тормышым сәхифәләре. ....146

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Мәгърифәт юлына маяклар кагучы (*Закир Һадиның тууына 150 ел*). ....177

ТАРИХ

Дамир ИСХАКОВ. Бөек Ауразиячелең бер ялгышы. ....151

Искәндәр ЯРМӘКӘЕВ. Фәнгә багышланган гомер. ....155

КИТАП КҮЗӘТУ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Әдип галим турында галим әдип. ....159

Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. Язмыш турындагы сер. ....163

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....166

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....169

СӘНГАТЬ

Розалина ШАҺИЕВА. Кинлек дәрте (*Милли мәдәният музее оешуга 20 ел*). ....172

ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Фәнзаман БАТТАЛ. Башта ук шулай дияргә иде! ....184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: воспоминания БАТУЛЛЫ «Мой Заинский край» (окон.); рассказы Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ; отрывки из романа-поэмы Ф.ГИЗЗАТУЛЛИНОЙ; стихи Р.АКЪЕГЕТ, Б.ИБРАГИМОВА.
«Литературное наследие»: Г.МУХАМЕТШИН. Трагедия «Песня волн».
«100 лет журналу «Магариф»: Г.ШАМСУТДИНОВ. «Очаг науки и просвещения».
«Дружба литератур — дружба народов»: Ф.КУТЛУ. «Переводческая деятельность — требование времени»; Л.ШАЕХ. «Разнообразие языков — всемирное богатство».
«Публицистика»: Ф.ХАТИПОВ. «Реки полны электричеством».
«Память»: Р.ЮНУС. «Страницы из жизни»; А.ЗАКИРЗЯНОВ. «Освещая путь просвещения».
«История»: Д. ИСХАКОВ. «Одна ошибка великого ученого»; И.ЯРМАКАЕВ. «Жизнь, посвященная науке».
«Книжное обозрение»: Р.ФАЙЗУЛЛИН. «О писателе-ученом — ученый-писатель»; Г.ГАЙНУЛЛИНА. «Секрет о судьбе».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Искусство»: статья Р.ШАГИЕВОЙ, посвященная 20-летию образования Национально-культурного музея.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Весеннее половодье; поэтесса Лэйсан ФАТХУТДИНОВА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: memoirs by BATULLA «My Zainsk region» (ending); stories by F.ZAMALETDINOVA, passages from novel-poem by F.GIZZATULLINA; poems by R.AKEGET, B.IBRAGIMOV.
«Drama»: G.MUHAMETSHIN. Tragedy «Song of waves».
«100th anniversary of magazine «Magarif»: G.SHAMSUTDINOV. «Center of science and education».
«Friendship of literatures is friendship of peoples»: F.KUTLU. «Translation activities are call of the times»; L.SHAEH. «Diversity of languages is global wealth».
«Journalism»: F.HATIPOV. «Rivers are full of electricity».
«Memory»: R.YUNUS. «Pages of life»; A.ZAKIRZYANOV «Illuminating the path of education».
«History»: D. ISKHAKOV. «One mistake of great scientist»; I.YARMAKAEV. «Life devoted to science».
«Book Review»: R.FAYZULLIN. «About scientist-writer by scientist-writer»; G.GAYNULLINA. «Secret of fate».
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Page of «Tatar Encyclopedia».
«Art»: article by R.SHAGIEVA devoted to 20th anniversary of the National Cultural Museum.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Spring flood; poetess Leysan FATHUTDINOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.03.2013, график буенча 01.03.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-496. Тираж 4020.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Фирүзә
Җамалетдинова

## ХИКӘЯЛӘР

### Кеше күңеле – кара урман...

Кырлар өстеннән пар күтәрелә, җир исе аңкый. Ишегалдында казлар кыйгылдаша, сарыклар бәэлди, сыерларның тук мөгрәве ишетелә. Авыл кышкы караңгылыктан исән-имин арынып, ямьле, тузганаклы майларга кереп бара.

Тузганак чәчкәседәй сап-сары эшләпәсен киеп, Сабираттинең ике генә тәрәзәле караңгы өеннән, иске гармун күрекләрен каера-каера, Пәттери чыга.

Аның өстендә – солдат шинеле, билендә – киң каеш. Аягында – солдат итекләре.

Менә берзаман күрекләр шыгырдап тартыла, авыл өстендә гармун тавышы инрәп куя. Юк, юк, гүя ул күк гөмбәзендә яңгырап ала. Бөтен халык урам ягына карый, аннан Пәттери янына җыела...

Ул эре-эре атлап, гармунын тарта-тарта күрше авылларга төшеп китә. Анда да Пәттерине яз саен көтеп торалар. Чөнки ул бөтен тирә-якка яз алып килә. Шатлык алып килә.

Кешеләрнең, йомырка йә клиндер салынган кесәләре бүлтәеп кабарганын күреп ул елмая, үзе берни дә сорамый. Ни бирсәләр, шуны гына ала. Барысын да эшләпәсенә сала. Чөнки белә: авыл кешесе кем булуына карамастан, һәркемне хөрмәт итә...

Пәттери гармунда уйный-уйный да тукталып бер сүз әйтә:

– Карале, миңа күз кыса, – ди. Кайчакта аның бу сүзе яшь кызларга төбәлә. Тегеләр оялышып читкә борылалар.

Аннан тагын гармунын тарта башлый ул. Әлбәттә, моң да, көй дә чыкмый, ларт-лорт килеп газапланган аһәң генә инри-инри бөтен җиһанга тарала.

Бераз уйнагач, Пәттери янә туктап кала һәм ак яулыгын җәеп бәйләгән, бәрхет камзуллы карчыкка – авылның остабикәсенә карап тора. Бармагы белән төртеп күрсәтеп:

– Кара, күз кыса, – дип ыржая.

---

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА – *язучы; «Догалы корт», «Еллар кәрваны», «Толымлы ай» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

– Әстәгъфирулла тәүбә, гармунын ишеткәч үк чыкмам дигән идем, – ди тегесе еламсырап, чыелдык тавыш белән.

Гармун иңрәвен шаян көлешүләр басып китә. Кешеләрнең кәефе үзгәрә, күңелләре күтәрелә.

Ул шулай авылга рух өсти.

Минем әбием белән әни урамда Пәттери күренүгә, еш кына бәхәсләшеп алалар.

– Җир өстеннән дивана булып үткән кешеләрнең бу дөнья өчен яхшылыклары юк, теге дөнья өчен гамәлләре юк, – ди әбием.– Алар ике галәм арасында асылынып торырлар ди...

– Менә бит, бөтен авылның күңелен күтәрде, бу изге гамәл түгелмени? – ди әни.

– Түгел шул... Монысы гына гамәлгә кермидер шул әле...

– Җүләрләр дә җәннәтле булмагач, кемгә эләксен инде ул җәннәт?! Кеше хакына үрелмиләр, беркемгә бер зыян салмыйлар...

Әби, үз уйларына бирелеп бераз сүзсез утырганнан соң, әйтеп куя:

– Бакыйлыкка күченгәнче өч-дүрт көн генә акылын җуйганнар җәннәтле булыр, ди китап...

– Син, әни, бигрәк инде, һаман китап та китап дисең... Яратып уйлыйсың да инде бөтенесен... Никтер, яз житте исә, Пәттеринең гармун тавышын ишетәсебез килеп китә бит, менәтерәк... Үзеннең дә бер дә өйдә калганың юк әле...

– Юк шул, – дип куя әби йомшак кына.

Әби Пәттеригә эре бакыр биш тиенлек акчалар алып чыга. Ул аларны бигрәк тә ярата. Бөтен кешегә күрсәтеп, мактанып йөри.

– Әйдә җырлап та җибәр, Пәттери, – диләр ир-егетләр кайчакта.

– Пәттери җырламый, – дип куя ул еш кына битараф кыяфәттә.

Язлар житкәнгә Пәттеридән дә күбрәк сөенгән кеше күрше-тирә авылларда да юктыр, мөгаен. Үзең сөенер өчен башкаларны да сөендерергә кирәк шул. Шатлык бит ул – сине хуплаучылар бар дигән сүз. Ул бит терәгең булу билгесе. Диваналар өчен дә әлеге төшенчә бер дә үзгәрми икән...

***

Безнең авыл егетләренең бер кабахәтлеге бар: алар үзләре белән сөйләшмәгән, башбирмәс, горур кызларны эре сөякле, дәү Пәттеридән озаттыралар. Һәм бөтен «бригада»лары белән артларыннан тыңлап, көлеп кайталар.

Бертапкыр клуб ишегалдында Камил абый Пәттери янына килеп басты да тәмәкесен кабызып җибәрде.

– Син алдалагансың. Янагыма сукты менә...– диде Пәттери бармагы белән төртә-төртә..

– Авырттымы?

– Авыртты шул.

– Кочакладыңмы соң?

– Кочаклатмады... Сукты...

Пәттери елап җибәрде.

– Елама, бүген сукмас ул, – дип юатты аны Камил абый. – Үзебез карап кайтырбыз... Кочакла да үп син аны...

Мин әлбәттә кем турында сүз барганны шунда ук чамаладым.

Безне ул көнне дәресләрдән азат итеп, классыбыз белән колхоз кырына бәрәңге чүпләргә җибәрделәр. Класс җитәкчебез Гүзәлия апа да безнең белән иде. Ул авылыбызга шушы көздә генә килде. Һәм күршебезгә – Хәмидә әбигә аны фатирга урнаштырдылар.

Укытучы апаның кап-кара калын, озын толымнарын тибрәлдереп өй каршыннан үтеп китүләрен егетләр генә түгел, без дә әбием белән сокланып карап калабыз.

– Бирсә-бирер икән Ходай гүзәллекне, – дип куя әбием аны күргәндә. – Тфү, тфү, күзләр генә тимәсен бу балага...

Тип-тигез асфальт юлдан килгәндәй, вак-вак адымнар белән, башын югары тотып, керт-керт кенә басып атлый ул. Хәтта бәрәңге басуында да үзгәрми икән атлап йөрешләре!

Чибәр һәм яшь укытучыны балалар да ярата. Аның һәр сүзен тыңлыйлар. Без дә, яныбызда Гүзәлия апа булганы өчен, бер-ике сәгать эчендә бер машина бәрәңгене чүпләп, машинага төяп тә җибәрдек. Инде үзебезгә үзебез ял оештырып, табышмаклар әйтешеп, җавапларын чишеп, көлешә-көлешә басып торабыз.

Берзаман басу читеннән мотоцикл тавышы ишетелде. Һәммәбез күтәрелеп тавыш килгән якка карадык. Тыкырдык тавыш якынайды-якынайды да, Камил абый булып алдыбызга ук килеп басты; мотоциклын бер яккарак авыштыра төшеп, уң аягын җиргә терәде һәм вакарь белән генә Гүзәлия апага эндәште:

– Утыр әйдә!

Гүзәлия апа аптырап калды.

– Утырмыйм, – диде ул гаҗәпләнү катыш елмаеп.

– Утыр, дим!

Камил абый боерулы тавыш белән әйтте.

– Мин балаларны калдыра алмыйм, – диде Гүзәлия апа.

Камил абый канәгатьсезлеген йөзенә чыгарып, мотоциклын пырылдатып китеп барды.

...Ә кичен клубтан кайтканда Гүзәлия апаны Пәттери озатты. Дөресрәге ул көнне Казаннан театр килгән иде. Укытучы апаның да карыйсы килгәндер инде, мөгаен. Ул болай клубка йөрергә бер дә яратмый. Бәлки әле аның безнең клубны да беренче генә күрүе булгандыр. Шунадырмы, үзенә иптәшкә мине дә ияртте.

Кайтырга чыккач, безне балтырлы галушларын изә-изә, аюдай лап-лоп атлап, Пәттери куып җитте. Гүзәлия апаның каршысына чыгып, беравык текәлеп торды да, ул бер генә җөмлә әйтте:

– Ай-яй матур кыз син! – диде.

Гүзәлия апа дәшмәде. Ул җилкә башларын сикертеп куйды. Шул мәлдә айлы төнгә толым очларыннанмы икән, хуш ис таралды. (Нинди генә чәчкәләрдән җыйганнардыр инде мондый ислемайны!) Аның бераз гына курыкканлыгы сизелеп тора иде. Шулай алар шактый озак сүзсез кайттылар.

– Ай-яй матур кыз син. Исемең ничек соң синең? – дип сорады Пәттери.

– Гүзәлия.

– Ник килдең соң син безнең авылга?

– Укытырга җибәрделәр мине, – дип җаваплады Гүзәлия апа тавышын калтыратып. Үзе аюдай дәү, үзе аюдай йомшак карт егеткә ул шомланып карап алды.

– Ә-ә укытырга! Кемне укытасың соң син? – дип сузды Пәттери фуфайка җиңенә борынын сөртә-сөртә.

Ул төн ап-аяз иде. Күктә ап-ак болытларга чалкан ятып көмеш ай йөзә. Йомшак кына чәчләребездән сыйпап айлы җил исә. Һәммә нәрсә аермачык якты булып күренә. Юлыбызга шыбыр-шыбыр яфрак коела иде. Пәттери балтырлы галушларын яфрак дингезендә коендыра-коендыра һаман сорау бирде:

— Мәптектә укытасынмы соң син?

— Әйе, мәктәптә, — диде кыяр-кыймас кына Гүзәлия апа.

Без инде өйгә якынлашып барабыз. Арттан бер төркем егетләр килгәне, аларның шук шаулашканы, дәртле аяк тавышлары ишетелә.

— Ай-яй матур кыз син, — дип кабатлый Пәттери.

Ул көнне гаҗәп хәл булды. Пәттери Гүзәлия апаны кочакларга җөрьәт итмәде. Укытучы апа ашыкмый гына капкаларына табан атлап китте дә караңгылыкка кереп эреде.

— Ай-яй матур кыз, — дип Пәттери алар капкасы төбендә сабыр гына басып калды. Мин өебезгә йөгердем.

Ә көннәрдән бер көнне безнең урамда бер яңалык булды: Гөлсинур апаларга Ерак Себер тарафларыннан энесенең улы кайтып төште.

Шәмдәй төз гәүдәле, зәп-зәңгәр күзле бу егет хәрби киемнән иде. Озын шинеле дә, башына кигән фуражкасы да төс-буена шулкадәрле килешә ки, аның янәшәсенә безнең авылның бер генә егетен дә якын да бастырырлык түгел иде. Хәрбиләр генә кия торган, ялт-йолт иткән, аякларына сыланып торган күн итекләренә карасаң, мөгаен үзеңне дә күреп буладыр әле...

Егет күренүгә авыл өстенә сүз китте: өйләнергә кайткан икән, диделәр. Бик еракларга, чит илләргә җибәрәселәр икән аны. Тик ялгызына гына андый ерак якларга бару рөхсәт ителми икән. Гөлсинур апача әйтсәк, «бик перспективалы егет» ди бу хәрби кеше.

Әлбәттә моңа туры килерлек кандидатура безнең авылда берәү генә, ул — Гүзәлия апа иде. Якты күңеле аның күзләреннән үк күренеп тора! Сөйләшүеннән үк сизелә. Чиста күңелле кешеләрне эзләп килүчеләр дә була икән, аларны кайдан да бер эзләп табалар икән шул...

Тиң икәнлекләрен сизенеп микән, алар үзләре дә бер-берсен бик тиз күреп алганнар. «Күңел ят булмаса, кеше ят түгел», ди минем әби. Дөрес әйтәдер ул. Бер дә ят дип тормаган Гүзәлия апа, кияүгә чыгарга да ризалык биргән.

Аларның ап-ак туй күлмәкләре киеп, язылышып кайтуларын да бөтен авыл хәтерлидер кебек әле. Ак болытка тиң иде Гүзәлия апаның күлмәге. Җиңнәре дә тавис кошы канатларыдай кабартып тегелгән, җитмәсә, муен тирәләре энҗе-мәрҗәннәр белән каелган. Туфлиләре исә кытай чынаягы кебек ап-аклар иде...

Әйе, хәтерлиләрдер, чөнки бу кадәр дә матур парны авылның моңарчы күргәне дә булмагандыр сыман.

Тик... матурлык ул бәхет түгел икән әле...

Икенче көнне, Гүзәлия киткән, дигән хәбәр бөтен авылны сискәндереп җибәрде.

Туй күлмәкләрен салып, карават башына элеп калдырган да, таң алдында Гүзәлия апа авылдан кай тарафларгадыр китеп тә барган...

Әле дә аларның туй балдаклары Гөлсинур апаларның сервантында, чынаяк тәлинкәсендә тора... Тузан утырган саен, ничектер тоныклана баралар сыман тоела алар миңа...

Шул хәлдән соң Хәмидә әбиләргә башка укытучылар фатир төште. Яшьлекләре гүзәл, үзләре горур иделәр. Аларны да Пәттери озатты. Тик Пәттери дә элеккеге Пәттери түгел иде инде. Ул клубтан кайтканда кызлар белән һаман бертөрле сөйләште. Сөйләшүе сулышыдай җиңел иде.

— Гүзәлия миңа елап-елап хатлар яза, — дип башлый иде ул сүзен.

— Елаганын каян беләсең соң? — дип сорады бер тапкыр укытучы Дания апа.

— Дәфтәр битендәге карасы агы-ы-ып-агы-ы-ып төшкән, — диде Пәттери.

Дания апа да хәйләкәр. Монысын уйлый белә микән, дип бирә инде ул шундый катлаулы сорауны. Гүзәлия апа дигәндә, белмәс сина!

Алар тынып калган арада борынга кычыткан исе бәрелә. Юл буендагы куаклар уйчан гына шаулашалар. Койма буйларындагы үлән арасында чикерткәләр сайрый. Күнелле булып китә...

— Алайса, нишләп барып алмыйсың соң аны? — Монысын Дания апа ихласлык аша сорап куя.

— Сине озатырга куштылар бит әле, менә, — ди Пәттери бик борчылган кыяфәт чыгарып.

Диваналарда да мәхәббәт була икән ул. Гүзәлия апа авылдан чыгып киткән атнада ук, Пәттери, өстенә солдат шинеле табып киде. Итекләрен дә кемнәрдәндер эзләп алган бит. Фуражка юллап бирүче генә булмагандыр ахрысы. Ул төп-төз басып, Гүзәлия апа яраткан теге хәрби кешегә охшатып йөрергә дә өйрәнгән иде...

Вакытлар үтте. Инде кызлар, кайсыдыр егетнең озатуын теләмәсәләр, үзләре үк Пәттерине култыклап алалар да, «Әйдә, бүген мине озатып куй инде,» диләр. Әлбәттә ризалаша Пәттери. Ул Гүзәлия апа турында шулай өзгәләнеп, тагын кемгә, кайда сөйли алсын соң?

Инде буыннар алмашынды. Пәттери элек бездән күпкә олылар белән клубка йөрсә, хәзер инде ул безнең белән иде. Сәхнәдә һаман Пәттери биеде.

— Пәттери, сальто! — дип кычкырдылар ана армиядә хезмәт итеп кайткан егетләр. Армиядә булмаса да, бу җәһәттән ул теләсә нинди сүзне аңлый, шинелен тиз-тиз салып бер читкәрәк ташлый да, һавада мәтәлчек ата башлый иде.

Җырла дисәләр дә ялындырып тормады.

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап
Сине күрәсем килә,

— дип, кысаларга һич буйсындырмыйча, җыр сузды. Гармунын алып килгәндә, кычкыртып уйнап та җибәрде. Җыр һәм моң әлләни чалымланмаса да, Пәттери уйнап җырлаганда күтәренке рух өскәрәк калкып чыга иде...

Җанында мәхәббәт бар иде шул аның...

***

Язмышларыбыз читтә язылган булып чыкты, без барыбыз да авылдан аерылдык. Чит якларга китеп тормыш кордык.

Авылда хәзер кеше дә юк дисән, дөрес була микән инде? Бәлки дөрестер дә. Чөнки авылны урам саен берничә карчык, шул исәптән минем әни һәм Пәттери тотып тора. Хәер әз-мәз картлар да бар әле барын.

Пәттери булганда авылда күнелле. Ул без кайтканны күрсә, каршыга йөгереп чыга:

— Сәлам, күрше, — ди. — Кайттыгызмы? — ди.

Күрше үк булмасак та, авылда кеше калмагач, бар да күрше инде.

Ир-егетләрне күрсә ихлас сөенә:

— Кая үсәсеңдер, кайткан саен үсәсең, син, әй, — дип аларның башларыннан сыйпый. Бер тапкыр мин аның шулай дия-дия түбә чәчләре коеган Гамир абыйның башыннан сыйпаганын да күрдем...

Без бу юлы кайткач та Пәттери өйгә килеп житте. Телевизоры ватылган икән.

– Миннән качтылар кешеләре. Сөйләшмиләр дә, мине ишетмиләр дә, – диде.

– Алып кайтып бирегез шуңа бер телевизор, – диде әни. – Үзе бөтен йомышыбызны тыңлый бит ул, бичара. Телевизор бик кирәк аңа. Теге, Хәмидә әбидә торган иде бит әле Гүзәлия исемле кыз. Шул күренмәсме дип карый инде ул аны...

Кичтән без шкафларны күчердек. Шулай аш үткәрергә урын әзерләдек. Күтәрешергә Пәттери йөгереп килеп җитте. Җен урынына эшли ул.

Әни шул тикмәгә генә:

– Ярый әле Пәттери бар, бөтен эшебезне кырып сала,– димидер.

Авылда яшьләр булса, Пәттери һаман җырлап-биеп күңел дә ачар иде әле, һаман кызлар озатыр иде.

Нишләтәсең, авылның язмышы башка яккарак юнәлеш алгач?..

Язмышны үзебез язабыз дисәләр дә, үзебез генә язмыйбыз бугай шул аны... Үз авылының бетүен кем генә теләр иде икән?

Ярый әле Пәттери бар... Авылның ялгыз карчыкларын да кыш чыгарга дип, балалары, бәрәңге, кәбестәләре, ярты хуҗалыклары белән бергә шәһәргә төяп китәләр шул... Пәттери кебек тотрыклы һәм туган җиргә тугрылыклы бер генә җан иясе дә юк икән безнең авылда...

***

Ашка ике-өч сәгатькә алданрак, иртүк килеп керде ул.

– Иртә бит әле, көтә-көтә арырсың инде Фәтхерахман, кешеләрне сәгать тугызга гына чакырган идек, – диде әни аңа.

– Миндә сәгать юк бит, – дип җавап бирде ул, беләзегенә бармагы белән төртеп.

Аның сәгатьне белмәве бөтенләй истән дә чыккан.

– Ашка соңга каласым килми минем... – дип ул, шинелен салып, алгы бүлмәгә табын артына ук кереп утырды.

Миңа аның чын исемен ишетү беraз сәеррәк тә тоелып китте. Чөнки ул биш яшьлекләр өчен дә, унбиш яшьлекләр өчен дә, туксан биш яшьлекләр өчен дә бары тик Пәттери иде. Аның башкача беркем дә буласы килмәде кебек.

Хәер, минем яшьтәшләрдән дә бөтен кеше әби-бабайга әйләнде, итәкләренә оныклары кунаклады. Кайсының чәченә тузганак мамыгыдай чал төште, кемнеңдер авыз-күз тирәләрен җыерчыклар ергалады. Ярты авыл зиратка күченеп бетте. Һәммәсенә мәңгелек йортны Пәттери әзерләште. Кабер казу аның өчен берни дә түгел: көче ташып тора чөнки, ә калганын ул уйлый белми иде... Пәттери генә картаймады. Минем әби: «Җүләр картаймый ул,» – ди торган иде. Әбием хаклы булгандыр инде, мәрхүмә.

Хәер, Пәттери картаймавы белән дә авылның хәтерен саклый, үзе дә белмичә, бай тарихын, рухын тотып тора кебек тоела...

Ә аштан соң, без, районга барып, аңа зур телевизор алып кайттык. Моңа язга чыккандагы кебек куанды, бичара. Гармуны тузмаса, бәлки күрекләрен кубара-кубара тартып, сөенечен уртаклашырга урамга ук чыгар иде. Бәлки күрше авылларга ук төшеп китәр иде... Хәер, теге, ерак еллар ышыгында калган язларда да күрше авыллардан Гүзәлия апаны эзләп йөрмәде микән әле ул, кеше күңеле – кара урман диләр, кемнәр белеп бетерсен соң аны?!

... Пәттеринең телевизорлы булуына үзебез дә сөендек. Чөнки безнең авылда әле мәхәббәт яши... Кем белгән, бәлки яңа экраннан Гүзәлия апага охшаган гүзәл бер кыз сыны да чалымланып китәр әле...

## Сугыш – озын гомерле

Ямаулы кара халатына сыргаанактай сарылган сап-сары йомычкаларны кагып-кагып төшерде ул. «Авыру килеш никләр җыям инде мин боларны азапланып, карчык кешегә кирәкме инде бу йомычкалар?» – дип уйлады. Хәер, ник җыйганын ачык белсә дә үз-үзенә шулай дип сорау бирде Нәүбәһәр.

Әнә генә ич үр! Шушыннан, осталар балта биеткән җирдән генә ап-ачык күренә шул ул. Карачы, бормаланып сузылган юл тасмадай җилферди гүя. Юк, юк, җилфердәмидер, картлык галәмәтедер инде анысы. Күзләр дә картая икән шул. Тозлы яшьләр ашыйдыр аларны да.

Карчык, керфекләрен челт-мелт йомгалап, җилфердек юлга карап торды. Шуннан китеп барды аның газизе яуга. Китте дә кайтмады... Күп гомерләр үткән инде... Күпме җәйләр кабатланган... Күпме учаклар сүнгән... Әле һаман әз генә өрү дә житә: күзләр гөлтли дә кабына... шуна йомычкаларны өстәп кенә торасы...

...Менә генә авызына бер йотым су капмыйча, ай буена ул урын өстендә ятты. Күңелендә аерылу газаплары янарды. Көн узган саен, авыр уйлар басып, аны тимер караватка ныграк сендерә бардылар. Ул уйларын җиңәргә тырыша, тик ни хикмәт, алар карчыктан көчлерәкләр иде шул.

...Кинәт караваты җир шары тирәли әйләнеп киткәнне тоеп, Нәүбәһәр сискәнеп куйды. Әйтерсең өе икегә аерылды.Өйнең ике ягында ике ут йомгагы пәйда булды. Ике йомгакның да ул елтырап торган күзләрен күрде.

– Син кем? – дип сорады Нәүбәһәр сул яктагысыннан.

– Мин – Нәфрәт, – дип җавап кайтарды йомгак.– Син мине танымыйсыңмыни?

– Таныйм икән шул. Күзләрең көндәшемнеке...

Карчык башын уң якка борды. Кинәт кечкенә генә өе нур белән тулды, бөтен дөнья яп-якты булды.

– Син кем? – дип сорады Нәүбәһәр. Ул бик нык дулкынланды.

– Мин – Мәхәббәт, – диде нур йомгагы. Карчыкка Хәмит күзләре карап тора иде. Кинәт тәрәзәләре зурайды, ишеге киңәйде. Һәм нур йомгагы шул якка тәгәрәде... аннан кинәт кешегә әверелде... кин ишектән япь-яшь ире аңа якынлашып килә иде.

– Кайттыңмы? Гомерем буена көттем мин сине! Кайтасыңны белдем, шуңа көттем...– дип сөйләнде карчык.

Иренең бер сүз дә дәшми янәшәсендә басып торуын аермачык күрде ул.

– Бигрәкләр озак йөрдең. Кадак Фәйзулласы кайтканга кайчан? Әтәч Хафизы кайтканга...

Шул мәлдә әллә нәрсә булды... Өе дә тораташтай катып калды. Ишек-тәрәзәләр дә үз хәленә килде. Хәмитен дә әйтерсең лә, җир йотты...

– Бу ни булды бу? – дип пышылдады, бармакларын көчкә кымшандырып. Елыйсы килде, елый алмады.

Шулай күпме ятканын хәтерләми дә инде хәзер. Аның бөтен тәне ут йомгагыннан пешкән кебек әрни. Шул көе дә бөтен җанына җиңеллек кунган, күңеленә, әйтерсең кошлар оялаган, алар аны күкләргә табан әйдәкилиләр иде.

...Җаны тулы җиңеллек булса да, карчык авырлык белән урыныннан купты. Хәмитенең теге көндәге төс-кыяфәте әле һаман күз алдында тора. Тәрәзәдәге яктылыкны ул әйтерсең моңарчы бер генә мәртәбә дә күрмәгән... иркен офыкларда таң шәүләсе чалымлана, еракта-еракта йомры нур йомгагыдай кояш кызара... Шушы яктылыктан аның йөрәге куәтләнеп типте. Аннан ул йомгакны ачыграк күрә башлады... Бөтен тәненә шул нурлар аша көч-куәт инә, җылы дулкын тарала иде. Шушы

таң аны ниндидер могҗизага урап, урыныннан кузгалырга мәҗбүр итте. Бу караватыннан тәмам туйганлыгын аңлады. Калтырана-калтырана өстәл янындагы урындыкка барып утырды.

«Йә, ни булды бу? Әллә соң мине алырга кайткан инде?» дип уйлады. Ул инде үлемнән курыкмый, караватыннан туйган кебек үк тоташ көтү газапларыннан торган гомереннән дә талчыккан иде.

Карчык юынгыч янындагы көзгегә күз салды һәм үз шәүләсеннән тәмам өне алынды: яңаклары очлайган, күзләре төссезләнгән, йөзенә сары суккан түгелме?.. Йа Алла!

«Ярый әле үлеп калган, – дип уйлап куйды, шунда янә ирен күз алдына китереп. – Мине бу хәлдә күрмәве хәерлерәктер дә бәлки... Тик миңа кузгалырга кирәктер... Хәмитем дога көтәдер мөгаен... Кымшанырга иде ничектер... Авыру батманлап керә, мыскаллап кына чыга, диләр шул... Хак әйткәннәр...»

Гомеренә беренче тапкыр башына шундый уй килгәнгә үзе дә аптырап китте. Гомере буена көтте бит югыйсә...

Үзе дә сизмәстән, караваты почмагына килеп утырды. Ятасы килә иде аның. Бераз гына хәл җыясы килә иде.

– Ярамый, – дип әмер бирде янә үз-үзенә. – Кымшанырга кирәк...

Ул авырлык белән урыныннан кузгалып, баскан көенчә генә аякларын сыпырыштырып, язып җибәрде. Тик оеган аяклар аны тыңламады, һаман ята торгач, тез буыннары шактый йомшаган иде. Карчык аксый-туксый комганын эләктереп ишегалдына чыкты. Бермәлгә буыннары калтыраудан, туктап, өй стенасына сөялеп тыңланып торды.

Еракта-еракта осталарның агач каезлаганы, балталарның тук-тук биешкәне ишетелә. Нәүбәһәргә күңелле булып китте. Аны яшәү дигән татлы газап янә ымсындыра иде...

Ә яшәве чын-чынлап икегә бүленгән: бер ягында – яшьлек һәм ләззәтле сөю, икенче ягында – сугыш, нәфрәт, тоташ газап һәм мәңге бетмәс хәлсезлек иде.

Һәм аны гомере буена хыяллары ташламады. Шунысы гаҗәп: алар һәрвакыт чынбарлыктан матуррак булдылар.

Бертапкыр, шулай, әнисе кайдандыр киндер тукыма юнәтеп кайтты. Нәүбәһәргә күлмәклек иде ул. Кыз хыялында аңардан шундый күлмәк тегеп киде ки – теләсә кайсы тегүче күрсә дә авызы ачылып калырлык, өрфия дә өрфия, күлмәк тә өрфия иде. Шуңа төзәтмәләр кертә-кертә тукыманы шактый сандык төбендә яткырды. Көннәрдән бер көнне авылның дан алган тегүчесе Мәгъсүмә түтигә күтәреп китте.

– Ничек кушсалар, шулай тегәм инде мин, – диде тегүче. Һәм нәкъ кыз кушканча каеды, кисте, типчеде, җөйләде... Күлмәк иясенә ошарга тиеш иде. Тик...

Киеп көзгегә карауга, нигәдер Нәүбәһәр аны салырга ашыкты.

– Йа Ходаем, барысы да үзең кушканча ласа, – диде тегүче кызның канәгатьсез йөзенә төбәлеп. – Күр, ничек килешеп тора... Киндер күлмәк өрфия булалмас бит инде... Өстеңдә тузсын, сеңелем, өстәүле булсын берүк...

– Әллә нәрсәсе минемчә түгел кебек, – дип мыгырданды ул.

– Кырт иткән ләбаса, – диде тегүче акланырга тырышып.

Чынлап та бөтен өлгеләре дә нәкъ үзе кушканча иде... Шунда ул бер хакыйкатьне ачты: хыялы күлмәктән ун тапкырга, юк, йөз тапкырга... юк, юк хисапсыз матуррак икән бит! Хыял чынбарлыктан матуррак була икән!

Хәмите аны шушы күлмәктән су юлында очратты.

«Әллә үземә түгел, күлмәгемә күзе төшкән иде микән соң?» – дип

куркынып искә төшерде Нәүбәһәр. Ана кинәт кыен булып китте. Гүя ялгыш бер уйдан хыяллары челпәрәмә килде.

Карчык көч-хәл белән кереп караватына ауды. Бик озак зәп-зәңгәр күкләргә төбәлеп Хәмитен уйлап ятты. Аны хәтерләргә сәләтле уйларына да рәхмәтле иде. Яраткан иде шул ирен. Шул ярату яшәвен мәгънәле итә, хисләрен тирәнәйтә, тормышын баета, ул мәгънә ана һаман куәтләнеп дәрман өсти, суларга һава бирә иде.

Шулай көн дә торып йөри башлагач, карчык үзен яшәүгә сусаган кешедәй хис итте. Ирен соңгы тапкыр ерактан күрсәтеп кенә алган үрне дә сагынган иде. Җанына йомычкалардай ябышкан хаста уйларын кагып төшергәндәй, сыпырына-сыпырына караватыннан торды да самавырын куеп җибәрде. Элеккечә шикәр кисәген тел астына салып, чәйләп алды.

— Йомшамагыз әле, бүген үк болай кирәкмәс, — дип аякларына көч җыярга боерды, аннан ишегалдына чыкты. Болытларны куалап, кисеп-кисеп җил исә иде. Җил исүе аның күңелен күтәреп җибәрде.

Янәдән кара халатын киеп алды да капчыгын култык астына кыстырып, кул арбасын эләктереп үр якка юнәлде.

Ул килеп җиткәндә соң иде инде. Үр гадәттәгечә яп-якты. Ире яуга киткән юл башында кояш нурлары биешә, янәшәдәге болыннан тукранбаш, мәтрүшкә исе аңкый, дымлы печән исе килә... Нәүбәһәр шуларны тойды. Ире белән ике җәй рәттән җыйган печәннән дә хушракислесенә аның башкача бер генә җәйдә дә тап булганы юк... Барыбер дә чәчкәле печән исе ана үткәннәрдән бер хатирә булып кагыла һәм татлы сагышта җанын эретә иде. Инде дөньялар үзгәрде. Болынны акчалы кешеләр сатып алган икән, дип тә сөйлиләр. Нindидер чит затлар койма тотарга биек тимер рәшәткәләр, умарта оялары да кайтарып куйдылар. Авылдагы ир-атларны өйләр төзергә яллап җибәрделәр. Умартачылар һәм дә каравылчылар торачак имеш бу йортларда... Әйтерсең монда мәтрүшкәле, тукранбашлы болын булмаган да...

— Болын исен йомычка исе басты тәмам, харап иттеләр, имансызлар, — дип үртәлеп тә куйгалый карчык. Тик аны ишетүче генә юк шул...

Инде төзүчеләр дә балталарын эшләрен йомгаклау күтәренкелеге белән тукылдаталар. Нәүбәһәр карчыкның ир-ат белән сөйләшмәгәненә алар инде гаҗәпләнмиләр. Килгәнен дә, киткәнен дә күрмәмешкә салышалар. Кыргыйлыгын гаепләмиләр дә, чөнки аның бирәр сере бардыр, дип уйлыйлар. Ә серен аның карчык үзе генә белә...

— Тук-тук ! Тук-тук-тук!

Балталар биеште дә биеште. Һәм кинәт тавышлар тынып калды.

Бу юлысы, әйтерсең, төзүчеләр дә аны юксынганнар иде.

— Нәүбәһәр әби! Кая югалдың син? Безнең арттан җыештырып торганың өчен сиңа премия тиешле. Йомычкага батып беттек менә... Хуҗага әйтербез әле без моны, — диештеләр.

— Үзегезгә булсын! Примия имеш, — дип үртәлде ул аларга күтәрелеп тә карамыйча. — Бер изге әйбер дә калмады дөньясында...

Шулчак чыбыркы шартлаганы ишетелде.

Көтү дә урыныннан кубып авылга табан юнәлеш алды. Зәп-зәңгәр һаваны кинәт тузан болыты каплады. Сарыклар бәэлдәшкәнә балта тавышларын күмеп китте. Карчык күзләрен кыса-кыса тузан болытының аргы ягына карады... Никләр карыйдыр ул анда һаман... Кара болыт артындагы зат аңа туган да, дус та түгел югыйсә... Шуны аңлаган көенә, күрмәмешкә салышып та яши белмәде шул...

— Изге җомга көнендә күземә чалынып йөрмәсәң ни була? Әйт, ни була?

Сарыклар кинәт бәэлдәшүдән туктады. Осталар балталарын читкәрәк алып куйдылар. Кайсыныңдыр бик яман ютәле купты. Ир-атлар кайчак тамашаны хатын-кызларга караганда да яратыбрак күзәтүчән, бу юлы да шулайрак килеп чыкты.

— Күземә күренмә! — дип сиңа бер генә әйтмәгән! Акылсыз баш!

Нәүбәһәр бу сүзләрне йөрәк әрнүе белән кычкырды, йөзе ачу белән тулышып, кызарып җыерылды. Бар көченә кычкырды ул һәм иелеп алып, бер уч йомычканы көтү куалап баручы карчык ягына ташлады. Тик көнбагыш таҗларыдай сап-сары йомычкалар хәлсез генә сибелеп таралдылар һәм җил аларны икенче якка очыртып китте...

Тузан болыты артыннан пәйда булган карчык күз кырые белән генә карап алды да бер сүз дә дәшмәде. Карашларын көтүнең соңгы сарыгы тоякларына бәйләргә тырышып, башын аска иеп, җәһәт-җәһәт атлавын белде.

Нәүбәһәр күзаллары караңгыланып, ларс итеп йомычкалы капчыгы өстенә утырды. Һаман вакытсыз очрап, ни дип татлыдан-татлы хыялларыннан бүлә соң ул аның? Хыялларыннан да аерырга ни хакы бар соң, җә?

Әнә шулай уйлады да кинәт тынып калды. Кеше алдында очраганы өчен кызгана да иде ул көндәшен.

«Аның урынында булсам, үзем нишләр идем икән? Мин дә шулай бер сүз дәшми үтеп китәр идемме? — дип уйлады. — Сугышны мин башламаган бит аны! — дияр идемме...»

Ул белә: аларның икесен дә бер үк хис яшәтте: Мәхәббәт һәм Нәфрәт. Икесе артыннан да бер тотам калмыйча тагылып йөрделәр алар. Сак белән Сок шикелле тавышлары һаман ишетелеп торды...

Авыл халкы бу тамашаны күп еллардан бирле күзәтә. Шуннан кызык таба диярсең. Кайчакта ирләре яуда үлеп калган ике көндәш очрашуының әтәчләр сугышына әверелеп китмәвенә бераз пошынып та яшиләр кебек тоела.

— Хәмит агайның кабере кай тарафларда икәнен дә белүче юк. Сөякләре дә әллә кайчан череп таркалып беткәндер инде мәрхүмнең... Болар һаман шуны бүлешәләр, — дип борын астыннан гына елмаеп, гайбәт сөйләшеп алалар.

Каенаналар, ак яулык читләре белән авызларын каплап, киленнәренә артыгын тел озайтырга ирек кылмыйча гына әңгәмәгә кушылалар:

— Һай, озын гомерле дә соң бу сугыш... Һай, озын гомерле дә, — дип уфтанышып куялар. Һәм сүз шунда өзелә...

Нәүбәһәр үзе дә кайчак:

— Ичмасам, талашсын иде ул! Афәт сугышның туфанын туздырыр идек бер. Икебезгә дә җиңелрәк булыр иде бит, — дип фикер йөртә.

Тик талашмый шул көндәше. Ни дип талашсын инде, җә? Синең иреңне яраттым шул, дисенме? Менә хәзер мин күбрәк тә газапланам, дисенме? Улым, әтисен бер тапкыр да күрмичә, япа-ялгызы картаеп бара дисенме? Бердәнбер оныгым да ятим калды, дисенме...

Боларны Нәүбәһәр болай да белә инде. Көндәшенең килене дә ябь-яшь көенчә дөнья куйды җитмәсә. Аны җир куенына салган көнне башында бер көфер уй бөтерелеп алган иде дә соң... аның өчен ул Ходайдан мең тапкыр ярлыкау сорады. «Мине ялгыз иттең. Улыңның ялгызлыгын күреп тә газаплан әле хәзер», дип уйлаган иде. Хәтта ирennәре дә шулай кабатлады бугай... Инде бу сүзне ник әйткәненә дә үкенеп туя алмый. Иренең улын очраткан саен бәгыре киселеп төшә... «Мин сүземне кире алдым бит инде, Ходаем, бирсәнче шуңа бер хатын-кыз заты, — дип тели. Тик чирек гасыр узса да теләге нигәдер һич кенә дә кабул булмый менә...

Яманлык турында уйлаган кешеләрне бер дә сөйми шул ул. Хәмите турында яман сүз әйткәннәре өчен күршеләренең күптән аяк эзләрен суытты. Көндәше хакында сөйләшкәннәрен дә бер дә яратмады...

Кайчакта туган тиешле сенелләре дә, Нәүбәһәрнең хәленә керергә тырышып, ирен яманлап сүз башлап карыйлар.

— Һай, чуар көнелле иде инде, безнең жизни, — диләр. Бу мәсьәләдә Каш тавы урамындагы сенелесе аеруча сүз куертучан. Нәүбәһәр шунда мунча ташыдай кыза.

— Ни әйткәнеңне беләсеңме, син, сенелем? Капканны жил аударганда торгызырга Хәмит кирәк булды. Бүген аны чүпкә чыгармакчысыңмы? — ди.

Хәзер тирә-күрше дә, туган-тумача да бу хакта ләм-мим, тел ачмыйлар инде. Акылы чуала башлаган карчык белән сөйләшү мәгънәсез, диләрдер мөгаен.

— Ике ел яшәгән иремә ни дип сүз әйттереп торыйм әле мин, — ди ул эчтән генә. Шул чакта аңа бик рәхәт була. Әйтерсең, ирен төпсез коедан тартып алган...

Иренең «төпсез кое» дигәне исенә төшкәч, нигәдер ут әвәрә килеп уйнап торган тирән чоңгылны күз алдына китерә Нәүбәһәр. Канлы яуларны киноларда да шулай күрсәтәләр бит. Сугышка үзе дә көн-төн нәләт укый ул. Ире яу кырына чыгып киткәч, киеп куйган кара халаты — сугышка булган нәфрәте, үпкә-рәнжешләре аның. Сөйгәненең шәүләсен дә күрсәтми бит менә. Нинди яман кодрәтле ул сугыш!

Кешеләр генә һаман имеш ире рәвешенә кереп төнлә моржадан Нәүбәһәр карчык янына җен төшә икән дип сөйләштерәләр. Имеш утлы шарга әверелеп, таң атканда гына моржадан чыгып, янә күккә аша икән ул... Чын дөресен үзеннән сорарга гына кыймыйлар... Бу хакта көндәшенә дә әйтештерәләр. «Сезнең аның моржасында ни эшегез бар?» — ди анысы.

Вакыт-вакыт Нәүбәһәр дә көндәшен җәлләп куя.

— Мин әле ике ел ирле булып яшәдем. Ул ике атна да яши алмады, мескен, — ди. — Япа-ялгызы бала үстерде. Күпме хәсрәт күрде. Авыл өстенә аты чыкты. Аллам сакласын, мондый хәлләргә төшүдән, — ди. Тукта, ник әле ул үзен һаман көндәшеннән өстенрәк саный? Шайтан котыртуы түгелме бу?

Балачагында әнисе: «Галәмнәр чиксез күп алар, балам, — күкләр галәме, сулар галәме, җир өсте һәм җир асты галәме, фәрештәләр галәме, шайтаннар галәме бар», дип сөйли торган иде. Аның сүзләрен искә төшереп, Нәүбәһәр шул галәмнәрнең барысында да яшәп ала гүя. Яши ала бит әле. Югыйсә җир асты галәменә генә сыешыр көннәргә дә ерак калмаган иде... Гомерне ахырынача яшәп чыгу ай-һай авыр да соң!

Әйе, коточкыч авыр заманнар булды.

Ярый әле урман коткарды барысын да. Ярый анда юкә мул иде. Каезлап кайткан юкәнең бер генә кайрысын да әрәм итмичә чабата үрделәр алар. Шуны җиде чакрым ераклыктагы базарга алып барып онга алыштырдылар. Бер пар чабатага дүрт йөз грамм чамасы алабута оны тия иде бугай. Нәүбәһәр үзе дә ашказаны суыруга түзә алмыйча, кайтып җиткәнче, оннын яртысын ялап бетерә торган иде. Ә көндәше нишләде икән? Ачлыкка түзгәндер ул... Улыма калсын дигәндер... Шулайдыр, югыйсә, тач Хәмиткә охшаш, шундый әзмәвер гәүдәле, нык бәдәнле гөрнадир үстерә алмас иде...

Көндәшенең улын күргәч тә бер сәер хис кичерә карчык. Әйтерсең каршысына яшьлеге килә... Күңеле күтәрелеп китә... «Көндәшем булмаса, мин бу йөзне, бу газиз чалымнарны мәңге күралмас идем бит», — дип уйлый. — Рәхмәт инде аңа, ди

Көндәше, иренә ияреп, авырлы көе өстенә килеп кергәч тә, бермәлгә тораташтай катып калды Нәүбәһәр.

— Син мине кичер берүк. Мин яраттым бугай аны...— диде ире каядыр, түр як тәрәзәгә төбәлеп.

Бер сүз әйтәлмәде хатын. Көндәше дә дәшмәде. Башын иеп, ире артына ышыкланып, тик басып торды. Хәер, мәхәббәткә ни әйтеп булсын соң? Һәммәсе яшь иделәр ул чакта. Яшьлек саташтыра икән инде шулай, дип фикер йөртә карчык хәзерге акылы белән дә. Ул чакта мәхәббәт янәшәсендә нәфрәт барын кем уйлап торган?..

...Кулына эләккән кием-салымын җыйнаштырды да әтисе нигезенә чыгып китте Нәүбәһәр.

Их, әтисе белән әнисе исән булсын иде дә соң менә хәзер! Бу дөньяның авырлыгы бер генә дә сизелмәс иде бит. Бу мәлдә карчык үзенең ничә яшьтә булуын да онытты. Күңел картаймый диюләре хак икән. Күз алдында әтисе белән әнисенең яшь-яшь сурәтләре пәйда булды.

Ул үзенең халык дошманы кызы икәнлеген исенә төшереп, куырылып куйды. Кайдадыр, әллә шаяртып, әллә чын, әтисе: «Кайда да юк без – ярлы крәстиянгә, үлсәң – Ленин, торсаң – Сталин бар», – дигән имеш. Көне белән ничек ишеткәннәр диген?.. Алдылар да киттеләр. Шуннан кайтмады инде ул... Бу хәсрәткә әнисе дә кыелып кына төште...

Нәүбәһәрнең әти-әниле бәхетле көннәре гүя яшен кебек елтырап күренеп кенә алды да, каядыр, күк катына кереп югалды...

Инде ни гомерләр, бер тотам да калмыйча артыннан котсыз сугыш шәүләсе ияреп йөри менә. Аңа ятимлеге тагылган...

Хуҗалары бакыйлыкка күченгән ятим йортны ул сыңар канат булып ачып керде. Баштарак ялгызлыктан курка иде, кунарга тирә-күршедәге карчык-корчыкны, бала-чагаларны чакырыштырды. Соңга табан ялгызлыгына да ияләште, ишек келәсе шакылдаганны да өнәми башлады. Язмышка каршы бару һич мөмкин түгел, сынауларга күнегергә кирәк, дип исәпләде. Иренең:

– Мин яратам бугай аны, – дигән сүзләре әле дә колагында чынлап тора кебек.

Тоташ әрнү-газаплы кичне аның исенә дә төшерәсе килми инде... Ул авырлыкны бүгенгесе көн дә күтәрерлек түгел... Рәнҗеше дә, газабы да, сөюе дә бергә укмашып нәни йөрәген таладылар... Ач этләр кебек иде һәммәсе дә...

Икенче көнне радиодан сугыш башланганны хәбәр иттеләр...

Авылдан көн саен ир-атлар яуга чыгып китте. Караңгы, куркыныч иде ул көннәр... Хәмиткә дә повестка озак көттермәде...

Ире капкасын шакыгач та хәлне чамалады Нәүбәһәр. Көтмәгән иде ул аны. Инде көтәргә хакым да юк, дип фикерли иде. Сөйгән хатыны – янәшәсендә, баласы – сөйгәне карынында үзенең барлыгын сиздереп ятадыр, дип бер көнләшеп тә куйган иде. Хәер, үзе дә бала бакмаслык хатын түгел иде дә соң, Ходай насыйп итмәгәч, нишләмәк кирәк?

Ә ул килде... Нәүбәһәр аптырап калды: аның бусага төбендә шулкадәр дә үз һәм шулкадәр дә чит ир заты басып тора иде. Алар шактый күзгә-күз карашып, сүзсез тордылар.

– Син мине гафу ит, зинһар, – диде ире.

– Син ялгыштың бугай, Хәмит, – диде хатын.

– Белмим... Сабыемны ятим итәсем килмәде бугай... Шулай да рәнҗемә син миңа... Дөньяныкы дөньялыкта калсын, Нәүбәһәр...

– Бәхилләшергә килгәндәй сөйләшәсең син...

– Шундый төш күрдем бүген... Имеш мине төпсез коега ташладылар... Чыгалмадым бугай мин аннан... Кичер син мине, зинһар... Алай-болай исән-сау кайта калсам, ташламам мин сине, ярдәм итеп яшәрмен...

Бу сөйләшүдән Нәүбәһәр берни дә аңламады. Иренең күз укларына эләккән саен карашлары җәрәхәтләнде. Йөрәге таланды.

Ничек кергән булса, шулай кинәт борылып чыгып та китте Хәмите. Авыл авыл инде ул: сер яшерәм димә. Юлда очраучылар, элекке хатыны янынннан чыгуын күрүчеләр булган имеш... Сорашканнар имеш... Кайсынадыр Хәмит: «Хатынның үгие юк аның, туганкаем», – дип җавап биргән имеш... Боларын ул сугышка чыгып киткәч сөйләделәр.

Нәүбәһәр дә бу хәлләрне үзенчә юрады: димәк, йөрәге суынмаган әле, әле җепләр өзелеп үк бетмәгән...

Ә ире сугышка чыгып киткән көн аннан аерылып кайткандагысыннан да авыррак булды бугай. Нәүбәһәр төне буена бер күз кысмады. Җәйге чилләдә нигәдер бик нык өшеде. Бармак очларын һаман тыны белән җылытты. Тик торганда елап та алды. Тулышып тамган яшь бөртекләрен учлары белән изеп бөтен битенә буяп бетерде. Алар тозлы иде. Артыгын да тозлырак иделәр бугай. Иреннен салкын җилдән ярылган җәрәхәтенә эләгеп шактый озак әчеттереп тордылар. Ник елаганын үзе дә аңламады. Горурлык дигән нәрсә булмаса, янәшәсенә барып, капка төбеннән озатып калыр иде дә сон... Бик тә, бик тә соңгы минутларда күзләренә төбәлеп карыйсы килә иде аның...

Тик ни йөзең белән бармак кирәк? Кеше ни әйтер? Мәхәббәтеңне яклый алмыйча, үз аякларың белән чыгып киткән хатын түгелме соң син? Ул үз-үзенә шундый сорау бирде дә унайсызланып куйды. Һәм кинәт башына бер фикер килде. Торна тавы ягындагы болында бер калкулык бар. Авылдан чыккан зур юлның шуннан үргә менеп киткәне аермачык күренә. Бер җәйдә ире белән печән чапканда игътибар иткән иде ул моңа. Менә хәзер шунда менәсе дә хушлашып каласы...

Иренең шәүләсен ул унлаган ир-ат арасыннан таныды... Беренче карашка алар барысы да шәүләләр кебек кенә күренделәр. Әйтерсең офыкка кеше күләгәләрен тезеп чыкканнар. Һәм җанлы күләгәләр һаман алга табан үрлиләр, шуышалар иде. Озаклап төбәлеп тора торгач, алар барысы да кешеләргә әверелделәр. Берсе, арада бер гөрнадиры, ана шул дәрәҗәдә якын иде ки, Нәүбәһәр аны бөтен барлыгы белән, күзләренә кадәр күрде гүя. Ул һаман артка каерыла, башын югары күтәреп нидер эзли иде... Менә Хәмит аңа табан борылды, менә кул болгады...

Хатынның карашы торган саен үткенләнә барды. Яктырак күргәне саен ныграк дулкынланды. Әйтерсең офыктагы рәшәләр аның күңелендә тибрәлә... һәм алар юлның теге очы белән үзара тоташканнар иде...

Менә Хәмит тагын икәү печән чапкан үргә табан борылып төбәлеп торды. Менә башындагы кәпәченә үрелде. Аны учына кысып, кулын югары ук күтәреп янә болгады...

Ялгыш күрде микән боларны Нәүбәһәр? Юк, юк, һич тә ялгыш түгел. Чын иде һәммәсе дә.

Көтмәгәндә үтә тыгыз, кырач җил исеп куйды. Хатынның яулык почмаклары, күлмәк итәкләре Хәмит басып торган үргә табан тартылып җилфердәде.

– Хуш Хәмит! – дип кычкырды ул үр башыннан. – Хуш газизем минем!

...Нәүбәһәр кинәт айнып китте. Йомычка тутырылган капчыгы өстендә утырып тора икән ул. Осталар да кайтып беткән. Көтү тузаны да басылган. Торналар тавы ягында рәшәләр уйный, биткә җәй эссесе бәрелә иде...

Япа-ялгызы калган икән бит... Дөнья тып-тыныч. Кечкенә тынлык үзенә бертөрле, гаҗәеп сихри. Ул әйләнә-тирәсендә йомарланып яткан сап-сары йомычкаларга төбәлеп елмаеп куйды. Күр, кара халатына да, ап-ак оекбашларына да сарылганнар икән, аларны берәмтекләп йолкып-йолкып читкә ташлады. «Тынычлык ни әйтсәң дә сугыш түгел шул ул,

– дип уйлады. – Жаны барның өмете бар шул, нишләмәк кирәк...» Аннан хәлсез аякларын көчкә кымшатып, йомычка тулы капчыгын мамык түшәк күтәргәндәй җиңел итеп уфалла арбасына куйды, як-яклап кысып бәйләде дә кайтыр юлга кузгалды.

Ашыкмый гына атлады ул. Көтәр кешең булмаганда ни дип ашыгырга инде? Әнә бит мизгел эчендә бөтенесе таралышып та өлгергәннәр, искәрми дә калган... Менә бит ничек яши адәм балалары...

Кинәт нидер югалткан кешедәй, шушы калкулыктан аеруча яхшы күренгән, карашлары белән генә ирен яуга озаткан үргә борылып карады. Анда баеп барган кояшның соңгы моңсу нурлары уйнаклый иде...

## Бәхет ул берәү генә...

Безгә алтын куллы кеше кирәк иде. Тик бу заманда каян табасың ди аны? Кайсы өлкәгә кагылма, һаман белгеч юк диләр. Һөнәр белгәннәре дә бик атлыгып тормый хәзер. Кеше эштән бизгән шул... Ил башына төшкән афәт икән инде бу...

Ә без аны таптык. Бик озак эзләп булса да... Төзелеп яткан биек-биек йортларга кереп йөри торгач, көтмәгәндә очрады ул.

Әлбәттә, гадәттәгечә, башта хезмәтенең әҗере турында килештек. Күп сорамады. Бу хәл безне бераз гаҗәпләндерде дә. Аннан аны кайдан, ничек килеп алуыбыз турында сөйләштек.

Икенче көнне иртән үк без үзе әйткән адрес буенча алтын куллы хатынны алырга киттек. Күккә ашкан торбаларыннан иртә таңда ук төтен бөркеп утырган зур заводлар арасыннан, тар гына тыкрыклардан борыла-борыла шактый озак бардык. Ул яши торган тулай торакның кыршылып беткән соры диварлары тирәсендә чырак-яктылык та күренми, шулай да көзге яңгыр юган тәрәзәләрдә берән-сәрән утлар шәйләнә иде. Без йорт янәшәсенә килеп туктадык. Монда һәммә нәрсәдән искелек исе килә, әллә кайдан борынга сыра ачысы бәрелә, шулай ук сазлык исе аңкый иде. Йортның тирә-юнен кыргыйлашкан куаклар каплап алган. Аларның ярымшәрә ботаклары болан мөгезләредәй тырпаешканнар... Һәм шушы тәртипсезлек аша тоныкына завод гүләве ишетелә...

Куакларның үз ирекләрендә теләсә ничек үсеп ятканлыклары шәһәр өчен бераз сәеррәк тә тоела. Киселмәгән, каралмаган, кайсы баскан, кайсылары бар буйларына җиргә үк сузылган...

Алтын куллы ханым безне көтеп торган икән: шушы куаклар арасыннан елт итеп килеп чыкты ул.

– Ял көннәрен яратмыйм мин. Элек заводта ял көнне дә эшләттеләр. Хәзер эш тә юк. Өйдә дә торасы килми...– диде машинаның арткы салонына кереп утыргач.

– Җылы өйдә дә торасы килми дисез инде, ә?

– Килми шул. Анда уйлар басып үтерә бит... Ә болай чыгып китәсең дә онытыласың...

Мин сәер җөмләләрдән бераз югалыбрак та калдым. Кешеләр төрле, аларның һәммәсенең үзенчә фикер йөртергә хакы бар, дип уйладым.

– Бик тыныч урында икән йортыгыз, – дидем сүз булсын өчен генә башка юнәлешкәрәк борылып. Әлбәттә, бу җөмләне әйтеп, үзем яшәгән шәһәрне бер дә белмәвемне дә сиздереп куйдым кебек... Хатын миңа аптырап карады.

– Анысын без үзебез генә беләбез инде, – диде ул тынгысыз моңсулык аша. – Элек монда уголовниклар тора иде. Хәзер юк инде берсе дә. Үлеп беттеләр. Кайсын чыгарып җибәрделәр... Алар урынына завод кешеләре керә барды...

Ул тыныч кына үзе гомер сөргән йортның тарихын бәян итте. Аның озак еллар шунда яшәп, әлеге тормыш итү халәтенә күнеккәнлеге аермачык күренеп тора иде.

Машина алга җилдерде.

Һич көтмәгәндә безнен юл аша кап-кара шәүлә йөгереп үтте. Кыяфәтенә караганда үзбәкме, таҗикмы — шул яклар кешесенә охшаган иде ул. Ирем ашыгып тормозга басты.

— Таптат син аны! — дип боерулы, җитди тавыш белән әйтеп куймасынмы хатын!

— Аллам сакласын... Ходай андый хәсрәтләр күрсәтмәсен... — дип пышылдадым мин.

— Монда киләләр дә бөтен дөньяга баш булалар. Кеше баласы бер дә кызганыч түгел аларга. Үз кесәләрен кайгырталар...

Мин аның фикерләвендә тагын да ныграк сәерлек сизеп, гаҗәпләнеп калдым. «Кем кайда тели, шунда яши, кайда теләсә — шунда эшли ич инде», дип уйладым.

— Менә минем улым... Ефәк кебек бала бит ул...

«Һәр анага үз баласы ефәктер инде», — дип җавап кайтарды күнелем. Тик бер сүз дә дәшмәдем. Сүзсез генә шактый юл үттек. Чөнки аның улы дөньясына күченеп киткәнлеген тоеп алдым. Уйларыннан бүлдерәсем килмәде. Хатын әле пошынып авыр сулап куя, әле «Бәбекәем минем», дип пышылдый иде. Ул арада килеп тә җиттек.

Безне, елмаешып, бер бакча чәчәкләр каршылады. Аларның һәммәсе җаныма якын. Мин аларның барысын да яратам. Җай буена төпләрен йомшартып, сулар сибеп, калерләп үстердем дә, хәзер чарасыздан аптырап торам...

Менә тагын котып җилләре исеп китте...

Кызганмыйлар чәчкәләрне көзләр...

Хатын да минем гөлләргә сокланды. Сальвияләр, петуния, дәлияләр, кашкарыйлар, хризантемаларның чәчкәләре эреләнеп, яфраклары җетеләнеп киткән иде... Җаннарына көз суыгы кереп тулган саен, алар эрерәк булып чәчәк аталар шул...

— Гөлләрегез ничек матур! — диде хатын, эчкә үтешли. Ул гөлләрнең күзләренә төбәлеп карады.— Туган ягымның кырларын, болын-басуларын искә төшерделәр. Күкчәчәкләрне ярата идем мин үзем... Хәзер белмим дә... Күптән басу чәчкәләрен күргән юк.

Ул ишектән килеп керүгә безнең бакча өенең таш диварларын кат-кат сыйпаштырып карап чыкты:

— Ташын тигез салганнар. Алтын куллы кешеләр эшләгән моны...

— Һәр эштә кирәк шул ул алтын куллы кешеләр, — дидем мин.

— Аларга да кадер бетте. Өмет тә калмады инде... Аның йөзендә борчылу, чарасызлык очкыннары чагылып китте.

— Алай димәгез, сез кешеләргә гел кирәк бит...

— Кемгә кирәк? — дип гаҗәпләнеп сорады ул. — Эшләре беткәнче. Хәер, рәхмәт инде. Чакырмасалар, өйдә уйлар басып үтерер иде әле...

Хатын тиз генә киемнәрен алыштырып алды.

— И бәбкәем минем, — диде ул эш коралларын барлаганда.

Шулай әрнү аша инрәп куйган мәлләрендә аның күзләре эчкә батып киткәндәй тоела. Тавышы җанны куырып ала. Баласына булган мәхәббәтен һәм ниндидер әрнүләрен җинеп, монда килергә җөрьәт итүенә ышанып булмый башлый.

— Улым алтынчы сыйныфка кадәр гел бишкә укыды. — диде хатын, ирем кертеп биргән измәне болгата-болгата.— Акыллы бала ул. Укытучылары мактап кына торды. Башы эшли диләр иде...

— Исәндер бит улыгыз? — дип сорадым мин. Хатын соравымны ишетергә теләмәде кебек.

— Хараплар иттеләр алма кебек баламны...

Анын ачы яшьләрдән кысылып беткән күзләре таш диварларга ачу түгеп карады.

— Мин үз баламның яхшы икәнлеген беләм, шуңа бу дөньяда беркемгә дә ышанмыйм, — диде. Ул үз-үзе белән сөйләшкәндәй тоела, әйтерсең, гомеренең һәр минутын хәсрәте белән яшәп ята иде...

Мин һаман анын янына керә-чыга йөреп торам. Әле плитә өстендә гөбер-гөбер кайнап, итле шулпа исе таратып утырган кәстрүл тирәсендә кайнашам; әле бәрәңге, әле суган-кишер арчып салам. Әле бакчадагы чәчәкләр янына юл алам.

Һава торышы шактый салкын торса да, кырау төшкәне юк. Чәчкәләрдә әле шатлык бар! Яшәү шатлыгы! Димәк, Ходай биргән көннәрнең кадерен белеп, Кояшка карап елмаерга мөмкин... моны гөлләр сизенәләр. Шуңа биеккәрәк үрмәлиләр. Һаман чәчәк аталар... Алар да кешеләр кебек һич яшәп туя алмыйлар икән...

Вакыт-вакыт котып җилләре исеп китә...

Кызганмыйлар чәчкәләрне көзләр...

Инде ашка токмач саласы гына калды. Мин тагын өйгә юнәлдем.

Алтын куллы ханым диварның икенчесенә күчкән. Ул измә тигезләгечләрен әле унга, әле сулга йөртә, әле әйләнә хасил итеп ышкый-ышкый тигезли. Үзе әйтерсең миңа сөйләми дә...

— Әйтте югыйсә, әнием куып җибәр, зинһар, берсе дә минем дустым түгел бит аларның, — диде. Ничек ишек төбеңнән кеше куасың ди, җә?..

— Яшьләр яшьләр янына чыга инде, улым. Синең янга килгәннәр бит алар, — диде әтисе.

— Кемнәр иде соң ул яшьләр? — дип кызыксындым мин.

— Кем белсен аларны, — диде хатын. — Тәрәзә төбенә машиналарын туктаталар да дөмбер-дөмбер музыка акырталар. Машиналары да, өебез дә селкенеп тора, билләһи менә... Без аларны кайлардан белик соң, улкаем?! Балам минем...

Хатын шулай әле минем белән, әле улы белән сөйләште:

— Авыру ул җитмәсә... Армиягә дә алмадылар... Бер тамчы сәламәтлеге юк бит сабыемның...

Анын «Улым минем!» дип инрәгәне саен йончыган йөзе тартышып куя, кулларының хәле китә һәм ул ачык тәрәзә аша күренгән соры күкләргә төбәлеп тора.

— Эшемне яраттым мин. Зарланмыйм. Яраткан эштән зарланмыйлар. Элек заводлар ел әйләнәсе берөзлексез эшли иде бит. Өйдә булырга туры килмәде. Берәр заман күрерләр, хезмәтемне бәяләрләр, дип яшәдем. Фатир да бирерләр дип уйладым. Белмим, нигә шулай уйладым икән мин?

Ул диварларны яратып-сөеп янә сыйпап алды һәм тагын гүя үз-үзе белән сөйләшүгә күчте.

— Җүләр булганга! Тагын ник инде? Бәяләделәр тәпәч... Кешедә кеше кайгысы калдымы?.. Балаларны карыйсы булган югыйсә...

Сабыемның: «Әни кирәк!» дип елый-елый йокыга киткәннәрен күрше хатыны сөйли иде... Мин һаман эштә булдым... Бакчага йөргән чорларында утренникларына бара алмадым, укырга кергәч җыелышларга азактан, тәмамланыр алдыннан гына килеп өлгерә идем... Укытучы һаман тирги: «Елына бер көндәлеген ачып карап, кул куеп җибәрмисез шунда»ди. Укытучы укытучы инде. Акыллы әйткән бит...

Хатын тынып калды, ераккарак китеп стеналарга текәлеп торды. Тип-

тигез иде алар... Соры, салкын измә аша өйгә алтын куллы кешенең хезмәткә мәхәббәте тарала иде. Ике ягы гына эшләнеп бетсә дә өй жылынып китте. Менә ничек була икән ул чын оста! Кулы тиюгә гөлләр түгелә дә төшә икән!

Мин тынлыкны аралап суган, петрушка кебек яшел тәмләткечләр алырга янә бакчага юнәлдем.

Урамда тагын да суыткан иде. Быел көз салкын килде шул. Тик теләсә нинди салкынга чыдам бу көзге чәчәкләр! Кырау гына төшмәсен! Ә кырауга каршы торалмыйлар алар, өсләреннән янгын тәгәрәп үткәндәй, кап-кара булып көеп китәләр. Яфраклары да, чәчкәләре дә, һәммәсе бер төскә керә.

Минем күңелем аларның төс югалтуларын да, үз-үзләрен югалтуларын да теләми. Чөнки алар кара көзгәчә чәчәк атып утырсыннар өчен мин күпме көчемне, күз нурларымны түктем...

Кыш ахырларында әле тышта буран уйный торган була. Вак-вак кар бөртекләре очкан көннәрдә мин нәни генә орлыкларны тәрәзә төбемдәге савытка — жир куенына салам. Алар көннәрдән бер көнне Кояшны күреп алалар... һәм зәгыйфь нәзек тәпиле, нәни генә үсентеләр калкып чыгалар да әкрен генә башларын күтәрәләр. Алар һаман Кояш эзлиләр, көн дә Кояш көтәләр... Еш кына тәрәзә артында күбәләкләр булып карлар уйный. Тәмам очып арыгач, эрергә дип алар да жиргә төшеп яталар. Гөлләрем моны күреп тора. Һаман ныгыйлар. Кояш нурларына ябышып һаман биеккәрәк үрлиләр. Мин иркәли-иркәли сулар сибәм, төпләрен йомшартам. Хәтта тәрәзә төбемдә чакта, аларга кешеләрнең, һай матурлар, дип карамауларын телим. Бакчага күчкәч сокланырлар әнә! Күз тигезәсем килми шул минем аларга...

Уйларымны бүлеп котып жилләре исеп куйды...

Кызганмыйлар чәчкәләрне көзләр...

Гөлләр генә түгел, суган кыяклары да, петрушкалар да яшәреп, ныгып киткәннәр икән. Мин кирәгенчә өзеп-өзеп алдым да янә өйгә кердем.

Хатын борылып та карамады. Аяк тавышымнан ук танып булса кирәк, сүзен дәвам итте:

— Бер тапкыр шулай Май бәйрәмендә безгә дә ял бирделәр... Балаларны сөендерим дип, күп итеп кабартмалар, пәрәмәчләр пешердем. Улым сәпитен алып урамга чыгып китте. Урамда булса да мин аны күзәтеп торам. Тәрәзәдән күземне дә алмыйм. Ничек рәхәт икән баланның бер гамьсез рәхәтләнеп уйнап йөрүен күзәтү, дип уйлыйм. Кайларда, нишләп йөрдем соң мин элек? Баемадык ласа! Ачка да үлмәс идек бәлки... Хәер, анысын кем белә?.. Әтиләре эчте шул... Шуның аркасында гаиләдә тынычлык югалды... Арбаны тартмый да, этми дә бит ул ирләр... Берүзең теләсәң нишлә...

Хәзер әйтәм, син карамадың баланы, дим... Тик хәзер әйтүдән ни файда инде... Хәер, әтисе дә гаепле түгелдер бәлки. Эчсә дә эштән калганы булмады. Беренче сыйныфта укыган чагы булдымы икән соң, улым әтисенә шалтырата икән.

— Әти, син автобустамы? — ди икән.

— Юк, мин эштә.

— Әтием, син беренче кайтасыңмы?

— Юк, әниең...

Мин йөгерәм генә инде... Тик соң кайтыла иде шул.

Хатын тынып, уйланып торды. Янә озын такта тигезләгечен куя-куя дивар тигезлеген тикшерде. Аннары тагын таздагы измәне шпателе белән стенага тиз-тиз атып алды. Измә коймак-коймак булып диварга ябышып калды. Шуны ул ялт-йолт сөртеп чыкты, аннан тигезләргә керешге.

— Берзаман карыйм: улым да, сәпите дә күренми. Нишләп күренми икән дим. Йөгерә-йөгерә ишегалдына чыксам — улым подъезд төбендә, жирдә ята.

Суламый да. «Улым! Үлмә, улым!»дип кычкырып җибәргәнмен. Улым күзен ачты. Аны күтәреп өйгә алып кердек. Подъездагы бала-чага күргән: бер егет килде дә башта аның велосипедын сорады. Илсур бирмәде. Аннан ул аңа шуның өчен булсын дип, конфет тоттырып китте, диләр... Кап-кара чәчле иде. Йөзе дә кара... Безнең як кешесенә охшамаган иде, диләр... Ә улым берни дә хәтерләми. Кемнеңдер сәпит сораганын да исенә төшерә алмады...

И бәбекәем минем... Мин үз улымның җүнле бала икәнен беләм... Өйдән чыкмый үскән бала иде ул. Читтә йөрергә бер дә яратмады... Йомшак холыклы, сүз тыңлаучан булды.

Хатынның күз нурлары түгелеп-түгелеп китә. Тавышы сабый сөйгәндәй йомшак кына ишетелә иде.

— Улым минем! — дип кабатлады ул.

Мин аны ашка чакырдым.

— Башта кулларны юып керик инде, — диде, бите буйлап елгадай аккан тирен костюм җиңе белән генә сөртеп алып. Яулыгының бер ягыннан чыгып торган чәчләре дә юеш тирдән укмашып чигәсенә ябышкан иде. Мин алтын куллы кеше алдында туңып, бөрешеп йөрүем өчен оялып та куйдым.

Икәүләп, бакчага, юынгыч янына чыктык. Юынгыч тирәсендәге пәйгамбәр тырнагы гөлләре кызгылт-сары ялкын булып яналар. Кичкә кадәрле дә кибеп җитә алмаган салкын чыктан көрән күзләре елтырый иде.

— Күр боларны, бер дә салкын дип тормыйлар. Беркемнең дә үләсе килми, ә? — диде алтын куллы хатын.

— Һәркемнең яшисе килә, — дип җавапладым мин.

Юк, мин аларның бер дә үлүләрен теләмәс идем... Шуның өчен утырттыммыни инде? Кыраулар үткәч кенә бакчага күчердем. Бу дөньяның чиксез иркен һәм чиксез якты икәнен алар тамырлары җиргә тигәч кенә тойдылар. Шул шатлыктан бер атна эчендә һәммәсе чәчәккә бөреләнде.

— Һәркемнең яшисе килә, — дип пышылдады хатын. — Тик безнең теләктән генә тормый икән шул...

Ул тагын авыр сулап куйды.

И гөлкәйләрем минем! Бу җәйдә сезне күрер өчен яныгызга кереп, сокланудан тел шартлатучылар аз булмады. «Искиткеч! Гаҗәеп! Матурлар!» диделәр кешеләр.

Чәчәкләрем аларның күзләрен иркәләделәр, тирә-якка хуш ис тараттылар. Ефәк канатларын җилпи-җилпи умарта кортлары очып килде. Алар да сокландылар. «Без-з! Без-з!» — дия-дия һәммәсенә кунып чыктылар, татлы гүзәллекне бал итеп җыеп алдылар...

Гөлкәйләрем! Сез булмасагыз мин дә бәлки җәһәннәм кырындагы бу бакчага болай ук атлыгып тормас идем әле. Бәлки алтын куллы кешене дә эзләп йөрмәс идек без...

Җәйнең чилләләрендә гөлләремә су сибә-сибә тамагым кибә, хәтта кичләрен дә бөркүдән башлар әйләнә, сулыш кыса иде. Тик су кызганмадым мин алардан. Бер тапкыр булды... ничектер вакытында килә алмадым шул. Башка кабатланмады мондый хәл... Шул арада башларын җиргә куеп яткан иде инде күбесе. Гел күз-колак булу кирәк боларга да, дип уйладым. Бөтенләй үлеп кипкәнче килеп житүебезгә сөендем. Менә ничек һаман чәчәк аталар әле алар! Тере җан бер тернәкләнә икән шул...

— Миңа да бу чәчкәләрнең орлыкларын бирерсез әле, әбием өстенә утыртырмын. Кара көзгәчә торалар икән бит елмаешып, — диде алтын куллы хатын. Мин гөл орлыкларын җыеп, аның кесәсенә салдым.

Без өйгә кереп табын янына утырдык.

— Кара икмәк кисеп җибәрикче, кара эш кешесе кара иписез туймый, — диде ул ярым шаяртып.

— Әлбәттә... Агы да бар, карасы да...

Хатын сабырлык белән генә кашыгын тәлинкәсенә сузды. Өрә-өрә кабып карады. Йөзенә ихлас елмаю җәелде.

— Һай тәмле булган ашыгыз!

— Шулкадәр эшләгәч, ничек тәмле булмасын инде ул! Эшләп ашаганда гына аш тәмле, диләр бит...

— Акчасы да шулай. Бәрәкәтле була, — дип өстәде хатын.

Икебез дә көлешеп алдык. Күңелле булып китте. Тик мизгел эчендә тагын үз эзенә кайтып төште. Ашаганда да яныннан җибәрми иде ул улын.

— Шуннан аның янына теге кара йөзле кешеләр килеп йөри башлаган. Мин эштә инде. Әтисе дә эштә. Берзаман өйгә кайтып керсәк, бала коса да коса. Нидер ашап агуланган инде, дибез. Ашыгыч ярдәм машинасы чакырттык. Бер дә агуланганга охшамаган, диләр. Куркынычрак, диләр...

Минем бит ишеткәнем дә юк андый нәрсәләр турында, котым очты. Ышанмадым. Каян белим мин әфьюннең нәрсә икәнен?.. Наркотик имеш...

Беркөнне баскычлардан төшкәндә карасам, бөтен подъездны «Илсур! Син безгә йөз мең тиеш!» дип язып тутырганнар. Имәнеп киттем. Шунда гына башыма барып җитте. Анда инде милиция кызыксына башлаган булган.

Бөтен тулай торак малайларын алып киттеләр. Бөтенесе, Илсур бирде, дигәннәр.

— Хәзер кайда соң улыгыз? — дип сорыйм мин. Ана теләмичә генә җавап бирә:

— Лагерьда... Кайда булсын инде... Үзе дә аптырап калды бала... Чарасыздан бәргәләнде... йөрәге әрнеде... Уеннан уймак чыга шул, улым минем... Үзебез дә нәкъ аның кебек үк телсез-һушсыз калдык. Авыр хәлгә юлыкканда ни уйларга, нишләргә белмисең икән ул... Һаман тынычлана алмый әле бала... Лагерьда да...

Без үскән чорда лагерь бер генә төрле була, анда пионерлар ял итә иде. Уйнаталар, ашаталар. Урман һавасы сулап, ныгып кайтасың шуннан. Авыл баласына ул әле эләкми дә. Уку алдынгылары гына баралар иде. Аңлашыла, бу пионер лагере түгел инде әлбәттә. Ананың аны башка исем белән атыйсы килми иде.

— Димәк, исән! — дидем мин. Күптәннән шушы сүзне көткән идем. — Исән кеше бер кайта бит инде... Аллаһтан сабырлык сорагыз.

— Аллаһтан, — дип пошынып әйтеп куйды хатын.

Аннан дәвам итте:

— Аллаһка ышанмыйм, ди идем әбиемә. Аның шашкан кешеләргә охшаш кыяфәте әле һаман күз алдымда тора. «Исәр! Син аны кеше янында кычкырып әйтмә. Никадәрле гөнаһка батканыңны беләсеңме? Ә гөнаһ өчен бу җир йөзендә түләү тиешле, ди иде. «Күпме инде ул гөнаһ хакы?» — дип сорыйм. «Бик кыйбат», — ди әби.

Безне Аллаһ ул Ленин бабай дип өйрәттеләр бит, ышандык укытучылар әйткәч. Яшь иделәр алар. Чибәр иделәр. Тешсез әбием алар янында кем инде, җә?.. Бер тапкыр кайттым да: «Әби, Аллаһ юк бит ул!» — дидем. «Кем әйтә аны? — ди. «Укытучылар», дим. «Аларга шулай әйтергә өстән кушалар, кызым, — ди. — Замана шулай үз законнарын үзе өйрәтә инде кешеләргә. Ә иман өйдә генә була, аны югалтырга ярамый», — ди. Мин ул чакта әбинең сүзләрен яхшылап аңламадым да...

Һаман өстән кушканча гына яшәсәң, менә нинди хәлләргә каласың икән ул... Ут төртеп суга йөгергән мин буламмы инде хәзер?..

Хатын тынып калды. Минем әллә кайчан, исән булса, бер кайтыр улыгыз, дип әйткән юату сүзләремә ялгап җибәреп:

— Кайтыр да бәлки...— диде. — Авыру бала бит ул... Авыру булып туарга

да тиеш түгел иде. Туганда җәрәхәт алган диделәр. Врачлар карамаган... Һаман башы әйләнде мескенкәемнең. Кан басымы да борчып тора. Янына бардык күптән түгел генә. Тагын да ябыгып, тартылып киткән. Коры сөяккә калган. Бер тамчы ите юк тәнендә. Мин гаепле түгел, әнием, ди. Ышан син миңа ди. Алдалый белми бит ул минем балам. Бала гына иде бит әле... Мәктәпне тәмамлаган гына көннәре...

Хатын авыр сулады. Бераз тын гына уйланып торды да янә дәвам итте:

— Ярый әле өч ай саен кучтәнәчләр, посылка җибәрергә рөхсәт итәләр. Иптәш малайлары исеменә дә җибәрештерәбез, вакытны сузып җиткерә алмаганда. Анда кучтәнәч көтәр кешеләре булмаганнар да бик күп, ди. Менә әле генә әллә ничәне ап-ак җәймәләр салдым. Үзе йоклап үскән иде шуларда. Матур балачагының хуш исен тойсын дидем, элеккечә крахмаллап та куйдым. Өйне хәтеренә төшереп торсыннар. Иптәшләренә дә бир, дидем. Хәзер андый ап-акларны җәймибез бит инде. Тик яталар ату...

«Ана өчен бала беркайчан да үсми, гомере буена бала булып кала шул», дип уйладым мин эчтән генә, ләкин уемны кычкырып әйтмәдем, йә гаепләгән кебек кабул итәр. Мин бу катлаулы дөньяда, кешеләр акча өчен бер-берсенең җанын кыйган заманда, имансызлар хәрәм ашау казаны янында кайнашканда ничек итеп, кемне гаепли алам соң? Беркемне дә рәнжеттермәс идем көчемнән килсә...

Хатын нидер көтеп күзләремә карады:

— Менә әйтегез әле, мин улым өчен оялырга тиешме хәзер? Үз-үземнәнме? Өметем сынды бит минем, канатларым киселде...

Нигәдер «өзелде»димәде, өметләр сыну куркынычрактыр шул...

Ул соравына миннән җавап таләп итми иде ахрысы, сүзләрен йөрәгеннән кысып чыгарды гүя:

— Минем бәхетем икәү иде. Беренчесе — Ана булу бәхете. Икенчесе — яраткан эшем. Тик ике бәхет бер куышка сыешып яши алмый икән бит. Бәхет берәү генә була икән ул... Менә ничек алдандым мин... Икедән берәү дә калмады... Балам киткән юлдан миңа хәсрәт, сагыш кына килеп тора хәзер...

Бер сүз дәшә алмадым. Сәбәп табып бакчага чыгып киттем. Кемнең кемнән оялырга тиешлеген һич тә уйлыйсым килми иде. Мин алтын куллы шушы кешенең үз баласының язмышын мондый яман хәлләргә бәйләп бәян итүен дә тынламас идем. Аллам сакласын! Бәла аяк астында йөри диләр... Хактыр... Хактыр...

Сүзсез генә гөлләремне сыйпаштырдым.

Кинәт котып җилләре исеп куйды.

Кызганмыйлар чәчәкләрне көзләр...

Караңгы чырайлы көзләр бик тиздән бакчамның да бар ямен алып китәр...

Гөлкәйләрем! Оеп кына кар яуганны тәрәзә аша елмая-елмая күзәткән көннәрегезне хәтерлисезме сез? Кар астыннан эт тизәкләре чыкканын, челтәрләнеп бозларның югары баруын жылыдан карап утыруыгызны искә аласызмы? Табигатькә ачу сакламыйсызмы сез? Әллә матур яшәп матур китү бәхет ул дисезме?

Гөлкәйләрем минем! Ник дәшмисез! Әллә көзләр дә төрлечә килә дисезме? Сабыр булырга кирәк дисезме? Җавап бирегез әле сез миңа... Алтын куллы хатынга, ул үстергән анага сезнең сүзләрегезне кереп әйтермен...



Флера
Гыйззәтуллина

# ЯНУ ДӘВЕРЛӘРЕНДӘ

РОМАН-ПОЭМАДАН ӨЗЕКЛӘР

## Агыйделдә — ак йола

*Өммәтнең аклык йоласын*
*Кай тарафларга уясы?*
*Актаныш — таңнар оясы,*
*Азнакай — Кояш кыясы...*

**Агыйделдә — ак пароход күрдисәм:**
**«Актаныштан киләдер» — дип, укталам.**
**Илбашчымы, тарихчымы, шагыйрьме, —**
**Бу төбәктән кемнәр генә чыкмаган!**
**Агыйделгә баш имәгән кем генә —**
**Урап кайтып Иртешләрдән, Томнардан[1]**
**Татар халкы кайда гомер сөрсә дә —**
**Ак күңелем — Агыйдел... — дип моңланган.**
**Михнәт төяп карурманнар кичсә дә:**
**«Таянычым — сандугачлы тал...» — дигән... —**
**Туган Илдә рухи хөрлек тоймасаң,**
**Чит Илләргә чыгып гыйбрәт ал... — дигән.**
**Уты, суы һәм дә агы-карасы**
**Бер колачка сыйган дөнья куганда.**
**Татар кара урман көен җырласа,**
**Кабыгын сала икән кара елан да!**
**Давыл куба икән — элсәң читәнгә —**
**Җебек ирнең җил талаган җиләнен...**

[1] Иртеш, Том — елга исемнәре

Флера ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА — *шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. «Йөрәгемдә шаулый карурман», «Күз нурларым», «Башкаемда дөнья исәпләре» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

**Ил өстенә тизрәк кояш чыксын дип,**
**Иртә таңнан халык бәхет отсын дип**
**Йөрәгемдә иңри Тәкъдир Имәнем.**
**Имани гамь юллап кара затларга**
**Моң сираты кичә Арча, Актаныш!..**
**Искә төшә «Әллүки»е Тукайның**
**Моң кылына чорналганда ак сагыш.**
**Меңъеллыклар көен көйләп сыкрана**
**Тукай бәгыренә сагыш сапкан моң.**
**Җиһан тавышы белән гимн җырлый таң,**
**Ә мин күз яшьләрен сөртәм ак таңның:**
**— Без бит, димен, тулган айлы, Тукайлы! —**
**Сер бирмәек көзге ачы җилләргә...**
**Иман аең җилдә җиләрелмәсә,**
**Башлар әрәм булмый туган Илләрдә.**
**Кылдан нечкә милли сиратларыңны**
**Кылыч орышына Тәкъдир салганда,**
**Сафлыгыңа синең, инсафлыгыңа**
**Җиһан тиклем Җиһан таңга калганда,**
**Чын Җиһангир җилән белән җил кумый,**
**Кыйбла уймый җил талаган җиләнгә...**
**Мәңге сүнмәс моңнар төшә башыма,**
**Рәхмәт әйтеп Иделгә баш игәндә.**
**Утын−суын йөрәк аша уздырып,**
**Сугыш аһы сөйри моңны тирәнгә.**
**— Әнкәй!!! — диеп, басып яшел чирәмгә —**
**Мин: «Әткәй!!!» — дип, сарылганда имәнгә —**
**Яшел чирәм,**
**яшел имән,**
**яшел ут —**
**Туып−үскән Авылымның яшь өне!!!**
**Балачагым чирәмлеген җир упты,**
**Имәннәрне сукты сугыш яшене.**
**Сугыш беткән көнне миңа хат килде**
**Көнчыгышта хезмәт иткән солдаттан.**
**Ал Кояшлы фотосыннан елмаеп,**
**Солдат миңа ярату́ын аңлаткан:**
**«Антлы серем», — дигән, — Япон сугышы... —**
**Сер сандыгым — сары диңгез, сабыр ай!!! —**
**Киерелеп басып Хинган[2] сыртына,**
**Таң Кояшын талкый сары самурай...**
**Кара таңнан хәбәр сала Каф җиле[3]:**
**— Көнчыгышы — Япун, Кытай тотыгы!!!−**
**Бүген таңда «Су анасы»н Тукайның**
**Кара карчыгалар тотып чукыды.**
**Кубарылып бакый утлык чорыннан,**
**Ут яңгыры койды Җиргә ал болыт...**
**Яу кырында янды татар моңсары,**
**Мәшһүр «Шүрәле»не ятим калдырып.**

[2] Хинган — тау исеме.
[3] Каф җиле — Кавказ җиле

***

...Сорау белән кумә ятим ятимне:
— Яшәп калу өчен каян көч алдың?...
Җил каршында калмас өчен җавапсыз,
Капшап карыйм боздай салкын
мич алдын.
Таң атуга тыңлап үги әмерен,
Түр басуга китәм башак җыярга.
Кар астыннан казып алсам бер башак,
Сөенечем белмим кая куярга.
...Башак эчендәге бодай бөртеге —
Безнең өчен булды энҗе-зөбәрҗәт!..
Чиләкләрне башак белән тутырдык,
Зөбәрҗәттәй өметләрне җегәрләп.
Ятимнәрен ачлык белән чарлаган
Хатирәләр изә җанны һаман да!
Каф тауларын тетрәндерер әрнеш бар
Кылыч-камыл яралаган табанда!

***

Минем үксез бала чагым шикелле
«Шүрәле»нең табаннары яралы.
Хакыйкатьне күзгә туры каратып,
Яраларны яматасы бар әле.
Агыйделдә йөзгән ак пароходның
Уртак хасияте бар изге Җир-суда.
...Хинган тауларына таба юл тотып,
Безнең яшьлек палубада җыр суза.
Сугыш нәфрәтләре безнең йөрәктә
Кайгы ургыллары булып ярала.
Аклык йоласына Ургыл сапканда,
Ак таплар да төшеп кала карага —
Кайчакларда туган-үскән ягың да
Йөкли алмый синең талант-көчеңне...
«Шүрәледәй кара йөзле»... булуым
Тәкъдир минем искә бик еш төшерде.
Унбиш яшьтән сөрген белән янады
Миңа мәрхәмәтсез Сәвит түрәсе!.
Җиңү көнне әйтте үгием: «Үлгәнче,
Ничек кенә мунча ягып керәсе?!. —
Сине дә бит иртә-таңнан юл көтә,
Ерак юлга чистарынып чыгарсың...
Ак юлыңны бәхеткә дип, юрарсың,
Йомгак итеп хәтереңә урарсың...»

## Каргыш

...Үзенә — үлемнәр, ә миңа
Үгием ак юллар юрады.
Әбкәмнән калган сүс талкысын
Яргалап чырага турады.
Соңгы кат коедан су ташып
Мунчаның кисмәген тутырды.

Кутырлы кулларын угалап,
Баскычта уйланып утырды:
«Көннең дә, төннең дә соңгысы!.. —
Көнеңне уздырма зарарга!?? —
Ташылган суы бар...
ягарга
Утынын кайлардан табарга?...»

***

Мин шулчак «ым» кактым коега:
— Бурасы эчерек, алама... —
Синнән дә, миннән дә калачак
Муртаеп авачак багана....
...Хәлнең дә соңгысын җыйнап, без
Чытырдап тотындык пычкыга.
— Карр!!! Ка–аррр!!! — дип, багана башында
Козгынмы, каргамы кычкыра.
Каргышымы ата–бабаның
Канатлы кош булып каңгыра?..
Үгием: «дошман!..»— ди, — карганы —
Шул минем җаныма кан ора...–
Шул мәлгунъ китерде узган ел
Атаңның да кара хәбәрен.
Табылыр идеме уртак зар,
Шул карга булмаса әгәрен?

***

Багана гөрселдәп ауганга,
Җирнеңме күчәре ычкынды?.. —
Анасымы әллә Җир–суның —
Каерып сындырды пычкыны.
Колгасыз, сиртмәсез коеның
Капкачы бар, ярый, ябарга.
«Барлык»ның шунсына куанып,
Тотындым мин мунча ягарга.
Мич эчен ут–ялкын ялмагач,
Йөрәккә үрләде ут теле:
— Кит, айдә!.. —
Никләргә киттем!? — дип
Гомерең үкенеп үткере!!!
Җирсегән, сусаган чагыңда
Син ошбу хатаңны онытма:
Куәтләп үгилек коткысын,
Җаныңны яктың син бу утка
Һәм менә яшь кенә көеңә
Каргалдың канатлы корыктан.
Кем инде: «Читләргә китәм — дип, —
Йортыңның коесын корыткан!?»

***

Яна мич... Ут яна, су яна,
Хәтердә миф чоры уяна.
Мифларның кануны: «Ут биреп
Кешене гөнаһка буяма!!! —

Ут бит ул аямый каптымы,–
Очыртып тәмугка төшерә...»
Кануннар — киртәме, сөюдән,
Көюдән сусаган кешегә?
...Күрәсең кануннар йомшара,
Мәңгелек ут җанны биләсә!..
Сөю дә,
чәчәк тә,
атом да
Шушы ут телендә сөйләшә.
Һәм шушы ут аша Тукайга
Тоташа багана тумәре».

Ирекле тел даулап юллыкка
Сикерә меңләгән «шүрәле».
Ихтимал, Яруллин җаныдыр.
Елый мич эчендә үкереп?
...Килде яз — наз көткән сәнгатен
Карында чагындук үтереп.
Кояшка каныккан кыргыйлык
Тукайны да читләтеп узмады.
Азат җыр дәгъвалап «шүрәле»
Буыннарда безнең сызлады.
Сугыштан безгә ни калды соң
Хисләнеп, сагынып сөйләргә?
Биештек без салкын өйләрдә —
Язылып бетмәгән көйләргә.

***

Бүгенге сай аңлы бай өчен
Һәр моңсар — карурман сарыгы! —
Бармагың тык кына... — шапылдап
Ябыла бүрәнә ярыгы...
Күпләрне акылдан шаштыра
Кандагы азатлык хәстәре.
...Утка күз салуга, тарихтан
Калыга Чыңгызхан гаскәре.
Чыңгызда — куе каш, очлы күз!
Даладай иркен, киң адымы...
Кан коеп аласы үчендә —
Борынгы бабамнар чалымы...
Яраткан чәчәге, мөгаен,
Хуш-исле тәкәббер Нарциссстыр...
...Мич алды — идәндә!..
Тирәндә
Шашынып уйный тынлы оркестр.
Нарцисслар тибрәлгән аланда
Ак тирмә кора яшь Тимучин...
Аклыкка хасланган Җиһангир
Җиһанны кыерлый ни өчен?
Ни өчен киң дала баласы
Сыялмый бу якты дөньяга?... —
Җавап юк! — Нарцисслар күзеннән
Бары тик битараф моң бага.

***

**Кешенең чәчәктәй гомерен**
**Яшь патша бернигә санамый.**
**Үз–үзен яратып масайган**
**Нарциссны да үлем сагалый.**
**Ут күрсәм, гомерлек үкенеч**
**Үкерә минем дә эчемдә.**
**..Каргалган көннәрем исемдә:**
**Язмышым шүрәле төсендә!**
**Иҗади ирегем, өметем**
**Кырыкка ярылган кыл сыман...**
**Кыл–күпер өзелми чыдар, дип**
**Кирәге чыгар, дип ымсынам.**

## Ут китабы

*Безнең буын — ятим буын —*
*Читкә китеп таралася.*
*Буыннарга әрнеш салып,*
*Яна кое баганасы.*

**...Ут китабы охшаш тарих китабына:**
**Белем эстәп мич актарам, ут актарам.**
**Мангул яуларына илтеп куша мине**
**Ватан сугышлары белән уртак ярам.**
**Хакыйкатьнең чыгышын да, баешын да**
**Сугыш–орыш илтеп ялгый кыл очына —**
**Сөрлегә ут, сөрлегә Җир, Чыңгызханның**
**Кояш кашлы, елан башлы кылычына.**
**Җибәрде соң бөек Чыңгыз нинди хата:**
**Данда йөзгән Кояш кинәт канга бата.**
**Мичтә өткән, сөрем төсле кара елан:**
**«Моңа татар гаепле!!!» — дип гайбәт сата.**
**Сугышта да, тыныч, имин тормышта да**
**Уктай очып алдан килә татар–бөркет! —**
**Һәр иртәдә зекер әйтеп шөкер кыла,**
**Киләчәкне Иман шарты аша йөртеп.**
**Яңа көнне хәерлегә, уңга юрап,**
**Кояшка ул сәлам бирә иң элгәре...**
**Шуңа күрә сөйрәлүче кардәшләрнең**
**Беркайчан да яктырылмый күңелләре...»**

***

**...Сөйрәлчекләр исәбендә йөри икән**
**Кяферләрнең ташлап качкан иманнары! —**
**Гасырларны–гасырларга ялгый–ялгый,**
**Актарыла мичтә гайбәт еланнары.**
**Миндә дә бит ага чиста татар каны... —**
**Канатланып оча алмыйм мин ни өчен?!**
**Иман тугрылыгын аяп көрәшкәндә,**
**Аз күргәнме әллә татар елан көчен?!.**
**Әллә биргән корбаннарын оныткан мы,**
**Көн күргәндә коллык хисен ертып–кисеп?!.**

**...Мин кичергән ятимлекне хәтерләтә**
**Кара елан күзендәге канлы кысык.**
**Канлы кысык кысып тота шигъриятем**
**Җаным утка ягу өчен күреп хәстәр.**
**Хакыйкатьнең дастанланган ядкаре ул:**
**Ут өстенә үрә баскан атлы гаскәр!!!**
**Шигъриятле, моңлы татар баласына**
**Куркып-өркеп арттан йөрү ярамаган.**
**Татарны тик...Кара гайбәт яласыннан**
**Ярамаулы яралары аралаган.**
**...Мин дә менә — ярамаулы яра колы! —**
**Коебызның баганасын кисеп яктым.**
**Мичтә янган шул утлардан гыйбрәт алып,**
**Тәкъдиремнең янар күрәчәген бактым.**

## Китү моңы

*Без китәбез... көтә алда -*
*Юл газабы — гүр газабы...*
*Без көтәсе заманалар –*
*Бимазалы, җеназалы...*

**...Киткән көнне кабат-кабат урадым**
**Газиз әнкәм яткан Әсәй зиратын.**
**Авызы-борыны җимерек сугыш хатасы**
**Йорт буенча йөртә сөрген чиратын.**
**Каргыш, рәнҗеш томаннары таралмый,**
**Туган якның таңы сызылып аткач та...**
**Китү моңы җырлата да җылата:**
**Китәбезме әллә мәңге кайтмаска?**
**Ирексездән Илдән сөрелгәннәргә**
**Ник шул кадәр битараф соң ак тараф?**
**Чыгыш белән баеш араларына**
**Гасырлардан киләп сара ак кораб.**
**Тукай моңы бу корабка маяктыр:**
**Иңнәрендә — җилкән түгел, канаттыр...**
**Канат җырын күкрәр күкләр көйләгән**
**Очыш хакын канатлылар түләгән.**
**Күкрәү михнәтеннән газап чиксә дә,**
**Аерылмаган татар аттан, Алладан...**
**Мин дә Тукай телен олылаганда,**
**Кара йөзне шаһит итеп ялламам.**
**Кер кундырмам Сөембикә рухына:**
**Аның рухы — Кояшлы бер дирһәмдер...[4]**
**Тәкъдир йөгем — язылачы тарихтыр,**
**Киләчәгем — укылмаган Коръәндер.**
**Мин шуларның һәрбарчасын берьюлы**
**Күкрәк читлегемә кысып йөртәмдер...**
**Нурихандыр өлкән ханы тарихның:**
**Янып язды Илнең коллык ачысын –**
**Үзәгенә үтеп «утлык» чорының**
**Коръән үбеп утка орган баш очын.**

[4] Дирһәм – борынгы көмеш тәңкә.

**Колгалидер тәүдә нәфис таллардан**
**Шигърияткә тибрәр бишек үрүче...**
**Изге Аналарның күкрәк сөтендә**
**Бөтен Җиһан Шәфәгатен күрүче.**

***

**Милли бишек җырын,бөдрә тал җырын**
**Һәрбер инсан тумышыннан ятлаган...**
**Меңәр еллык тәмуг уты кичеп тә,**
**Татар моңы төпкә китеп батмаган;**
**Кара еллар уттан–утка салса да–**
**Моң күтәргән Илне көрәш үренә...**
**Шуңа ахры Җирдә яшәү теләге**
**Алтын балык булып күзгә күренә.**
**Өлге алып җырсыз–моңсыз явыздан**
**Күңел күген басса нәфси чуарлык,**
**Моңсарларга килә һәрчак ярдәмгә**
**Әкият белән аралашкан чынбарлык.**

**Ярык тагарактан ярлы көн күрсә,**
**Байларның да башы сызлап ярыла.**
**Шушы хакта сөйли кебек Агыйдел,**
**Кайта–кайта Илһамият ярына.**

***

**Ил Язмышын җигелеп тарту һөнәре**
**Һәр инсанның килсә икән хәленнән!**
**...Берәү Урал өя сөю хисеннән,**
**Чыга алмый берәү сазлык ләменнән.**
**Шушы «сазлык бакасы» да еш кына:**
**— Тау өйдем!!! — дип, күкрәк кага**
**Мөнбәрдән...**
**Кешелекнең мондый хәвеф–хатасын**
**Киләчәгең бәхилләтер — кемнәрдән?!.**
**Икейөзле бу дәһшәтле заманда**
**Кемнәр сихәт өрер рухи ярага?**
**Халык кендек канын низагка түксә,**
**Агыйделләрнең дә суы карала.**
**Нинди генә төрен тарих калкытмый**
**Каралуга этәрүче хатаның?!**
**Татар халкы «яну» дәверләрендә**
**Җуйган бит ул Ватан тиклем Ватанын.**
**Барын җуйган, сандугачлы, былбыллы**
**Тал–тирәген әмма күздән җуймаган.**
**Эшкә озатканда газиз улымны –**
**Сайрар былбылларга тыңлап моңланам:**
**— Җил–давыллар купса, сак бул, балам!..., — дим, —**
**Штурвалың ычкындырма кулыңнан!!!**
**Татар халкын утка сөргән сөргеннәр**
**Чыдам даулый безнең Язмыш кылыннан... –**
**Азатлыкка алып чыгар көрәшнең**
**Өлгесен ал, улым, агымсулардан?!.**
**Иман кыйбласына хәер–хак өммәт**
**Сөю анты белән рухын сугарган.**

**Кайгыларга уралса да, Уралда**
**Каф тауларын бик еш искә төшергән:**
**«Сызлавыклы бавырыма дәва», дип, —**
**Аш пешергән төеп солы төшеннән.**
**Олы кеше — солы төше хакында**
**Һәрбер буын бәет, дастан көйләгән.**
**Киләчәккә ялгап аклык йоласын:**
**Җыру чигеп нәкышләгән, җөйләгән.**
**Алтын балык тайпылмаган кыйбладан**
**Ак пароход юнәлсә дә кай табан...**
**Татар халкы ут белән су арасын**
**Балык кына чагыннан ук айкаган.**
**Шул чактан ук Илнең Хәтер Кояшы**
**Ислам кыйбласына кайтып уелган.**
**Шул чактан ук утка ирек куелган**
**Татар каны Идел булып коелган.**
**Хезмәт белән, сөю белән үрелеп**
**Әмма тормыш тамырланган Ватанда.**
**Без — шагыйрьләр кайсы яктан килсәк тә,**
**Тоташабыз Агыйделгә, ак таңга.**

***

**Ачыклыкта тотып барлый хәтерен**
**Тамыр җәрәхәтләренә бай Ватан:**
**Идел аша күпер салганы өчен,**
**Богау киеп катор киткән кайнатам!**
**Корал алып яуга киткән үз атам:**
**Башын салган Алман яккан утларга...**
**Ата-баба хакын хаклый беләм мин,**
**Ут йотудан белмим ничек туктарга.**
**Белмим ничек дәваларга бәгырьне,**
**Кемгә ярып күрсәтергә йөрәкне...**
**Сугыш чорларыннан бирле Ил-көнгә**
**Без йөрәкләр белән булдык терәкле.**
**Ут телендә,су телендә аңлашып,**
**Суд казаларыннан калдык сакланып.**
**Авыл белән ач-ялангач булсак та,**
**Бераүне дә таламадык, сатмадык.**
**Артык күп үтмәде кебек вакыт та**
**Сатлык җаннар янә Илгә ут ора.**
**Утның тәүге чыганагын таптырып,**
**Тарих вулканнары төптә котыра.**

Батулла

# ТУГАН ЯГЫМ – ЗӘЙ ТӨБӘГЕ

ХАТИРӘЛӘР

### Надан укытучы

Милиция мәктәбеннән куып кайтаргач, әти мине РОНОга алып китте. Ул вакытта РОНО мөдире Кузнецов исемле керәшен дәдәе иде. Әти бер сарык түшкәсен алдына салып, мине матай артына атландырып, Зәйгә чапты. Сарык үз эшен башкарды. Мине Кадер җидееллык мәктәбенә укытучы итеп җибәрделәр. Өчле-тугызлы укыган, кичә генә аттестат алган авыл малае үзе укытучы булсын әле. Җиденче сыйныфта миннән ике-өч яшькә олы малайлар (егетләр) бар иде. Юллама тотып РОНОдан чыкканда бер укытучы:

— Башың икеме әллә синең, Кадер авылы мәктәбеннән тәҗрибәле укытучылар да кача! – дип миңа пышылдады.

Мин әле аның ни әйткәнен аңлап бетерми идем. Тәвәккәлләп Кадер авылына киттем. «Бишенче-җиденче сыйныфларда математика укытырга» дип юлламада язылган булса да, миңа география, физкультура һәм хезмәт дәресләрен тоттырдылар. Географиясе авыр түгел, кичтән бирелгән теманы яхшылап укып барасың да сөйлисең. Физкультурасы да әллә ни кыен түгел, күнегүләр ясатасың, кыш көне чаңгыда йөрергә алып чыгасың, ярышлар уздырасың. Ә менә хезмәт дәресе ул — тәмуг, җәһәннәм иде. Балаларны балта эшенә өйрәтергә, кызларны чигү чигәргә, аш пешерергә өйрәтергә тиешле дәресләрдә мин ни кылырга белми аптырыйм. Мәгариф министрлыгы хезмәт дәресләрен кертеп, бер караганда бик яхшы гамәл кылды. Ләкин Кадер авылы мәктәбендә бу (фаҗига булмаса да) драматик төс алды. 20-25 бала 45 минут буе эшсез утырырга мәҗбүр иде. Эшсез бала тик утыра алмый. Тормыш тәҗрибәм юк, мин аларга ни сөйлим, укыган китапларымның эчтәлеген, әкиятләр сөйлим, тынлыйлар, матур утыралар. Бер-ике атнадан соң минем сүз маям бетте, мәктәпнең ун көрәге бар, ә балалар 20дән артык, көрәк белән бер тапкыр кар көрәргә мөмкин яки бакча казырга мөмкин. Ул эшләр беткәч тагын бушлык. Ни кылырга белмәгәч, ир тавышы кергән үсмерләр кызларны кыса, күкрәкләрен әвәли башлый. Берничә ир бала хезмәт дәресеннән качып, рус теле укытучысының бәдрәфкә кереп киткәнен сагалап торган да дилбегә белән ишеген бәйләп, ике киртәгә корылган бәдрәфне күтәреп, авыл буйлап алып барып, күпер төбенә куеп киткәннәр. Икенче көнне нигә алай иттегез, дигәнгә:

— Рус теленнән контрольный булырга тиеш иде, дәрес булмасын өчен шулай эшләдек! – дигән җавап алдык.

*Ахыры. Башы узган санда.*

Кырык ел рус теле укыткан бу затлы нәселдән чыккан карчык икенче көнне үк гариза язып, мәктәптән китте.

Бу мәктәптә бер генә укытучының дәресе тыныч уза иде, Бәдретдин абыйныкы гына. Бәдретдин дингез офицеры булып хезмәт иткән, озын буйлы, ак чырайлы, һәрвакыт битен ялтыратып кырган, кигән киеменә тузан төшми торган артык пөхтә ир иде ул. Ул физика-математика укыта, дәресендә чебен очкан тавыш ишетелерлек тынлык. Бәдретдинне балалар үзара Бәшәр дип йөртә. Бәшәр абзый кырыс, усал, тәртип бозган укучының янагына сугарга да, якасыннан элеп, дәрестән ишегалдына чыгарып ташларга да кулыннан килә. Артык тәртипсезрәкләрне ул мәктәп базына ташлап, өстенә өстәлләр, урындыклар өеп, сәгатьләр буе тота торган иде. Аның дәресендәге тынлык хөрмәттән түгел, куркудан иде. Бәшәрдән күрмәкче мин дә азау ярган Микаиловның янагына суктым, шуңа бүген дә үкенеп бетә алмыйм. Бу хәл чарасызлыктан, наданлыктан, балалар рухын аңламаудан, тәҗрибәсезлектән икәнен аңлыйм мин, ләкин соң. Бу үсмер Туңылҗадан төшеп укый иде. Туңылҗада урыслар да яши, ләкин алар урыс телен оныткан, Ана телләре татар теле иде. Микаиловның ата-анасы юк, әбисе белән генә яши. Курку белмәс малай иде ул. Укытучыдан да, мәктәп директорыннан да, РОНО вәкиленнән дә ул курыкмый. Хәтта Бәшәр абзый да, аны базга ябып тотуына карамастан, җиңә алмады. Ул җиденчене көчкә тәмамлап авылда калды. Ишетүемчә, Микаилов алга таба укымаган да, эшләмәгән дә, әбисенең пенсиясенә, бакчадан алган бәрәңгесенә яшәп ятканда бер авылдашын үтереп, пенсиясен алган. Аны атарга хөкем иткәннәр.

Кадердә укытканда Яңа ел бәйрәмен уздырышып, мин беренче гыйнвар көнне Шыкмайга кайтып киттем. Әхмәт авылыннан туры юл беткән, Бура-Киртә авылы аша әйләнгеч юлдан кайтам. Бура-Киртәнең Шыкмай очына җитәрәк күрәм, Закир абзыйлар капкасы янында халык җыелган. Якынрак килсәм, барысы да җылаша, Закир абзый үлгән икән. Тетрәнеп киттем. Иллегә дә җитмәгән тап-таза ир егет егылсын да үлсен, имеш.

Закир абзый сугышка китеп хәбәрсез югалган кеше иде. Аның минем белән яшьтәш улы да атасыз ятим үсте. Югалган Закир абзыйдан 1956 елда хәбәр килеп төшмәсенме? Ундүрт ел узгач язган: кайтам, дигән, исән-сау дигән. Фашист әсирлегеннән котылып, бу якка чыккач, аны Совет фашистлары Колымага аткарган икән. Ирекә чыккач, бераз акча эшләгән дә хатыны, балалары янына, туган авылына кайткан. Олы сөенеч иде бу, 40 000 сум акча белән кайткан, дип сөйләделәр. Ул вакытта бу бик зур байлык. Йорт сал, каралты-кура житкер, машина ал, киен, аша, эч. Кайткан шатлыктан Яңа ел көнне Закир абзый бөтен туган-тумачасын, авылдашларын җыеп, галәмәт олы мәҗлес оештыра. Аракы мул була. Эчәләр. Шатлыгыннандыр инде Закирҗан абзый артыграк эчеп ташлый, икенче көнне баш төзәтергә грамм аракы табалмыйлар, Закир абый яна, чыдый алмагач, инешкә төшеп бәкегә ятып, күп итеп бозлы су эчә, ләкин хәле җиңеләйми, ул егыла. Өч чакрымдагы Җәйләүгә, керәшен авылына барып көмешкә алып кайтырга ат белән кеше юллыйлар, көмешкәне кайтарып җиткергәндә Закирҗан абзый җан тарткан була инде. Ундүрт елдан соң туган туфрагына ятып үләргә кайткан икән.

Бу вакыйга миңа бик авыр тәэсир итте.

### Агитбригада

Кадер авылында укытучы булып эшләгәндә мине агитбригадага чакырдылар. Киттем. Солтангәрәй абый (минем элеккеге җизнәм), кызык мәзәкләр сөйләячәк, «чичүтке» бииячәк, спектакльдә уйнаячак. Зәй

китапханәсендә эшләүче ике яшь кыз җыярлаячак, мин аларның яшьрәгенә үлеп гашыйк булган идем. Мин гармун уйнарга тиеш. Беренче концерт Урта Багражда узды. Программаны карарга Зәй гәзитенең баш мөхәррире Канафин белән хәбәрче, Кабан авылы егете Петр Егоров та килгән. Пьесада Солтангәрәй абый олырак яшьтәге кешене, мин ике кызга да гашыйк егетне, ике китапханәчебез ике гүзәлне башкара иде. Кыландык инде, Солтангәрәй абый гаять талантлы комик актер иде ул. Бер пәрдәлек пьесаны уйнап чыктык та тәнәфес игълан иттек. Уңыш шәп иде. Сәхнә артына Канафин белән Петр килеп керде, алар безне котладылар, кулларыбызны кат-кат кыстылар. Әттәч инде гел!

Канафин төбәк гәзитенең баш мөхәррире, Петр шул гәзиттә хәбәрче булып эшли.

Икенче өлеш башланды. Кызлар җырлый. Халык ярата. Аннан соң Солтангәрәй абый мәзәкләр сөйли башлады. Халык егыла-егыла көлә. Минем эч кычыта. Минем дә шулай уңыш казанасым килә. Минем дә мәзәкләрем бар. Солтангәрәй абый мәзәкләрен тәмамлап, сәхнә артына чыкты, сәхнәдә җырчы. Мин ялынам: зинһар, мине дә сәхнәгә мәзәк сөйләргә чыгар, Солтангәрәй абый, дим. Ялына торгач ул риза булды.

Бу мәзәкне мин Шыкмайда, капка төбендә Куян Кыямы сөйләгәннән ишеткән идем.

— Бер җәбрәй товар сатарга дип, ярапланга утырып, калага бара икән. Аста зур-зур авыллар, авылларда зур-зур базарлар кала. Җәбрәй очучы янына килеп: мине зуррак базарда төшереп калдыр әле, дип тинтерәтә башлаган. Аста тагын да зуррак базарлы авыл күренгән. Төшер мине шушы базарга, дип кычкырган җәбрәй. Очучы «үлем элмәге» ясап, очкычны астын өскә әйләндереп, янә турылаткан. Җәбрәйнең тавышы тынган. Калага килеп кунаклагач, очучы пассажирлардан сорый икән: теге җәбрәй кайда ул? Тегеләре: Базарлы Матакта товарларын сатарга төшеп калды ул, дигәннәр.

Халык әллә ни көлмәде. Әмма концерттан соң артка агарынган Канафин белән Җәгүр йөгереп килеп керде.

— Безобразие! — дип кычкырды Канафин. — Кем сиңа рөхсәт итте башка халык вәкилләрен мыскыл итәргә? Нигә аны сәхнәгә чыгардың?— дип бригада җитәкчесе Солтангәрәй абыйны да, мине дә утлы табага бастырды.

Мин беренче тапкыр чытырдап «яндым», ләкин бу соңгысы булмаган икән әле!

Шуннан соң агитбригадада вакытында мин кызык сүз сөйләргә сәхнәгә чыкмадым. Хәзер уйлап куям, әтинең кыл өстендә торган чагы булган ул, әгәр дә Канафин белән Петр НКВДга барып әйтсә, әтине чакыртып: үзеңнең антисоветик мәзәкләр сөйләвең җитмәгән, улыңны да шуңа котыртасыңмы? дип әтине утыртып та куйган булырлар иде. Шөкер, Канафин да, Кабан егете Җәгүр дә бу «эшне» йомып калды. Хәзер дә аларга чиксез рәхмәтләр укыйм.

Сәхнәдә мин тагын «яндым». 1967 елда Илһам Шакиров концертының сөйләүчесе булып, мин Мәскәүгә гастрольләргә киттем. Соңгы концертыбыз Чайковский исемендәге концертлар залында узды. Зал тулы, залда дәүләт эшлеклеләре белән чит ил кунаклары да бар. Авызыма шайтан төкердеме? Мин сәхнәдән торып, кырым татарлары турында бер-ике җөмлә әйттем. Бу хәтәр «яну» иде.

1968 елда Мәскәүдә СССР язучыларының корылтаенда Некрасов китапханәсе сәхнәсеннән «Таш баскычлар буйлап менгәндә» исемле хикәямне укып, тагын «яндым». Имеш, анда советларга каршы сүз булган

икән. Олы исемле ике язучы (Ибрай абый белән Гариф абый) минем өстән шулай язып биргәннәр.

1969 елда мин телевидение буенча «Тычкан баласы Чикыл» исемле әкият сөйләгән идем, аның белән дә «яндым». Әләкчеләр анда да гаеп тапканнар. Имеш, ул әкияттә дә советларга каршы фикер бар икән.

1972 елда Казан университетының тулай торагында мин «Мортаза» исемле тарихи хикәямне студентларга укыган идем. Берничә әләкче КГБга житкергәннәр. Анда да антисоветик фикер тапканнар. Бу хикәя Казан җимерелгәннән соң татар халкын көчләп чукындыру вакыйгалары турында иде.

Соңгылары җәбрәй турындагы мәзәк кебек кенә булмады, КГБда җавап бирергә туры килде.

Агитбригада белән без Зәй төбәгенең байтак авылларында булдык. Бишавылында, Шыкмайда, Бура-Киртәдә, Югары Пәнәчедә... Концерт гаять зур уңыш казанды. Соңгы концертлар шулкадәр зур уңыш белән бара иде, без инде бер-беребезгә ярашып беткән идек. Хәтта аерылышасы килми башлады. Чөнки мин китапханәче кызга гашыйк идем инде. Ләкин, ни өчендер, безгә кабат күрешергә насыйп булмады.

## Зәй холкы

Жир шарында яшәүче алты миллиард кешенең холкы нибары дүрткә генә бүленә диләр: холыкнамә булганлыгы турында язалар.

*Меланхолик*
*Сангвиник*
*Холерик*
*Флегматик*

Яши торгач, мин бишенче билгеләмәне таптым. Тагын Зәй холкы бар икән. Мин алда сөйләячәк шәхесләргә бишенче билгеләмә: Зәйский холык хас. Нәрсә соң ул *Зәйматик (Зәй холкы)* алдагы барлык холыкларны да үз эченә алган сурәттә, үзе аерым холык булып тора. Әйтик, Зәйдән чыккан атаклы шәхесләр бераз мактанчык, кайчак шапыртык, эшчән, кеше күзенә күренергә ярата, игътибар уртасында булырга тырыша. Һәм ул боларның барысына ирешә дә. Әйтик, башка төбәктә туган-үскән шәхесләр кылачак эше турында кычкырып йөрми, мыштым гына башкара. Зәйский холык түзеп тора алмый, кычкыра: мин роман язып бетердем, мин пьеса язып ташладым, ди. Баксаң, зәйский ул романын башламаган да, пьесасы әле аның башында гына. Сүз әйтелгән, оятка калмас өчен, зәйский роман язарга тотына, көчәнә-көчәнә пьеса яза башлый һәм тәмамлый да. Роман чыга, пьеса куела, роль уйнала. Зәйский оятка калмады. Бу мактану үзенә үзең маяк, план корудыр. Үзеңне эшләтер өчен алдан вәгъдә биреп ташлаудыр. Кайда синең романың, кайда синең пьесаң дип сорасалар, жир тишегенә кереп кит, ләкин Зәй холкы жир тишегенә керергә теләми һәм үзен иҗатка мәҗбүр итә. Бу үз-үзең белән ярышып эшләүгә тиң халәт. Зәйскийләр телгә беткән булыр, һәр мәҗлестә үзеннән-үзе табын агасына (томадага) әверелеп китәр. Берәр мәҗлестә Хәйдәрнең, Мөдәрриснең, Батулланың, Аязның, Хатыйпның җөм генә тик утырганын күргәнегез бармы? Юк! Сүз мәйданында алар алда. Һәм, әйтергә кирәк, әйткән сүзләре тәэсирле, үтемле, кайчак әче дә була. Зәйскийләр мактаса, артык мактый, хурласа артык хурлый торган кешеләр. Бу Аязга аеруча хас сыйфат, Илдар Юзи әйтмешли:

— Аяз башта чөя күккә, аннан тибә күткә!

Бер мисал.

Аяз Гыйләҗнең җәйге ял йортындагы китап киштәләре төрле китап-

журналлар белән шыгрым тулы икән. Бары тик бер шүрлек кенә буш диярлек. Анда нибарысы ике китап тора. Урын житмәү сәбәпле, идәндә өелеп торучы китапларга карап, Батулла хуҗага дәшкән:

— Аяз абый, нигә бу бичара китапларны менә бу буш киштәгә урнаштырмыйсың? — ди.

— Юк, парин! — ди Аяз.— Бу киштәгә мин татарның бөек язучыларын гына куям. Әнә, анда Әмирхан Еники дә Равил Фәйзуллин. Яз, ыслушай, син дә шулар кебек, бу киштәдә өченче китап синеке булыр!

Ни сәбәпледер, Аяз Гыйләҗ белән Равил Фәйзуллинның аралары бозылып китә. Шул заманда Батулла тагын Аяз Гыйләҗнең җәйге өенә кунакка бара. Китап киштәсенә бакса, ни күрсен, анда бер генә китап: Еники генә. Аны-моны уйлап тормастан, Батулла:

— Аяз абый, кая китте бөек Фәйзуллин? — дип сорый. Моңа каршы өй хуҗасы сүгенеп ала да болай ди:

— Кире уйладым әле мин, ыслушай, парин...

Байтак вакытлар узгач, Аяз Гыйләҗ белән Әмирхан Еники арасыннан да кара мәче йөгереп уза. Батулла Аязның җәйге өенә килгәч, шуны күрә: буш киштә юк, аннан Еники китабы да алынган, ул киштәгә элек идәндә аунаган «Новый мир» журналы дыңгычлап тутырылган була.

Батулла Аязга үзенең яңа чыккан китабын сузып:

— Ага кеше, менә син әйткән өченче китапны мин яздым! — ди. Әмма хуҗа кырыс кына:

— Күрмисеңмени? Синең китапка анда урын юк! — ди.

Бервакыт Мөдәррис кызмача Матбугат йортына килеп керде.

— Нинди шатлыгың бар, Мөдәррис, кош тоткандай горур күренәсең? — диде Барлас Камал.

— Яңа гына Акмулла турында поэма язып бетердем! — диде Мөдәррис.

— Укып күрсәт! — диләр егетләр.

— Укырлык түгел әле! — ди дәһи.

— Алайса, бер-ике куплетын гына әйтеп күрсәт!

Сизеп торам, Мөдәррис поэмасын башламаган да әле, юлда аның башына Акмулла турында поэма язарга фикер генә килгәндер. Әмма Мөдәррис югалып кала торганнардан түгел, позага басып, күкрәк тавышы белән мизгелдәк (экспромт) укый башлады:

— Биләвендә татар хатынының
Күкрәк сөтен авыз итсә дә,
Юккамыни ничә халык аңа
Урын әзерләгән киштәдә?!
Шагыйрьләрне җырлар гына түгел.
Язмышлар да бергә кушалар...
Әнә кайдан килә — Акмулладан
Башланган ул мәшһүр Мусалар.

Бу гаҗәеп бер мизгел иде. Мәҗлес тынып калды, аннан гөрләтеп кул чабарга тотындылар. Мөдәрриснең Акмулла турындагы поэмасы байтак айлар күренмәде. Мөдәррис үзе дә юкка чыкты. Мөдәррис голәма алдына биргән вәгъдәсен үтәр өчен ябылып, «Акмулла арбасы» исемле поэмасын язып ята иде. Ул әсәр 1984 елда Акмуллага багышланган китапта басылып чыкты.

Инде килеп, алты миллиард халыкның холкын билгеләү өчен мин түбәндәге җәдвәлне тәкъдим итәм.

*Меланхолик*
*Сангвиник*
*Холерик*
*Флегматик*
*Зәйматик*

Әтием Мөхлисуллада да Зәй холкы иде. Башта шыттырып мактана иде дә, соныннан сүзен юкка чыгармас өчен жене белән эшли иде, алдан кычкырганын барыбер үти иде.

## Мөдәррис

## (1946–2006)

*СССР язучылары Берлеге әгъзасы (1973); Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләге иясе (1992; Татарстанның халык шагыйре (2006).*

Мәктәпкә киткәндә, кичке уеннарга чыкканда, атам-анам, әби-бабам:

— Аң бул! Тәртипле йөре! Йөзебезгә кызыллык китермә!— дип озатып кала торган иде?

Балигъ булып, авылдан чыгып киткәндә, авылым халкы:

— Аң бул! Авылыбызның йөзенә кызыллык китермә!— дип мине басу капкасы төбендә Казанга озатып калды.

Казаннан чит илгә чыгып киткәндә дә Татарстан халкы мине:

— Татар милләтенең йөзенә кызыллык китерә күрмә!— дип чит илләргә озатып кала кебек.

Аллаһы Тәгаләгә чиксез шөкерләрем, атам-анам, авылдашларым, милләтем каршында йөзем ак, намусым пакь, дип картлык көнендә горурлана торган якташларыбыз турында уйлыймын.

Чыннан да, бармы соң шушы кагыйдәләрне гомеренең азагына чаклы бозмаганнар? Кемнәребез белән горурланабыз, матур мәгънәсендә, кемнәр белән мактана алабыз соң без — Зәй кешеләре? Туган ягыбыз, кече ватаныбыз һәм бөтен олуг милләтнең паспорты буларак, без кемнәрнең исемнәрен атый алабыз?

Дуслык мәжлесләрендә гелән якташлар турында сөйләшәбез.

— Фәлән артист безнең якныкы, — ди берсе.

— Төгән жырчы безнең авылныкы, — ди икенчебез.

— Безнең яктан фәлән язучы чыккан, — ди өченчебез.

Мактанычмы бу, әллә горурлыкмы?

— Эш күплектәмени, жегетләр! Зәй төбәгеннән бер Мөдәррис Әгъләм чыккан да бик житәр иде, — ди Аяз Гыйләжев.

Әйе, Зәйдән башка бер генә язучы да чыкмаган булса да, бушлыкны бер шагыйрь — Мөдәррис Әгъләм тутыра алган булыр иде.

Карап торырга мәһабәт буе да юк, жаваплы урыннарда да утырмый, һавага ашкан, күктерәр йортлар да төземи, типтәр әйтмешли: ябай гына бер адәм, сөйләшеп торганда тавышы да чыгар-чыкмас кебек. Аның каравы, шигырендә, китапларында һәм сәхнәгә менеп, халык алдында шигырь әйткәндә Мөдәррисне алыштырып куялармыни? Мондый чакларда ул буйга да биегәеп китә кебек, мәһабәт каһарман кыяфәтенә керә, тавышы бөереннән чыга башлый, ул гайрәт белән гаделсезлеккә каршы нәгърә ора. Сәхнәдә олуг әверелеш башлана. Кая киткән ябай гына Мәдәррис? Кая киткән читенсенеп кенә сөйләшә торган Зәй малае? Сәхнәгә олы шагыйрь хужа булып алган. Ул анда падишаһ. Обкомнарын, райкомнарын, алигархларын бер кырда

торсын. Шигърият түрендәге алтын тәхеттә шагыйрьләр солтаны Мөдәррис җәнапләре хакимлек кыла. Мөдәррискә илле яшь тулган! Бу Мөдәррис бәйрәме генә түгел, бу бөтен милләт бәйрәме иде. Ю-ук, Мөдәррис татарның иң мәшһүр артистларын, атаклы җырчыларын да җыймаган мәҗлесенә, үзен мактатыр өчен бер өер мәдхиячеләр-ләббәйкәләр дә чакырмаган; культура министры да, обком вәкиле дә килмәгән, каләмдәшләре, якташлары, тамашачылар, аның шигырен сөюче укучылары — вәссәлам! Артистлар да аның шигырьләрен сөйләделәр, «нәфис сүз осталары» дип аталганнар да Мөдәрриснең әсәрләрен укыдылар — рәхмәт.

Озын төннең,
Җиде төннең уртасында
Кеше көче, кеше уе, кеше аңы,
Кеше рухы, кеше тәне, кеше җаны
Әверелә моңлы көйгә, гүзәл сынга...

*Мөдәррис Әгъләмов.*

Ләкин шигырь уку сәнгатендә, нәфис сүз сөйләү ярышында Мөдәрриснең үзен узучы булмады. Шигырьнең аскы тукымасына үтеп, гайрәтле каһарман тавышы илә яттан сөйләп, Мөдәррис һәр шигыре белән халыкның бәгъренә үтеп керде. Сәхнәдә милләт каһарманы, сәхнәдә халкын афәтләрдән сакларга, дип мәйданга чыккан олуг Шагыйрь хакимлек итә. Халыкның игътибары бер кулга, Мөдәррис ихтыярына буйсынган иде. Шигъри сәләте өстенә Мөдәррискә тәэсир итү көче, актерлык куәсе да бирелгән. Шуңа күрә, аның бер генә шигырен дә гамьсез тыңлап булмый. Ул сине өермә кебек, давыл кебек бөтереп ала. Син «Мөдәррис Әгъләм шигърияте» дигән сихри дәрьяга чумасың. Яшерен-батырын түгел, шагыйрьләр арасында гына түгел, профессиональ артистлар арасында да, «нәфис сүз осталары» дип аталганнар арасында да шигырьне Мөдәррис кебек оста укучылар бик сирәк.

Башка жанрларга кереп чәчелмичә генә, бары тик шигырьгә генә мәхәббәт тоткан шагыйрьләр Кол Гали, Кандалый, Акмулла, Дәрдмәнд, Рәми, Туфан, Хәким, Арслан, Рәшит, Роберт Әхмәтҗаннар, Равил, Рәдифләр, Зөлфәтләр...

Һәм Мөдәррис шулар рәтендә.

Кайчакларда уйлап куясың: шагыйрь пәйда булсын өчен нинди алшартлар кирәк икән? Нишләп бу шагыйрь яки җырчы нәкъ менә шушы төбәктә, шушы авылда, шушы вакытта туган, ни өчен башка җирдә түгел?

Мөдәррис 1946 елда Зәй төбәгенең Бистебашы (Пусташит) авылында туып, күрше Бишавылы (Түбән Биш) урта мәктәбендә генә укып чыккан татар баласы, юкса. Питербур, Киев, Мәскәү кебек шәһәрләрдәге бар унайлыклары булган мәктәпләрдә дә укымаган. Шушы утыз дәрәҗә суык булган көннәрдә, язу карасы ката торган агач мәктәптә укып та шагыйрь булып була икән, кана. Мәктәптә укыган чакта ук Мөдәрриснең шигырьләре зур матбугатта еш күренә башлаган иде. Беренче шигырьләреннән үк Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким шагыйрь буларак Мөдәррисне үз араларына кабул итте, яклады, күтәрде. Хәзер инде Тукай бүләгенә ия Мөдәррис Әгъләм үзе яшь шагыйрьләрне барлый. Ул олуг остаз!

1958 елның көзендә «Кызыл Зәй» гәзитендә 12 яшьлек Мөдәррис Әгъләметдиновның «Истәлекләр» исемле шигыре басылып чыккан иде.

Истәлекләр алар күп төрле,
Истәлекләр алар күп кала –
Бер истәлек булып әнкәмнең
Чиккән сөлгеләре саклана.

Чиккән сөлгеләре саклана,
Бизәге дә аның бизәге –
Карый сыман миңа бизәктән
Әнкәемнең нурлы күзләре.

Такташ беренче шигырен – уналтыда, Җәлил унөч яшьтә язган, дибез; ә безнең Мөдәррис исә унике яшендә чып-чын шигырь язып ташлаган икән. Сабый баланың шушы беренче шигыре азау ярган шигырьчеләрнең такмакларын ишекле-түрле куып йөртерлек шәп килеп чыккан.

Чыннан да, кайбер шагыйрьләр урау юллар аша, кайлардадыр адашып йөри-йөри үз юлын таба. Мөдәррис инде беренче шигыреннән үк үзенең шагыйрь икәнен дөньяга кычкыра.

Ун елдан соң, 1968 елда Аккош күле буенда бер могҗиза була. Хәсән Туфан каләмдәшләре алдында яна шигырьләр укый.

… Эт тә үрчи, аларның да
Өреп йөргән көне.

Бәлки хәбәр салалардыр:
Килә, диеп, бүре;
Үзләре кеше янында
Бүренең бер төре.
………………………………

Такта чәйне ваткан кебек,
Бер чеметем ватып, –
Гасырларның катламыннан
Алды мине вакыт.

Алды— салды тормыш дигән
Кайнап торган суга:
Кайный тормыш –
Кандай куе
Җан ачысы чыга…

Әдипләр Хәсән Туфанның шигырь артыннан шигырь укуын үтенәләр. Аларның барысы да: Хәсән Туфан үз шигырьләрен укый, дип уйлый. Соңыннан ачыла ки, тере классикларны сокландырган бу шигырьләр Мөдәррис Әгъләмовныкы булып чыга. Хәйран калган язучылар, аптыраганнан-йөдәгәннән сорап куялар:

– Кем соң ул Әгъләмов, каян килеп чыкты соң әле ул? – диләр.

Әле күптән түгел генә Зәй төбәгенең Бишавыл урта мәктәбен тәмамлаган Мөдәррис Әгъләмов әнә шулай шаулап әдәбиятка кереп китә. Һәм шуннан бирле кырык алты ел буена Мөдәррис шул шигърияткә-халыкка хыянәтсез хезмәт итә.

Аның хыянәтсез иҗаты гел тантана, гел шау-шу белән генә үсмәде, әлбәттә. Тук кыяфәтле әдәбият белгечләре, ялгышмауларына артык нык инанган тәнкыйтьчеләр Мөдәрриснең иҗатына шик белән, бераз кимсетебрәк карадылар. Бу да табигый хәл. Аңлап бетермәгәннәрдер, Мөдәрриснең олы куәсен күреп бетермәгәннәрдер, мотлак. Бәгъзеләренең күңел күзе ачылып җитмәгәндер. Күңел күзе сукыр кешенең өстән карап, вәкарь фикер йөртүе әдәбиятка-сәнгатькә файда урынына зыянны күбрәк сала. «Заманның сулышы сизелми, совет чынбарлыгының тантанасы күренми, милли коймаклар, узган-үткән турында балавыз сыга» кебегрәк «әдәби-фәлсәфи» терминнар кулланып, Мөдәрриснең әсәрләренә «кырын күз белән» караштыргаладылар.

Ләкин Мөдәрриснең иҗатын, аның шагыйрьлеген әче тәнкыйть белән кимсетеп, теттереп мактау белән үтереп булмый иде инде. Шагыйрь йә бар ул, йә юк! Шагыйрь бар икән, ул «кыйналган» саен ныгый гына барачак.

Иҗатын кимсетә алмагач, бәгъзеләре Мөдәрриснең шәхси кылмышларына, аның үз-үзен тотышына бәйләнә башладылар. Университетта укыганда ул беренче «сәяси таякны татыды». Мөдәррис үзенең эчке талантын күңел сиземләве сизгән, акыл зиһенләве белән белгән шәхес буларак, авызлыкны тешли торган чыгымчы ат кебек, «дингез тубыктан» диберәк яши иде. Ул вакытта философиядән дә, тарихтан да, әдәбияттан да олы, «өстен фән» кертканнәр иде. Һәр студент хәрби курслар узып, сугыш һөнәренә өйрәнеп чыгарга тиеш иде. Мөдәррис авызлык тешләп, шул «иң мөһим», иң хәтәр дәресләргә йөрми, имтихан тапшырмый. Тәртибе шулай, димәк, андый

студентка стипендия дә эләкми, шагыйрь Мөдәррис ачлы-туклы яши. Гадәттә, хәрби курсларның башына хисе каткан окопниклар, әдәбиятына, сәнгатенә, тарихына төкереп карый торган наданнарны куя торганнар иде. Мөдәррис кебек бәйсез холыклы кешене шул солдафоннарның коры әмерләре ничек тыеп тора алсын? Риваятьләргә күрә, Мөдәррисне кафедрага алып кереп бик каты кысалар.

– Студент Аглямутдинов, син ни өчен хәрби курсларга йөрмисең, димәк, син Советлар ватанын агрессорлардан сакларга теләмисең? Син – дезиртир!

– Мин – шагыйрь! Минем максатым кеше үтерү түгел! – дип Мөдәррис университетны ташлап чыгып китә.

Кулына мылтык алырга теләмәгәне өчен, шагыйрь Мөдәррисне университеттан куып чыгаралар, дисәң дә хата булмас.

... теләмим мин баш иярге;
Баш болай да иелә ул
Баш иярдәй кешеләргә.

Бу – Мөдәррис!

«Кан җибәргәч җиңел була, энем», –
Табиб шулай дип акыл сата.
Мин, ышанып, кан тамырын кистем,
Исем китте... –
Шигырь агып ята.

Бу да – Мөдәррис!

Шагыйрьнең серле китабы менә шушы шигырь белән ачылып китә. Мөдәрриснең җәрәхәтләр алган йөрәгенең тибеше, ул узган юл, зиһенендә яралган бөек максаты, мең еллар аша ата-баба токымының токымына күчә барган нәселдәнлеге һәм шигъри елъязмасы тулган шушы китап – шагыйрьнең халкы каршысында тоткан имтиханы. Бу китап Мөдәрриснең ата-анасы, мәктәбе, туган авылы һәм гомум татар милләте алдында исәп-хисап тотуыдыр, мөгаен.

Мөдәрриснең шәхесе шушы кыска гына биш юллыкка тулаем кереп тулган. Бу аның тәдбире (программасы), бу аның тоткан юлы, бу аның максаты, китапка кергән башка барлык шигырьләр шушы биш юллыкның аңлатмалары, исбаты, дәлилләре сыйфатында килә.

Кандалыйлар, Акмуллалар, Тукайлар, Туфаннар бөек максатларына ничек тугры кала алган булсалар, Мөдәррис тә шулай, үз тәдбиренә сабит.

Кыенмы соң ул үз максатына, үзең корган тәдбиргә тугры-сабит булу? Максаты ачык булганнарга ул әлләни кыен түгелдер. Чөнки ул максатына тугры калса, кыенлыклар, җәберләр, кимсетүләр булачагын яхшы белә. Ул шул кыенлыкларга үзен әзерли, шуларга каршы тору өчен көч җыя башлый.

Купшы романтика аркасында гына олы максат куеп, шул максатны үтәү юлларында кыенлыкларга, җәзаларга дучар булгач, кеше максатыннан баш тарта, андыйларга кыенрак. Антыңа, максатыңа хыянәт итүдән дә олы гөнаһ, олы җәза юктыр. Беренче шагыйрь тән җәзасы, көнкүреш җәфалары гына ала, ә соңгысы тән җәфасы, көнкүреш кыенлыклары күрми, әмма вөҗдан газабыннан ул аерыла алмаячак. Яки андыйлар үзләренең сәләтсезлеге өчен талантлылардан үч ала башлаячак.

Тарихлардан укып беләбез, сәләте эченә сыймый торган затлар җәмгыять корган кануннарга яраклаша алмый, аның янындагыларга кыен, түрәләр андыйларны сөйми, шагыйрьнең көнкүреш шартлары уртачадан түбән

була. Гадәттә, андыйлар, хәмер эчә башлый. Ләкин андыйлар тормыш дулкыннарында, «хәмер дингезенә» батып та үлми. Затлы иҗаты аларны батырмыйча бөят[1] кебек өстә тотып тора. Андыйларга олы исемнәр дә, яхшы шартлар да бик сонлап килә яки бөтенләй килми.

Чайкый-чайкый,
Борып сыга-сыга
Киптерә дә
салып бәләкли.
Каралта да юа, тормыш шулай
Сынап тора рухи халәтне.

Мөдәррис тә утны, суны, жиз торбаларны кичкән егет. Гаиләсез дә, фатирсыз да, паспортсыз да калып, шыр ялангач, урамда, суыкта дистәләрчә еллар кан калтыраган, жаны калтыранган кеше. Суык йортларда яктылык, жылылык күрмичә, кайнар аш күрмичә каңгырып, сукбай кебек күп яшәде ул. Ләкин зарланмады. Зарланып кем аны аңлар иде? Күбесе: барысына да үзе гаепле, диләр иде. Ниһаять, ул паспортлы да, йортлы да булды. Бу эштә шагыйрь Зөлфәт гаиләсе ана нык терәк иде. Фирая ханымга рәхмәт!

Әйе, үзенең жылы куышын үзе кора алмаган кеше, шагыйрь булса да, композитор, рәссам булса да, мактауга лаек түгел, шиксез. Миңа калса, Мөдәрриснең һәм холыклары белән аңа охшашларның үз фәлсәфәсе дә бу эштә зур роль уйный кебек. Андыйлар: «мин талант иясе, бәс, сез мине карагыз, миңа шартлар тудырыгыз, мине алкышлагыз, чөнки мин зур талант. Талантлы кешегә барысы да килешә, ашаса да, эчсә дә, сүгенсә дә. Мин Алланың кашка тәкәсе, шулай булгач, сез минем әдәпсезлекләремне кичерегез, минем турыда кайгыртыгыз», дип гамәл кылалардыр сыман.

Олы-олы талант ияләренең халык күнеле белән исәпләшмичә, әдәпсез сүз сөйләве, сүгенүе һәм сәрхуш килеш халык алдына чыгуын мин шулай гына аңлата алам.

Мөдәррис үз көнкүреше турында уйламады, дөрес. Аның паспорт юнәтергә һәм фатир алырга йөрмәвен шулай аңлатып булмыймы икән?

Ләкин байгыш-сукбай кебек яшәсә дә, Мөдәрриснең беркайчан да халык алдына, шигыре алдына «салмыш» чыкканы булмады, халык алдында ул көфер сүз сөйләмәде, сүгенмәде.

Мөдәррис ул шигъри табигатьнең олы сәләтле иркә баласы. Иркә балалар гадәттә тормышта кыенлыкны күбрәк татыйлар. Мөдәрриснең тормышы да ал да гөл була алмады.

Мөдәррис сукбайлыкны үзе сайлады бугай ул. Тукай ни өчен гаилә кормаган, Илһам ни өчен өйләнмәгән, Мөдәррис ни өчен үзен кайгыртмаган? дип кызыксынучыларга җавап бер. Тукай белән Илһам өйләнеп, гаилә корып, чүпрәккә, тормыш-көнкүреш чытырманлыгына кереп батсалар, алар бары тик гаиләнеке генә булып калыр иде, Тукай да Илһам да тулысы белән халыкныкы. Аларны бүлгәләргә хакыбыз юк. Мөдәррискә дә шушы халәт кирәгрәк түгелме икән? Күчмә халыкны утрак тормышка, шәһәргә куып кертеп булмагандай, боларны да гаилә кысаларына кертүе шактый кыен булыр иде.

Мөдәррис милләтебезнең тарихы, бүгенгесе, киләчәге турында елларча киеренке рәвештә уйлап, шул уйлар сөрешен шигъри юлларга сала баручы фидакарь шәхес. Аның иҗат мәйданы – милли мохит, милли тарих, Ана теле. Аның башка темасы була алмый. Шагыйрьнең һәр күзәнәгендә милләт язмышы чагыла. Кайберәүләргә аның шигырьләре кабатлану, бертөрлелек булып тоела килде. Блокны без: нигә гел таныш булмаган Ханым турында гына язасың, дип бертөрлелектә гаепләмибез, Тукайны без нигә гел һаман

[1] бөят – батучыларга ташларга әзерләнгән түгәрәк калкавыч

шул татар, милләт дип кәгазь тутырасың, дип шелтәләмибез, без аларның бу «бертөрлелеләген» югары күтәртмәгә куеп, аларның үзенчәлекле иҗаты, дип сөйләшәбез.

Айкала-чайкала килә сәрхуш Шагыйрь...
Аһ, кадерлем!
Ул – канымның бер тамчысы!
Бәлки кунар йорты юктыр, бәлки
бүген
Хыянәт иткәндер аңа илһамчысы.

## Аяз
## (1928 – 2002)

*Татарстанның халык язучысы (1993); ТАССР һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1978, 1985); Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләге иясе (1983); Горький исемендәге РСФСР Дәүләт бүләге иясе (1987).*

*Ике башыннан да яна торган шәм мин.*
Аяз Гыйләҗев.

Зәй ягыннан чыккан мәшһүрләр байтак, әмма Зәй туфрагы Аяз Гыйләҗевнең бер ялгызын гына биргән булса да, үзен аклаган булыр иде. Чыннан да, Аяз исеме житмешенче еллар әдәбиятына ургылып килеп керде. Аның һәр әсәре (уңышка очраса да, уңышсыз булса да) шау кузгатты, бәхәсләр куптара килде. Бу хәл язучы буларак Аязны чыныктырды, шәхес буларак тамырында ныгытты. Тәнкыйтьнең иҗатына битараф калуыннан Аллам сакласын! Аязга барысы да мул эләкте, хурлау да, хуплау да. Аның беренче пьесасы «Җиз кыңгырау моңнары» Камал театрында (1959) куелып, зур уңышсызлыкка очраган иде. Хөрмәтле «Чаян» да авторның бу әсәрен көлке угына тотып, карикатура ясап чыгарган иде. Аның «Җиргә тапшырылган серләре» белән «Эңгер-меңгер» пьесалары да әллә ни озак баралмады. Миңа калса, аның бу әсәрләре шактый саллы иде, катлаулы драматик вакыйгаларга корылган иде, әллә режиссерлар әсәрләрне аңламады, әллә актерлар автор идеясенә каршы уйнады, һәрхәлдә спектакльләрдә ярашканлык булмады. Автор бер якка, уенчылар икенче якка, режиссерлар өченче якка тарта торгач, әсәрләрне бармастай иттеләр кебек.

Аяз Гыйләҗевнең иң нык бәхәс кузгаткан, гаугалы әсәре «Өч аршын җир»дер, мөгаен. Аның шул исемдәге пьесасы да катлаулы язмыш кичерде. Бу әсәр «гаугалы» дигән дан алып, озак елларга сузылган кыйналу чорын узды.

Хөрмәтле Марсель Сәлимҗанов сөйләгән бер мәзәк хәл хәтердә сакланган:

— Аязның «Өч аршын җир»ен, Туфанның «Ат караклары»н репетицияләр башларга торганда туктаттылар. Обком секретаре Мирзаһит Вәлиев чакыртып ала, ишектән килеп керүгә үк: нишләп син Миннуллинның «Өч аршын җир»е белән Гыйләҗевнең «Ат караклары»н подпольно куеп ятасың анда театрда? дип башлады бу. Бер пьесаны да укып карамаган, Аяз белән Туфанны аерыр-аермастан әмер бирә, тыя. Килеп кемдер әләкләгән, бу игътибар белән тыңламаган. Менә шундыйлар татар сәнгате белән идарә итте инде. Еллар узды, пьесаларны куйдырмадылар.

Ниһаять, ул әсәрләр талантны тыеп торучы бөтен киртәләрне җимереп, дөньяга чыкты, сәхнәләрдә уйналды. Аяз Гыйләҗевкә кадәр колхозлашу чорындагы гаделсезлек һәм үз икмәгенә үзе керәчин сибеп качкан «кулак» турында болай кыю итеп язган кеше булмады, шикелле.

Мал иясенә охшар дигәндәй, Аязның әсәрләре дә үзе кебек кытыршы холыклы була килде. Таш капчыкта утырып чыккач та Аяз шома гына яши алмады. Ул:

— Безнең күкрәкләр орденнар тагар өчен түгел, тукмалыр өчен киң яратылган! — ди торган иде.

Бу кыйналулар гына Аязның рухын сындыра алмады. Ул үҗәт рәвештә янадан-яна әсәрләр иҗат итә торды. Алар Аяз агага мәшһүрлек алып килә торды. «Көзге ачы җилләрдә» пьесасы аңа олы шөһрәт алып килде, аннан соң күпме романнар, повестьләр аның данын ныгытты. «Көзге ачы җилләрдә» әсәрендә Аяз ага тышкы яктан тәти әхлаклы булып күренгән коммунист инженер Ибраһимны тискәре каһарман уртага куйган. Халык арасында танылган бу кешене барысы да «фәрештә», дип уйлап ялгыша. Халык табына торган бу кеше намуссыз, әхлаксыз, ялганчы, бозык кеше булып чыга. Ул заманда шушындый киная, тел төбе белән язылган (Еникинең «Саз чәчәге»ннән башка) әсәрләр юк иде, шикелле. Уйналган спектакльләр санынан Аяз аганың бу әсәре рекорд яулаган иде. Режиссеры Абдулла Йосыпов.

— Мин иң беренче драматург түгел, иң беренче мин романчы! — дип әйтә торган иде Аяз абый.

Аның бу сүзләрендә тыйнаклык та бардыр, ихтимал. Тәнкыйтьнең роле дә юк түгелдер, мөгаен. Әмма башка бер фараз да бар. Аяз Гыйләҗевнең пьесаларын аңлап, аларга ачкыч табардай режиссерлар булмады кебек. «Өч аршын җир» пьесасын режиссер Фаил Ибраһимов ничек итеп сәхнәләштерде! Теленне йотарсың, валлаһи. Режиссерның табышлары, рәссамның җиһазлары, актерларның бирелеп уйнаулары камиллек хасил итә иде. Бу спектакль чын мәгънәсендәге сәнгать әсәре иде.

Язучы буларак та, гаилә башлыгы буларак та Аяз ага бәхетле иде. Алар Нәкыя апа белән өч гөрнәдир егет үстерде. Аларның берсе — мәшһүр драматург Мансур Гыйләҗев, икенчесе — мәшһүр галим Искәндәр Гыйләҗев, өченчесе — малтабар Рашат. Өчесе дә саф татарча сөйләшә, татарча укый торган милләтебез угланнары.

— Милләтнең йөзен саклап калыр өчен иң беренче үз гаиләңдә татарча тәртип урнаштырырга кирәк! — ди торган иде мәрхүм.

Аның бу фикере сүздә генә калмады, Аяз моны үз гаиләсендә үрнәк рәвештә исбат итте.

Аяз ага катлаулы холыклы кеше иде. Аның усал чакларын да, ярдәмчел вакытларын да еш күрә торган идек. Аның бу дөньяда бозылышкан шәхесләре дә юк түгел иде.

Кешенең кылган хаталары үзе белән гүргә китсә, аның кылган яхшылыклары гына дөньяда кала, диләр. Кылган яманлыклары гүренә сыймыйча, дөньяда калса — эш харап, ул яманлыклар тагын да үрчем бирәчәк, кешелеккә зыян салачак. Аяз абыйдан бу дөньяда олы иҗат — яхшылык кына калды. Шөкер.

Үлем үкенечсез булмый! Йөз яшен тутырган, үз әҗәле белән вафат булганнарның үлеме дә үкенечле була. Җир җимертеп, ялкынланып, ярсып, алгысап иҗат иткәндә генә, иҗатының алтын тәхетенә менеп җиткәч кенә, 75ен дә тутырмыйча, җан бирү бигрәкләр дә аяныч шул.

Аязның мактаулы исемнәрен, алган бүләкләрен язсаң, язып, санасаң — санап бетереп булмас: Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы һәм башкалар. Зәй төбәгендә Баграж авылында Аяз Гыйләҗ музее ачылды. Татарстанның халык язучысы, Тукай бүләге иясе Аяз Гыйләҗев 2002 елда, 74 яшендә гүр иясе булды. Урыны җәннәттә булсын!

## Сөббух ага
## (1913 – 1971)

Сөббух ага Рәфикъ нахакка гаепләнеп, ватаныннан аерылып, егерме ел кырыс котыпта яшәргә мәҗбүр ителгән шәхес иде. Зәй шәһәрендә Сөббух Рәфикънын исеме онытылмаслык итеп беркетелгән. Сөббух Рәфикъ исемендә урам бар, Зәй китапханәсенә аның исеме бирелгән һәм, ниһаять, шәһәр хакимиятенең карары нигезендә Сөббух Рәфикъ исемендә төбәккүләм бүләк тәгаенләнгән. Алдынгы эшчеләргә, һәвәскәр артистларга, журналистларга, укытучыларга ел саен ике бүләк тапшырыла. Бу гамәл дә язучыбыз Сөббух аганың якты истәлеген халык аңыннан җуйдырмас өчен эшләнә. Аның танылган әсәрләреннән ике китабы бар: «Беренче яз» (1958) һәм «Тын елга буенда» (1971).

## Хәйдәр
## (1952 — 2000)

*Язучы, Татарстан язучылары берлеге әгъзасы (1983), журналист, «Иске кара урман» (1982), «Яшел алмалар» (1987) «Су кызы» (1990), «Ут теле» исемле китапларның авторы.*

Ул Дүртмунча авылында туып-үскән кеше. Без бер мәктәп тәмамладык, ул шигырь китаплары да чыгарган, ул хикәя китаплары да язган язучы гына түгел, ул радио-телевидение буенча Зәйдән чыккан менә шушындый атаклыларыбыз турында сөйләп, мәшһүрлек яулаган журналист та. Ләкин Хәйдәрнең гомере фаҗигале тәмамланды. Ул пычактан узды. Туган авылы Дүртмунчада җирләнгән. Урыны җәннәттә булсын!

## Симаш
## (1945 – 1997)

*СССРның атказанган спорт остасы (1970); Татарстанның атказанган физкультура хезмәткәре (1994); СССР чемпионы (1968-76); Олимпия уеннары чемпионы (1972).*

Федор Симашов дөньякүләм танылган якташыбыз, атаклы чаңгычы, дөнья чемпионы, Баграж егете, Түбән Биш урта мәктәбен тәмамлаган үз керәшенебез. Чыннан да, Симаш Унберенче Олимпия уеннарының Япониядәге Саппоро шәһәрендә узган ярышларында (1972) икенче урынны яулап, көмеш бүләк алган каһарман, «СССРның атказанган спорт остасы» дигән дәрәҗә яулаган якташыбыз (1970). Кызганыч ки, ул арабыздан бик иртә китте. Авыр туфрагы җиңел булсын. Атаклы якташыбыз рухына Зәй шәһәренең бер урамына, бер мәктәбенә, бер спорт коллективына Федор Симашов исеме бирелде. Аның исеменә багышлап, ел саен Зәйдә чаңгы һәм башка төр спорт ярышлары узгарыла.

Финляндиягә баргач, сөйләшеп утырганда дустым Фәйсал Самархан әйтә:

— Сезнең Советлар Союзыннан килгән бер урыс чаңгычысы Симашов финиш алдында егылды!

Мин әйтәм:

— Ул урыс түгел, татар спортчысы, без бер мәктәптә укыдык, — дим.

— Ничек? Нигә аның исеме татарча түгел? – диделәр дусларым.

Мин Симашовның керәшен татары икәнен әйттем.

— Аһ! — диде Фәйсал. — Мин аннан ерак түгел генә басып тора идем, аның татар икәнен белгән булсак, тартып торгызып, күтәреп булса да финишика чаклы илтә идек!

Симашов шул абынуыннан соң беркайчан да чаңгы эзендә егылмады. Ләкин туган ягына кайтып, яшьләргә ярдәм иткән чакта аның йөрәге тибүдән туктады.

Урының җәннәттә булсын, Федор туган!

## Дунай (1937)

*Татарстанның халык артисты (1982); Россиянең атказанган артисты (1996); Тукай исемендәге Татарстан дәүләт бүләге иясе (1998).*

Зәй төбәгендә туфрак бик тә уңдырышлы; анда шагыйрь дә, язучы да, галим-академиклар да, атаклы көрәшчеләр дә, спортчылар да, игенче, нефтьчеләр дә үсә тора, Аллага шөкер, орлыгы Бохарада түгел. Әмма, дуслар, Зәйнең бер тугае бар — Зичә буе. Шул тугайда Бишавылы мәктәбе утыра. Менә шушы мәктәпне мин университет дип атар идем. Багыгыз сез, кемнәр чыккан аннан, юк, без—шагыйрь-язучылар гына түгел, халык артисты Наил Дунай дигән тагын бер шәхесне биргән мәктәп ул.

Керәшен йолаларына хас буларак, Дунайның өч исеме бар. Керәшенчә аның исеме Микулай, урысча-рәсми исеме Николай, сәхнә исеме исә — Наил. Сабакташлары, сәхнәдәшләре арасында ул бары тик Дунай гына.

Дунай Әхмәт авылында Иван дәдәйнең ихатасында дөньяга килгән егет. Ул атасы кебек умартачы булып та киткән булыр иде, аның кулы бу эшкә ятышып тора иде. Ул бәлки рәссам булып та киткән булыр иде, бала чактан ук ул үзе әтмәлләгән буягычлар белән рәсем ясый торган иде. Сигезенче сыйныфта укыганда, тарих дәресендә ул Богдан Хмельницкийны ясап, бөтенебезне шаккатырган иде. Ул бәлки биюче, җыручы булып та киткән булыр иде, ул ата-бабасыннан ишеткән керәшен халкының борынгы җыруларын гаҗәп йомшак тавыш һәм моң белән җырлый иде. Ләкин аны театр сәнгате бөтереп үзенә алды. Дистәләрчә рольләр башкарган Дунай, дистәләрчә пьесаларны татарчага тәрҗемә иткән язучы да. Дунайның тәрҗемә теле атаклы Габдулла ага Шамукның тәрҗемәләре кебек житди, халыкчан һәм югары өслүбтә була. Яшерен-батырын түгел, Дунай тәрҗемәче-язучы буларак инде әллә кайчан Татарстан язучылар берлегенең хакыйкый әгъзасы булырга лаек шәхес һәм озакламый ул шулай булыр да, иншалла.

Түбән-Биш авылындагы урта мәктәп ул, чыннан да, кайбер университетларга тора икәнен мин Мәскәүдә укыганда ук аңлаган идем инде. Театр училищесында Киевтан, Мәскәүдән, Ленинградтан, тагын әллә нинди олы шәһәрләрдән төрле милләт студентлары җыелган иде. Безгә анда Пушкиннарны, Гогольләрне, Островскийларны өйрәтә башладылар. Башка егетләр-кызлар ябырылып имтиханга әзерләнә, «Ревизор»ны, «Үле җаннар»ны укыйлар. Чеховның хикәяләрен чәйниләр. Без бит инде боларны Бишавылы мәктәбендә чагында ук, Гатуф кызы Рина апа Садретдиновадан укып өйрәнгән идек, дибез Дунай белән. Шулай итеп, авылда алган белем белән без Мәскәүдә дәүләт имтиханнары тапшырдык.

— Сез Гогольне каян беләсез? — дип сорыйлар иде башка милләт студентлары.

— Белмәскә! Без бит урта мәктәп тәмамладык, — дибез.

— Без дә урта мәктәп тәмамладык, алайса, сезнең алтын медальләр, —диләр.

— Юк, алтын түгел, аттестатта өчледән башка билге юк, — дибез.— Сезнең?

— Аттестатта дүрт тә биш,— диләр.

Чыннан да Түбән-Биш урта мәктәбе ул университет булган икән!

Зәй якларының табигате, болыннары, урманнары, күктәге тургайлары, сабантуйлары, питраулары, нардуганнары күңелне һаман чеметә, йөрәкне һаман жирсетә...

Була шундый холыклы кешеләр: үзләре эчкерсез булса да, гаугачан, шау-шу куптара, тиз кызып, тиз бәхәскә кереп якыннарына рәхәтсезлек тудыра андыйлар. Бер караганда, шундый шау-шулы кешеләр каты холыклы сыман тоелыр. Баксаң, андыйлар шактый тотрыксыз булып чыга. Бер фикердән икенчесенә, бер эштән икенчесенә, бер хатыннан икенчесенә бик еш күчәләр.

Бар басынкы, тавышсыз, гаугасыз, сабыр кешеләр, бер баксаң, алар йомшак, сыек буынлы булып күренә, әмма чынлыкта бу кешеләр үзсүзле, башлаган эшне ташламас, хатын-гаилә белән уйнамас, хыялга гына таянып, вакытны бушка әйләндермәс, алар тормышка җайлаша белер, гаиләсен нык тотар, бай булмаса да, таза тормыш корыр, әнә шундый үҗәт холык булыр аларда.

Каһарманыбыз – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, М.Җәлил бүләге иясе Наил Дунаев нәкъ менә шундый шәхес, сабыр, ләкин үҗәт холык иясе.

Зәй төбәгенең Әхмәт авылы Зичә инеше ярына, тау итәгенә сыенып урнашкан. Кечкенә Микулай, ягъни безнең булачак артистыбыз, менә шушы авылда дөньяга килгән. Иван дәдәйне Ходасы бер нәрсәдән дә мәхрүм итмәгән: балалары, уллары, кызлары күп булды, шөкер. Һәрберсе үз тормышын үзе корырдай таза тәрбия бирде Иван дәдәй балаларына. Оста умартачы иде ул Иван дәдәй. Малы-туары мул булды. Каралты-кура таза булды, шөкер. Кечкенә Коля-Микулайны да ул, үзе кебек, күп мал асрап, күп умарта тотып, шәп йорт корып, авылда яшәр, дип өметләнә иде. Бу өметләр нигезсез түгел иде, чөнки Микулайның бу эшләргә кулы ята, тырыш, сабыр, кушкан йомышны азагына кадәр җиткезә белә торган бала булып үсте...

Юк шул, дөнья син дигәнчә генә бармый икән. Сөекле улы Микулай укырга хирыс булды. Мал-туар, бал-умарта, каралты-кура арасыннан аны сәнгать, олы сәхнә тартып алды. Иван дәдәй монысына да чәпчемәде, сабыр кабул итте ул бу вакыйганы: «Әйдә, булмаса булган икән, безнең өйдән дә бер артист чыксын айса[2]», – диде.

Чү! Җиңгиләр керәшен җырулары җырлый. Керәшен очында туй!

Нәрсәдән башланды соң әле ул сәнгатькә тартылу? Кем аны бу «эшкә» котыртты?

Җыр ярата иде Микулай. Әнисе җырлаганны, апасы, җиңгәсе, авыл хатыннары, авыл дәдәйләренең җырлаганын ул сәгатьләр, төннәр буе, мәҗлес таралганчы тыңларга да риза иде.

Эштән бушаган арада Дунай Микулай туган авылы Әхмәткә, ата-анасы йортына ашыга.

Дунай кайткач, тозлаган яшелчә, җиләк-җимеш, табагы-табагы белән ит-аш өстәлгә менеп утырды. Аннан соң – җыелды күрше-күлән, туган-тумача, агайне-ыру, карчык-җиңгиләр. Китте сөйләш, җырлаш. Җиңгәсенең искиткеч итеп җырлавын ишетеп, Дунайның тамагына әче төер тыгылды. Болай итеп бер җирдә дә, беркемнең дә җырлаганын ишеткәне юк Дунайның.

Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын...

[2] айса – «алайса»ның керәшенчә әйтелеше.

Бу жырны аның бала чакта ук ишеткәне бар. Дунайлар ыруы борын-борыннан шушы жирдә утырды. Дунай атасы белән урманда чүнниктә эшләгән чакта да урман эченнән шушы жыру ишетелә торган иде. Качкын Ычтапан шулай урманда жырлый, дип сөйлиләр иде.

Качкын Ычтапан инде күптән үлгән, ә жыр һаман яңгырый. Чабактауга Питрауга менгәч тә, урман эченнән гел шушы жыру ишетелә иде. Күрше авылга – Түбән Биш мәктәбенә йөргәндә дә Микулай колагында гелән шушы жыр чыңлый иде. Кем жырлый аны урманда, кем жырлады аны Питрау көнне? Әллә урман үзе чыгарганмы бу жыруны.

Мәжлес янә кыза. Жыруны бөтен мәжлес күтәреп ала, Дунай гына жырламый, ул жыруны тыңлап ләззәтләнә.

Жырдан соң шау-шу, сөйләшү, көлешү...

Шулкадәр сагынып кайта аларны Дунай. Әхмәт авылын, болыннарны сагынып кайта, тауларга менә. Барысын да бер көнне күреп, барысы белән дә берьюлы сөйләшеп чыга да, икенче көннәрне кая барыр жир тапмый йөри, бөтен яшьтәшләр иртә таңнан эштә, карт-коры да бала-чага бага, алар да һаман эштә. Биш-алты көн уздымы, кире калага китәсе килә башлый, артистлар янына, шау-шулы шәһәргә, театрына ашкына башлый. Яратып, сагынып, ашкынып кайта да, ашкынып калага китү турында хыяллана башлый Дунай. Гомере буе шулай булыр микәнни соң? Гомеркәйләр буе? Шәһәргә барса – авылын сагыныр, авылга кайтса – театрын сагыныр микәнни?

*Бу өлешне мин «Соңгы чабыш» хикәясенә керттем.*

Жырга колак салган сабый үзе дә жырлый башлый. Дунай да жырлый торган иде яшь чагында, йомшак, артык көчле булмаган тавышы белән ул күрше-тирә халкын әсир итә торган иде. Әйе, жыр китерде аны сәхнәгә, мотлак жыр алып килгәндер аны сәхнәгә. Мәктәптә укыганда...

Дөресрәге, сигезенчедә укыганда башланды бугай сәхнәгә, сәнгатькә тартылыш. Әле яңа гына Казанда укытучылыкка укып чыккан кыз Зәй төбәгенең Түбән Биш авылы урта мәктәбенә әдәбият укытучысы булып килгән иде. Мәрвәрия апа Жиһаншина. Әнә шушы укытучы булмаса, бәлки, Наил Дунай дигән артист та булмас иде. Кем белә? Шигырь сөйләп, дәрес аңлату – ул сәнгать дәресләре иде. Мәрвәрия апа Казанда укыганда ничек итеп татар театрына спектакльләр карарга йөрүе турында сихерле итеп сөйли торган иде. Хәтердә, хәтердә, хәтердә булмыйча ни, барысы хәтердә! «Биш бүләк» спектакленең ничек куелышы, нинди мәшһүр артистларның ул спектакльдә катнашуы турында Мәрвәрия апа сөйли; сөйләми, уйнап күрсәтә, жырларын жырлый, «Биш бүләгем, кайтсам тартынмассың, тиздән кайтам, кунак итәрсең».

Мәрвәрия апа сабыйлар йөрәгенә ялкын кабыза белә шул.

Жанлы сәнгать дәресләре булган икән ул Мәрвәрия апаның әдәбият дәресләре, театр белеме биргән икән лә Мәрвәрия апа укучыларына, профессиональ театрлар гына куя ала торган пьесаларны уйнаткан икән лә Мәрвәрия апа Дунайларга. Барысы да, барысы да Дунайны сихерләгән икән, аны сәхнәгә котырткан икән ләбаса. Хәер, бер Дунайны гынамы икән? Мәшһүр шагыйрь, Тукай бүләге иясе Мөдәррис Әгъләмне дә, артист-режиссер, драматург Батулланы да, язучы Хәйдәр Гайнетдинне дә, язучы Рәүф Гыйззәтуллинны да, тагын башка бик күпләрне дә сихерләгән икән лә Мәрвәрия апа.

Иван дәдәйнең каралты-курасында тәпи баскан, мәктәптә канат ярган Микулай Дунай, аттестат алгач та, 1956 елда турыдан-туры Мәскәүнең

Югары театр мәктәбенә укырга китә. Бер мәктәптән, бер чыгарылыштан өч егет – Хәмзә Арсланов, Батулла һәм Микулай Дунай театр мәктәбенә кереп тә кайталар.

Язмышлар төрле, Хәмзә Арсланов мәдәният хезмәткәрләренең өлкә комитетында хезмәт итте, Батулла да, театрны калдырып, язучылык эшенә керешә, өчесеннән берсе артист булып китә.

Авыл аны тудырды, тәрбия итте дә шәһәргә озатты.

Ләкин авыл сагындыра, укытучылар сагындыра, сыйныфташлар сагындыра.

Кайтып киткәләү генә сагынуны баса алмый. Гәүдән – шәһәрдә, күңелен-җирсүен – авылда. Әнә шул ике арадагы сагыну Дунайның йөзенә кайчакларда сагыш шәүләсе сирпи. Дунай театр кешесе, ул, бик теләсә дә, авылга кайтып тора алмас иде. Театрсыз ул үзенең гомерен күз алдына да китерә алмый. Театр бик тә сихерле җир бит ул. Бер эләктердеме – мәңге дә ычкындырмый.

Ләкин шулай театр белән авылы арасында җирсеп яшәсә дә, Наил Дунай бәхетле язмышлы кеше. Чөнки ул үҗәт рәвештә шушы язмышны үзе эшләде, үзе корды. Мәктәп сәхнәсе, Мәскәү театр мәктәбе, аннары – татар халкының иң бөек сәнгать йорты, Камал театры сәхнәсе. Вәссәлам!

Илле ел бер үк эштә. Театрның хәлкәйләре мөшкел вакытта, айлар буе булыр-булмас хезмәт хакын ала алмыйча интеккән чакларда да, башкалар кебек, озын акча эзләп, башка җайлырак һөнәр эзләп, Дунай театрны ташламады. Һәм дөрес эшләде. Әнә шул үҗәтлеге аны шәхес итте, бүгенге Дунай итте.

Дунайның Казандагы фатирына керәбез. Дунайның хатыны Татьяна оныклары белән əвәрә килә.

Алар беренче мәртәбә Чаллы төбәгенең Борды авылы Сабан туенда очраштылар. Татый да (Татьяна Григорьевна Батаеваның керәшенчә исеме) – Дунайны бик ошатып калды. Ошатмаслыкмыни: буй-сынлы, мәһабәт җегет. Дунай да Татыйны ошатты. Ошатмаслыкмыни: кыз гүзәлләр гүзәле, укымышлы. Менә шушы күз карашлары аларны гомерлеккә яр итте. Мәскәүдә Дунай – театр училищесында, Таня – китапханә институтында укыганда алар өйләнеште. Батулла аларны кодалады, Туфан Миңнуллин кияү егете булды. Хәзер инде профессор, сәнгать академиясенең проректоры Татьяна Григорьевна белән халык артисты Наил Дунаев оныклар тәрбияли. Бәхетле гаилә дими, ни диярсең!

– Уйнаган рольләреңнең иң якыны? – дип сорыйм Дунайдан.

– Барысы да якын, дисәм, артык традицион җавап булыр... Фигаро миңа бик кадерле роль. Ни генә әйтсәң дә, Фигаро минем иҗат биографиямдә зур урын тота... «Өч аршын җир»дәге каһарман, Шамил Усманов...

– Тәнкыйтькә мөнәсәбәтең ничек?

– Мактасалар – тәнкыйть әйбәт, хурласалар – яман!

Дунайның бу ярымшаяру белән әйтелгән сүзләрен болайрак шәрехләргә кирәктер: олы исемнәр яулаган Наил Дунаев иҗатына театр тәнкыйте игътибарлы иде, дип булмас шикелле. Аның иҗаты турында әтрафлы, тирән, кин, төпле монография әлегә язылмаган.

– Артист булып китмәгән булсаң, син кем булыр идең?

– Мин елга капитаны булырга хыяллана идем...

– Һәм булдың да... сәхнәдә син капитан да булдың...

– Әйе, «Хуш, Назлыгөл!» спектаклендә мин авыр язмышлы капитанны бик сөеп-яратып уйнаган идем. Ул роль дә – минем иң кадерле бер иҗат җимешем.

– Остазларың?

– Остазлардан мин, шөкер, ундым... Сабый чактагы укытучыларым

Мәрвәрия апа Жиһаншина, Василий Зингаровлардан башлап, Мәскәү профессоры Михаил Гладков, Хәлил ага Әбҗәлилов, Галимә апа Ибраһимовалар, Марсель Сәлимҗановлар минем иҗат мәктәбем була килде.

Мәктәп дигәннән, Наил Дунай хәзер инде үзе остаз: сәнгать академиясендә үзе шәкертләр тәрбияли.

Дунай үзе уйнаган, үзе уйнамаган спектакльләрнең игъланнарын җентекләп җыеп килә икән. Йөзләгән белдерүләрне, сәнгать музееп тутырырлык хәзинәне туплаган Дунай. Шул игъланнар арасында без «Наил Дунаев тәрҗемәсе» дигән гыйбарәне еш очратабыз. Наил Дунаев тәрҗемәсендә төрле милләт драматургларының әсәрләре татар сәхнәсендә уйнала килә. Дөресен генә әйтсәк, аның бу хезмәте Татарстан Язучылар берлеге игътибарына лаек. Һәм ул күптән инде бу эше белән Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булырдай шәхес.

Дунай һәр эшендә, һәр шөгылендә дә үҗәт яшәде.

Ул балыкчы да бит әле. Йә, нәрсә калган инде әти кешегә, бабай кешегә, зәмһәрир суыкларда, боз ватып, бәке тишеп, кармак салып, сәгатьләр буе шыртлака чиерткәнен көтеп утыру? Җәйге эссе чилләдә көннәр буе калкавычка багып утыруның ни рәхәте бар икән соң? Юкса, Дунай үзе балык ашамый, дусларына өләшә эләккән балыкларын.

Ул – ата «болельщик», ягъни җанатар да. Хоккей белән футбол ярышы буласы көнне Дунай үзенә урын табалмыйча йөри. Сәхнәдә эше булмаса, һичшиксез, ул стадионга чабачак яки телевизор экранына ябышып утырачак. Барыбер түгелмени соң – кем капкасына туп кергән, «Ак Барс»ныкынамы, «Торпедо»ныкынамы. Юк, Дунай өчен барыбер түгел. Ул үз командасы өчен җан ата.

Дунай, акрын гына атлап, театрга бара... Йөзләрчә рольләр инде уйналган: Тукай, Ромео, Фигаро, Усманов; уннарча рольләр уйнала; тагын ничәме-ничә рольләр әле уйналыр!..

Әйе, 75 яшь тә килеп җиткән икән шул. 50 ел сәхнәдә уйналган икән шул! Озын булсын сәхнә гомере!

Иван дәдәйнең ыруы-нәселе таза буынлы, озак яшәр, иншалла. Артист пенсиягә китми ич ул, йөрәк түзми, сәхнә тарта. Еллар узар, Дунай әле сәхнәдә булыр. Тагын еллар узар. Дунай сәхнәдә булыр... Мондый ихлас, мондый үҗәт кеше сәнгатьтән мәңге китмәс!

Дунай турында телевизион фильм төшерелде, ул »Үтә җәйләр, көтә зәйләр» дип атала иде. 1997. Режиссеры Әхтәм Зарипов.

## Мөгаллимнәр

Безнең Бишавылы мәктәбендә укытучылар үзгә холыклары белән гомергә истә калды. Мәктәптән чыгып киткәнгә кырык өч ел узган (бу китапны басмага әзерләгәндә 57 ел узган иде инде.), алар теп-тере килеш күз алдында басып тора. Йә алар усаллыклары белән, йә юашлыклары белән, йә булмаса, үткен телләре белән, йә гүзәллекләре белән хәтердә уелган.

Бик сабыр, юаш, күрәсең, ул иске зыялы нәселдән булгандыр, Билал Рәфикъ углы Бикташ абзый безне бишенче сыйныфта зоологиядән укытты. Ул беркайчан кычкырмый, сүгенми, балаларга тырнак белән дә чиртми. Нишләсәләр дә түзә иде, бичара. Без — авыл мокытлары, таяк, йодрыкны гына аңлый идек шул. Билал абзый безнең кем икәнебезне бер күрүдә аңлагандыр. Без аның йомшаклыгыннан файдалана идек, шаярабыз, төртешәбез, парта өстеннән чабабыз. Башыбызны тилегә салып, әдәп

кысаларыннан тыш сораулар бирәбез. Аны кыен хәлгә калдырып, тәмләззәт алабыз.

— Котыпта нинди җәнлекләр яши, Батуллин?— диде ул минем артыма борылып кызлардан көнбагыш талавыма түзмичә.

Ул көнне безнең класс миче тыгылган иде, утын янмый, пыскый, дәресханәгә төтен чыга. Шулчак ишектән миччеләр, ике озын керәшен дәдәе килеп керде, мин тоттым да:

— Котыпта жирафлар яши!— дидем.

Бу минем тарафтан хаинлек иде. Рөхсәт ителмәгән алым иде. Олы яшьтәге укытучыдан көлү иде. Класс тыела алмыйча көлә. Мин аягүрә баскан килеш җинелгән укытучының йөзенә багам. Аның күзләреннән рәнҗү, көчсезлегеннән гаҗизлек галәмәтләре карап тора. Миччеләр, бүлтәеп торган кирпечне чүкеч белән ваталар. Шулчак Билал абый, миңа гына ишетелерлек итеп:

— Ш-шам-макай!— диде.

Бу сүз бик тәэсирле әйтелде. Тәнәфескә чыккач, сыйныфташларымның чөя-чөя мине мактавы да, котлавы да сөендермәде, мин бәхетле түгел идем. Билал абзыйның әче рәнҗеш белән әйткән сүзе мине изгән иде.

— Шамакай!

Дәрестә Билал абый безгә куяннар турында сөйли.

— Сорауларыгыз бармы, балалар? — диде укытучы.

— Бар! —диде Ашыттан төшеп укый торган Риф Идиятуллин.

— Нинди сорау? —диде Билал абый.

— Абый, аталану-аталану дип әйттегез, куяннар ничек аталана? — диде Риф.

Укучылар тыннарын кысты, ничек җавап бирер укытучы?

Билал абый күзлеге өстеннән Рифка карап:

— Идиотуллин! Атаңа бер ана, бер ата куян алдыр да, шуларның ничек аталанганын карап тор! — дип бүлмәдән чыгып китте.

Рәфикъ углы Билал Бикташ уку елы бетүгә үк безнең мәктәптән китте.

Шуннан соң зоологиядән Александра Александровна Глухова керә башлады. Бервакыт Александра Александровна дәрестә, мин шаярып утырганны күреп:

— Батуллин, сөйлә, сөйрәлүчеләр төркеменә ниләр керә?— дип кычкырды.

Мин, аны-моны уйлап тормастан:

— Сабан!— дидем.

Укучылар пырхылдый, укытучының җене чыккан, шадралары да кызарган.

— Ул нинди сабан тагын?— дип сорый ул кырыс тавыш белән.

— Трактор артыннан сөйрәлеп бара торган сабан инде! Сөйрәлүчеләр төркеменә керә! — дигән идем, укучылар тыелып тора алмады, гадәттән тыш шартлау белән көләргә тотындылар.

Александра Александровна мине, сырт якамнан тотып:

— Абындырып чыгарасы нәрсә! — дип класстан өерттереп куып чыгарды.

Александра Глухова ул үзе шадра булса да чибәр хатын иде. Мин аңа бераз гына гашыйк та идем шикелле. Гашыйк кеше тик утыра алмый инде.

Тугызынчы сыйныфта укыганда урыс теле-әдәбияты укытучысы Рина Гәтүф кызы Садретдиновага гашыйк булдым. Шул гашыйклыгым миңа чытлыкланырга куша, тик утыртмый, Рина апаның дикъкатен җәлеп итәргә боера.

— Батуллин, син анда шаярып утырасын, үзен Гогольнен «Ревизор» дигән әсәрен кем язганын да белмисендер әле, — диде Рина апа.

Мин әллә белмичә, әллә ул мине шаяртканга, мин дә аны шаяртыйм дипме, хәтерләмим инде:

— Плюшкин!— дидем.

Бу юлы да мин дәрестән мәхрүм калдым.

Мин, ихтимал, химик та булып киткән булыр идем, бу эшкә Семен Павлович Семенов комачаулады. Яшерен-батырын түгел, ир укытучыларыбыз көмешкә белән дус иде инде. Артыгын кыланмасалар да, сизелә, күренә торган иде. Без күрмәгәнне әти-әниләр күрә бит. Химия дәресендә мин:

— Семен Павлович, көмешкәнен формуласын язып күрсәтегез әле,— дигән идем, класс бер авыздан көлеп җибәрде, мин тагын класстан колак кактым.

Әле яна гына армия хезмәтеннән кайткан физкультура укытучысы Михаил Ильич Петров безнен сөекле укытучыбыз Рина апа артыннан йөри башлады. Бу хәбәрне төрлебез төрлечә кабул итте, мина аеруча хәтәр тәэсир итте бу хәбәр, чөнки мин Рина апаны сөям. Ярый, боларнын эше пешә, ахрысы, Рина апа да Михаил Ильичка каршы түгел бугай. Михаил Ильич яшь, чибәр, офицер, урысчасы яхшы. Нигә? Килешсәләр, мин үлмәм әле дип торганда, Рина апабыз Михаил дәдәбезне ташлап, Дүрт Мунчага вакытлы ялга кайткан озын буйлы бер офицерга кияүгә чыккан, дигән хәбәр классыбызны екты да салды. Без барыбыз да Миша дәдәй өчен җанатабыз, борчылабыз. Ул вакытта шундый гадәт бар иде, яшь офицерлар ялга кайткан арада кемгә дә булса өйләнеп китәләр иде. Аларнын сөйләнеп торырга вакыты юк, өйләнергә кирәк. Чит илдә хезмәт итәчәк офицерлар, һичшиксез, гаиләле булырга тиеш икән. Мин Михаил Ильичтан да каты кайгырганмындыр, минем дә сөекле укытучымны Польшага алып китәләр бит. Шул көнне Михаил Ильич безгә чангылар өләшеп, тауда шуарга кушты. Үзе бик борчулы иде, тау башында ап-ак чүчинкәсе белән бер кирәксезгә кар йомарлагы тибә-тибә йөренә, без тау башына менеп, янә аска шуып төшәбез. Михаил Ильич урысча җыр шыншый:

И волны бьются о борт корабля...

Минем Исхак абыйдан да шушы җырны ишеткәнем булгалады, ул дингезче иде, ләкин бу җырнын татарча мәгънәсен анларлык урысчам юк. Шул турыда уйлый-уйлый мин тау башыннан аска төшеп киттем, сикертмәдә егылып, бер чангымны сындырдым. Мәктәп чангысын сындырсанмы? Бетте баш! Михаил Ильич ашый башымны! Чыннан да, мин сынык чангымны күтәреп, тау түбәсенә менгәндә Михаил Ильич җыландай ысылдап, юка иреннәннән сытып мина:

— С-син абормот! Түләрсен чангыны икеләтә!— диде.

«Үсмер генә булсам да анлыйм мин сине, Миша дәдәй, сина бүген бик авыр, син мина түгел, теге, Рина апаны алып киткән Дүрт Мунча абормотына булган ачуынны мина түгәсен, шуна күрә, икеләтә чангы түләтсән дә, сина үпкәләмәм», дим эчтән генә.

Шул көнне төнлә Дүрт Мунча авылына барып, Михаил Ильич Ринасын урлап алып кайткан. Бөтен класс белән шатланыштык. Шуннан бирле Рина апа белән Михаил дәдәйнен аерылганнары булмады. Ин сөенгәне мин булганмындыр инде, әби әйткәндәй, машалла, Миша дәдәй, җегетлегенне күрсәттен, дидем эчтән генә. Түләтмәде, чангы бәясен сорамады да Михаил

Ильич, әмма ул тау башында җырлаган җырны мин һаман аңлап бетерми идем әле.

И волны бьются о борт корабля...

Урыс теле дәресендә мин:
—Рина Гатуповна, нәрсә ул «аборт»? дидем.
Укытучым тотлыгып калды, аннан соң мина туры карап:
— Батуллин, здесь не Елабужская фельдшеро-акушерская школа! — дип кычкырып җибәрде, малай! Гүзәл Рина апа урынында Кабаниха басып торамыни.
Ул дәресне мин тагын мәктәпнең салкын өйалдында узгардым.
1969 елда Гөргөри, Рөстәм Мингалим, мин авылдан авылга йөрергә, игенчеләр, укытучылар белән очрашырга чыгып киттек. Йөри торгач, безнең якка, Бишавылына да барып чыктык, Рина апа белән Михаил Ильичка кунакка кердек.
— Һо-о, нинди затлы егетләр килгән! — дип каршы алды Михаил Ильич. Рина апа мич каршында нидер маташтыра башлады.
Михаил Ильичның чырае аксыл иде, ул ике кулы белән эчен тотып йөри, утырганда да бөгелеп төшә, эчен тота.
— Ашказанында язва аның, кровоточащая рана! — диде Рина апа.
— Кая, берәр нәрсәң бармы соң? — диде хуҗа.
Хуҗабикә өстәлгә бер шешә борыч аракысы чыгарып утыртты.
Шешә өч кешегә тигез итеп бүленде, Михаил Ильич стаканны каплап та куйды, тагын бөгелеп төште. Ул озак ыңгырашып утырды, соңыннан елмаеп куйды:
— Җибәрде, шайтан! — дип безне кыстый башлады.
Озак кына мәҗлес корып утырганнан соң без хушлаштык.
Юлда кайтканда Гөргөри әйтте:
— Без бу кешене соңгы тапкыр күрәбез, кан косты бит, —диде.
Кырык өч ел вакыт узып киткән, Михаил Ильич әле һаман сау-сәламәт, язвасы да беткән, чырае да матур күренә, сиксәннең өстендә.

### Бәчели дәдәй
### (1915— 2005)

Хаклы булган безнең укытучыбыз Бәчели дәдәй Зингаров: аның өчлесе башка мәктәпләрнең бишлесе булган икән.
Зәй төбәгенең Туңылжа дигән керәшен авылында туып-үскән математика укытучысы Бишавылы мәктәбендә озак еллар укыткан Василий Андреевич Зингаровның 1954 елда әйткән сүзе искә төшә:
— Утыр, Батуллин, сиңа өчле, майлы өчле! Ләкин минем өчлем башка мәктәпләрнең бишлесенә тора, шуны онытма.
Хаклы булган сөекле остазыбыз.
Бу кеше турында без матбугатта язып, радио-телевидениедән дә сөйләдек. Мөдәррис тә, Дунай да, башка мәктәптәшләребез дә Василий Андреевич Зингаров турында телдән-телгә күчереп, мәзәкләр, дәрестә булган кызык вакыйгалар турында сөйлибез һәм әле һаман сөйләп туймыйбыз. Аны күреп белмәгәннәр дә очрашкан чакларда:
— Җәле, математика укытучыгыз, теге абзый турында сөйләгез әле, — диләр.
Василий Андреевич легендар укытучы.
Математик булып китмәсәк тә, без Зингаров дәдәйнең дәресләрен

әдәбият, халык авыз иҗаты буенча дәресләр итеп истә калдырганбыз. Математика, физика, геометрия, тригонометрия, астрономиянең катлаулы мәсьәләләрен ул авыл балалары аңларлык итеп, әкият, мәзәк аша аңлатырга тырыша иде. Математика дәресләре бик эчпошыргыч, күңелсез була, дип әйтүчеләргә аптырыйм мин, Зингаров абыйның дәресләре кызык эстрада концертына әверелә торган иде. Кагыйдәләрне ул мәшһүр татар көйләренә җырлап бирә.

Кояш ничек чыга? Астрономиядән бүген «Кояш» темасы. Бәчели дәдәй ишектән ашыгып килеп керә. Кулындагы сыйныф журналын, китапларын өстәлгә ташлап:

— Күпер төбендә торучы Кәҗә Микулаен беләсезме? — дип сорый. Беләбез әлбәттә. — Менә шул Кәҗә Микулаенын атасы Көҗмәнең бабасы элек солдат кызмәтендә жегерме биш жыл черегән. Кызмәтен тутырып кайткач, монын янына каль белешергә киләләр. Карале, Көҗмә дәдә, кайда кызмәт иттең сун? дип сорыйлар моннан. Жырак Көнчыгышта, Кояш чыга торган жирдә, ди Көҗмә. Сын, сез анда нишләдегез? дигәч, салдат Көҗмә: бер взвод салдат белән имән бастырык астына таш кыстырып, жегерме биш жыл буе көн саен Кояшны һай-һулап чыгарып тора идек, дигән... Кара халык ышанган инде, бичара. Кояш, әлбәттә, Көҗмә бастырыгы белән түгел, гравитацион көчләр аркасында көн саен чыгып тора.

Шулай итеп, Кояш темасы башланып китә.

Ышкылу көче. Физика дәресе. Бәчели дәдәй гадәтенчә ашыгып килеп керде дә, иң артта утыручы Әлфриткә туры карап:

— Биктебаеп!— диде.

Югары Пәнәчедән килеп укучы Әлфрит Биктебаев ялкау гына аягына калыкты.

— Биктебаеп, син әле яңа гына баскыч төбендә егылдын, — диде укытучы.

— Ие, абый, егылдым шул, — ди жегет.

— Ни өчен син егылдың, Биктебаеп?

— Таеп егылдым, абый, анда бозлавык бит.

— Тайганыңны да, бозлавык икәнен дә бөтен кеше белә. Ә менә син укымышлы кеше буларак, фән теле белән әйт, син ни өчен егылдың? Ә?

— Сың, абый, тайгак бит инде анда...

— Ышкылу көче аз булганга син тайдың, Биктебаеп. Бозлавыкта ышкылу көче аз була, шуңа күрә, синең олтаның таеп китә. Утыр, Биктебаеп... Гөрпинә жиңгән шунда көл яки ком сипкән булса, син таймаган булыр идең. Чөнки, ком яки көл нишли, Биктебаеп?

Биктебаев тагын калка.

— Ком сипкәч аягасты нишли?

— Аягастында ышкылу көче арта...

— Дөрес, Биктебаеп, утыр.

Менә шушы дәресне син тыңламый утырып кара. Истә калдырмый кара.

Василий Андреевич сөйләгәннәрдән:

— Урыс бояры Матюшка (Матвей) Коровин Калмык жирләрен биләп тора. Анын уллары: Тонгол, Иван, Борис, Федор исемле булалар. Тунылжа исемле керәшен авылы 1690 елда барлыкка килә. Беренче кабер Федорныкы, ул 1692 елда үлгән. Тоңгол 1718 елда үлгән. 1699 елда ачлык була. Эссе жәйдә 40-45 дәрәжә кызу була. Мур кырылышы башлана, маллар кырыла, халык үлә. 1698 елда карсыз суык. Урман өши, агачлар корый, 1699 елда урманны корт баса. Яфракларны ашап жиргә коела, жирдәге үләнне ашый.

1918 елның 13 үктәберендә ВЦИК уполномоченные Иннокентий

Серафимович Кожевников җитәкчелегендәге отряд Түбән Биш, Шыкмай Борды, Суыксу, Сидоровкадан Минзәләгә уза. 1919 елның 22 мартында Минзәләне Колчак ала. Аннан Чаллыны кулга төшерә. 1919 елның 20 май көнне Минзәлә, Зәй азат ителә. 1921 елда ачлык башлана, халык күпләп кырыла.

Туңылҗада урыслар да күп була, ләкин алар татарлашып-керәшеннәшеп бетә.

## Зингаров ысулы

Без, сугыштан соңгы үсмерләрнең өйдә дәрес хәзерләргә вакыты булмый иде. Каралты-кура арасында да, колхоз эшләрендә дә әти-әниләргә булышабыз, урманга утынга, печәнгә барабыз. Утын яру, бала карау кебек эшләрнең барысы да үсмерләр җилкәсенә иде. Кая анда Кояш турында, ышкылу көче турында китап укып утыру. Бар алган белемебез дәресханәдә, укытучы сөйләгәннән булды. Аңлата алган укытучының дәресе шундук үзләштерелә, талантсыз, формаль укытучының дәресе укучының башына керми кала.

Василий Андреевич Зингаров сугышка кадәр Нәкый Исәнбәт белән бергә эшләп алган кеше. Нәкый ага Исәнбәт тә аны хәтерли иде:

— Әйе, 1938 елда Әтнә урта мәктәбендә без бергә эшләдек. Ул физика, математика, астрономия укытты. Мин аны «Зәңгәров» дип йөртә идем. Хәтерлим, һо-о, ул зәңгәр күзле керәшен җегете бик тере зиһенле кеше иде. Исәнмени ул? Утыз җиделәрдән, сугышлардан исән кайта алганмыни ул? Синең укытучыңмыни ул? Һо-о, мин бик шат аның шундый җегетләр тәрбияләвенә, сәлам әйт миннән...

Василий Андреевич Исәнбәт белән булган вакытлары турында «Яшьлектә очрашулар» исемле мәкалә дә язып чыкты. «Шәһри Чаллы», 1996, 12 апрель саны.

Тумыштан үткен телле, зиһенле Бәчелинең Исәнбәт белән аралашуы аның талантын тагын да арттыргандыр, мөгаен. Бәчели дәдә чын мәгънәсендә фольклорчы, җор телле, усал телле остаз була белде. Кырыс булса да, ул баланың рухын аңлый торган миһербанлы шәхес була белде. Өйдә дәрес хәзерләргә мөмкинлегебез булмавын да, бүген төнлә сигез чакрымнан чи утын сөйрәп кайтканны да ул белеп тора бит, ярым ач, ярым ялангач, салкын тиеп тамагы шешкән булса да дәрескә килгән бу бичара баланы ул бастырып сүксенме, монда, дәрестә алып калсын, дип, Зингаров абый бар көчен, бар булдыклыгын җигеп, дәрес аңлатырга тырыша, педагогикада җыр-бию ысуллары белән математика укыту каралганмыдыр, юкмыдыр, миңа нәмәгълүм, әмма Зингаров ысулы иң кулай ысул булгандыр, дим.

Озын тәнәфестә гармун белән җырлы-биюле уеннар уйный торган идек. Үзенә күрә бу тән язу да, сәләтләләр ярышы да иде. Зичәбашның Виктор Петров иң яхшы биюче санала иде. Талантлы егет иде Виктор, бик тә оешкан, культуралы, пөхтә кеше иде, кайда ул, нигә күренми? Шундый талантлы кеше тормышның кырыс борылмаларында югалып калдымы?

Тәнәфестә уйнаганнарыбызны Зингаров абый күз кырые белән генә күзәтә. Дәрестә шул күзәтүләрен файдалана торган иде. Әйтик, берәребез элементар математика формулаларын белмичә торса, ул:

— Ә үзең Аллария-ләрияне ничек матур җырлыйсың, —дип мактый, аның мактавы сүгүгә әверелә, янәсе, матур биисең, матур җырлыйсың, дәресеңне белмисең, диган сүз иде ул.

Шуннан соң Зингаров формуланы «Аллария-ләрия» көенә үзе җырлап бирә: җәя ачыла, «а» плюс «б» җәя ябыла, ике квадрат тигез була «а» квадрат плюс ике «а» «б», плюс «б» квадрат...

Концертларның бер кырда торсын, җырның кушымталары вакытында остазыбыз, кара такта тирәли биеп тә китә торган иде.

Чичиков белән геометрия. Урыс әдәбияты буенча әле яна гына Рина апа безгә Чичиков белән Коробочка турында сөйләп дәрес тәмамлаган. Урыс теленнән сон ук геометрия дәресе. Зингаров абый әсбапларын өстәлгә ташлап, Гогольне яттан сөйли башлый.

И какой же русский не любит быстрой езды...

Нәфис сүз остасы Василий Андреевич Зингаров Гогольне татарча сөйләүгә күчә:

Әй, син, каз, дип кычкыра Чичиков үзенең кучере Ычтапанга...

— Чичиков үле жаннар сорарга «Н» губернасына Коробочка янына бара, кучере Ычтапан атларны куа. Янгырлы көн була бу. Арткы тәгәрмәчкә ябышкан балчык тәгәрмәч кысасыннан атыла-китә, атыла-китә, Чичиковның суртюк якасына бара-куна, бара-куна. Биктебаеп, менә син шул балчыкларның тәгәрмәч кигиләренә туксан градус белән атылып китеп, Чичиковның якасына барып сыланганын беләсенме?

— Юк, абый, белмим,— ди Биктебаев.

— Белмәсән, хәзер белерсен...

Геометриядән «Орынма» темасы башлана. Баксан, тәгәрмәчнен кысасы ул — геометрик әйләнә икән, кигиләре шул әйләнәнең радиуслары икән, ә геометрия законы буенча һәр радиус, орынмага туры почмак хасил итеп төшә икән. Балчык исә әнә шул орынма буенча очып китә икән.

Контроль эш вакытында Зингаров абый бик тә кырыс була иде. Күчерттермәс өчен ул, кулына озын туры сызгыч алып, урындыкны калку жиргә куеп, хәлфә-казый шәкертләрен күзәткәндәй күзәтә иде. Әмма аттестатка дәүләт имтиханнары биргән чакта ул математикадан зәгыйфьрәкләргә комиссиягә сиздермичән генә ярдәм итеп йөри иде.

Кырыс, әмма гадел-миһербанлы остазыбыз Василий Андреевич Зингаров гомерем буе мина үрнәк булды. Мин дә озак еллар шәкертләр тәрбияләдем. Һәм Бәчели дәдәйгә охшарга тырыштым, кырыс, әмма гадел булырга омтылдым.

Табигать үзенекен итте, Зингаров абый пенсиягә чыккач, каләмгә тотынды. Хатирәләр һәм әдәби әсәрләр яза башлады. Анын әсәрләре күпләп басылды, китаплары чыкты. Зингаров абый да язучы булды.

Безнең мәктәпне тәмамлаган укучылар физматка барып керә тордылар. Безнең сыйныфтан гына физмат, техник ВУЗларга кереп укыганнар байтак. Алар математиканың шагыйрьләре иде. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең абыйсы, минем сыйныфташым Мәүжетдин Әгъләметдин математиканың шагыйре, Рәшит Ногманов, Фәйзелхак Закиров, Гамир Мөбарәкжановлар, Аудаким Фирсов, Махиян Расихы һәм тагын башка бик күпләр техника, физмат өлкәсенә кереп чумдылар. Бертуган Заһир, Ирек Исрафиловлар КАИ тәмамлады. Аудаким физмат бетереп, шул ук мәктәптә Зингаров традицияләрен дәвам итә, балалар тәрбияли, математиклар әзерли. Гамир исә Казанның иң мәшһүр математикларыннан берсе, математика фәне буенча олы галим булды. Гамир да язучы, ул «Татарча математика терминнары» дигән гажәеп кыйммәтле китап авторы. Гыйльфанов Мәсгут исә механизатор буларак, «Хезмәт даны орден»нары белән күкрәген тутырды. Бишавылы егете Михаил Аверьянов физмат бетереп, бераз укытучы булып эшләгәч, «юридическийны» тәмамлап, прокурор булып эшли, классик әдәбият әсәрләрен татарчага тәржемә итә.

## Гурий дәдәй (1926–1998)

*Язучы, Татарстанның атказанган культура хезмәткәре (1996; «Алгы сызыкта»(1960); «Йолдызлар белән янәшә» (1970); «Афәт» (1991) исемле китапларның авторы.*

*Керәшен аерым милләт түгел. Бар керәшен халкы, мишәр халкы, башкорт халкы, бар типтәр халкы, нугай халкы. Шуларның барысын да үз эченә алган бар бер Татар милләте.*

Гурий Тавлин.

Зәй тәбәгендә туып-үскән шушы олы шәхес турында әйтми калсам, гөнаһысын кая куярмын! Баграж авылында туган Гурий Тавлин катлаулы гомер кичерде, фаҗигага бай булды мәрхүмнең житмеш еллык гомере. Озын буйлы, мәһабәт кеше, чибәр чырайлы, салмак холыклы, матур кеше иде мәрхүм. Утны-суны кичеп, сугышта озак еллар йөреп, орденнар тагып кайткан бәхетле жегет иде ул. Ләкин ачык сугышта дошманнарның кайда икәнен белгән Гурий дәдәй сугыштан соңгы тыныч вакытта дошманының кайда икәнен белми калды. Совет ватанына тугры икәнен каны белән, батырлыгы белән сугыш кырларында исбатлаган Гурий дәдәне астыртын жылан чакты, ул һич гаебе булмаган килеш, үзе саклап калган Совет иленең рәхимсез зинданына кертеп ябылды. Гурий үзенә ташламалар ясауларын теләнеп йөрмәде, исемнәр сорамады, ярдәм сорап, түрәләр янында бөтерелмәде, юкса бит, ул керәшен халкының гына түгел, бөтен татар милләтенең олы язучысы иде. Аның репрессия заманы энциклопедиясенә торырлык соңгы «Афәт» романы үзе генә дә ни тора?

Шөкер, Зәй хакимиятенең теләге белән Гурий Тавлинның исемен мәңгеләштерү йөзеннән Зәй шәһәренең бер урамына Гурий Тавлин исеме бирелде. Аның исемендә мәктәп тә булачак.

Авыр туфрагың жинел булсын, Гурий дәдәй!

## Соңгы әңгәмә

И гомер, и фани дөнья!.. Барысы да тәкъдирдә язылганча килеп чыга: жиһанга кайчан туачагыңны да, мәңгелек йортына кайчан китеп барасыңны да алдан белеп булмый. Гаять катлаулы гомер юлы үтсә дә, яшәү дәрте белән, ижат белән канатланып яшәгән Гурий дәдәй Тавлин үзенең яраткан гәзите «Мәдәни жомга» редакциясенә әле күптән түгел генә килеп киткән иде, югыйсә. Бәхилләшеп китүе булган икән, бахырның!.. Соңгы мәртәбә әңгәмә корып китүе булган икән. Нишлисең, теге дөньяда да яхшы кешеләр кирәк, ахры...

Искиткеч самими, саф күңелле кеше иде ул Гурий дәдәй, хөсетсез, мәкерсез шәхес, ватан сугышында фронтларны аркылыга-буйга йөреп, орденнар тагып, исән-сау кайткан баһадир иде ул. Совет зинданнарын да аркылыга-буйга йөреп, исән-сау кайткан каһарман иде ул. Озын, мәһабәт буйлы, нурлы чырайлы ир-егет иде ул Гурий дәдәй. Хатын-кызлар аңа караса, дөньясын оныта иде. Гүзәлләр арасында уңыш казана алмаганнар аннан кара көнләшү белән көнләшә, бигрәк тә көнләшүченең кызы мәһабәт ир ягына күчсә, ул көнләшү чиргә, кара үчкә әверелә.

Аны авылдашы, дусты сатты. Нахак яла якты. Ул гомере буе шул авыр

йөкне, нахак бәлане күтәреп йөрергә һәм үч алу йөге асып яшәргә мәҗбүр ителгән бичара иде. Әйттем мин ана:

— Гурий дәдәй, — дидем. – Син котыл ул авыр йөктән. Ир-егет булып кал! Син ул кешене яки бөтен голамә алдынга рәсми рәвештә фаш ит, фаш ит тә, кабат ул турыда уйлама, иркенәеп калырсың. Яки син аны кичер, бернинди дә үч алма. Аны үз вөҗданы белән бергә-бер калдыр. Әнә, Хәсән абый Туфан үзен чаккан Шәйхи Маннурга сүз әйтмәде, үч алмады. Алар мәҗлестәш булып йөри.

Гурий дәдәй тәки дошманыннан үч алалмады, аны кичерә дә алмады. Шулай авыр йөк белән китеп барды. Мин аның белән җәһәт әңгәмә корган идем, бер-ике көннән аның үлем хәбәрен ишеттем. Менә ул әңгәмә.

— Гурий дәдәй, син инде җитмештән уздың, язучы кеше бу яшьтә нишли?

— Узган юлына йомгак ясый.

— Йомгак ниндиерәк соң?

— Канәгатьләнү юк.

— «Афәт» романың сиңа дан китерде...

— Басылмаган тагын биш романым сыкрап ята. Мин үзем теләгәнчә иҗат итә алмадым.

— Ни сәбәпле?

— «Халык дошманы» булганым өчен. Төрмәдә узды яшь гомер. Иреккә чыккач та, шул нахак тамга өстемнән төшмәде, эшкә алмадылар...

— Җитмештән узган язучы алга таба ни кыласын уйлыймы?

— Аңа вакыт калмады.

— Вакытны Гурий дәдәйгә Аллаһ Тәгалә күп бирсә?

— Җигелеп эшләр идем. Керәшеннәр турында олы әсәр язар идем. Яртысы язылган инде.

— Керәшеннәр аерым милләтме?

— Юк!

— Ни өчен?

— Бар мишәр кавеме, бар керәшен калкы, бар типтәре, башкорты, әмма без бер милләт – татар милләте кешеләре.

— Керәшен арасыннан чыккан артистлар, язучылар бар, ләкин алар мөселман-татар исемнәрен алып иҗат итәләр. Ни өчен шулай?

— Дискриминация сәясәте аркасында. Үз исемеңнән баш тарту ул – үз халкыңнан аялу. Миңа әллә ничә әйттеләр: мөселман исемен ал, китабыңа мөселман исеме куй, диделәр. Алыштырмадым.

— Мин керәшен сәнгатькәре булсам, мөселман исемен дә, урысныкын да алмас идем, фәкать керәшенчәсен генә язар идем. Григорий түгел – Гөргөри, Яков түгел – Җәкәү, Аксинья түгел – Үкчинҗә. Саф татарча, матур яңгырашлы исемнәрне әрәм итеп, йә урысча, йә мөселманча исем алучыларга син үпкәлисеңме?

— Үпкәлим.

— Зәй шәһәрен керәшеннәрнең башкаласы, дип йөртәләр. Килешәсеңме?

— Килешәм. Зәй ягында гына керәшеннәр яшәгән 23 авыл бар. Шунда минем туган авылым Урта Баграж урнашкан.

— Керәшеннәрдә бер кешенең өч исеме була. Паспортта урысча, әйтик, Николай, керәшенчәсе – Микулай, шулар өстенә аны үзара мөселман исеме белән Мансур дип тә йөртәләр. Бу гадәтнең тамырында нинди тарихи сәбәп ята икән?

— Мин бу йоланы белмим. Керәшеннәрнең гадәтләрен син миннән яхшырак беләсең, ахры.

— Якын киләчәктәге өметегез?

— «Казан утлары»нда Казан ханлыгының 1552 елда җимерелүе хакынла «Һәлакәт» дигән романым чыгар, дип уйлыйм.

— Иншалла! Көтеп калабыз.

*Мәдәни җомга, 1998, 27 февраль.*

## Мансур Хәсәнов
## (1930 – 2010)

*Татарстан язучылары Берлеге әгъзасы (1976); Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1992); Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1995); профессор (1974); Татарстан Фәннәр академиясенең президенты (1992)); Татар энциклопедиясе институтының директоры (1992); Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнде.*

Фәкыйрь елларда Бигеш авылы кешесе Хәсән абзый курасында дөньяга килгән Мансур, чабата киеп күрше авылга мәктәпкә йөргән Мансур алга таба укып академиклар академигы дәрәҗәсенә иреште.

Әйе, бар икән бит горурланып башкаларга сөйли торган якташларыбыз, бар. Каян килә бу самимилек, фидакарьлек һәм рухи байлык?

Бер чишмә суларын эчеп, бер туфрак икмәген ашап үскәннәрнең холкыфигыле дә охшаш була, имеш. Бәлки дөрестер дә. Күптән түгел генә Зәйгә кунакка кайткач, Зәй төбәгенең Бигеш авылында туып-үскән академиклар академигы, Татарстан язучылары берлегенең хакыйкый әгъзасы Хәсән углы Мансур Хәсәнов та шуңа охшаш сүз әйткән иде.

— Зәйләр алар үҗәт холыклы, бу якларның суы-туфрагы шундый, күрәсең! — дигән иде.

Без барыбыз да һәр елны Зәйгә, Сабантуена кайтабыз. Аллага шөкер, безне онытмыйлар, без дә рәхәтләнеп туган якка кайтабыз, якташларыбызны онытмыйбыз.

Кызганыч, Мансур Хәсәнов 80 яшен тутырганда гүр иясе булды.

2010, 15 март көнне Мансур Хәсән углы Хәсәновны җирләделәр. 80не тутырып килгәндә вафат булды. Кайберәүләр аның кырыслыгы, усаллыгы турында әйтә, ләкин күп кеше аның кешелеклелеге турында сөйли.

Марс Макаров:

— Ул бик ярдәмчел кеше иде, Мансур Хәсәнович. Композитор Фәтхерахман Әхмәдиевкә ике бүлмәле фатир эшләп бирде. Шәүкәт Биктимиров депутат чагында минем өчен фатир сорап, Хәсәновка керде, бик җылы каршы алган аны Мансур абый.

Ринат Тажи:

— Бик яхшы кеше иде мәрхүм, авыр вакытта ул миңа телефон керттерде.

Шамил Закиров:

— Мансур Хәсәнович Камал театрының дусты булды, ул гел ярдәм итә торган иде.

Марс Макаров:

— Үз кеше иде ул Мансур абый.

Мансур аганы шушындый кешеләр, шушындый сүзләр белән соңгы юлга озатып калды.

Авыр туфрагы җиңел булсын!

## Хатыйп Миңнегулов (1939)

*Филология фәннәре докторы (1991), профессор (1992), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1994) Татарстан Дәүләт бүләге иясе (1995).*

*Хатыйп Миңнегулов татар әдәбият белеменең якты бер маягы, имән баганасы... һәм дөнья тюркология фәнендә зур хезмәтләре нигезендә абруйлы урын билгән олы ихтирамга ия профессор.*
Шакир Абилов, галим.

*Зәй ягының Апач авылында туып-үскән академик Хатыйп Миңнегулов татар әдәбияты тарихы буенча бәһаләп бетергесез бик күп китаплар язды. Җентекли башласаң, исең китә: бу зыялы галимебез берүзе халкыбызның алгарышы өчен шулакадәр зур хезмәт куйган.*
Фоат Галимуллин, профессор.

Күп бала белән тол калган Гайнельхаятнең чәндер-арык улы Хатыйп эшкә дә, укуга да чарыш бала булып үсә. Колхоз эшендә дә, йорт-кура арасында да сабый Хатыйп олылар гына башкарырлык эшләр эшли. Ачлы-туклы яшәп, урта мәктәп тәмамлый. Илле чакрым ераклыктагы Кәшер авылындагы мәктәпкә карурман аша йөргәндә Хатыйп киләчәктә дөнья күләм олы галим, профессор, академик булачагы турында уйладымы, юкмы, әмма Хатыйп яхшы укуы белән, күп белергә тырышуы белән инде укытучыларның игътибарын жәлеп иткән иде. Әйе, ул гыйлем дөньясына чумачак, монысы хак! Һәм шулай булды да. Якташыбыз, Имәнлебаш авылында җирләнгән галим, шагыйрь, музыкант, табиб, мулла Тажетдин Ялчыголның иҗатын өйрәнеп, китаплар бастыручы Хатыйпның тагын бихисап фәнни хезмәтләре бар. Ләкин никадәр генә җитди галим булмасын, Хатыйп мәҗлес уртасында, табын агасы, алып баручысы, әйдәүчесе. Анда да Зәй холкы.

## Гамир Мөбарәкҗанов (1932)

*Математика фәннәре кандидаты, профессор; ГНИПИ-ВТ ның өлкән фәнни хезмәткәре; Казанның «АСУ – Компрессор», Мәскәүнен «АСУ-ЗиО», Грозныйның «АСУ-Машзавод», Мәскәүнен «АСУ--Манометр--ЕС», Казанның «АСУ — Вакууммаш» заводларында баш конструктор; ОСТ 25-911-80 АСУнын «Техник-экономик мәгълүматларынын шартлы билгеләре системасы» исемле фәнни хезмәтнең авторы; Хезмәт Кызыл Байрак ордены кавалеры, «Отличник приборостроения».*

Ашыт (Куш Елга) авылында Мөбарәкҗан курасында туган Гамир исемле егетне мин 1952 елдан хәтерлим. Ул сигезенче сыйныфка йөри иде. Мин сигезенчегә житкәндә ул чыгарылыш укучысы иде. Математика укытучысы Василий Андреевич Зингаров аның турында:

— Башлы жегет ул Жирәнчәч! —дигәне истә калган.

Зингаров авызыннан ул сүзне ишетү без — «башсызларга» гына түгел, хәтта яхшы математиклар өчен дә олы дәрәҗә иде.

Чыннан да, Гамир абый зу-ур башлы, аксыл-жирән чәчле, базык-таза гәүдәле, жор телле кеше. Ул хәзер дә шулай, профессор булуына карамастан, шаян, мәзәкчән бабай.

Без, малай-шалайлар тәнәфескә чыккач, кайсыбыз тәмәке тартырга агачлар арасына качабыз, кайсыларыбыз шайтан чабып, «чыгыртайлы» уйныйбыз. Гамир кыңгырау шылтырау белән дәресханәдән чыгып, бәдрәфкә йөгерә, йомышын йомышлый да, шулай ук йөгерә-ашыга дәресханәгә кайтып, чишелеп бетмәгән мәсьәләсен чишәргә утыра. Юк, сыйныфта уза торган чүп мәсьәлә түгел, югары математика мәсьәләләрен чишә. Мәктәп программасындагы катлаулы мәсьәләләрне Гамир, Мәүҗетдин Әгъләметдинов, Рәшит Ногманов кебекләр күнелдән, такта янында ук чишеп бирә. Хәтерлим әле, Зингаров җитәкчелегендә мәктәптә югары математика түгәрәге оешты, дәресләрдән калып, кич буе алар без аңламаган телдә (югары математика телендә) сөйләшә торган иде.

— Гамир, энем, син һичшиксез, университетка математикага китәргә тиеш! — диде аңа Зингаров дәдәй.

Гамир гына түгел, тагын бик күпләр физмат бетерде.

Риваятьләр йөри Гамир Мөбарәкҗанов турында. Имеш, ул керү имтиханнарында билетны ала да:

— Можно отвечать? — ди.

Профессор Владимир Владимирович Морозов билетны алып карый да:

— Это очень сложная задача, милый мой человек, сядьте, подумайте! — ди.

— Нет! — ди Гамир. — Я готов.

Гамир кулына акбур алып, бер сүз әйтмичә, әйтер иде, урысча белми, «вот так, вот так» дип мәсьәләнең чишелешен язып күрсәтә. Комиссия шаккката. Профессор тагын башка бер билет алырга куша. Гамир монысын да шундук чишеп бирә. Математикадан язма эшен дә Гамир унбиш минутта язып тапшыра: «5».

Имтиханнарны кабул итеп бетергәч, профессор Морозов ялга китеп бара. Сентябрь ае килеп җитә, укулар башлана, профессор Морозов дәресханәгә керә дә күз карашы белән кемнедер эзли башлый. Бераздан:

— Где тот рыжий парень? Врожденный математик! — дип сорый ярдәмчеләреннән. — Кажется, его фамилия Муба... Мубаракзянов...

— А он по-русскому не прошел, «2» получил! — дигән җавап алгач, Морозов:

— А здесь сидят те, кто получил по математике «3», а по-русскому «5»? Здесь не литературный институт, здесь мы преподаем математику, нам нужны сильные математики, а по-русски он научится не хуже вас! Верните его!

Университетка керә алмаган оятыннан авылына кайтырга куркып, Гамир Елга портына йөк ташучы булып эшкә урнашкан була. Гамирне университетка, аудиториягә кайтаралар. Гамирны дәресханәдә күргәч, профессор:

— В нашем полку прибыло! — дип кочак җәеп каршы ала.

— Владимир Морозов ул дөньякүләм мәшһүр математик иде. — ди Гамир абый. — Париждагы математиклар җәмгыяте СССР математиклары арасыннан бары тик Морозовны гына математик дип саный иде.

Без Гамир мәктәптәш белән ел саен Сабаен туена кайтабыз. Сөйләшеп сүзебез бетми. Гамир әдәбиятны яхшы белә, урысчасын да, татарчасын да су кебек эчкән кеше.

— Гамир абый, синең беренче диссертацияң нинди темага иде?

— «Классификация алгебры Ли» дип атала ул. Аурупа телләреннән тыш ул диссертация Кытай теленә дә тәрҗемә ителде.

— Лие кем, ни-нәрсә инде аның?

— Франциядә яшәгән бөек матетамик ул. Софус Ли!.. Дифференциаль тигезләмәләрне кайчан чишеп була, кайчак аны чишеп булмый. Менә шул Ли алгебрасының системасын мин төзедем.

— Бу бездәй кеше аңлый торган нәрсә түгел икән.

— Лобачевскийның Евклидныкы булмаган геометриясен дә аңламаганнар.

Гамир никадәр генә мина Ли алгебрасын аңлатырга тырышмасын, мин берни дә аңламадым. Аптырагач:

— Линың чыгышы Кытайданмы? – дип сораган булдым.

— Бәлки Кытайдандыр. Кытайлар тикмәгә генә тәржемә итмәгәндер... Аннан мине профессор иттеләр, институтларда югары математика укыта башладым. Аннан Фәнни тикшеренү институтына мин проектировщик булып урнаштым. Эшем буенча нинди генә илләрдә мин булмадым, кайсы гына шәһәрдә мин булмадым, бөтен заводларга «ЭВМ ярдәмендә идарә системасы»н эшләдем, минем кул астында 600 кеше иде. Әминова дигән бер галимә үзенең фәнни хезмәтендә минем диссертациянең 70 битен кулланган. Чынлыкта диссертацияне янадан бастырып чыгарган кебек булды инде ул.

Мин бу кешенең математика сәләтенә гомер буе сокланып яшәдем, шул турыда үзенә әйткәч, ул шаркылдап көлә башлады:

— Миннән дә башсыз кеше юктыр ул, Батулла! — диде Гамир дус. – Сугыштан соңгы елларда авылда ат абзары бар иде, «конно-товарная ферма» дип атала иде ул. Бөтен абзарны тирес баскан икән. Шуннан ферма мөдире әйтә: әйдәгез әле, малайлар, тиресне күксагыз басуына чыгарыйк әле, ди. Нигә, дибез. Мөдир әйтә: атларга ятып йокларга урын юк, ди. Тирес чыгара-чыгара җаныбыз чыга язды. Вәйт, җүләр, мин атларның басып йоклаганы турында башыма да китермәгәнмен. Мөдир безне хәйлә белән эшләткән булып чыкты. Ну, атлар рәхәтләнеп калды абзарда.

Гамир математикага кагылышлы бик күп китаплар авторы. Өч томлык Югары математика буенча дәреслекнең авторы Гамир Мөбарәкжанов. Ана теленда чыккан томнар болар. Техник югары уку йортларының һәрберсендә укытырлык татарча дәреслекләр алар.

Гамир Мөбарәкжанов исемле бу шәхесне татарча чыккан шушы китаплары өчен, һичшиксез, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы буларак кабул итәргә кирәк!

— Ничәнче елда чыкты алар?

— 2000, 2002, 2003 елларда чыкты, аннан соң 2008 елда «Математика тамгалары һәм терминнары барлыкка килү тарихы» сүзлеген чыгардым. 150 дән артык фәнни хезмәтем бар... Ул хезмәтләрем минем гравитациягә багышланган. Атом чиксез таркала бит әле. Менә шул таркалуның структурасын ничек табарга?

Электрон чиксез кечерәя, чиксез бүленә, дигәнне без гел укыйбыз, ишетәбез, атом-төш галимнәре һаман аска төшә, нейтрино да бүленә икән, нейтриноның массасы юк, тизлеге бар икән, юк дәрәҗәсендәге кисәкчек нейтрино үзе чиксезваклана икән: нуклон, кварк, глюон, лептон... Боларны аңлар өчен яки атом-төш фәне галиме яки математик Гамир Мөбарәкжанов булырга кирәктер. Мин сүзне гади аңлашыла торган темага бордым.

— Гамир абый, атаклы профессорың Морозов турында тагын берәр вакыйга сөйләле...

— Сабый чагымда булды бу вакыйга. Абыем Гарифжан, урыны җәннәттә булсын, вафатына бер ел тулды, күршегә дусты янына кереп китте. Аш вакыты җиткәч, әни абыйны алып чыгарга кушты. Кереп киттем, аларның усал эте бар иде. Алга да бара алмыйм, артка да чигә алмыйм, эт мине куып житәчәк, тешләрен ыржайтып, миңа ташланды, абыйлар чыгып коткармаган булса, мин нишләр идем, билгесез. Шуннан соң мин этләрдән курка торган булып калдым, кабат көчекләргә якын килмәдем... Шулай да мине берсе тешләде, каһәр. Университетта укыганда профессорым Морозов беркөнне

әйтә: син доцент Александр Зиновьич Петровны беләсенме ди. Беләм дим. Ул бит синең теманны суккан, суккан да докторский язган. Язган да яклаган да. Петров тулай торакка килеп, минем кәгазьләрдән күчереп алган булган икән. Менә бу эт тешләгәннән дә куркыныч тешләү иде. Аннан соң ул кеше «Пространство Эйнштейна» дигән китап чыгарды, анда да минем хезмәттән бик күп мисаллар китерелә, ләкин автор кемнән алганы турында язмый. Морозовның плагиатлардан сак булырга өндәп әйтүе иде. Икесе дә мәрхүм инде. Гөнаһлары булса, икесе дә Алла каршысында җавап тота торгандыр. Морозов математика белән җенләнгән адәм иде, аның гаиләсе булмады.

— Син дә математика белән җенләнгән кеше бит.

— Җенләнсәм дә мин тиз өйләндем. Рәмзия белән җенләндем. Минем ике мәхәббәтем булды, берсе — математика, икенчесе — Рәмзия.

Гамир Мөбарәкҗанов гомерлек юлдашын әллә кайлардан эзләмәде, ул үзенең авылдашы, Алабуга педагогия институтын тәмамлаган кызга өйләнде. Балаларын, оныкларын үстереп бетерделәр инде.

— Мин йөрмәгән ил, шәһәр калмады, ләкин мин үзебезнең милләт кызы, үзебезнең авыл кызына өйләндем. Всю Европу обошел, лучше Маши не нашел, дигән кебек, Рәмзиядән яхшы хатын очратмадым.

— Рәмзия ханым кайсы һөнәр иясе?

— Ул гомере буе Алман теле белән Ана теле укытты...

Рәмзия белән Гамирның алтын туйлары булып узды, шөкер. Аларның углы Рөстәм 22 яшендә физика-математика буенча кандидатлык диссертациясе яклады, кызлары Илмирә Медицина университетын алтын медальгә тәмамлап, Чаллыда табибә булып эшли. Машалла!

## Фаяз Хуҗин
## (1951)

*Шәриф улы Фаяз Хужин, Карман авылында туган. Археолог, Болгар шәһәрләренең һәм шәһәрчекләренең тарихы вә археологиясе буенча белгеч. Тарих фәннәре докторы. Татарстан Дәүләт бүләгенә ия (1994).*

Фаяз Хужинның «Алмыш ханның карары» исемле фильмда Алмыш хан турында сөйләгәне (1997).

— Болгар дәүләтенә кергән болгарлар үзләре, суарлар, аларны суазлар дип тә йөртәләр, эсегельләр, берсулалар — боларның бөтенесе дә төрки телдә сөйләшә торган халыклар булган. Ягъни бер-берсенә бик тә якын халыклар. Идел Болгарстанының барлыкка килүе турыдан-туры безнең Алмыш хан белән бәйләнгән. Алмыш ханны кайбер чыганакларда шундый баһадир, олы гәүдәле, максатчан, нык холыклы итеп сурәтлиләр. Шулай булмый мөмкин дә түгел, дәүләт төзегән хан шулай булырга тиеш. Мин санап киткән бөтен кабиләләр дә Алмышның кул астына яшәргә ашкынып тормаганнар, димәк, ул монда бераз көч тә күрсәтеп алырга, башка төрле ысуллар уйлап табарга тиеш булган. Менә шушы ысулларның берсе — Ислам. Болгар дәүләте хәзәрләр кул астында була. Баштагы чорларда бу бик унай була. Хәзәр дәүләте куәтле дәүләт, алар кул астында яшәве үзенә күрә унайлыклар да тудырган. Алмыш, нишләп әле мин хәзәрләргә буйсынып яшәргә тиеш? дип баш калкыта башлый. Һәм Исламны рәсми рәвештә кабул итә. Бик таралган бер фикер яши. Имеш, Багдаттан Болгар иленә килеп, гарәпләр Ислам динен тараткан. Ибн Фадлан калдырган хәбәрләргә караганда, алар килгәнгә чаклы да Ислам дине Идел буенда тамырланган, илдә көчле бер рухи халәт булган. Һәм Ханәфи мәзһәбендәге дин инде Болгарда кин җәелгән була. Әлбәттә, рәсми рәвештә Ислам 922 елда кабул ителә, ләкин рухи могҗиза буларак, Ислам инде пәйгамбәребез салаллаһу

галәйһи вә сәлам вакытында ук Болгарга килеп житкән була. Бөек акыл иясе буларак, Алмыш хан халкыннан аерыла алмый һәм ул солтанат халыкларын бер дин — Ислам байрагы астына туплый.

## Качкыннар

Атам Мөхлисулла мин унынчыны тәмамлар алдыннан кактырып-суктырып кына мина кайсы уку йортына керергә кирәклеген сизләрә башлады.

Фәхрулла абыйларның бер сарыгы кинәт егылып үлде. Аһ иттеләр, ваһ иттеләр, сугыштан соңгы елларда мал үлү ул кеше үлеме белән бер. Мал духтырын чакырталар, үлгән малны яралар, үлеменең сәбәбен тикшерәләр. Хужалар гаебе белән булса, акча чыкмый, берәр чир белән тәгәрәгән булса, акча тия. Мал духтыры Тикан дәдәй, килә яра, карый, бик акыллы кыяфәт белән малны тикшерә. Тикан хужа гаебе белән үлгән сарыкка:ниндидер чир белән үлгәнлегенә таныклык бирә дә Фәхрулла абый акчасын барып ала, акчаның яртысы Тиканга була. Тиканны һәйбәтләп, тавык суеп сыйлыйлар, шуннан сон бүртенгән Тикан киерелеп торып тарантасына утыра да атын чаптырып китеп бара. Кышын кашовкага яхшы ат жигелгән булыр. Тикан яхшы толып кигән булар. Бояр дими ни диярсен, билләһи.

Табын янында әти сүз кузгата:

— Рәхәт яши, чукынмыш Тикан... Аты үз кулында, сыйдан сыйга гына йөри, кыш буе яна суйган ит ашап чыга... Мал духтыры ул — патша...

Әтинең мине Ветеринария институтына имтихан тотарга кыставы иде бу. Чыннан да ул: аттестатын тотып, мал духтырлыгына укырга китте, дип мине Казанга озатып калды. Ләкин мин: мал духтырларын кайда укыталар, дип сорашып та тормадым, тоттым да Мәскәү театр училищесына документларымны тапшырдым.

1956 елдан алып мин Мәскәүдәге театр уку йортының шәкерте. Өченче сыйныфка житкәч, 1959 елның кышында мин каникулга Шыкмайга кайттым. Максатым спектакль куеп, авыл халкына ни өчен укып йөргәнемне күрсәтү иде. Әти авылдан бөтенләйгә күченеп китәргә әзерләнгән. Йортны саткан, анда Солтанхәмит абый белән Асбия апа гаиләсе кереп утырган. Әти белән әни, ике сабый энекәш мунчада яшәп яталар икән. Әби вафат булган. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәжигун!

Егетләрне-кызларны клубка жыйдым. Шатланышып риза булдылар. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»еннән качкыннар пәрдәсен алырга булдык. Икенче бүлектә концерт иде. Егетләр кырда калган эскертләрдән ат белән фермага салам ташый. Салам алып кайтканда атларын клуб янында туктатып, клубка кереп бер репетиция ясыйбыз, йөкләрен бушатып кырга киткәндә тагын клуб янында туктап репетиция ясыйбыз. Егетләр кырда салам төягән арада мин кызларга бию куям, жырларын тәкрарлыйбыз. Бу концертка мин биш бию куйдым. Зәмһәрир суык, салам ташучы егетләр репетиция ясаганда шабыр тиргә баталар. Булатны Райф Усманов башкара, Ат карагын мин үзем, шәкертне Кәле Галимжан, ялган акча ясаучы Тимушны Балык Хәнифе. Качкыннар пәрдәсен без суфлерсыз уйнадык. Егетләр сүзләрен ятлап алдылар.

Хәзер киемнәр юнәтергә кирәк иде. Катнашучылар шулкадәр дәртләнгән, бөтен авыл буйлап картларга кереп, әбиләрнең сандыкларын ачтырып, иске күлмәкләр, ертык туннар жыйдык. Сәхнә уртасында чын учак ягып, генераль репетиция узгардык. Качкыннар хоры гажәеп шәп килеп чыкты, авыл егетләре күкрәк киереп «Без качкыннарны» жырлый. Клуб эче дәһшәт, шом, гайрәт белән тула.

Беренче концертны Бура-Киртә авылында куйдык. Керү бәясе бер

сум иде. Басып торырга урын калмаган. Бура-Киртә халкы шаккатты. Спектакльне суфлерсыз, яхшы темпо-ритмда, гайрәтле итеп уйнады шыкмайлар. Тамаша куярга мин Мәскәүдән үк әзерләнеп кайткан идем. Грим, вазелин, гуммоз, хәтта париклар да алган идем. Качкыннарны мин шулай итеп гримлыйм, гуммоз белән зур кәкре, бәрәңге борыннар ясыйм, уйнаучыларны хәтта авылыбыз кешеләре дә танымый иде.

Әллә ничә авылда уйнадык: Бура-Киртә, Бордыбашы, Кадер, Бишавылы, Ашыт, Югары Пәнәче, Шыкмайда, шомарып беттеләр егетләр-кызлар, биюләрне чатлатып бииләр, җырлаучылар да матур, безнең авылга фельдшер булып килгән Клара исемле кыз бик тә матур җырлый, шәп бии иде.

Китәр вакыт җитте. Җыелган акча байтак иде. Шул акчага клубка гармун алырга булдылар. «Янда калдырылган» маяга без — концертта катнашучылар, авылның актив яшьләре Зәкия апа йортында зур дәстархан корып, таң атканчы күңел ачтык. Бу уңышлы спектакльне юу да, мине озату мәҗлесе дә иде. Онытылмас мизгелләр иде ул. Хәзер сагышлы уйга батам. Куян Райф бандитлар кулыннан кичкән улының кайгысын күтәрә алмыйча, яшьли үлде, Балык Хәнифе дә улының матай белән бәрелеп үлгәнен авыр кичерде, вафат булды. Музыкантыбыз Өлфәт тә сәер шартларда гүр иясе булды. Аның гәүдәсен Себер урманында агачка асылынган килеш тапканнар. Юкса, Өлфәт үзенә кул сала торган җебеки егет түгел иде. Мин болар турында «Юл буенда зәңгәр чәчәк» китабында яздым. Ләкин китапта аларның исеме бераз үзгәртелгән.

Галимҗан да сәер китте дөньядан...

Күрше Әхмәдетдин Райфы та, Галимҗан да өйләнмәде. Райф тракторын бакча башында сүндерә дә ындыр артлатып кына өенә кайта. Шуннан соң ул урам як капкадан йөрми. Райф әнисе ни пешерсә, шуны карусыз ашый да китап-журналга тотына. Аның укымаган китабы юк. Ләкин беркайчан да ул укыганнары хакында авыз ачып кешегә сөйләмәде.

Галимҗан исә бригадир кая кушса, шул эшкә барып кайта, мал-туарын карый да гәҗиткә чума, телевизор карый. Монысы эчәргә аракысы булмаганда. Аракы булганда берни кирәк түгел. Аның нәрсә эшләгәнен бөтен авыл белә: салырына булмаганда ул сөйләшми, өендә утыра. Салып алса, Галимҗан урамда, кибет төбендә, клубта – яшьләр янында. Аекта авызыннан бер кәлимә сүз тартып ала алмассың, йөз грамм керүгә, Галимҗан үзе әйтмешли, «Татар дәүләт филармониясенең нәфис сүз остасы»на әверелә дә куя.

– Галимҗан, өйләнеп җибәрәсеңме әллә? – дип шаярталар. – Авылда сез ике күрше инде карт буйдаклар: син дә Райф.

Галимҗан шундук сүз таба:

– Син, агайне, минем яшь буйдак булган чакны да онытма, ха-ха-ха, – дип үз сүзеннән үзе көлә. – Аннары сун, син агайне-ак мыек, Райфка кагылма, Райф белән минем өчен дустыбыз вә күршебез алдынгы тракторчы Хәйрулла тырыша... Статистика мәгълүматларына бакканда, бер иргә уртача ничә бала туры килә? Ә?.. Бер иргә уртача ике бала. Безнең регионда, ягъни Түбәночта да нәкъ шулай, Хәйрулла Ярмөхәммәтовта биш бала, Әхмәтзәкидә дүрт бала, Райф белән миндә нулевой күрсәткеч, ә безнең регионда уртача ир саен икешәр бала! Димәк, мин дә, Райф та ике бала атасы, ха-ха-ха...

Галимҗан салган көнне кибет яны, капка төбе гөрләп тора: түләүсез театр.

Шулчак айгылдап көлүче ирләр яныннан Сәгыйрь карт узып бара иде; күрәсең, ул йомыш белән кибеткә килгән дә, кибет төбе тулы салмыш ирләр булгач, башка йомыш тапкан булып, кибетне узып бара. Аек булса, Галимҗан аңа:

– Исәнме, Сәгыйрь абый,– дияр иде, юк, бүген Галимҗан ни уйласа

шуны әйтәчәк: – Ә-ә, Шыкмайның нәсел үгезе, иптәш пенсионер – камунис Сәгыйрь Госмановский, дравствуйте! – дип кычкырды нәфис сүз остасы.

Сәгыйрь исәнләшүме, нидер мыгырданып кибетне узып китте.

Галимҗанга илһам килгән иде, ул позага басып:

– Һо-о, эт симерсә, иясен танымый, ди! Сез безләрне танымадыгызмыни, иптәш Госмановский? Ә мин сезне беләм, сез иптәш камунис Госмановский Түбәночка төшеп, тол ханым белән женси ихтыяжларыгызны канәгатьләндерү белән мәшгуль идегез...

Галимҗан радио-телевидение, газета-журналда нинди төче-купшы сүз языла, эчкәч шул телдә сөйләшә.

Ирләр әдәпсез көлә. Көлмәүчеләр дә бар. Житәр сина, Кәле, дип кыюсыз гына эндәшүчеләр дә бар. Дөрестән дә, карт кешедән көлү килешми, янәсе. Сәгыйрь мондый чакларда һични әйтми, бәхәскә керми, ишетмәмешкә салыша. Тора-бара ул бөтенләй сангыраулаңды. Кемдер: юри чукракка салыша, ди. Хактыр да, нишләмәк кирәк, каршы әйтсә, ул янган утка май гына сибәчәк, халык усалланды, кул белән шаярулары да ихтимал. Ишетмәсән яки ишетмәмешкә салышсаң – иң яхшысы.

– Ишетә ул! – ди Галимҗан.– Ишетә нәжес. Үзенә кирәкне бик тиз ишетә, курвы!

Чыннан да, Сәгыйрь бригадирлыктан пенсиягә чыккач, идарә тирәсендә куштан булып йөрсә дә, япа-ялгыз калды. Балалары райүзәктә урысча укып, шәһәргә күчте. Кайтмыйлар. Карчыгы да дөнья куйды. Сәгыйтдиновка бик ярарга тырышып йөрсә дә, эше пешмәде. Шулай, безнең халык – бичара: түрдә утырганда түргә кирәген әйтергә шүрли дә, түрәлектән төшкәч, ярар, узган эшкә салават, дип үч алмый. Үч алырдайлары да Галимҗан кебек, кабып-кыюланып алгач кына тел тибрәтә. Монда кайсысын хурларга, кайсысын хупларга да белгән юк. Шуңа күрә, халык һаман дәшми. Бусы, яна житәкче фәрештәме? Халык сөйләшә торган хайванга әверелде кебек, ат кебек эшли, эшләгәненең чиреген дә ала алмый. Йә аңны югалтканчы эчәргә, йә куштан булырга, йә телеңне аркылы тешләп, женең өзелгәнче заяга эшләргә, йә шәһәргә качарга гына кала.

Шулчак кибет янына машина килеп туктады. Машинадан фотоаппарат аскан, магнитофон тоткан бер хатын-кыз чыкты, аннан соң Сәгытдинов төште.

– Менә, иптәш Дилаева, бу бригада жегетләре! – диде прид.– Любое турында яза аласыз, механизаторлар, терлекчеләр...

– Ярый, иптәш Дилаева, мин киттем,– диде прид. – Сезне сөйләшкән вакытта килеп алырлар.

Прид машинасына утырып китте. Япь-яшь кыз өрлектәй ирләр арасында ялгыз калды.

– Жәгез, кемнән башлыйбыз? – дигән булды кыз.

– Ну, әлбәттә миннән,– диде Галимҗан.

– Сез кем? – диде Дилаева магнитофонын көйли-көйли.

– Мин тулы канлы совет гражданины, иптәш Дилаева,– диде Галимҗан. – Киң вә күпьяклы белгеч. – Галимҗан Бәдретинов аган булам.

Көлү куәтле булды. Тәжрибәсез хәбәрче үзенең көлке хәлгә кала баруын сизми иде, ахрысы, ул җәй көне дә чүчинкә киеп, ялангач тәнгә сырган күфәйке салган бу кеше белән «күпьяклы белгеч» төшенчәсе арасында ниндидер аерма барлыгын күрде бугай, дөрес сөйлиме ул, дигәндәй, бер төркемгә, бер Галимҗанга карап алды.

– Әлбәттә,– диде Галимҗан.– Нинди эшкә кушсалар, мин шул эшне сыйфат билгесе белән башкарам. Сәнәк белән мал асты чистартырга бирәүгә дә кушмыйлар. Мина – Галимҗанга гына ышанып тапшыралар ул бик

тә мөһим участокны... Арба өстендә лайлалы силусны таратырга кемгә кушалар? Әлбәттә Галимҗанга.

Ул кай урында көләселәрен дә белә, кеше көлгәндә сөйләми, туктап тора.

— Сез, Дилаева иптәш, бик дөрес килгәнсез... Минем күрсәткечем бик зур...

Халык тәгәрәп китә, көлү кешеләрне буып ала, кыз да көлә, ләкин көлкенең сәбәбен белми.

— Әлбәттә, зур күрсәткечкә ирешү өчен мин бер сәнәк белән ун мең тонна, икенче сәнәк белән алты йөз ситнир тизәк төядем. (Көлеш.) Мин бик тырышам, иптәш кариспандинт, социалистик ярышта алда барам. Мин бөтен Советлар илен күмеп китәрлек тизәк чыгардым, иптәш.

Кыз үзенең каршысында тилчә телле халык шамакае басып торганын һаман аңламый кебек. Һәм җитди сөйләшмәк булып, микрофонын Галимҗанга якынрак тотып:

— Әйтегез әле, Галимҗан абый, сез ничек бу нәтиҗәләргә ирештегез? — диде.

Галимҗанга бу гадәти сорау яңа ризык кына бирде, ул илһамланып, хәтта сөйләгәннәренә үзе инангандай, микрофонны тотып болай диде:

— Иртә таңнан торып, кичке караңгыга хәтле физик эш белән мәшгуль булсаң гына күрсәткечең зур була. Хатынсыз ирләр өчен бу күрсәткеч эш аеруча мөһим. (Көлеш.) Безнең калхуз җитәкчеләре дә бик кайгыртучан халык, туклану мәсьәләсен уңай хәл итеп, эшче кулларны рациональ кулланырга ирештеләр...

Эстрада театрының көлке тамашасы гөрләп бара: халык көлә, артист иҗат итә.

Хәбәрче:

— Сезнең эштән соңгы вакытыгыз...— дип башлаган иде, Галимҗанның җавабы авызыннан атылып та чыкты:

— Сәнгать, культура, опера безнең мавыгу. Менә мин үзем, иеме, эчкечелек белән мавыга башладым, мавыгуларым нәтиҗәсез булмады, авылдашлар шаһит, мин сәрхушлек дәрәҗәсенә ирештем. Үз өстемдә нәтиҗәле эшлим, эчү системам бар: булганда эчәм, булмаганда — юк. Менә мин кичәгенәк бер җыр тудырдым әле...

Галимҗан опера җырчылары кыяфәтенә кереп, җыр башлады, аның тавышы да опера җырчыларына пародия иде:

— Сау бул, Ә-әми-нә-ә!.. Кө-өт мине-е!..

«Операдан» соң Галимҗан такмакка күчте:

Дулкынланып сулар керә
Парахут идәненә;
Иң бәхетле, матур тормыш
Совет илендә генә-ә...

Гөрләтеп кул чабалар, көләләр. Шау-шу бераз тынгач, Галимҗан янә сүз башлады, ул кинәт үзгәрде, үз хәленә кайтты һәм гаять җитди рәвештә:

— Ә беләсезме, бу җыр өчен мин җырчысын да, шагыйрен дә капкага терәп атар идем! — диде.

Кемдер бу сүзләрне «кызык ясау өчен әйтелде» дип уйлап, көлеп куйды.

— Көлмәң! — диде Галимҗан. — Кызык түгел. Кая караган кариспандитлар? Кая караган НКВД? Ә?..

— Мин сезне аңламыйм, Галимҗан иптәш! — диде Дилаева.

— Аңларга тиешсез, иптәш кариспандинт! — дип кычкырды Галимҗан.—

Парахутка дулкынланып сулар кергәч, парахут бата, дигән сүз. Парахут батканда, панимаешь, ин бәхетле, ин матур ил Советлар иле генә була алмый. Бу, иптәшләр, провакация, бу диверсия. Жырга салынган бомба! Димәк, кемдер парахут идәнен алдан ук тишкән!

Берәү дә көлмәде. Дилаева тиз генә магнитофонын жыя башлады. Галимжан нотык сөйләүче кабыгына кереп юри сөйлиме, әллә үз инанычын әйтәме – анлавы кыен, ләкин аның кыяфәте куркыныч иде, күзләр шар ачык, ике каш та мангайга менгән, бармаклар ара-тирә халык өстенә, хәбәрче кызга янау болгый.

– Не позволю! – дип кычкыра Галимжан.– Значит, парохут бата, ә без жырлыйбыз булып чыга: врагу не сдается наш гордый «Варяг», да?

Галимжанның шаярып башлап та хәтәр жәнжалга кадәр барып житкәнлеген авыл халкы белә; Нәжип абзый хәбәрче кызны читкәрәк тартып:

– Кызым, син хәзер аннан ераграк йөр инде, аның өянәге шулай,– диде.

– Я себе позволю! – дип Галимжан кычкыра. – Мин үземә рөхсәт итәм ки... Мин төйнәлгән йодрыкларымны эшкә жигә алам, ягъни сугыша алам... Совет кәжәсенә карата физик көч кулланырга ярамый, ягъни кәжәне кыйнамаска кирәк. Физик көч кулланып, мин сезне егылырга мәжбүр итә алам, әмма аның өчен статья бар...

Халык таралып бетте. Галимжан сүрелә төште дә, тирән көрсенеп, кибетнең таш баскычына утырды.

– Их, сез...– диде ул үзалдына. – Сезләр, сезкәйләр. Наданнар бит сез, мәхлуклар.

Кемне сүгә ул? Авылдашларынмы? Әллә гәжит халкын ачуланамы?

– Сезгә шар-шор күләргә булсын да, шапор-шопыр чөмерергә булсын да, гыр-гыр йокларга булсын...

Галимжан салмак кына торды да ипләп кенә үз өенә таба, Түбәночка атлады. Бераз баргач, ана Сәгыйрь очрады.

Аңа килеп житәрәк, Галимжан жыр башлады, бу жырлау түгел, сыкрауга охшаган иде.

> Яңа утырткан тупылларым
> Сынган каты давылда;
> Бер жылыймын, бер жырлыймын,
> Китәм туган авылдан...

Сәгыйрь белән тигезләшкәч, Галимжан, туктап карт колагына:

– Бибизәкия түти жыры! – дип кычкырды.

Үзе нәтижәсен көтеп тормады, китеп барды. Ул өенә кайтып, чишенмичә генә чоланга кереп ауды.

«Бибизәкия жыры» дигән сүздә тирән мәгънәне аңладымы икән Сәгыйрь карт?

Каршы як күршебез Хәлилә түти сүзе:

– Аның аркасында Зәкия түти ике тапкыр төрмәдә утырып чыкты. Сәгыйрь үз күзенә тавык тизәге салып, сугыштан котылды, Алабугадагы немец әсирләренен Германиядән килгән паюгын талап симерде. Милләт айгыры кебек, солдаткалар янына йөрде.

Галимжан бу жыры белән: Зәкия апа әллә кайчан гүр иясе булды, ә син, бетле күз һаман исән, сине жир һаман күтәрә! дип әйтергә теләгәндер.

Тап-таза ир-егетне жиңде Сыек Иблис. Тора-бара Галимжан айнымас булды. Өйдә авыру анасы. Майжамал түтине аяклары ятакка аударды. Оян-оян дип йөрде дә, оян гына булып чыкмады ул каһәр. Менә шушы хәл Галимжанның бөтен хыялларын жимерде. Анасы түшәккә егылгач

Галимҗан белде: ул өйләнмәячәк. Үз анасын карамаган хатыннар заманында, ирнең гарип анасын кайсы яхшы хатын тәрбия кылыр икән? Көн саен ашатырга, эчертергә, астын алыштырырга, атнага бер мунчага алып кереп юындырырга кем риза булсын? Үзе күз тоткан хатыннар арасында ул андый батырны күрмәде. Бәлки ул хаталанадыр? Әмма барыбер өйләнмәскә булды. Галимҗан гарип анасының әнә шул мәшәкатьләрен үз өстенә алды. Барысын да үзе эшли, зарланмый, әнисенә авыр сүз дә әйтми иде. Шулай яшәп бетерергә уйлады. Инде авыру әнисе дә дөнья куйды. Өйләнергә соң кебек тоелды. Ятим йортта ялгыз буйдак ни кылсын? Эчә. Бар тапканы шуңа житеп бара. Көннәрдән бер төнне ул шулай каты махмырдан мунча ягып керер, мунчасын иртә томалапмы, әллә йөрәге тотыпмы, Галимҗан вафат булыр. Кем белә, кем кистереп әйтә ала: юк, бу эшне Галимҗан алдан уйлап эшләмәгәндер дип?

Хәйруллаларның каршы ягында тагын бер ятим нигез, ялгыз йорт артыр. Электр чыбыкларын, радио чыбыкларын өзәрләр. Тәрәзә, ишек, капка кадакланыр. Ишегалдын тутырып кычыткан, әрем, алабута үсәр.

Галимҗан язмышы турында мин күп уйланам. Гаҗәеп талантлы, укымышлы шәхес иде ул мәрхүм, дүрт кенә сыйныф бетерсә дә ул күп укый иде. Әдәбиятны-сәнгатьне анлый иде.

Янчык Сәләхи токымы гомер-гомергә фәкыйрь булды. Сәләхи бабайның да Бәдигылҗамал әбинең дә, Нурмый абыйның да туйганчы ашаганы булмагандыр. Иң башта Бәдигылҗамал белән Сәләхи бабайның баш баласы Нуретдин атылып үлә, аннан соң төпчек углы Нурмөхәммәт сабый чактан кызамыктанмы, чәчәктәнме акылга таман булып кала. Анысын урманда агач бәреп үтерде. Аннан соң Майҗамал түти ике баласы белән тол кала. Инде менә Галимҗан да юк. Бетте нәсел. Бер рәхәт күрмичә, дөньядан китте тулы өч буын.

Мин куйган «Качкыннар»да Шәкерт ролен Галимҗан шундый оста уйнады ки, соңыннан анын һәр әйткән сүзен кабатлап йөри башладылар.

«Менә хәзер пылау ашасаң иде».

Галимҗанны җирләгәч, Шыкмай ятим калды кебек. Аның кызмача чакта куптарган җәнҗаллары да онытылды, аның былагайланып, олы кешеләргә хас булмаган тәртипсезлеге дә юкка чыкты. Аның ярамаган яклары үзе белән китте, ә якты хатирәләре калды, алар безнең арада.

Гүрең нур булын, Галимҗан дус!

Мин Мәскәүгә китеп бардым, минем урынга Ат карагын уйнарга яңа килгән укытучыны кертеп, шыкмайлар Зәй төбәген әйләнеп чыкканнар. Гаять зур уныш казанганнар һәм һәвәскәрләр фестивалендә Зәйдә беренче урынны алганнар.

*Галимҗан «Галимхан» исеме белән «Юл буенда зәңгәр чәчәк» китабына кереп калды.*

## Туган як табигате

Безнең авыл тау ышыгында урнашкан. Чаллы ягыннан килгәндә, авыл күренми. Тау башына житкәч кенә, мәһабәт бер матурлыкны күреп, туктап каласын. Юлчы каршында мул табигать манзарасы ачыла.

Тау астында Шыкмай авылы. Тау ышыгына елышкан өйләр синең аяк очында ята кебек. Өйләр шул кадәр тыгыз салынган ки, биектән караганда, тоташ бер поезд составын хәтерләтә. Шул поездның һәр вагоны — бер хуҗалык. Ишегалдында кем нәрсә эшли— һәммәсе дә тау башыннан аермачык күренә. Әнә, Сәләхетдин бабайларның жил капкасы астыннан Маһиҗамал түтинең чуар тавыгы атылып чыкты, чыкты да, урам аша

йөгереп, Хәйруллалар капкасыннан кереп китте. Әнә, Васби түти Ләпәйләр тыкрыгыннан суга төшеп бара. Бар да уч төбендәгедәй ап-ачык.

Авылны урталай бүлеп, Зичә суы ялтырап ята. Су буенда тал-тирәкләр үсеп утыра. Зичәнен аргы ягында яшәүчеләрнен бакчалары урманга барып тоташа. Бакча башыннан урманга хәтле нибары 800 метр гына кала.

Шыкмайдагы ул яшеллек! Карагыз әле, әнә, югарочта куе таллык күренәме? Аны бәләкәй урман, дип ялгыша күрмәгез. Югары алачык яны борын-борыннан урман кебек шаулап торган. Бу — югароч яшьләренең кичке уенга җыела торган урыннары. Клуб, авыл Советы биналары, җыен мәйданы мәһабәт тупыллар белән уратып алынган. Һәр йорт каршында, ишек алларындагы бәләкәй бакчаларда шомырт, миләш, сәрви агачлары иңрәп утыра. Түбәноч Габделхак абзыйлар бакчасында тагын бер бәләкәй урман күренә. Биредә тупыллар, таллар, усак агачлары үсә, үзенә күрә кечкенә геня ял паркы.

Ә-нә, тегермән келәтләре дә биек тупыллар түгәрәге эчендә утыралар. Ул тупылларга зират агачлары килеп кушыла. Ул зиратны һич тә «үлем почмагы» дип атамассың. Нинди генә агач юк анда. Сирин, нарат, чыршы, каен шаулый, чып-чынлап катнаш урман инде.

Шыкмай ягында кибеккән юлаучыга атлаган саен чишмә очрап тора. Тау булган җирдә чишмә булмыймыни? Рәхим итегез, ә-әнә, югароч киленнәре Ерак Чишмәгә суга бара. Ә-әнә, Дәрәтаудан Зичәгә ике чишмә агып төшә, берсе Гелдәрәй юлыннан, икенчесе Каршы Таудан чыга. Түбән оч басмасына житәрәк, Сәхи бабай чишмәсе челтерәп ага. Сәхи бабай, чишмә бәреп чыккан җирне чистартып, су юлын ачып, зур гына кисмәк утырткан, шуна күрә, ул чишмәне аның исеме белән атаганнар. Эшкә баручылар, эштән кайтучылар, шул чишмәгә ятып, рәхәтләнеп су эчәләр.

Шыкмайның иң матур чишмәсен күрәсегез килсә, әйдәгез, таудан аскарак төшик... Тау уртасына житкәндә без өстәл кебек чыгып тора торган бер урынга тукталабыз. Бу — авыл яшьләренең уртак уен урыны. Бу төшкә Сабантуй көнне бик күп халык җыела, яше-карты, бала-чагасы дигәндәй, һәммәсе дә шушында менеп, җырлы-биюле уен уйныйлар. Өстәлдән астарак Кызыл Тауның горурлыгы — Шарлама коя. Шарламаның суы тешенне сындырырлык салкын, ширбәт шикелле татлы, чык тамчысыдай саф.

Шарламадан астарак, Комлык тавы итәгеннән үк Шыкмайның данлыклы әрәмәсе җәелеп китә. Ике чишмә урман кебек куе әрәмәне суга туендырып тора. Әрәмәдә зирекләр, нәзек каеннар шаулый. Чү, әрәмә эченнән курай тавышы ишетелә түгелме сон?.. Шакмайның атаклы курайчысы Мәгъсүмә әби әрәмә камышыннан курай ясый торгандыр. Әбиләр сөйләвенә ышансаң, бу әрәмәдә кайчандыр бүре дә булган. Бәлки, булгандыр, Җәләй качкынны яшереп тотарлык булган әрәмәдә бүресе дә булгандыр. Куян белән төлке күренгәли торган иде.

Бу язмаларны укыгач, якташларым:

— Син бит, туган, элеккеге Шыкмай турында сөйлисең? Хәзер Шыкмайдан шыксыз жир юк! — диярләр, бәлки.

— Нишләп элек булсын! — диярмен мин. — Ун-унбиш ел да юктыр әле, мин сөйләгәннәрнең һәммәсе дә бар иде, һәммәсе дә исән иде.

Кошлар сайравы күптән инде ишетелми. Үрдәкләр күптән инде бу якларны ташладылар. Кошлар инде күптән бала чыгармый. Күптән инде әрәмәдә курай тавышы ишетелми: тегермән буасы өчен турый торгач, әрәмә юкка чыкты. Зирекләр, тирәкләр беткәч, әрәмә суы корыды. Хәзер куе әрәмә урынында ике кәкре зирек тырпаеп тора. Клуб янындагы тупылларның кайсын яшен сугып сындырды, кайсы картаеп, үзе корыды, кайсын үзебез корыттык. Алмашка башкаларын утыртырга кулдан килмәде. Габделхак

абзый урманындагы агачлар да, карчыклар авызындагы, менә төшәм, менә төшәм, дип эләгеп торучы берничә теш сыман, бик нык сирәкләгән. Югароч чишмәсе торбасыннан су, тамаргамы, таммаскамы, дигәндәй, сыкранып кына саркый. Мәһабәт Шарлама да юкка чыккан.

1949 елда без, малайлар, кызлар, урманнан төпләп алып төшеп йөзгә якын агач утырткан идек. Хәтерегездәме, авылдашлар Хәйрулла, Гакыйф, Нурзаһит? Шуннан соң авылда күмәкләп агач утырту булганын мин хәтерләмим. Ә без утырткан шомырт, миләш, кура җиләге агачлары чын бакчага әйләнеп киткән иде. Хәзер дә ул бакча шаулап үсә.

Мондый бакчалар берничә булса, авылыбыз бик ямьле булыр иде.

Хәзер халык мул, рәхәт яши, җимеш бакчалары булдырырга, өй буйларында аллы-гөлле чәчәкләр үстереп, ихаталарны гөлбакчага әверелдерергә вакыт та, мөмкинлек тә бар. Тик моңа кешеләр күнегеп, гадәтләнеп җитмәгәннәр әле. Язларын, көзләрен күмәкләшеп, гөр килеп агач утырту — үзе генә дә күнелле бер вакыйга бит. Халкыбызда өмәләр уздыру йоласы борын-борыннан килә. Өмә ул — күмәк эш кенә түгел, күңелле бәйрәм дә, кешеләрне тәрбияләү чарасы да. Эштән тәм табу, аны бәйрәмгә әйләндерү — нинди гүзәл йола! Язын агачлар утыртыр вакытлар җиткәч, бу гүзәл йоланы искә төшерәсе иде.

Кайбер якларда бала тугач, яшьләр өйләнешкәч, агач утырту гадәте бар. Ә андый агачларны гадәттә аеруча кадерләп, карап үстерәләр. Бу матур эшне безнең авыл кешеләре дә гадәт итеп алса, начар булмас иде бит!

Шуны да әйтергә кирәктер: табигатьнең гүзәллеген тулысы белән кире кайтару мөмкин эш түгел. Әмма табигатьнең ярлылана баруын туктатып була торган эш. Моның өчен хуҗалык җитәкчеләренең һәм халыкның бер сүздә булулары шарт, һәркемгә мәгълүм ки, Татарстанда яшеллеккә, алмагачларга, чәчәккә күмелеп утыручы авыллар бик күп. Бу матурлыкны тулысы белән авыл кешеләре үзләре булдырган һәм булдыра алалар.

Сарман төбәгенең Кутәмәле авылында механик булып эшләүче Альберт Сәгыйтов белән сөйләшергә туры килде. Мин шул авылда председатель булып эшләүче, элеккеге танышым Галиев абый турында сораштыра башладым. Бу кеше талантлы оештыручы, үз эшенә жаны-тәне белән бирелгән шәхес иде.

— Күптәннән китте бит ул безнең авылдан! — диде Альберт Сәгыйтов. — Авыл халкының Галиев абыйны бер дә җибәрәсе килмәгән иде... Аны артта калган хуҗалыкка күчерделәр... Ну, малай, эшне куеп җибәргән ул анда. Халык та яратып өлгергән. Гел мактап сөйлиләр. Шуның өстенә авылларны яшелләндерергә тотынган. Һәр кешегә агач алып кайтарткан, прәме нәрәткә кертеп, колхоз эше иттереп, ныклап тотынган ул. Биш-алты елда авыл урман эчендә утырачак, билләһи!

Гаҗәп кешеләр бар бит! Колхоз кереме турында да кайгырта, колхозчыларны онытмый, матурлыкны да истән чыгармый. Андый кешеләр өчен һәммә нәрсә дә мөһим, һәммә нәрсә дә кадерле.

Табигатьне саклау, яңарту колхоз җитәкчеләре, колхозчыларның иң изге бурычы! Бу мөһим мәсьәләдә җитди эшкә керешү күптән вакыт.

*2010*



Рөстәм
Акъегет

# КҮҢЕЛЕМ – САЛАВАТ КҮПЕРЕ

***

**Яшьтәшләрдән**
**тагын берәү китте...**
**Янәшәдә**
**йөри Газраил.**

**Алмагачта**
**сирәк алма калган.**
**Кайсын сайлар бүген,**
**кайсын сайлар**
**кара төндә искән**
**көзге җил...**

***

**Агачлар биек булганда,**
**түбәләр түбән иде...**

**Түбәләр биек булганда,**
**агачлар түбән инде,**
**башларын игән инде...**

***

**Сыгыла талым,**
**сыгыла талым,**
**иманнәрем сынганда...**

**Сыгылам микән,**
**сынам микән**
**язмышлар сынаганда?..**

Рөстәм АКЪЕГЕТ (Фәйзуллин) (1951) – *шагыйрь; «Ак болыт шәүләсе», «Төнге сулар», «Янды бер шәм таңнарда» исемле шигырь китаплары авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

***

Яна утын,
бии ялкын.
Гомер мизгел —
карап торам
яшәү белән үлем туен...

## Октябрь кояшы

Агач очларыннан кояш саркый,
урман эче үтә күрәли.
Яфрак кыштырдавы ишарәли күк
йөргән монда элек Шүрәле.

Октябрьнең урталары тора,
ел фасылы сынган урталай.
Көз читенә якынлашып барам,
җәй башыннан карый бер малай.

* * *

Еракка китеп барам мин.
Нәрсәгә якынаям?..
Бергә көлешкән идек без,
ялгыз булырмы елау ?!.

***

Күк йөзе ак
ай тулып.
Ургыла нур
ыргылып.

Туган теле
искә төшкән —
Эт улый
Бүре булып.

## Син кайткач

Күңелем — салават күпере.
Җанга сыймаган шатлыкны
тургайлар түгә күктән.
Болытның карасыннан да
кояшлы яңгыр көтәм!

## Көнбагыш бага кояшка

Көнбагыш бага кояшка.
Су буе — камыш-җикән.
Егет әле малай гына,
ә кыз инде буй җиткән.

Су кергән ул иртә таңда,
күкрәге дулкын сизгән.
Миләш әле сары килеш,
кыз аннан мәрҗән тезгән.

Көнбагыш бага кояшка,
күзләр дә җитәр микән?..
Егет әле малай гына,
ә кыз инде буй җиткән.

## Баксаң...

Баксаң агачка —
яфрак коела...
Баксаң күкләргә —
йолдыз атыла...

Баксаң суларга —
йолдыз суларда...

Баксаң җирләргә —
яфрак җирләрдә...

Баксаң үземә —
кергән көзенә...
Тик күңел җайдә
җәяү йөгерә...

## Кояш сурәте

Караңгы кичтә,
зәмһәрир салкында
килә тизрәк язны күрәсем.

Шуңа микән,
тәрәздәге
бозлы чәчәкләр өстенә
кайнар сулыш өреп,
ясап куйдым кояш сурәтен...

## Сырхау чакта

Яз назына түзә алмый,
бөреләр шартлый гына!..
И куан идең бер чабып —
йөгерә алу шатлыгына.

## Кабырчыклар

Кабырчыклар — сүнгән тере дулкын,
диңгез шавы килә алардан.
Диңгезләрдә минем булганым юк,
кабырчыклар...
искә төшә диңгез яңадан.

Әллә канда кайнап уянамы
ерак бабамнарның хәтере?
Җир йөзеннән күптән китсәләр дә,
җанда алар исән һәм тере.

Күз алдымда (гәрчә күргәнем юк)
яшь ананың шашкан күзләре,
зәңгәрлеге белән тәтенле Күк,
чатыр чаты, учак эзләре...

Колакларда (гәрчә ишеткән юк)
ат кешнәве, елау тавышы...
Искән җилләр кагылгалап үтә,
таныгандай иске танышын.

Хәтерлим күк дала кылганнарын,
шулар аша узган юлымны.
Кабырчыклар...
Күзләремне йомам — диңгез шавы,
сукырларча сузам кулымны...

## Җиде ятны гафу иттек

Ә без
бер-беребезне
ничек шәп алдадык!
Аннары аңладык та соң,
тик күзләргә
яшьтән бүтән
берни сыйдыра алмадык.

Кайгыбыз уртак булса да,
һәркем аерым елый.
Җиде ятны гафу иттек,
ә үзебезне... булмый!..

## Мәрҗәннәр

Әкрен генә күзләреңне сөрттем,
сөртә торгач, бәлки, бер чыгар
элеккеге саф, ялангач күзләр,
гүя иртән төшкән чык сыман.

Дымлы пәрдә каплый карашыңны,
шундый якын, шундый таныш ул.
Искә төшә безнең уртак таңнар,
ак күлмәктән таңны каршылау.

Искә төшә язгы күк күкрәү,
тамыр җәеп суккан ук-яшен.
Муенсаңның җиргә сибелүе
әйтерсең лә энҗе күз яше.

Искә төшә... Әйе, сибелде ул,
коелды ул яшьлек эзенә...
Эри күзләр... ә мин мәрҗән
тезәм, ачы яшең аңа тезелә...

## Карыйсың...

Бер уйласаң,
бөтен нәрсә тәртип,
бөтен нәрсә
канун – законнарга буйсынган...

Тик нигәдер кинәт яшен яшьни...
һәм карыйсың,
күк чалт аяз,
тал сынган...



Газиз Мөхәммәтшин

# ДУЛКЫННАР ҖЫРЫ

3 ПӘРДӘЛЕК ТРАГЕДИЯ

**Катнашалар:**
Динтимер — бакырчы.
Исән — аның улы.
Коләхмәт — Исәннең иптәше, элекке кол.
Карт — киезче.
Талап — би.
Җамалбикә — аның бикәсе.
Гөлзирәк — аларның кызы.
Вәсимә, Раушания — Би сараенда Гөлзирәк белән бергә үскән кызлар.
Мирзашәех — Түбәнтау биенең улы.
Ана.
Кыз бала.
Мәчет каравылчысы.
Тимербай — башкорт атлыларының башлыгы.
Зыянгир — би гаскәрендә йөзбашы.
Тирече.
Казначы.
Бөтиче.
I-сакчы.
II-сакчы.
I-мәҗрух.
II-мәҗрух.
III-мәҗрух.
Сугышчылар, рухлар, кәнизәк кызлар, сарай хадимнәре.

---

Газиз МӨХӘММӘТШИН (1932-72) – *танылган татар язучысы, прозаик һәм драматург; «Без әле җирдә яшибез», «Кояш кызы», «Йөрәктәге эзләр», «Саумысез, аккошлар» һ.б. күп кенә китаплар авторы. «Дулкыннар җыры» – моннан кырык ел элек язылып, авторның мирас архивында яткан. Матбугатта беренче тапкыр басыла.*

*Вакыйга X-XI йөзләрдә Идел буендагы Болгар дәүләтендә бара.*

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Язгы көн. Идел яры. Урман. Күке һәм сандугач тавышлары. Сул якта имәнгә чылбырланган Исән. Янында богаулы иптәшләре — Карт белән Коләхмәт. Уң якта кораллы ике сакчы. Идел ярыннан салчылар җыры ишетелә. Аның беренчесе пәрдә артында, калганнары пәрдә ачылгач җырлана.*

*Салчылар җыры*

Идел өсләрендә дулкыннар.
Идел төпләрендә упкыннар.
Дулкын кебек ярсып шауласак та,
еласак та —
Безнең зарыбызны кем тыңлар!
Ә-ах, Идел-Иделкәй,
Ә-әй гомер-гомеркәй!..

Идел яннарында томаннар,
Идел ярларында боланнар.
Болан кебек җитез оланнарның
Кул-аягы
Нигә бәйле икән, туганнар!
Ә-ах, Идел-Иделкәй,
Ә-әй, гомер-гомеркәй!..

Идел өсләрендә саллар бар,
Илнең эчләрендә маллар бар.
Күкрәк көчен түгеп тапкан малны,
Хәләл малны
Безнең кулдан нишләп алганнар!
Ә-ах, Идел-Иделкәй,
Ә-әй гомер гомеркәй!..

И с ә н. Гел безнең хакта җырлаган шикелле.

К о л ә х м ә т. Сал бәйләүчеләр. Әй гомер-гомеркәй!

И с ә н. Болан кебек җитез оланнар идек. Ә хәзер?

К о л ә х м ә т. Хәзер Талап бинең әсирләре.

И с ә н. Ирекле болан шикелле йөргән көннәр аз булды шул.

К о л ә х м ә т. Ирекле юлбарыс шикелле диең. Боланны, ахыр килеп, Талап сунарчылары ега. Ә без аның үз ялчыларын күпме ектык!

I-с а к ч ы. Әй сез, шым калыгыз! Югыйсә төннек тишекләрегезне үзем томалармын.

II-с а к ч ы. Тимә, сөйләшсеннәр. Күпме генә гомерләре калды.

I-с а к ч ы. Әллә кызганасызмы?

II-с а к ч ы. Алар да адәм баласы ич.

I-с а к ч ы. Һа! Бу «адәм балалары» өч атна буе бөтен Идел буен тетрәтеп торды. Күпме Морзаларның дәүләтен бөлдерде. Оныттыңмы әллә?

II-с а к ч ы. Андый хәтәр эшләр тиз генә онытыламыни!

И с ә н. Ишетәсеңме?

К о л ә х м ә т. Үзәкләренә үттек.

И с ә н. Күпме ачларны туйдырдык. Күпме халык әз генә булса да ирек тәмен татып калды. Кыю идек.

К а р т. Ирекка чыккач, ир йөрәгенә кыюлык кирә, улым.

И с ә н. Бабай, син — күпне күргән акыл иясе. Әйт, бөтен хыялларыбыз пыран-заран килдемени? Бөркетләр өч кенә атна ирекгә очып калдылармыни? Хәзер нишләргә?

I-с а к ч ы. Туктагыз дим, шакшы мәхкүмнәр! Тамагыгызга пычак кертәм бит.

II-с а к ч ы. Ярар инде. Сөйләшмәгәч тә нишләсеннәр соң... Алланың кызганыч бәндәләре.

К а р т. Сакчы хак әйтә, улым. Без хәзер — кызганыч бәндәләр. Кулларда богау, муеннарда элмәк.

К о л ә х м ә т. Шулай да нишләргә соң?

К а р т. Фәләгебезгә буйсынырга кала. Җиһанның алтыны да, көче дә алар кулында.

И с ә н. Ә без?

К а р т. Без ялгыз бөркет идек. Ялгыз бөркет, гәрчә ирекгә очса да, ни кыла?

И с ә н. Без күп идек.

К а р т. Өч авыл. Алар белән бигә каршы чыгып буламы соң?

И с ә н. Чыктык ич, көрәштек!

К а р т. Көрәшебез файдасыз булды. Элек өч авыл торган урында хәзер хәрабә, көл оча. Өч авылдан исән калучылар — менә без өчебез.

И с ә н. Тагын йөз генә сугышчым булган булсачы шул чакта! Кыяксу кичүен сакласак, камый алмаслар иде. Йөз кеше житмәде.

К о л ә х м ә т. Корал булса, болай да иманнарын укытыр идек. Чалгысәнәк белән ничек жинәсең.

К а р т. Бүтән колларны күтәрә алмадык. Бергә эш — бергәйле. Ялгыз торнаның күзен карга чукый.

И с ә н. Ник мин Ташлы чишмә урманында көрәштәшләрем арасында ятмыйм?! Бергә сугыштым, әмма бергә үлә алмадым.

К а р т. Алар сине үлеләр арасыннан эзләп алды, улым. Аңсыз идең.

К о л ә х м ә т. Фетнә башлыгын каршысына тотып китерүчегә би йөгерек аргамагын вәгъдә иткән.

I-с а к ч ы. Ә Зыянгир йөз башы, сезне үтерми-нитми кайтарып житкерсәм, миңа бер куй бирәчәк. Һа! Армай сезнең бугазыгызны кых иткәндә, мин симез куй боты кимереп, кымыз чөмереп ятачакмын.

II-с а к ч ы. Зыянгирнең хәзер дә нигъмәте житеп ашкан. Ак чатырда куй тыгынып, кымыз эчеп ята. Әнә, күрәсеңме, ит кайнаган казаннарны? Исе монда да житкән шикелле, сизәсеңме?

I-с а к ч ы *(иснәнә)*. Әйе, әйе. Каравыл алмашырга күп микән әле?

II-с а к ч ы. Ку-үп...

И с ә н. Кыздыра. Дөньясын яндырырга тели, ахры.

К о л ә х м ә т. Бу нәрсәләр безне күләгәгә дә бәйләмәделәр ичмасам.

К а р т. Бөтенләй хәлем бетте. Башыма кызу капты. Бер генә йотым су!

И с ә н. Тагын иреккә чыксам күрсәтер идем мин аларга! Корбан булган дусларым өчен туйганчы үч алыр идем. Тагын бер ай, бер генә атна иректә йөрисе иде! *(Тартыла.)* Юк, нык бәйләгәннәр, каһәрләр. *(Тартыла.)*

I-с а к ч ы *(йөгереп килә)*. Кузгалма, кяфер заты! Шушы сөңге белән корсагыңны чәнчермен.

И с ә н. Теге чакта... урманда тавышыңны ишетелмәгән иде. Батыр гына олан икәнсең... богаулы адәмнәр алдында дим.

I-с а к ч ы. Ә-ә, теленә салынасыңмы, патша дошманы! *(Сөңгесен күтәрә.)*

II-с а к ч ы *(аны туктатып)*. Акылың бармы-юкмы?!. Аны үтерсәң, би үз башыңны чабачак бит.

I-с а к ч ы. Ыхх... Син аны мәеткә чутла инде. Исеме исән булса да — тиздән жаны чыгачак.

К а р т. Су, бер генә йотым су!

I-с а к ч ы. Карт көзән. Ташлы чишмәдә туйганчы эчмәдеңмени?

К о л ә х м ә т. Ялынма, бабай... Ичмасам агач күләгәсенә бәйләгез.

II-с а к ч ы. Әллә шулай итәбезме? Карт тәпиләрен сузмагае.

I-с а к ч ы. Сузса — баш китәрлек эш түгел. Гавам өчен бер тамак кимер.

И с ә н. Бабай, түзәргә тырыш. Киләчәккә көченне жыеп тор.

К а р т. Язмыштан узмыш юк. Озак газаплар күрсәтмичә тизрәк үтерсеннәр иде.

К о л ә х м ә т. Үлемнән куркасыңмы соң, бабай?

К а р т. Юк. Фани дөнья рәтләнмәсме, рәтләнмәсме, дип, гомер буе тырыштым, көттем, өмет иттем. Рәтләнмәде. Киярга киемем, ашарыма ашым, баш төртергә үз почмагым булмады. Дөньядан туйдым. Үкенми китәм.

К о л ә х м ә т. Батыр йөрәкле син, бабай. Мин куркам. Ә син, Исән?

И с ә н. Мин үлемнең үзеннән курыкмыйм. Якты дөньяны ташлап китүдән куркам. Кояштан, ләйсән яңгырлардан, салават күперләреннән, чәчәкләрдән, агачлардан, менә бу яшел яфрактан аерылуы кыен миңа. Күзләрем аларны күрмәс, колакларым Идел дулкыннары шаулавын, күк күкрәүләрен, сандугач-күке тавышларын ишетмәс. Ә

жир минем үлемемне, бер улының югалуын сизмәс тә, мин бардагы шикелле сызылып таңнар атар, кызарып кояш баер, җилләр исәр, кошлар чыркылдашыр, балыклар уйнар. Кешеләр көләр, елар. Ә мин гүр куенында ятырмын. Гүрем тар, салкын булыр, тып-тын булыр...

I-с а к ч ы. Гүр иясе булсаң, куаныр идең. Гәүдәңне котырган этләргә атмасалар...

И с ә н. Без инде хәзер үк котырган этләр кулында.

I-с а к ч ы. Һа!.. Гүрдә күрәсеңне күрсәтеп куйыйммы, байгыш?

II-с а к ч ы. Жилкенмә әле. Без аларны кыйнарга түгел — сакларга куелган. Әй, тизрәк урыныңа бас. Кыймылда инде, атаң ташбака түгелдер бит. Күрәсеңме кем килә? Би кызы.

*Жырлый-жырлый Гөлзирәк керә. Кулына чәчәкләр тоткан.*

Г ө л з и р ә к. Вәсимә, Раушания, монда килегез. Монда чәчәкләр күп.

Т а в ы ш. Хәзе-ер... Кош оясы таптым.

Г ө л з и р ә к. Нинди оя? *(Сәхнәдәгеләрне күреп.)* Ай!.. Сез кем?

*Йөгереп Вәсимә белән Раушания керә. Сәхнәдәгеләрне күргәч, чәчәкләрен ташлап кире чабалар.*

В ә с и м ә, Р а у ш а н и я. Каравы-ыл!.. Шүрәле оясы... Урман шүрәлеләре!.. Меңгә якын!.. Үтерәлә-әр!..

*Бераздан кыюланып, агач артларына поса-поса, боларны карый башлыйлар.*

Р а у ш а н и я. Үзегез шүрәлегә дә охшамагансыз икән. Кеше шикелле.

И с ә н. Кем шүрәле дип әйтә?

Р а у ш а н и я. Мин түгел.

В ә с и м ә. Мин дә түгел.

Р а у ш а н и я, В ә с и м ә. Алай булгач кем соң?

Г ө л з и р ә к. Чынлап та әйтегез әле, кем сезнең кулларыгызга богау салды? Кем сез?

II-с а к ч ы. Шанлы һәм данлы биебезнең бер бите ай, икенче бите кояштай сөекле кызы, рөхсәтегез булса, бу фәкыйрегез җавап бирер иде?

Г ө л з и р ә к. Йә, батыр сугышчы, рөхсәт итәм, әйт!

II-с а к ч ы. Боларның берсе — мәрхәмәтле әткәгезнең әмеренә буйсынмаган качкын — colларның атаманы. Калган икесе — ярдәмчеләре. Без аларның сугышчыларын кырып бетердек. Бу өчәвен, әсир төшереп, олуг би каршына алып кайтабыз.

I-с а к ч ы. Синең әткәңнең вә ки Аллаһы Тәгаләнең явыз дошманы болар. Каты газаплардан соң тереләй җиргә күмеләчәкләр, яки дә балта белән башлары чабылачак.

В ә с и м ә. Мескен бәндәләр. Газапларын җиңеләйт, Ходаем!

Р а у ш а н и я. Фәрештәләр канатлары белән каплап торсын.

Г ө л з и р ә к. Кәрванымның сезгә кушылуына ике көн. Нишләп мин аларны бер дә күрмәдем соң?

II-с а к ч ы. Күзләреңә ялгыш чалынып йөрәгеңә шом төшмәсен дип, Зыянгир йөзбашы аларны иң арттан алып барырга гарыз итте. Тукталышларда ак чатырдан читтә тотарга боерды.

Г ө л з и р ә к. Безнең көтүләрне куып китәргә, ашлык амбарларыбызны басарга ниятләгән илбасарлармыни инде бу?

И с ә н. Елкы көтүегезне генә алып киттек. Бүтән теләкләребезгә ирешә алмадык. Үкенечкә калды.

Г ө л з и р ә к. Ә-ә, мин сине таныдым, углан. Син — Динтимер бакырчы улы Исән ич.

И с ә н. Хәтереӊ әйбәт икән, чибәр кыз.

Г ө л з и р ә к. Синең дә кулларың оста иде. Бакырдан койган көзгеңне онытмадыңмы?

И с ә н. Зурлавың өчен рәхмәт! Ул көзге чынлап та әйбәт иде.

Г ө л з и р ә к. Мин аны гел үзем белән йөртәм... Болар кемнәр?

К а р т. Мин, кызым — киезче. Гомерем буе тирмә киезләре, киез бүрекләр бастым.

Г ө л з и р ә к. Картаймыш көнендә бу һөнәренне ташларга уйладынмы? Күсәк тотып урман юлларына чыктынмы?

К а р т. Тамагым туймасмы, дигән идем, кызым.

Г ө л з и р ә к. Ә син кем, егет?

В ә с и м ә. Атаманны син белсән, бу шүрәлесен без беләбез. Әйе бит, Раушания?

Р а у ш а н и я. Беләбез генә дисенме! Бу углан...

Г ө л з и р ә к. Сорамаганда, авызыгызга каз мае кабыгыз, кызлар.

К о л ә х м ә т. Мин Коләхмәт, көтүче. Әткәннең колы. Димәк, синең дә колың.

Г ө л з и р ә к. Әткәң кем?

К о л ә х м ә т. Ул да көтүче. Маткол исемле. Нәселебез белән коллар без. Исемнәребездән үк күренеп тора.

I-с а к ч ы. Әй йолдыздай нурлы йөзле гүзәл кыз, түбәнчелек белән кичерүенне сорыйм. Бу кяферләр белән озак сөйләшергә ярамый. Әткәннең фәрманы шундый.

К а р т. Су, су! Алла хакы өчен су бирегез!

Г ө л з и р ә к *(кызларга)*. Тизрәк су алып менегез.

В ә с и м ә, Р а у ш а н и я. Кичер, Гөлзирәк, без куркабыз.

II-с а к ч ы. Рөхсәт итегез, мин дә сезнең белән барыйм?

В ә с и м ә, Р а у ш а н и я. Рөхсәт, рөхсәт, бик рөхсәт!..

*Вәсимә, Раушания һәм II- сакчы суга китәләр.*

I-с а к ч ы. Изге күңелле биебезнең изге күңелле кызы, бу мәхбүсләргә су эчерергә ярамый. Могтәбәр биебезнең фәрманы шулай.

Г ө л з и р ә к. Хәзер могтәбәр би кызының фәрманын тынла, сакчы. Бу бабайны күләгәгә яткырырга кирәк. Ачкычларны бир.

I-с а к ч ы. Э-э, әй мәк чәчкәседәй алсу.

Г ө л з и р ә к. Йә!.. Мәк чәчкәседәй кызының сүзен тынламаган адәмнәрне әткәм нишләтә?

I-с а к ч ы. Зинһар харап иттермә! Ачкычлар йөзбашы Зыянгирнын үз кулында.

Г ө л з и р ә к. Күз ачып йомганчы китереп житкер!

I-с а к ч ы. Эт кебек чабам *(чыгып йөгерә.)* Әй мәрхәмәтледән дә мәрхәмәтлерәк бинен Идел камышы шикелле нечкә билле кызы... Чабам...

И с ә н. Нишлисен син, Гөлзирәк? Бигә ишетелсә!

К о л ә х м ә т. Матурлыгы гына түгел, батырлыгы да бар икән Гөлзирәкнең.

Г ө л з и р ә к. Исән, әле кунакта идем. Әткәм чакыртты. Түбәнтау биенең улы килгән. Әткәм мине шуңа бирә. Ни әйтерсең?

И с ә н. Ни әйтим! Бәхетле углан икән.

Г ө л з и р әк. Минем аны күргәнем дә юк.

И с ә н. Әткәннең үз уе бардыр.

Г ө л з и р ә к. Белмим.

И с ә н. Гөлзирәк! Алтын алмам!..

Г ө л з и р ә к. Исән батырым! Мин — ирекле кыз. Үлсәм дә мин ана чыкмаячакмын.

И с ә н. Рәхмәт, Гөлзирәк! Син чыннан да ирекле, кыю кыз, ә минем менә ирегем юк. Сәгатьләрем санаулы. Арабызда нинди упкыннар ятуын күрә торып сөйдем, йөрәгемне тыя алмадым. Кичер мине!

Г ө л з и р ә к. Син мине һаман да элеккечә сөясеңме, Исән?

И с ә н. Соңгы сулышымны алган чакта да телемдә синен исемең булыр, Гөлзирәк, йөзенә туры карый алмыйм: матурлыгыннан күзләрем камаша. Сөям, бәгърем, сөям!

Г ө л з и р ә к. Рәхмәт!.. Аһ, киләләр дә. Сез бер нәрсәгә дә гаҗәпләнмәгез. Мин ни кушсам да карышмый үтәгез, ямә?

И с ә н. Гөлзирәк!

Г ө л з и р ә к. Тсс!

*Чиләк белән су тоткан II-сакчы күренә. Артыннан, аның коралларын күтәреп, Вәсимә белән Раушания.*

Г ө л з и р ә к *(картка су салып бирә).* Эч, бабай.

К а р т. Рәхмәт, кызым, мең яшә! *(Йотлыгып эчә.)*

В ә с и м ә. Уф, бу яр ай-яй биек икән. Егылсаң, Иделгә төшеп җиткәнче җаның чыгар.

II-с а к ч ы *(коралларын киеп).* Теге кая югалды, теге?

Г ө л з и р ә к. Ачкычка китте. *(Исән белән Коләхмәткә су эчерә.)*

II-с а к ч ы. Мин җүләрне кичер, сылу кыз, әмма Зыянгир йөзбашы.

Г ө л з и р ә к. Аңа мин үзем әйтермен.

II-с а к ч ы. Тыңлыйм һәм буйсынам.

И с ә н. Суың өчен рәхмәт, көч-куәт кереп китте. Хәзер үземне ирекләгедәй батыр итеп сизәм. Бу чылбырлар да булмаса...

Г ө л з и р ә к. Әмма Зыянгир алдында бик батыраерга тырышмагыз. Ул да, безнең бөтенебез шикелле, иелгән башларны ярата.

К о л ә х м ә т. Аңлашыла. Тик сез ни уйлагансыздыр бит.

Г ө л з и р ә к. Тсс!

*Хәле беткән юан Зыянгир белән I-сакчы керә.*

З ы я н г и р. Уфф-ыфф!.. Аяк астында туфрак булыйм... Уфф-ыфф!.. Бөтен җирне актарттым... Кая киттеләр, дим...Уфф-ыфф!.. Аллага мең шөкер, югалмаганнар...Уфф-ыфф...

Г ө л з и р ә к. Кайгыртып йөрүең өчен рәхмәт, Зыянгир әфәнде. Әтиемә сине мактарга уйлап торам әле.

З ы я н г и р *(шатланып һәм ялагайланып).* Уфф-ыфф!.. Мең-мең рәхмәт яусын сиңа, дөньяда тиңе булмаган гүзәл кыз! Мин — турылыклы колың. Һәр теләгең — минем өчен изге.

Г ө л з и р ә к. Бу карт әсирне кояш сукмагае. Әллә күләгәгә күчерәргә боерасызмы?

З ы я н г и р *(икеләнебрәк).* Һм, уфф! Ничек дип әйтим... Ул инде би дошманы дисәк...

Г ө л з и р ә к. Әтиемә, авыр булса да, Зыянгир әфәнденең унганлыгы аркасында исән калдылар, диярмен инде.

З ы я н г и р. И акыллы кыз, үзем дә нәкъ шуны уйлап тора идем. Килүем дә шуның өчен иде. Әй сакчылар, ошбу картны күләгәгә күчерергә боерам!

I һ ә м II-с а к ч ы. Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз.

*Зыянгир билендәге кәмәреннән чишеп ачкыч бирә. Сакчылар картны, чылбырдан ычкындырып, күләгәгә яткыралар. Ачкычын Зыянгирга кире бирәләр, Вәсимә белән Раушания аларга булыша.*

К о л ә х м ә т. Бу Зыянгирнең кешеләргә гел зыяны гына тияме дисәм — файдасы да эләгеп куя икән.

И с ә н . Үз файдасы өчен көчәнә бит.

З ы я н г и р *(алларында кылычын бутап әтәчләнә).* Әй, сез, тыныгыз гына чыксын, телегезне кисеп агач ботагына эләрмен, ишәк углы ишәкләр.

Г ө л з и р ә к *(колакларын тотып).* Ай, батыр Зыянгир, нинди сүзләр сөйлисең!

В ә с и м ә. Фи! Аксөяк сүземе бу?

Р а у ш а н и я. Фи!

З ы я н г и р. Түбәнчелек белән баш орам, кичер, бөтен Болгар патшалыгындагы бердәнбер монтадир бинең бердәнбер зирәк кызы! Әһем... Ишәк дип әйтү уемда юк иде... Ишәк урынына бүтән сүз уйлап тора идем... Әһем... Һич ишәк түгел иде... Уфф — ыфф... Ишәк диң, ә...

*Гомуми көлү.*

I-с а к ч ы. Хи-хе~хи-хе...

II-с а к ч ы. Хо-ха-хо-ха...

З ы я н г и р *(сакчыларга җикеренеп).* Үрә кат... Э-э-э... Иш... иш... Һм, һм... Лач... лачыннар!..

Вәсимә, Раушания. Бусы менә — йөзбашы сүзе.

Зыянгир. И кызларның асыллары, күнелемне эреттегез... Ә сез көлеп калыгыз: тагын ике көннән көлә дә, елый да алмассыз, диваналар.

Исән. Анысыннан курыкмыйбыз. Сезнең ише диваналарны асылга, ефәккә төреп, акыллы адәмнәрне ачка тилмерткән гаделсез дөньясына төкереп көлә-көлә китәбез.

Зыянгир *(ярсып)*. Ы-ы-ы... Хәзер үзем көлдерәм, канлы яшегезне йота-йота көләрсез... Гаскәр!

I һәм II-сакчы. Тынлыйбыз һәм буйсынабыз!..

Гөлзирәк. Зыянгир әфәнде, болары да күз алдында тормаса иде. Карт янына чыгарсыннар.

Зыянгир. Гаскәр, карт янына чыгарып чылбырлагыз! *(Ачкыч бирә.)*

Сакчылар. Тынлыйбыз һәм буйсынабыз.

*Исән белән Коләхмәтне чыгарып кире керәләр.*

Гөлзирәк. Зыянгир әфәнде, яз бәйрәмендә бөтен мәргәннәрне җиңгәнсең. Үзең шуны телгә дә алмыйсың. Тыйнак кеше икәнсең, Зыянгир әфәнде.

Зыянгир. И дөрес әйттең, акыллы кыз — син йөргән сукмакның туфрагы булыйм — бик тыйнак мин, мәмләкәтебездә беренче тыйнак, икенче андый тыйнак юк.

Гөлзирәк. Бәйге хакында безгә дә сөйләсән иде!

Вәсимә. Әйе шул, сөйлә әле, сөйлә!

Раушания. Куй шул тыйнаклыгыңны, оялма!

Зыянгир. Нәфис аягыгызга кигән башмак булыйм. Яз бәйрәмендә мине Уразай Малик кунакка чакырды. Әче баллар да, пылау, казылык ише нәрсәләр дә, йөзем вә хәлвәләр дә күп булды. Сорнайлар кычкыртып, барабаннар кагып, кубыз, курай уйнатып, кәнизәк кызлар белән күнел ачтык... Уфф!.. Тирәяктагы Саръя башлыкларының, би-морзаларның асыл угланнары бик күп җыелган иде. Хәтта ки Бөек Болгар шәһәреннән белгуар кияве дә килгән иде...

Өченче көнне бәйге ачылды. Уразай Маликнең төпчек кызы җинеп чыккан угланга үзенең аккош канатыдай йомшак куллары белән чиккән менә шушы энҗе кәмәрне бүләк итәчәк иде. *(Билендәге кәмәрен күрсәтә.)* Менә ошбу кәмәрне, менә минем нәфис билемдәге кәмәрне... Ыхх!..

Кызлар. И-и, бигрәк матур, бигрәк затлы кәмәр икән!..

Сакчылар. Моңа угланның да угланы гына лаек. Мактау һәм дан безнең бөркет күзле, тимер куллы йөзбашына!

Зыянгир. Кит, җирәнгеч кол. Энҗесен тартып өзә яздың бит... Үрә кат! Урынына-а атла-а! Бер-ике, бер-ике... Кхы...

Гөлзирәк. Зыянгир әфәнде!..

Вәсимә. Аксөяк димәссең, фи...

Раушания. Әйе шул. Фи...

Зыянгир. Кичер, акыллы биебезнең гөл шикелле саф кызы, энҗе башмагыңның бер бөртек энҗесе булыйм. Дәвам итәргәме?

Гөлзирәк. Әлбәттә!

Вәсимә. Әлбәттә!

Раушания. Әлбәттә!

Зыянгир. Менә бәйге ачылды. Өч көн, өч төн барды. Җәя чынлавыннан, ук сызгыруыннан колаклар тонды, җәя тартып бармак тиреләре кубып төште. Бөтен затлы угланнар арып егылып бетте. Дүртенче көнне иртәнге намазга азан әйткән чакта сызык янында мин генә басып калдым.

Вәсимә. Шундый акыллы, матур мәргән киявең булса иде. Эһ...

Раушания. Эһ...

Сакчылар. Мактау һәм дан Зыянгир йөзбашына!

Зыянгир. Алтын балдагыгызның асылташ кашы булыйм, чибәр

кызлар... Гаскә-әр, үрә кат! Алга атла! Бер-ике, бер-ике. Каршыма тукта! Бер-ике. Кире беткән и... и... иш... һым... Сакчылар, нишләп хатыныгыз каршында торган шикелле тыныгыз чыкмый? Мине мактаганда тамагың ертылганчы акыр! Ягез, тагын бер! Бер, ике...

Сакчылар. Мактау һәм дан безнең дөньяда бер батыр йөзбашыбызга!

Зыянгир. Кычкырыбрак, сөнгеле карачкылар!

Сакчылар. Мактау һәм дан безнең дөньяда бер батыр йөзбашыбызга!

Зыянгир. Катырак!

Сакчылар. Мактау һәм дан безнең дөньяда бер батыр йөзбашыбызга!

Зыянгир. Хәзер ярыйсы. Һәр төштә, һәр чакны шулай акырып йөрегез. Үрә кат! Алга-а ат-ла! Бер-ике, бер-ике... Гаскәр, тук-та! Гаскә-әр, борыл! Бер-ике. Үрә кат!

Гөлзирәк. Шуннан ни булды?

Кызлар. Әйе, әйе, бәйге ничек тәмамланды?

Зыянгир. Шуннан Уразай Мәликнең төпчек кызы бөтен кәрра алдында алтын чәркәгә салып миңа бал бирде. Чәчәк шикелле иреннәрен тибрәндереп «Эч, юлбарыстай көчле, лачындай үткен күзле Мәргән!» — диде. «Биш-алты йөз углан арасында син генә миңа лаек», — диде. Яна торган җир ташы кебек кара күзләреннән нур бөркеп елмайды. «Алтын чәркәң булыйм, и гүзәлләр гүзәле!» — дидем дә төзләнеп балны әчеп җибәрдем. Шул чакта бөтен Идел буе: яшә, Зыянгир, дип кычкырып, шаулап-гөрләп, күндавылбазлар кагылып, зорна-курайлар уйнап торды.

Шуннан ул нәфис билемә шушы энҗе кәмәрне бәйләде. Бөтен Идел буе тагын шау итеп, күндавылбазлар дөпелдәп, торналар чыелдап торды.

Гөлзирәк. Егет икәнсең!

Кызлар. Яшә, асыл егет!

Сакчылар. Мактау һәм дан Зыянгир йөзбашына!

Зыянгир. И саба җиледәй йомшак тавышлы кыз, күтәрдең күңелемне, калфагыңны чиккән ука җеп булыйм... Гаскәр! Бер-ике, бер-ике... Үрә кат!.. Ы-ых!..

Гөлзирәк. Осталыгыңны без дә күрсәк иде?

Зыянгир. Бәйгеләшергә асыл зат угланнар юк бит.

Вәсимә. Бу берсе озын, берсе кыска урман шүрәлеләре ярар бәлкем?

Зыянгир. Гаскәр!.. Шушылар белән?.. Үрә кат!.. Мин?.. Бер-ике, бер-ике... Тук-та!.. Һы-ы...

Гөлзирәк. Әгәр мин бәйгедә җиңүче оланга үз кулларым белән салып бал бирсәм?

Вәсимә (*йөгереп кувшин белән бал алып керә*). Менә, би үзе генә эчә торган затлы бал.

Раушания *(йөгереп чәркә алып керә)*. Менә шул затлы балны салып эчә торган көмеш чәркә.

Гөлзирәк. Мин әллә Уразай Мәликнең төпчек кызыннан ямьсезрәкме, тимер йөрәкле Зыянгир?

Сакчылар. Мактау һәм дан тимер йөрәкле Зыянгирга!

Зыянгир. И таң алсуыдай алсу битле кыз, колагыңдагы алтын алкаңның ае булыйм. Ул бала синең башмагыңа үкчә итәргә дә ярамый.

Гөлзирәк. Әтиемнең дә колагына искәрермен — «Зыянгир йөзбашы бик игътибарлы булды», диярмен.

Зыянгир. Баш өсте. Идел камышыдай зифа буйлы кыз. Әүвәл үзем атып күрсәтим. *(Ук-җәясен көйләп.)* Усактагы саесканны күрәсеңме? Хәзер урман гайбәтчесенең җанын җәһәннәмгә җибәрәм. *(Угын төзи.)*

Раушания. Әй, әй... Җан иясе бит. Әрәм итмә. Әй, кош, кош!.. Гомере бар икән — очты. Мәмләкәттә беренче мәргән икәнсең, саескан утырган ботакка тигез!

Зыянгир. Тыйнакка күрә генә мактанмый йөрим... Һы... *(Ата.)*

Кызлар. Тиде! Ботакның очын алып китте. Яшә, мәргәннәр Мәргәне!

Сакчылар. Мактау һәм дан Мәргәннәр Мәргәненә!

Гөлзирәк. Минем кулымнан бал эчәргә лаек углан.

*(Чәшкегә бал агызып бирә.)*

Көмеш чәшке төпләрендә —
Алма кисәкләре бар.
Җырлап бирәм, эчеп җибәр —
Тәңгә сихәтләре бар.

Зыянгир. Җилкәндәге шәльяулыгыңның ука чугы булыйм, гыйззәтле би кызы. *(Эчеп җибәрә.)*

Гөлзирәк. Инде сакчылар белән алышып кара.

Зыянгир. Колың булыйм... Сакчылар, үрә кат!.. Алга-а а-ат-ла! Бер-ике, бер-ике. Ту-ук-та! Борр-рыл! Ук-җәяңне ал! Көйлә! Төзә! Ат!

Кызлар *(көләләр)*. Тимәде. Бер ук өстән, икенчесе астан очты. Хи-хи-хи...

Зыянгир. Бүлтерек бәрәннәр. *(Ата.)* Күрдегезме, ботак очын тагын кыйды.

Кызлар. Кыйды, кыйды. Мен яшә!

Сакчылар. Мактау һәм дан ботак очы кыючыга!

Вәсимә *(чәшкегә бал сала, җырлап Зыянгирга бирә.)*

Эч әле, егет, эч әле,
Эчкәнеңне күрәем.
Синең өчен мин үләем,
Хак язганны күрәем.

Зыянгир *(эчә)*. А-а-а, корсагымны ут шикелле яндырып төшеп китте. Ут төрттеләрмени. Шәпле тай кебек маңгайга типте.

Гөлзирәк. Зыянгир йөз башы, Идел буенда синнән оста бүтән Мәргән юкмы?

Зыянгир. Моңа хәтле күзләрем күрмәде, тавышын колакларым ишетмәде.

Раушания. Андый Мәргән бар.

Зыянгир. Кем ул?

Гөлзирәк. Исән атлы углан.

Зыянгир. Кайда ул? Китерегез, атышабыз.

Гөлзирәк. Ул монда, Зыянгир әфәнде. Богауда, әсир.

Зыянгир. Ә-ә-ә... Ы-ы-ы. Булмый. Ничек инде мин кол белән бәйге кылыйм? Сарай әһле йөземә төкерер, диванга кертмәс.

Гөлзирәк. Әти, гаскәр башлыгына кемне билгелик, дип кинәшкән иде. Синенчә ничек, Зыянгир әфәнде, бу урынга кем лаек булыр икән?

Зыянгир. Эһе-һе-һе, хи-хи... Кем дип... Син йөргән сукмак читендәге нәфис чәчәк булыйм... Шәһри Болгар патшасының зиһене бар синдә... Хи-хи-хи... Бар инде андый кеше, бар... һм... Сакчылар, халык дошманнарын тизрәк бире китерегез! Биебезнең Чулпан йолдызыдай кызы боера.

Сакчылар. Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз.

*Бер чылбырга теркәлгән әсирләрне алып киләләр.*

Зыянгир. Богауларын салдырыгыз!

*Сакчылар әсирләрнең богауларын салдыра, алар, берни аңламыйча, гаҗәпләнеп торалар.*

Зыянгир. Карт түмгәкне читкәрәк куегыз, боларына ук белән җәя бирегез!

Сакчылар. Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз. *(Ук-җәяләрен салып бирәләр.)*

Гөлзирәк *(колларына корал эләккәч ярсыган егетләрне тынычландырырга ашыга)*. Зыянгир әфәнде, сезнең белән атышып карамакчы була. Мин үтендем. Ул тыңлады. Сез дә тыңлагыз.

Зыянгир. Йә, адәм әтрәкләре, киер җәяңне!

Гөлзирәк. Юк, ышанмыйм, тидерә алмаслар.

Вәсимә. Уклары бер терсәк читтән китәчәк.

Раушания. Әйе, әйе.

Коләхмәт. Эх, моны усак богагына түгел — черек төпкә атасы иде. *(Ата.)*

И с ә н. Әз генә түз! *(Ата.)*

К ы з л а р. Тимәде, тимәде. Уклары бөр төрсәк читтән китте!

С а к ч ы л а р. Ха-ха-ха, хе-хе-хе...

З ы я н г и р. Әйттем бит. Менә ничек атарга кирәк. *(Ата.)*

К ы з л а р. Тиде, тиде. Ботак очын тагын кыеп төшерде. Өч тапкыр рәттән.

Р а у ш а н и я. Бу чәркә дә сиңа насыйп икән. *(Жырлап бирә.)*

Эчеп җибәр салганын,
Сорама кайдан алганын.
Эчеп җибәрсәң салганын,
Баса йөрәк янганын.

З ы я н г и р. Рррәхмәт!

Г ө л з и р ә к. Бу сөрхәнтәй сакчыларга да әзрәк бирикме әллә? Кем сугышчылары дисән, Зыянгир йөзбашы сугышчылары бит.

З ы я н г и р. А-а-а...А-а-а...

Г ө л з и р ә к. Нәрсә?

З ы я н г и р. А-а-а... а-аяк астыгызда туфрак бул-бул-булыйм... Туй-туйганчы чөмерсеннәр.

В ә с и м ә. Мәгез, сөрхәнтәйләр, туйганчы чөмерегез!

I-с а к ч ы. Сакта торганда... *(Іяк астына чиртә.)* кәгәргә рөхсәт ителми. *(Савытны тарта.)*

II-с а к ч ы *(савытны үзенә тартып).* Дөрес, теге нәрсә үзе бик нык тыя, чәнчелгере.

Г ө л з и р ә к. И Ходаем, әллә синең боерыгыңны тыңламаска итәләр инде?

З ы я н г и р. Итәләр? Кем итә, нәрсә итә?.. И-ы-ы. .. Эч!

С а к ч ы л а р *(шатланып).* Тыңлыйбыз һәм буйсынабыз!

З ы я н г и р. Үрә кат? Ку-лы-ңа чәркәне тот! Күтәр! Эче-еп җибәр!.. Бер-ике, бер-ике... Чәркәне тагын суз! Күтәр! Тагын чиртеп куй!.. Берр-ике...

В ә с и м ә. Чөмерегез, чөмер, Зыянгир саранбай үзе сыйлап торганда...

З ы я н г и р. Чәр-чәркәнне тагын суз! Күтәр! Йотып куй!.. Мин сине!.. Бер-ике, бер-ике... *(Үзе дә марш атлый башлап.)* Теләгең үтәлде... Бер-ике, бер-ике...

Г ө л з и р ә к. Әтигә синең оста Мәргән икәнеңне бик ныклап әйтермен инде.

З ы я н г и р. Минем шикелле икенче оста Мәргән әле анасыннан да тумаган.

С а к ч ы л а р. Мактау һәм дан әле анасыннан да тумаган Зыянгир йөзбашыңа!

Г ө л з и р ә к. Без дә сиңа җырлап-биеп күрсәтер идек.

З ы я н г и р. Бие соң... җыжырла...

Г ө л з и р ә к. Думбра юк. Сакчыларга боерсаң, йөгереп алып килерләр иде.

З ы я н г и р. Думбра? Ә-ә думбра!.. Гаскәр, йөгереп кил!.. Бер-ике, бер-ике...

*Сакчылар, игътибар итмичә, марш атлап үзара сөйләшәләр.*

З ы я н г и р. Гаскәр, йөгер!

I-с а к ч ы *(кул селтәп).* Тик тор әле, аптыратма! Син бит минем иң якын дустым, шуны беләсеме!..

II-с а к ч ы. Тукта, мин сөйлим әле... Мин синең өчен җанымны ярып бирәм... Кая, бер үбим әле үзеңне. Иел әле, иел!..

*Марш атлый-атлый кочаклашып үбешәләр.*

З ы я н г и р. Гаскәр, ур-урманга чап!

I-с а к ч ы. Чап та чап дип аптыратты бит бу нәрсә. Әллә чыгып тагын берәр чәркә зәмзәм эзләп карыйбызмы?

II-с а к ч ы. Әй баш та үзеңдә. Әйдә. Йөзен күрмәс идем шушы бирәннең, тфү!.. *(Кочаклашып җырлый-җырлый чыгып китәләр.)*

Биек тауларның башыннан, абзыем,
Күренә әрлән оясы, җаныем.
Михнәте күп, рәхәте юк, абзыем,
Утта янсын дөньясы, җаныем.

Г ө л з и р ә к. Уф!.. Моны чылбырлап куегыз инде.

*Зыянгирнын кулларына богау салалар, агачка чылбырлап куялар.* .

З ы я н г и р. Ә? Сез кем?.. Кая барабыз?.. Юк, мин бүтән эчмим... Кара әле, хатынны чакыр әле...

Г ө л з и р ә к. Авызына чүпрәк тыгыгыз.

К о л ә х м ә т (*Зыянгирнын авызына җилән итәге тыга).* Менә шулай. Хатын кирәк булдымыни! Кая, бу нәстәкәй берәр чәркә калмадымы?

В ә с и м ә. Калды, йә эч!

К о л ә х м ә т *(эчә).* У-ух... Тагын берәрне түнтәрсәң, атынны оныттырыр.

И с ә н. Гөлзирәк, исемне жыя алмыйм, ничек уйладың син моны?

Г ө л з и р ә к. Ярату әллә ниләр уйлата, бакырчы егет.

И с ә н. Батыр кыз син, Гөлзирәк.

Г ө л з и р ә к. Мин кәрванымны сезнең юлга бордым. Сезне бу урында ике көн көтеп тордык.

В ә с и м ә. Ни уйлавын башта безгә дә әйтмәде.

Р а у ш а н и я. Куркуымнан үлә яздым. Йөрәгем «леп-леп» килә. Серен аңлый башлагач кына хәл керде.

К а р т. Оланнар, озак юанмыйсызмы!

И с ә н. Дөрес, бабай, ычкынырга вакыт. Рәхмәт, кызлар. Хушлашыйк, Гөлзирәк!

К о л ә х м ә т. Рәхмәт, кызлар-жанкайлар! Без дә хушлашыйк, Вәсимә!

Р а у ш а н и я. Ичмасам бәләкәй сакчы да китеп югалды. Әйдә, булмаса — булган икән, без дә саубуллашыйк, бабай.

Г ө л з и р ә к. Исән, мин синең белән китәм. Бергә. Бу хәлләрдән соң атам сараена кайта алмыйм!

И с ә н. Син бу сүзләрне әйткәндә, мин үземне дөньяда иң бәхетле егет дип уйлап тордым. Рәхмәт, сиңа, әмма минем янда сиңа бик кыен булыр.

Г ө л з и р ә к. Синсез миңа тормыш юк. Күктә кояш, Жирдә якты көн юк. Калдырма мине батыр егет! Башымны кайгыга салма. Мин мәхәббәтемнән башка читлектәге сары сандугач шикелле сарыга сабышырмын.

Без бу куркыныч илдән еракка-еракка китәрбез. Чит илләргә, тыныч жирләргә. Бәхетле булырбыз.

И с ә н. Гөлзирәк! Патша биләр безне кешегә чутламыйча чабып, асып торган чакта, әти-әниләр, апа-сеңелләр ярдәм сорап ялварып торганда — ир егетнең жаны түзәрме? Ат менеп, кылыч уйнатыр углан тыныч жир эзләп китәрме!

Г ө л з и р ә к. Ходаем! Мин сине әле генә бер элмәктән йолып алдым. Икенчесенә үз ихтыярың белән башынны тыгасыңмы?

И с ә н. Ташлы чишмә урманындагыларны берәү дә йола алмас инде. Алар каны үч алырга өнди. Мине яу көтә. Үз яныма тагын көчле йөрәкле, тимер күкрәкле кыю угланнарны жыярмын. Минем кулларым богауны татыды, а-а-а, ирекнең тәмен беләм мин хәзер!.. Хуш, Гөлзирәк!

Г ө л з и р ә к. Ни күрсәк бергә күрербез. Шатлык килсә — уртак булыр, үлем житсә — жаныбыз бергә чыгар.

И с ә н. Гөлзирәк, синең күкрәгеңдә ир-егетләр йөрәге. Син — кыю кыз.

Г ө л з и р ә к. Һәм үзсүзле кыз.

И с ә н. Киттек, Коләхмәт дус, киттек, бабай!

К о л ә х м ә т. Киттек. *(Зыянгирга.)* Шөкер ит, бу юлы исән каласын. Әмма намуслы яу кырында бергә-бер очрашырга Ходай күрсәтмәсен.

К а р т. Йә, хушыгыз, оланнар! Изге юлыгыз уң булсын, теләгегез үтәлсен. Очлы уклар читләтеп үтсен, өстегезгә кылычлар күтәрелсә, фәрештәләр канатлары белән капласын. Яу кырында егылсагыз, онытылмассыз. Халык өчен гаеп китте дип, без оныкларыбызга, алар үз оныкларына сөйләр. Бәетләр әйтер, сагынып жырлар... Фатыйха, оланнар!

И с ә н. Изге теләкләрең өчен рәхмәт, бабай!

Коләхмәт. Аерыласыңмыни, бабай?

Бабай. Аерылам, оланнар. Тәнемдә аргамак иярләрлек җегәрем, кулымда сөңге күтәрерлек көчем беткән. Бу аһ-зарлы җирләрдән ераграк китеп, калган гомеремне борчусыз үткәрәсем һәм җиһан белән тыныч кына саубуллашасым килә. Хушыгыз! *(Китә.)*

Егетләр, Кызлар. Хуш, бабай!.. Хәерле юл!.. Рәхәттә яшә!.. Без сине онытмабыз!.. *(Кул болгап озаталар.)*

Гөлзирәк. Безнең атлар куак артында тышауланган.

Исән. Ашыгыйк, дуслар. Иркен сахраларга, саф җилләр кочагына! Яңа көч, яңа угланнар жыярга!

Коләхмәт. Хуш, күз нурым. Мин синең яныңа алтын башлык, ука бишмәт киеп, булат кылыч тагып кайтырмын. Сиңа бер янчык энҗе бүләк итәрмен.

Вәсимә. Һи мактанчык егет, әллә мин сездән каламмы!

Коләхмәт. Миннәнме, җаный?

Вәсимә. Синнән! Гөлзирәктән ничек калыйм, ди. Әйе бит, Раушания?

Раушания. Әйе шул. Әллә кайларга ничек ялгыз җибәрик! Бергә уйнап-көлеп үстек — бергә үләрбез.

Исән. Үләргә түгел, — җиңәргә!

*Чыгалар. Атлар чабып киткән тавыш ишетелә. Зыянгир азаплана торгач, авызыннан үзенең җилән итәген төкереп чыгара.*

Зыянгир.
Йә Зөләйха! Каный сәнең дәрдең, малы-ың,
Зиба буең, озын сачың, нечкә билең?
Тулган ай тик балкыр иде сәнен йөзең, —
Сән ул хальдән бу халгә дөшдең имди-и-и?!.

*Пәрдә*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Би сарае. Пәрдә ачылганда Талап би өстәл янында кәгазьләр карап тора. Йөзендә шатлык. Ләкин ул бик тиз борчылу белән алмашына. Би уйланып сарай буенча йөри. Әйберләрне ала, куя, тагын өстәлгә иелә, тәрәзәләрдән барып карый, Жамалбикә керә.*

Җамалбикә. Әткәсе!

Талап *(сискәнеп)*. Ә?

Җамалбикә. Борчыласың, әткәсе, йөрәгеңдә кайгың бар.

Талап. Нинди кайгы?

Җамалбикә. Белмим. Түбәнтау биенең улы Мирзашәех килгәнгә ике көн булды. Бәйрәмнәр ясарга, күнелен ачарга иде. Кияү буласы углан бит.

Талап. Күңелем бәйрәм теләми. Дөрестән дә борчылыбрак торам.

Җамалбикә. Ник, әткәсе?

Талап. Гөлзирәк кайтырга чыктык дип, бер чапкын җибәрде. Бүтән юк. Хәзер кайда ул? Ник хәбәре юк, аптырыйм.

Җамалбикә. Минем дә йөрәгем урыныннан купкан. Илләр-җирләр болганып торган заман. Теге фетнә басылдымы соң инде?

Талап. Басылды. Зыянгир йөзбашы ул инсафсыз колларны Ташлы чишмә урманында камап атлы гаскәре белән таптап, кырып бетерде.

Җамалбикә. Ходайга шөкер икән.

Талап. Ул да, иң әшәке өч колны богаулап кайтыйм, дип чапкын чаптырды да, кичәле-бүгенле чапкыннар күренми. Бу эш тә шикләндерә.

Җамалбикә. Зыянгир кулына бер эләксәләр — ычкындырмас. Кансыз вә комсыз адәм. Комсызлыгы аны усал, кыю итә. Иминлектер.

Талап. Шуның өчен мин аңа алтын саплы кылыч бүләк итәргә

ниятлим. Күрше биләр Талапның байлыгын күрсеннәр, хезмәтчеләрен ничек олылаганын белсеннәр.

Ж а м а л б и к ә. Әйбәт уйлагансың.

Т а л а п. Зыянгир, аны алгач, тагын да тырышып хезмәт итәчәк. Кол-хезмәтчеләргә тагын да усал булачак. Ә кара халык мине түгел — Зыянгирны каһәрләячәк.

Ж а м а л б и к ә. Эшне нечкә йөртәсең, әткәсе. Минем акыллы бием! *(Иркәләнә.)*

Т а л а п *(иркәләп)*. Купшы бикәм! Бу акыллы биеннән башында зур уйлар туып тора әле. Берничә елдан «Минем падишаһым!» дияргә туры килмәсен.

Ж а м а л б и к ә. Барына мең шөкер, әткәсе. Булмастае хакында хыялланмыйк.

Т а л а п. Ә мин хыялланам. Сүземне сүз итәр өчен малым да, җаным да кызганыч түгел. Кил әле бире. *(Өстәл янына киләләр.)* Күрәсеңме?

Ж а м а л б и к ә. Төшенеп җитмим. Нindидер кәкре сызыклар.

Т а л а п. Бу кәгазьгә безнең биләмәләр сызылган. Урман-болыннар, елга-күлләр — һәммәсе дә. Безнең Югарытау дәүләте уч төбендәгедәй күренеп тора.

Ж а м а л б и к ә. Ә-әй, шулай икән. Менә шәһәр, менә елга борылып киткән. Авылларга чаклы төртке-төртке итеп куйган.

Т а л а п. Монысы Түбәнтау биенең дәүләте. Безгә терәлеп тора. Би картайган, озак яшәмәс. Улы Мирзашәех безнең сарайда. Кияү булырга тора, төшендеңме?

Ж а м а л б и к ә. Төшенеп җитмим, әткәсе.

Т а л а п *(ярсый башлап)*. Көннәрдән бер көнне би җан бирә. Авыр туфрагы җиңел булсын, Аллаһы әкбәр. Урынына безнең сөекле кияү менеп утыра. Аңладыңмы?

Ж а м а л б и к ә. Безнең сөекле кияү... әйе... кияү...

Т а л а п *(ярсып)*. Ул яшь, тәҗрибәсез. Мин тотам да, яхшылап сөйләшеп, риза булмаса, гаскәремне җибәреп урыныннан бәреп төшерәм — «өф!» итеп. Ике җирне бер итәм. Талап бинең дәүләте икеләтә арта, көчәя. Аннан бүтән биләр чыштырдап карасыннар. Мин аларны берәмберәм йота барам. Халыкларын кол итәм, биләрен чыбыркы астырып көтү көтәргә җибәрәм. Ха-ха-ха!.. Аңлыйсыңмы?..

Ж а м а л б и к ә. Әткәсе!.. Акылына кил, әткәсе!..

Т а л а п. Ха-ха-ха!.. Мин үз акылымда. Шуннан, көч һәм гаскәр җыйгач, шәһри Болгарга — белгуарның үзенә сугыш белән барам. *(Йодрыкларын йомарлап.)* Җимерәм, кырам, яндырам, мәет белән бөтен мәмләкәтен каплыйм, каннан күлләр ясыйм. А-а-а, кеше башларыннан таулар өям. Болгар-тәхетенә үзем утырам... Мин — ана лаек кеше! Мин, мин, мин генә!.. Белдеңме, мин... Хәзерге белгуарны бер көймәмә ишкәкче итеп чылбырлап куям. Ишсен, ха-ха-ха!.. Йөртсен Талап патшаны!.. Ха-ха-ха...

Ж а м а л б и к ә *(куркып)*. Әткәсе! Йә, Алла, үзең сакла!

Т а л а п. Мин — падишаһым, син — ханым-солтаным! Ха-ха-ха... Аннан соң минем атлы гаскәрем вису халыкларын изеп-сытып ташлар, кара болыт булып Буртаслар җиренә бәреп керер. Тагы да арырак китәр, арырак!.. Ха-ха-ха... Мин бөтен Иделнең, бөтен җирнең... *(Кулларын җәеп җирне кочаклагандай итеп күрсәтә.)* Бөтен җирнең хуҗасы булырмын. Ха-ха-ха, ха-ха-ха... Һәр мәмләкәт, һәр патша минем аяк астымда аунап ятыр... Ха-ха-ха... Ә мин... Мин... мин!.. Ха-ха-ха, ха-ха-ха... Мин!..

Ж а м а л б и к ә. Әй Ходаем... Әткәсе, әткәсе!.. Тукта дим, җитәр. Кеше дәүләтенә нәфсеңне сузган адәм үзенекеннән дә мәхрүм кала... Әй Ходаем...

*Талап бинең экстазы үтә. Кинәт алмашынып, хәлсез адымнар белән барып урынына утыра. Башын алдына салып уйлана.*

Т а л а п *(әкрен)*. Казначы!

Ж а м а л б и к ә. Казначыны чакырыгыз!

*Казначы керә. Билен бөгеп би янына килә. Каршысына тезләнеп, башын иеп хәрәкәтсез кала.*

Т а л а п. Безне олуг дәүләтебезнең мал-байлыгы кызыксындыра!

К а з н а ч ы. Гомерең озын булсын, олуг биебез! Дәүләтең, Ходайның ярдәме белән, сәгатьләп арта. Болгар илендә иң бай буласы көнең, инша Алла, якын.

Т а л а п. Амин!

Ж а м а л б и к ә. Хуҗаның күңеленә сүзләрең ошады, казначы.

Т а л а п. Көтүләребез иминме? Төрлекчеләребез безгә әүвәлгечә ихлас белән хезмәт итәме?

К а з н а ч ы. О, тәнең сырхау күрмәсен, игелекле би! Көтүләрең, Ходайга шөкер, чебен-черки хисабында ишәя. Аларны йөртергә иркен сахра-кырлар тараеп бара. Терлекчеләрең, рәхәт тормышларыннан бик тә канәгать булып, сиңа хәерфатиха кылып гомер сөрәләр... Кичә бер коба тананың койрык шәрифе өзелеп чыккан иде. Көтүче колны камчы белән орды. Иллә карышмак та кол икән: гөнаһым юк, дип елый-елый карышып үлеп китте. Ә коба тананың койрыгы, Ходайга мең шөкер, сихәтләнде.

Т а л а п. Аллага шөкерләр итеп.

Ж а м а л б и к ә. Бу сүзләреңне дә би хуп күрде, казначы.

Т а л а п. Игенчеләребез, һөнәрчеләребез вә бүтән адәмнәребез үз шөгыльләрендәме, күңелләре тугрылыктамы?

К а з н а ч ы. Игенчеләр, Алладай күргән биебез өчен үлсәк эшләп үлә без, дип, көндез кояшта, төнлә ай яктысында һаман басуында хезмәт итәләр. Ямаулы чикмән авылы адәмнәренең сиңа хөрмәтләре бигрәк олы. Без чокырларга яшергән ашлыкларын алып чыкканда, зур куанычларыннан күңелләре тулып,чыр-чыр елашып калдылар.

Т а л а п. Ямаулы чикмәндәге тугры хезмәтчеләребезгә безнең рәхмәтебезне җиткер. Янә биш чокыр ашлыкларын алып кайт.

Ж а м а л б и к ә. Олуг биең аларны үзенең мөбарәк игътибары белән кабат куандырырга тели,

Т а л а п. Әйе, куанышып гомер итсеннәр.

К а з н а ч ы. Дөя кәрваннарың шәһри Болгар базарында бик табышлы сәүдә итеп кайтты. Бал, балавыз,кырпы балыгы җилеме, сусар, кеш, ас, кондыз, кызыл һәм кара төстәге «бортас» төлкеләре, кама, тиен ише җәнлек-җанвар тиреләре, күн әйберләр, ук саплыклары, бүрекләр, аяклы мал алып барган идек. Гарәбстан сәүдәгәрләреннан алтын-көмеш, ахак-фирәзә һәм гәрәбә, Иран сәүдәгәрләреннән кыйммәтле ташлардан төрле бизәнү әйберләре алдык. Кытайлардан бронза көзгеләр, төрле төстәге зиннәтле ефәкләр алмаштык. Парча, келәм, бөркәнчек, комган, борыч, йөзем җимеше, ир һәм хатын-кыз коллар, чикләвек ише нәрсәләр дә байтак алынды.

Ж а м а л б и к ә. Туй нәрсәләренең күбесе хәстәрләнгән икән, Алла боерса!

Т а л а п. Боерса! Боера торгач, шактый боерып ташлаган икән Аллаң! Миңа пыяла беләзек белән тәһарәт комганы түгел — Дамаск корычы, франк кылычлары, тимер киемнәр кирәк. *(Урыныннан сикереп торып, ярсып йөренә.)* Алтын кирәк миңа, алтын, алтын... алтын!.. Алтын белән булат, кылыч алдында бөтен галәм тез чүгә. Алтын белән булат кылыч — дөньяның хөкемдары. Шулар миндә булса — мин хөкемдар, мин, мин... мин!.. Ха-ха-ха!.. Мин хөкемдар булырмын!.. Моңа ирешү өчен һичнәрсәне, һичкемне, хәтта Алланың үзен дә кызганып тормам... Ха-ха-ха... Ха-ха-ха!.. Минем алтыннарымның шәүләсе патшабиләрнең күзләрен сукырайтыр, акылдан шаштырыр. Минем атлы гаскәрем булат кылычларын чайкап

дошман дәрьясына каршы чапканда, тояк тавышларыннан таулар жимерелер, елга-күлләр чайкалып ярларыннан түгелер... Ха-ха-ха, хаха-ха!.. *(Казначыны күтәреп алып муеныннан буа.)* Миңа алтын кирәк, алтын, алтын... алтын! Аны алу өчен, кесәсендә бер мыскал алтыны булган бәндәләрне менә шушы кулларым белән менә шушылай итеп мин үзем буачакмын. Төшенденме, кол?

*Казначы сүз әйтә алмый, буылып тыпырчына. Талап аны этеп жибәрә. Кинәт сүрелә. Шашкын ярсуы бер дә булмагандай юкка чыга. Әкрен генә «алтын, алтын!» дип кабатлый-кабатлый, сүлпән генә килеп урынына утыра. Башын күкрәгенә салып уйга кала.*

Ж а м а л б и к ә *(аның аркасыннан сыйпый).* Әткәсе, әткәсе! Булыр, Аллаһы боерса, жаның теләгәне булыр.

Т а л а п. Бүтәннәрнең жанын алып, үз жаным теләгәнне эшләрмен. Казначы, дәвам ит!

*Казначы идәндә аунап ята. Куркуыннан ияге төшкән, авызы ябылмый. Үзен очкылык тота.*

Ж а м а л б и к ә. Казначы, ишетәсеңме? Сиңа биең эндәшә.

К а з н а ч ы *(бер кулы белән иягеннән, икенчесе белән баш түбәсеннән этеп авызын яба. Бинең аяк очынарак килә. Моннан соң да аны вакыт-вакыт очкылык тоткалап тора).* О, сараең алтын тәңкәләр белән тулсын! Кичә бер гаскәрең Нократ жирләрен талап, ганимәтләр алып кайтты. Бер чүлмәк алтын тәңкәне печатьләп казнаңа куштым.

Т а л а п. Ә-ә, алтын!.. Әйбәт!. Гаскәргә безнең күнелебез булганын житкер. Кеше башына яртышар чүмеч әче бал бирергә, борай боламыгы пешерергә куш, туйганчы ашасыннар... Дәвам ит, казначы!

К а з н а ч ы. Тагын елкы вә дәхи сыер көтүе, ир һәм кыз коллар бар... Берсе... берәве...искиткеч... Менә... *(Бикәгә карый.)*

Т а л а п *(кызыксынып).* Йә, йә!..

*Казначы торып бинең колагына сөйли. Куллары белән хатын-кызларның гәүдә, бил-күкрәк рәвешен күрсәтә.*

Ж а м а л б и к ә *(ачуланып).* Нәрсә пышылдашасыз анда? Казначы, бикәнә дә сөйлә!

Т а л а п.. Әнкәсе, монда бикә биме, әллә менә мин би биме? Без дәүләт серен серләшәбез.

Ж а м а л б и к ә. Иркенләп сөйләшегез, күз өстегездә тормыйм. *(Пырылдап чыгып китә.)*

Т а л а п. Әнкәсе!.. Эһем... Без ул... з-э-з... тайны, әйе, әйе, тайны бүген кич үзебез кереп карарбыз. Әйбәт дисең инде, ә?

*Казначы баш бармагын күрсәтә.*

Эһем... Бик мәслихәт... Күңелле хәбәрләрең өчен сиңе бүләклисебез килә, казначы. Бер көтү савым сыеры бирикме, әллә бер янчык алтынмы?

К а з н а ч ы *(шатланып).* И юмартларның юмарты, мәңге яшә!

Т а л а п *(уйланып).* Юк, синең сыерларың болай да күп, ә алтын безнең үзебезгә кирәк. Без сиңа йә бер чибәр кәнизәк, йә бер сафьян читек бирик.

К а з н а ч ы. 0 биләр бие, рәхмәт яусын!

Т а л а п. Юк, кәнизәкне син барыбер сатып жибәрерсең, ә сафьян читек киеп син кая барасың! Гел безнең сараебызда хәтфә палас өстендә йөрисең. Иң әйбәте без сиңа бер алтын акча бирик!

К а з н а ч ы. Байлыгың артсын, юмарт би!

Т а л а п. Бисмилла иррахман иррахим! Мә әле, тот әле. *(Кесәләрен актара.)* Бәй, яныбызда акчабыз юк икән бит. Бәлкем үзеңнеке бардыр?

К а з н а ч ы *(акча көтеп кулын сузып торган жиреннән аптырашка калып).* Ә?.. Юк шул... Әй. бар, бар! Менә. *(Талапка тәңкә бирә.)*

Т а л а п *(тәңкәне карап).* Алтын!.. Нихәтле кодрәт синдә, алтын!.. Казначы, мин аны үземдә калдырам. Синең төсең итеп тотарга... Бар, чыгып эшенә тотын.

К а з н а ч ы *(аптырап).* Ә?.. Ә алтын тәңкә?!.

Т а л а п. Бар, бар, эшеңдә бул.

К а з н а ч ы. Тыңлыйм һәм буйсынам. *(Читкә,)* Каһәр генә суккан адәм икәнсең! *(Алтын тәңкәдән күзен алмыйча арты белән чигенә-чигенә чыгып китә.)*

*Җамалбикә керә.*

Җ а м а л б и к ә. Йә?!

Т а л а п. Нәрсә йә?

Җ а м а л б и к ә. Ни әйтте ул колагыңа?

Т а л а п. Бик әйбәт байтал куып кайттылар, күз салсаң иде, диде.

Җ а м а л б и к ә. Алдакчы! Кыз белән байталны аермаска мин! *(Читеген салып бигә орырга килә.)* Менә күрсәтим әле байталны!

Т а л а п *(урыныннан төшеп кача).* Әнкәсе, дим, бикә!.. Билләһи тай иде... Әлләлла!.. Озын сачлы, ягъни озын яллы...

*Куышып йөриләр.*

Җ а м а л б и к ә. Мә, мә тагын! Кызыңның туе булырга тора, оят кирәк, карт айгыр!

Т а л а п. Әлләллә!.. Айгыр түгел — яшь тай... Хадимнәр күрер...

Җ а м а л б и к ә. Казначы ләгънәтне шәһәрдән кудыртам. Уф!..

Т а л а п. Ярамый, бикәм, аңгыра булса да чут эшен әйбәт белә. Уф!..

Җ а м а л б и к ә. Гөлзирәк белән Зыянгир йөзбашыннан чапкын килде. Бүген көтегез, дигәннәр. Уф!..

Т а л а п. Уф!.. Мондый күңелле хәбәрне баштук әйтәсең калган. Читек салып интеккәнче. *(Иркәли.)*

Җ а м а л б и к ә *(иркәләнә).* Шул гадәтеңне һаман ташламыйсың. «Озын сачлы» колыныңны сатам.

Т а л а п. Сат, бикәм, сат.

*Утыралар. Җамалбикә читеген кия.*

Җ а м а л б и к ә. Куанычлы хәбәр да алынгач, Мирзашәехнең күңелен ачасы иде.

Т а л а п. Кияүгә болай да күңелсез түгелдер әле, кәнизәклар тирәсендә кайнаша шикелле.

Җ а м а л б и к ә. Кияү үк түгел ич.

Т а л а п. Булмаса — булыр. Җәтмәгә башы кергән балыкның койрыгы да кермимени? Мин аның нечкә кылларын тартып карыйм әле. Син чыгып торсаң да ярар. Сый әзерләт. Кияүне монда чакыр.

Җ а м а л б и к ә. Нечкә кылларын каты тартып өзеп җибәрмә. *(Чыга.)*

Т а л а п. Курыкма, өзмәм. Дошман адәмнәрнең башларын бик күп өзсәм дә, файдасы тиярдәй күренгән кешеләрнең кылларына да кагылмыйм... Ә теге озын сачлы, йомшак тәнле колың белән кети-кети уйнау насыйп булмады, күрәсең. Кызганыч, сатып олактырыр. *(Өстәлдәге кәгазьләрне төреп куя.)*

*Мирзашәех керә.*

М и р з а ш ә е х. Шанлы бигә кечелекле сәламем булсын!

Т а л а п. Вәгаләйкемәссәлам! Утыр, асыл углан!

М и р з а ш ә е х. Рәхмәт! Сезнең алда басып тору да бәхет.

Т а л а п. Сүзләрең күңелебезгә ошады. Вакытың ничек үтә, ямансу түгелме? Дәүләт эшләре белән мавыгып, сиңа тиешле игътибар бирә алмадык.

М и р з а ш ә е х. Мондый сарайда, мондый гүзәл җирдә ямансуларга мөмкинме соң! Ә мин — табигать баласы, табигатьне яратам.

Т а л а п. Илебез, суыбыз күңеленә хуш килсә, без шат.

М и р з а ш ә е х. Илебез сезне өзе-

леп яратучы ир-егетләргә, суларыгыз балыкка-кошка, сәхра-кырларыгыз киек-җәнлекләргә мул икән. Кичә ауга чыгып бер кыр кәҗәсе аттым.

Т а л а п. Гүзәллеккә тине булмаган икенче бер кыр кәҗәсен дә атарга ниятлисең икән, ниятлә, ниятлә! Әле чапкын килде. Кызым Гөлзирәк бүген сарайда булачак.

М и р з а ш ә е х. Бу куанычлы сүзләрдән зиһенем таралды. Ниһаять, мин чибәр Гөлзирәкне — рөхсәтегез булса — кәләшемне күрәчәкмен.

Т а л а п. Бездән рөхсәт!

М и р з а ш ә е х. Дәүләтенең игечиге булмаган олуг би, якты бәхетем тулы түгел, бер читен кара күләгә каплап тора.

Т а л а п. Без боерабыз, сөйлә!

М и р з а ш ә е х. Кәләшем мине яратыр микән соң? Яратмаса нишләрмен?

Т а л а п. Эшләмәссең. Безнең кызыбыз безнең сүздән чыга торган кыз түгел. Без кушсак — яратыр.

М и р з а ш ә е х. Рәхмәт, олуг би! Күзләрем ачылып, тирә-ягым нурланып китте.

Т а л а п. Әйе, кәләш алгач инде күзләрне бераз ачыбрак йөрсәң дә ярый... Безне икенче нәрсә кызыксындыра: кәләш белән кайда яшәргә ниятлисең?

М и р з а ш ә е х. Кадерле әткәем үз яныннан җибәрергә теләми. Олы сарайда яшәрсез, ди. Мин үзем, яна сарай салдырып, аерылып чыгуны артыграк күрәм.

Т а л и п. Ни сәбәптән, сөйлә — боерабыз!

М и р з а ш ә е х. Әткәем дәүләт эшләре белән мәшгуль. Илчеләр, сәүдәгәрләр кабул итә, мәҗлесләр үткәрә. Һич тынычлык күрми, мин андый шөгыльләрне аңламыйм да, яратмыйм да. Күңелем сәхра-болыннарга тарта.

Т а л а п. Алай икә-ән, алай икәән. Син әле яшь, асыл углан, күп хәлләрне аңлап бетермисең. Без сезгә әткәңнең олы сараенда калырга киңәш итәбез.

М и р з а ш ә е х. Киңәшегезгә төшенеп бетмим, олуг би.

Т а л а п. Безнең дөрес сүзебезгә үпкәләмә — Түбәнтау дәүләтенең куәтле бие бик олыгайды, оҗмах ишекләренә якынаеп килә. Шундый чакта төпчек улының сарайда яшәве гаҗәпме?

М и р з а ш ә е х. Сезнең акылыгыз киләчәкне бик ерактан күрә, зирәк би. Әмма сарайда минем олы абыем бар бит.

Т а л а п. Гореф буенча, әткәсе урынын төпчек ул били.

М и р з а ш ә е х. Абый беләсен. Миңа дәүләт тә, казна да, гаскәр дә кирәк түгел. Мин аңа кызыкмыйм.

Т а л а п. Кызыкканың ни?

М и р з а ш ә е х. Тыныч тормыш. Идел буенда, урман-кырларда дус угланнарны җыеп кубыз чиртеп, думбра уйнап уен-көлкеле мәҗлесләр ясауга ни җитә! Һәм тагын...

Т а л а п. Әйтеп бетер!

М и р з а ш ә е х. Шунда кәнизәк кызлар җырлап торса да әйбәт була.

Т а л а п. Һм. Озын сачлылармы?

М и р з а ш ә е х. Әйе.

Т а л а п. Һм. Кәләш куеның күргәч, кәнизәкләр белән кирәгеннән артык мавыгырга, кәеф-сафа кылырга киңәш итмибез.

М и р з а ш ә е х. Хәл каләренчә бу киңәшне тотарга тырышырмын, олуг би.

Т а л а п. Сүзләреннән шул беленде: канатларың лачынныкы түгел икән — югары оча алмассың.

М и р з а ш ә е х. Болытларга күтәрелгән күп лачыннар, канатлары каерылып, җиргә егыла, би. Ә җирдә яшәгән җиргә егылудан курыкмый.

Т а л а п. Әмма гомеребезнең алдагы көннәрендә эшләнәчәк эшләрнең куанычы бу борчуны җилел юкка чыгара.

М и р з а ш ә е х. Сүзләрегез хак, олуг би, киләчәктә эшлисе эшләребез күп әле.

Т а л а п. Ә хәзер бераз күңелебезне ачсыннар. Янәшәбездән урын

алырга рөхсәт итәбез, яшь углан.

Мирзашәех. Рәхмәт, олуг би! *(Утыра.)*

Талап *(кулга кул суга).* Музыка! Биючеләр!..

*Музыка башлана. Атылып рухлар чыга. Рухлар биюе башкарыла. Алардан соң ак ефәктән киенгән кызлар чыга. Музыка үзгәрә. Рухларның шау-шулы, барабанлы һәм быргылы тигезсез музыкасын Идел суыдай салмак һәм моңлы вальс алыштыра. Жырчы кыз жырлый, башкалар биилəр.*

*Кызлар вальсы*

Жырчы.
Алмагачка чыклар төшкән,
Аны сандугачлар эчкән —
Күрәсеңме, егеткәй?
Минем күңелем сиңа төште,
Исемнән чыкмыйсың һич тә —
Сизәсеңме, егеткәй?
Чәчәк аткан алмагачлар,
Чут-чут сайрый сандугачлар —
Тыңладыңмы, егеткәй?
Ул да тыңлый торгандыр дип,
Мине уйлый торгандыр дип,
Уйладыңмы, егеткәй?
Яз — гыйшыклар үбешкән чак,
Егет-кызлар күрешкән чак —
Беләсеңме, егеткәй?
Челтер-челтер чишмә ага,
Чибәр кызлар суга бара —
Килерсеңме, егеткәй?..

*Музыка бетә. Жырчы һәм биючеләр чыга.*

Талап. Хәзер без сиңа могжизачы күрсәтәбез. Хәерсез кол теләсә кемнең тавышы белән сөйли һәм дә ки теләсә кем сурәтенә керә.

Мирзашәех. Мин бичараны кичерегез, олуг би, ул кол сезнең үз сурәтегезгә кереп тәхетегезгә менеп утырмасын.

Талап. Борчылма, би улы. Ул безнең тәхетебезгә менәргә өлгергәнче, без аның үзен башсыз сурәткә кертербез. Ха-ха-ха!..

Мирзашәех. Ха-ха-ха... Сез дә могжизачы икәнсез, олуг би.

*Ишек артында шау-шу, көрәш башлана. Зыянгирның: жибәрегез, мин бәхетсез колны хужам янына кертегез, хужамның аяк астында жаны чыксын, а-а-а», — дигән тавышы ишетелә*

Талап *(көлеп).* Әнә, әйттем бит — хәйләкәр кол Зыянгир йөзбашының тавышы белән акыра.

*Дуртаякланган Зыянгир күренә. Шыншый-шыншый Талап би янына килә. Аның артыннан куркынган Жамалбикә керә. Хадимнәр, хадимәләр ишек төбенә жыелалар.*

Зыянгир. А-а-а-а, үз кулларың белән үтер, Мөбарәк би!..

Талап *(урыныннан күтәрелеп).* Син кем? Зыянгир йөзбашы сурәтенә кергән могжизачымы, әллә чынлап та Зыянгир йөзбашы үземе?

Зыянгир. Үзе, үзе... А-а-а...

Талап. Кем — үзе?

Зыянгир. Үзе. Зыянгир — йөзбашының үзе.

Талап. Ни булды, сөйлә!

Зыянгир. А-а-а!..

Талап. Тизрәк сөйлә, каһәр суккан адәм!

Зыянгир. Идел кыясы янында ялга туктагач, бер атлы гаскәр һөжүм итте...

Жамалбикә. Кызым!.. Ул кайда?..

Талап. Нинди атлы? Ниткән гаскәр?

Зыянгир. Фәрманыңа буйсынмаган колларның без белмәгән икенче гаскәре... А-а-а...

Жамалбикә. Кызым!.. Гөлзирәгем!.. Тизрәк әйт, ул ни хәлдә, исәнме?

Зыянгир. Гөлзирәкне дус кызлары белән әсир итеп алып киттеләр... А-а-а...

Жамалбикә. Әсир итеп!.. Йә Алла!.. Йә Алла!.. Ха-ха-ха!..

*Жамалбикә һушы китеп ауганда, Мирзашәех тотып кала. Хадимнәр Жамалбикәне күтәреп алып чыгалар.*

Т а л а п *(хәлсезәнеп урынына утыра, башы күкрәгенә салынып төшә)*. Бикә!..

З ы я н г и р. Алар меннән артык иде. Без юлбарыс шикелле сугыштык, Кяфер гәүдәләре белән Идел яры тулды, каннарыннан дулкыннар кызарды. Мин берүзем илле кешене дөмектердем.

М и р з а ш ә е х. Йөзбашына мактану килешми.

З ы я н г и р. Фетнәчеләрнең егерме бишен кырып салдым.

*Зыянгир сорау белән өч бармагын күрсәтә. Мирзашәех, ярый, дигән мәгънәдә баш кага.*

З ы я н г и р. Мин үзем генә дә аларның өч баһадирын чәнчедем.

*Талап кинәт сикереп тора. Кылычын күтәреп шашкан кыяфәттә Зыянгир өстенә бара. Зыянгир дуртаякланып әкрен-әкрен чигенә. Сүзсез сцена.*

М и р з а ш ә е х *(араларына кереп, Талапның кулларыннан тота)*. Кичерегез, мәрхәмәтле би!

Т а л а п. Алла кичерер, ә мин бу шакшыны кичермим. Үз кулларым белән башын кисеп этләргә ташлыйм.

М и р з а ш ә е х. Сезгә сүзем бар.

Т а л а п. Сөйлә, боерабыз!

М и р з а ш ә е х. Гөлзирәкне тизлек белән коткарырга кирәк.

Т а л а п. Киңәшең ни, би улы?

М и р з а ш ә е х. Моның өчен гаскәр, көч кирәк.

Т а л а п. Дәвам ит!

М и р з а ш ә е х. Ул көч менә бу адәмнәрдә. Акыллары чамалы булса да, кулларында кыргый көч. Алар сезнең көчегез. Аларны үтереп үз көчегезне киметәсез.

Т а л а п. Йә, йә!

З ы я н г и р. Би улы дөрес әйтә.

Т а л а п. Тик тор, кызганыч җан.

М и р з а ш ә е х. Ул хәзер үк Гөлзирәкне коткарырга чыгып китсен. Үзе югалтты — үзе тапсын. Үтәмәсә — җәзасын алыр.

Т а л а п. Сүзләреңдә хаклык ишетәм, би улы.

З ы я н г и р. Мәрхәмәт, мәрхәмәт, хуҗам!?

Т а л а п. Гаскәребезнең башында шушы барсын дисеңме, акыллы углан?

М и р з а ш ә е х. Әйе.

Т а л а п. Йөз кешегә баш була алмаган мәҗнүн мең гаскәрне ияртә алырмы?

М и р з а ш ә е х. Сезнең каршыгызда әүвәлге дәрәҗәсен кайтару өчен бу адәм хәзер җәһәннәмнән шайтаннар биен дә өстерәп чыгарачак.

Т а л а п. Син, хөрмәтле би улы, без уйлаганча ук беркатлы угланга охшамыйсың. Әгәр без гаскәребез башына синең үзеңне куярга уйласак?

М и р з а ш ә е х. Мин дә кәләшемне коткарырга бүген үк китәм. Әмма гаскәр белән түгел.

Т а л а п. Әйтеп бетер, боерабыз!

М и р з а ш ә е х. Башта йөзбашына әмерегезне бирегез.

Т а л а п. Тор, кол!

З ы я н г и р. Мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе, изге күңелләрнең...

Т а л а п. Әгәр сөекле кызыбыз өч көннән яныбызда утырмаса, вә яки фетнә башлыкларының кулаягына кабат богау салынмаса сине юлбарыслар читлегенә ташларга боерачакмын.

З ы я н г и р. Сөекле кызыгыз өч көннән яныгызда утырыр.

Т а л а п. Бар, ашык, йөзбашы, быргылар кычкыртып, күндавылбазлар сугып гаскәрне күтәр!

З ы я н г и р. Тыңлыйм һәм буйсынам! *(Ашыгып чыга.)*

Т а л а п. Инде сүзеңне дәвам ит!

М и р з а ш ә е х. Бу дөньяда теләгенә ирешим дисәң, өч нәрсәгә таянырга кирәк. Аның беренчесе — көч. Арыслан көчле булмаса бар җанваркиекләрне тетрәтеп торыр идемени?

Т а л а п. Дөрес. Икенче таяныч ни?

М и р з а ш ә е х. Әмма, олуг би, кайчакларда көчле арыслан сыймаган тишектән төлке үтә. Икенче таяныч — хәйлә.

Т а л а п. Монысы да дөрес, хәйләсез дөнья файдасыз.

М и р з а ш ә е х. Инде соңгысы — мәхәббәт. Көч һәм хәйлә чигенгән жирдә мәхәббәт жинә. Сөйгәненнән бер күз карашы үлене терелтә, шулай ук аның бер сүзе терене үтерә. Гыйшык эше ак шәһәрләр сала, чүлләрдә күлләр казый, тигез жирдә таулар өя, ил тутырып жимеш һәм ашлык үстерә. Гыйшык эше шулай ук илләрне бөлдерә, тәхетләрне жимерә, меңнәрчә батыр угланнарын йөзгәйөз китереп сугыштыра, суештыра, олуг би.

Т а л а п. Безнең көчебез ярсу ат менгән гаскәр, кылыч, сөңгеләр. Ул бүген, безнең әмеребез буенча, кан коярга китәчәк. Хәйләбез ни?

М и р з а ш ә е х. Сезнең зиндан базыгызда фетнәчеләр башлыгы Исән дигән угланның әти-әнисе һәм сеңлесе богауда утыра. Аларны нинди язмыш көтә?

Т а л а п. Базар мәйданында кайнап торган сумалалы казаннар көтә.

М и р з а ш ә е х. Казаннар астына утны һәрчак үрләтергә мөмкин. Бүген аның әтисен, богауларын салдырып, әмерегезне үтәсә, һәркайсына ирек вәгъдә итеп улы янына жибәрергә кирәк. Гөлзирәкне, аның дус кызларын, кяфер башлыкларын сарайга китерсен. Аннан...

Т а л а п. Аннан казаннар астын дөрләтербезме?

М и р з а ш ә е х. Дөрес, олуг би.

Т а л а п. Өченче таянычны да әйт инде.

М и р з а ш ә е х. Гөлзирәк минем кәләшем. Мин бүген кич, кол кыяфәтенә кереп, фетнәчеләр арасына китәм. Кайнар мәхәббәтем качкынколлардан үч алырга, сөйгәнемне алар тырнагыннан коткарырга ярдәм итәр, дип өметләнәм.

Т а л а п. Юк, кысыр борай башагы түгел синең баш. Карт тавыкка киңәш бирерлек күкәй була алгач, беркатлы түгел син, түгел, би улы.

М и р з а ш ә е х. Сүзләрегез күңелемә май булып ятты, олуг би. Хәзер бакырчыны чакырырга кушыгыз.

Т а л а п *(кул шапылдата)*. Хадимнәр, сакчыларга әйтегез — зиндан базыннан ир мәхбүсне китерсеннәр!

М и р з а ш ә е х. Ул карт риза булыр микән?

Т а л а п. Булмаса үзең әйткән хәйләне эшләрбез: хат яздырырбыз.

М и р з а ш ә е х. Укый-яза беләмени?

Т а л а п. Каян килеп колга хәреф тану! Хатны бөтиче язар, кул тамгасын салыр.

М и р з а ш ә е х. Сезнең башыгыз, хөрмәтле би, галим-затлар башы.

Т а л а п *(канәгатьләнеп)*. Сүзләрең безгә ошады, би улы.

*Богау чылтыравы ишетелә. Сакчылар Динтимерне алып керәләр. Ул куллары белән күзләрен каплап тора.*

М и р з а ш ә е х. Син биләрнең бие каршында күзеңне каплап торасыңмы?

Т а л а п. Аларның һәммәсе шулай итә — яктыга чыгаргач, күзләре чагыла, күрәсең.

Д и н т и м е р. Дөрес, хуҗа, зинданың бераз караңгырак шул.

Т а л а п. Бакырчы, без сине һәм синең гаиләңне ашаттык, эчерттек, жиребездә куыш корып яшәргә рөхсәт иттек. Дөресме?

Д и н т и м е р. Дөрес, хуҗа.

Т а л а п. Шулай икән, безне начар би дип буламы?

Д и н т и м е р. Син бүтән биләрдән дә начар би түгел — шулар кебек, хуҗа.

Т а л а п. Син инде кемгә хәердога кылырга тиеш?

Д и н т и м е р. Өчебез дә зинданында сиңа хәер-дога кылып ятабыз, хуҗа.

Т а л а п. Ә малаен?

Д и н т и м е р. Ул да изгелекнен кадерен белә торган углан. Богаулы кулларын күтәреп сиңа рәхмәт укый торгандыр.

М и р з а ш ә е х. Аның куллары богаулы түгел инде, бакырчы.

Д и н т и м е р *(газаплануын сиздермәскә тырыша).* Инде өлгердегезме?!. Балам!

Т а л а п. Ул иректә, бакырчы.

Д и н т и м е р. Иректә?!

Т а л а п. Әйе.

Д и н т и м е р. Ничек?

Т а л а п. Без аның богауларын салдырырга әмер иттек. Урманда калган берничә юлбасарны үгетләп хак юлга кертү өчен иреккә җибәрдек.

М и р з а ш ә е х. Ул моны эшләргә ант бирде.

Т а л а п. Вәгъдәсендә торса, без сезгә дә азатлык бүләк итмәкче идек, бакырчы.

М и р з а ш ә е х. Әмма ул антына хыянәт итте.

Т а л а п. Сараебызга кайтмады.

М и р з а ш ә е х. Зинданда газаплануыңа би түгел, үз улың гаепле.

Д и н т и м е р *(шатлыгын яшермичә).* Димәк, Динтимер оясыннан очкан бөркет исән?!

Т а л а п. Исән!

М и р з а ш ә е х. Исән.

Д и н т и м е р. Димәк, җирдә Динтимернең дә нәселе калачак!

Т а л а п. Кала!

М и р з а ш ә е х. Кала.

Д и н т и м е р. Димәк, угланнарның бер күтәргән кылычлары төшмәгән әле. Хакыйкать исән икән әле, аны бөтенләй үк буып ташлый алмагансыз икән әле!

Т а л а п. Хакыйкать?

М и р з а ш ә е х. Нинди хакыйкать?

Д и н т и м е р. Тырнагыгыздан тагын ычкынганнар икән, дим.

Т а л а п. Сүзебезгә ышанмаска батырчылык итәсенме әллә, бакырчы?

Д и н т и м е р. Юк, хуҗа, үз улымны белгәнгә күрә генә әйтүем.

Т а л а п. Күндавылбаз һәм быргы тавышлары колагына керәме, бакырчы?

Д и н т и м е р. Керә.

Т а л а п. Инде менә бу тәрәзәдән сарай мәйданына кара, ни күрәсең?

Д и н т и м е р. Гаскәрләрен сафка тезелә.

Т а л а п. Бу гаскәр Ходай кушуы, безнен әмеребез буенча, хәзер Идел урманына китәчәк.

М и р з а ш ә е х. Һәм синең фетнәче малаенны чылбырлап би каршысына китерәчәк.

Т а л а п. Ә без иң әүвәл малаенны, аннан кызың белән хатынынны синең күз алдында сумала кайнаган казанга әкрен-әкрен генә батырырга боерачакбыз. Картаймыш көнеңдә ялгыз башынны калдырмас өчен, үзеңне дә кечекләрен янына ташлатачакбыз.

Д и н т и м е р. Менә бу сүзләренә ышанам, хуҗа.

Т а л а п. Әмма без үз хезмәтчеләребезгә һәрвакыт йомшак күңелле булдык. Бу юлы да җан кыярга теләмибез. Хәзер үзеңне дә азат итәргә әмер бирәчәкмен.

М и р з а ш ә е х. Ә син улың янына кит.

Т а л а п. Башкисәр качкыннарын таратсын. Кызымны һәм аның дус кызларын сарайга кайтарсын.

Д и н т и м е р. Кызынны?

Т а л а п. Әйе, безнең Гөлзирәк исемле сөекле кызыбызны.

Д и н т и м е р. Гөлзирәк сылу алар янындамыни?

М и р з а ш ә е х. Дин дошманнары аны әсир итеп тоталар.

Т а л а п. Алар белән син үзең дә улыңны ияртеп сарайга кайт.

Д и н т и м е р. Шуннан соң ни, хуҗа?

М и р з а ш ә е х. Шуннан изге күңелле би бөтенегезне дә азат итәр.

Д и н т и м е р. Бер киткәч ник кире кайтырга? Хатыным белән кызымны да хәзер үк җибәрегез.

Т а л а п. Алар зинданда кала. Кайтмасагыз, җәзаланачаклар.

Д и н т и м е р. Кызым, әнкәсе... улым.. Менә нинди көннәргә төштем.

Т а л а п. Хәл иттеңме?

М и р з а ш ә е х. Йә, уйладыңмы?

Д и н т и м е р. Нәрсәсен уйлыйсың, ул инде күптән уйланылган.

Т а л а п. Сөйлә, боерабыз!

Д и н т и м е р. Нәселебездән сатлык адәм чыкканы юк.

Т а л а п, М и р з а ш ә е х. Ничек?

Д и н т и м е р. Үз җанымны коткарам дип, улымны изге эшенә, дусларына хыянәт итәргә өнди алмыйм.

Т а л а п. Хатының һәм кызың хакында уйла, тиле бакырчы!

Д и н т и м е р. Уйладым, хуҗа. Алар да сүземне хуплар.

М и р з а ш ә е х. Малаенны уйла!

Д и н т и м е р. Уйладым. Ул яшьтән үк кыю һәм хөр булып үсте. Мине аңлар, башы бар.

Т а л а п. Ә безнең бер тырнак астына йөзәр инә кадый ала торган оста җәлладларыбыз бар.

Д и н т и м е р. Үлем ачысы хыянәтче ләгънәтеннән татлырак.

М и р з а ш ә е х. Бәхетсез адәм, үзеңне дә, гаиләнне дә күрә торып утка тыгасың.

Т а л а п. Би улы, алтын бәһасе сүзләренне әрәм итмә. Мин бу киребеткән колны беләм. Безнең изге теләкләребезгә карышкан икән, нишләмәк кирәк — бик кызганыч булса да, җәзалаудан бүтән чара калмый. Хат язсыннар. Хатка каршы күнелебезгә хуш килердәй хәбәр алмасак, якшәмбе көнне, Аллаһы боерса, өчесен дә базар мәйданына алып чыгарбыз.

М и р з а ш ә е х. Сүзләрегездә акыл ишетәм, данлы би.

Т а л а п *(кул шапылдата)*. Бөтичене чакырсыннар!

*Бөтиче кереп баш ора. Бинең аяк очына утырып, каурый каләмен, кәгазь-карасын җайлый, язарга әзерләнә.*

Т а л а п. Яз: «Сөекле угылым! Әткәң, әнкәң һәм сенелең — өчебез дә сиңа күптин-күп сагынычлы сәламнәребезне күндерәбез вә исән-иминлек, тәнеңә сихәтлек, озын гомер теләп, Аллаһы Тәгаләгә догалар кылып калабыз.

Сөекле угылым! Сәлам соңында шуны белдерәм, без бүгенгесе көндә бинең зиндан базында ябылып ятабыз. Якты кояш нурын күрмичә сукыраешып беттек инде. Әгәр дә мәгәр бу хат кулына кергәч тә, юлбасар качкыннарыңны таркатып җибәреп, бигә баш орып кичерүен сорамасаң, киләсе якшәмбедә безне базар мәйданында сумалалы казаннарга батырып үтерәчәкләр.

Минем хакка, сиңа тормыш биргән кадерле әнкәң хакына, үзеңне өзелеп яраткан сөекле сенелең хакына безгә үлем газапларын күрсәтмә! Кайтмасаң, без сине фатихабыздан мәхрүм итеп, ләгънәтләп үләчәкбез. Соңгы сулышыбызда телебездә сиңа бәддога булыр!..

Бинең көч-куәт чиксез. Булмастай эш өчен көчәнеп үзеңне дә, безне дә һәлак итмә! Бу фани дөнья сез генә үзгәртә алырлык түгел. Алла кушмаган эш булмый. Кайт, улым! Кайтып гөнаһ эшләреңнән тәүбә итеп биебезгә баш исәң, ул, мәрхәмәт итеп, сине гафу кылыр һәм безне дә салкын зинданыннан җылы көн яктысына — иреккә чыгарыр. Кайт, угылым, берүк кайт, зар-интизар булып, канлы күз яшьләребез белән көтеп калабыз.

Бу хатны минем әйтеп торуым буенча сарай бөтичесе язды. Дөресләп тамгамны салдым. Амин!..»

М и р з а ш ә е х. Кадерле би, сез мине гаҗәп-хәйран итәсез!

Т а л а п *(канәгать елмаеп)*. Би улы, дәүләт кадәр дәүләт белән идарә итүчегә бик күпне белергә кирәк. Бу эш теләсә нинди адәми затның кулыннан килми.

Д и н т и м е р. Бу кадәр мәкер дә теләсә кемнең кулыннан килми, хуҗа. Исән угылымның күңелен әткәсен һәм әнкәсен ярату хисе җиңсә, һәм ул тозагыңа эләксә, нахакка түгелгән газиз каннарыбыз тотсын сине, хуҗа!

Т а л а п. Хатка бу ахмак колның тамгасын куегыз!

*Сакчылар Динтимернең бармагына кара буяп, аны хатка бастыралар.*

Т а л а п. Күз алдымнан югалтыгыз!

Д и н т и м е р. Үзеңә һәм нәселеңә ләгънәт төшсен, би!

*Сакчылар Динтимерне алып чыгалар.*

М и р з а ш ә е х. Мина да жыенырга вакыт, олуг би.

Т а л а п. Юлыңны уң итсен, бинең батыр угланы! Гөлзирәгемне коткарсаң, теләгәнеңне сорарсың.

*Зыянгир керә.*

З ы я н г и р. Данлыларның данлысы, шанлыларның шанлысы гайрәтле би, гаскәр сафка басты, фатиханны күтә!

Т а л а п. Әйдәгез!

*Чыгалар. Көчәя барган Кундавылбаз һәм быргычылар тавышы астында пәрдә ябыла.*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### I күренеш

*Идел буе. Каршыда текә яр. Аста Идел. Аргы якта урман-таулар. Уртада юан нарат. Нарат төбендә балта белән генә юнып ясалган өстәл, утырыр өчен агач төпләре. Пәрдә ачылганда тирә-якта сугыш тавышы.*

Я р а л ы *(сөнгесен сөйрәп аксыйаксый үтә).* Ай, ай!.. Алла! Алла!.. Бетүем шушы икән... Алла!..

В ә с и л ә, Р а у ш а н и я. *(Икенче яралыны култыклап ярдан төшеп киталәр).* Хәзер абый, хәзер. Җәрәхәтләреңне юып әйбәтләп бәйләрбез. Сызлавы шундук басылыр.

Я р а л ы *(ыңгырашып).* Укны... суырып чыгардыгызмы күкрәктән укны?

Р а у ш а н и я. Алдым, абый, алып аттым. Борчылма.

Я р а л ы. Борчылмассын...

Г ө л з и р ә к *(өченче яралыны алып керә).* Менә утыр шушында, егет. *(Башын бәйли.)* Сөңгеме?

Я р а л ы. Сөңге.

Г ө л з и р ә к. Ничегрәк булды соң?

Я р а л ы. Миләш куагы артыннан атылып чыкты мәлгунь. Карт әби янына олактырамы әллә, дип торам.

Г ө л з и р ә к. Курыктыңмы?

Я р а л ы. Курыктым дип... Бик ул чаклы түгел... Үзем дә чалгым белән муенын эләктереп өлгердем. Башы үлән арасына төшеп тәгәрәп китте. Нәкъ кабак менә...

Г ө л з и р ә к. Уф үләм, сөйләмә.

Я р а л ы. Сине би кызы диләр, шул дөресме?

Г ө л з и р ә к. Дөрес.

Я р а л ы. Син алайса сараегызда жаның теләгән ризыкны ашагансыңдыр?

Г ө л з и р ә к. Әйе.

Я р а л ы. Жаның теләгән киемне дә киденме?

Г ө л з и р ә к. Кидем.

Я р а л ы. Жаның теләгән жиргә йөрденме? Теләсәң йокладың, теләсәң тордыңмы?

Г ө л з и р ә к. Әйе.

Я р а л ы. Соң алай булгач ник безнең белән кьрмыскага талатып урманда ятасың?

Г ө л з и р ә к. Ә син үзең нишләп ятасың, егет?

Я р а л ы. Минме? Мине монда

берәү дә камчылап эшкә кушмый. Мин монда туйганчы ашыйм, беләсенме? Әле менә кичә ит ашадым. Ә минем гомеремдә ит кабып караганым юк иде. Бер елны морзаның этеннән талап алып сөяк кенә кимергән идем.

Г ө л з и р ә к. Син колмы?

Я р а л ы. Кол.

Г ө л з и р ә к. Монда бит ит кенә ашатмыйлар, сугышалар да. Үтереп куйсалар?

Я р а л ы. Үтерсәләр үтерсеннәр. Әмма кабат морза кырына кайтасым юк.

*Арыган-талган Исән керә.*

Г ө л з и р ә к. Исән!.. Ничек?.. Әйбәтме?.. Яраланмадыңмы?

И с ә н. Юк, Гөлзирәк. Уф-ф! Без аларны Иделгә куып төшердек.

*Өстәлдәге чиләктән су ала. Ләкин эчәргә өлгерми. Сәхнә аша сугышчылар йөгереп үтә башлый.*

С у г ы ш ч ы л а р. Камыйлар!.. Йә Алла!.. Болгар белгуарының атлы гаскәре килеп житте... Качыгыз, качыгыз!.. Алдагы сакны таптап үтteләр... Качыгыз!..

И с ә н *(каршы төшеп).* Туктагыз, тукта!

С у г ы ш ч ы л а р *(туктый башлап).* Исән батыр, эшләр харап!.. Без бик аз калдык...

И с ә н. Коләхмәт кайда? Исәнме ул?

С у г ы ш ч ы л а р. Әле исән иде... Яшен суккан каен янында... аучыларны ияртеп белгавыр гаскәренә каршы йөгерде.

И с ә н. Ә сез, сез?.. Үз туганнарыгызны ташлап качтыгызмы?

С у г ы ш ч ы л а р. Без ни... Алар күп... Болыт кебек...

И с ә н. Анда хәзер бер тотам аучылар мең дошманга каршы жан аямый сугыша. Ә сез, яу укларына күкрәк куясы батырлар, арка күрсәткәнсез. Батыр исеме харам сезгә!..

С у г ы ш ч ы л а р *(оялып, хурланып).* Без хәзер китәбез... Яндык... Су гына эчик тә...

*Су эчәләр. Башкорт атлылары башлыгы Тимербай керә.*

Т и м е р б а й. Кайһыгыз Исән батыр була?

И с ә н. Мин булам. Ә син кем, туган?

Т и м е р б а й. Бед — Агыйдел табагындагы башкорт ыруыннан. Минем исемем Тимербай. Морза игенселәрө. Һыбайлы утыз авылдашым менән һиңә кушылырга килгәйнек.

И с ә н. Рәхмәт, Тимербай, рәхмәт! Ярдәмегезне мәңге онытмабыз.

Т и м е р б а й. Рәхмәтенде һунынннан әйтерһөң, Исән батыр. Тирә-якта һугыш. Әмеренде бир — кайһы тарафка бәрәек?

И с ә н. Мена бу тарафта безнең сугышчыларны кысрыклыйлар.

Т и м е р б а й. Тыныс тор, Исән батыр, Мәргәннәргә ярдәмгә барып етәрбез. *(Чыга. Сәхнә артында аның тавышы.)* Атларга менәргә! Кылысларны кулларыгызга алыгыз!.. Алга, Урал таудың кыю бөркеттәре! *(Ат тояклары тавышы. Башкорт атлылары һуй-һуйләп кычкырып сугышка керә.)*

И с ә н *(кылычын күтәреп).* Минем арттан, туганнар! Би сөңгеләренә күкрәк белән!

С у г ы ш ч ы л а р. Күкрәк белән, күкрәк белән!..

Г ө л з и р ә к. Исән!

И с ә н. Гөлзирәк!

Г ө л з и р ә к. Беләкләрегезгә көч, йөрәкләрегезгә кыюлык салсын, Ходаем!

И с ә н, С у г ы ш ч ы л а р. Амин!

*Чыгып йөгерәләр.*

Я р а л ы *(урыныннан тора).* Кайда минем чалгы?

Г ө л з и р ә к. Син йөрмә, син яралы.

Я р а л ы. Дусларым тезләнеп

сугышканда күләгәдә утырыйммы? Тагын берәр кабак башны үләнгә тәгәрәтә алмаммы!..

Г ө л з и р ә к. Алла сиңа ярдәм бирсен!

Я р а л ы. Рәхмәт, сылу кыз! *(Чалгысын алып чыга.)*

*II-сакчы керә.*

II-с а к ч ы. Исәнме-саумы, мөбарәк биебезнең ай кызылдай гүзәле!

Г ө л з и р ә к. Исәнме... бәй, сакчы бит син!

II-с а к ч ы. Әйе шул. Әткәннең элекке сакчысы.

Г ө л з и р ә к. Элекке дисәнме?

II-с а к ч ы. Әйе шул. Син әсирләрне алып качкач, шыпырт кына мин дә сыздым. Тегендә кайтсам, әткәң барыбер тере килеш тиремне туный иде бит.

Г ө л з и р ә к. Монда нишләп йөрисең соң?

II с а к ч ы. Элек би гаскәре идем, хәзер шул би гаскәренең үзе белән алышып карасаң иде дим. Гомеремдә бер генә тапкыр булса да...

Г ө л з и р ә к. Изге уй белән килгәнсең, сакчы, рәхмәт!

II-с а к ч ы. Кая карама, сугышалар, кырылышалар. Иң катысы кай төштәрәк соң?

Г ө л з и р ә к. Әнә теге якта.

II-с а к ч ы. Алай икән. Ярый, мин киттем... Карале, Раушания исемле кыйгач кашлы гына, елмаючан гына дус кызың бар иде. Ул да мондамы?

Г ө л з и р ә к. Монда, батыр сакчы.

II-с а к ч ы. Әйбәт икән. Син әйт әле аңар: бәләкәй сакчы сәлам күндерде диң. Исән-сау калсам, күрешербез, үлсәк инде — каберебезгә килсен. Ярыймы? *(Колларын төкреклэп, жиннәрен сызгана.)* Бисмилла иррахман иррахим, әгузе билла һимина шайтан irражим! *(Сөңгесен алга сузып тота.)* Жиремсуым, әткәем, әнкәем өчен, Раушаниям бәгърем өчен! Йә Алла, мәдәт бир, мәдәт, мәдәт! *(Марш атлап сугыш гөрләгән якка китә.)*

Г ө л з и р ә к. Мәдәт бир, Ходаем, мәдәт, мәдәт!..

*Вәсимә белән Раушания керә.*

В ә с и м ә. Ничек түзәм мин, ничек егылмый йөрим! Чигү инәсе генә тотып өйрәнгән бармакларым канлы чүпрәк юа.

Г ө л з и р ә к. Ир-егетләргә тагын да авыррак, Вәсимә.

В ә с и м ә *(аны тыңламыйча).* Чәчәк кенә иснәп үскән идем, монда кан исеннән башым әйләнә. Мәетләр өстеннән атлап йөрим.

Р а у ш а н и я. Моннан ары чәчәк исенең кадерен ныграк белерсең.

Г ө л з и р ә к. Әйдәгез, кызлар, тизрәк! Иң көчле сугыш яшен суккан каен янында.

В ә с и м ә. Коләхмәтем дә шундамы?

Г ө л з и р ә к. Әйе.

Р а у ш а н и я. Сез бәхетле. Берегезнең Исәне, икенчегезнең Коләхмәте үз янычызда. Минем генә бәләкәй сакчым кайларда йөри торгандыр? Үле микән, тере микән!

Г ө л з и р ә к. Ул да шунда. Яшен суккан каен тирәсендә алыша.

Р а у ш а н и я. Ничек?.. Безгә каршымы?

Г ө л з и р ә к. Юк, безнең яклы. Би гаскәреннән качып хәзер генә килде. Сиңа сәлам күндерде. Исән калсам күрешербез, үлсәм каберемә килсен, диде.

Р а у ш а н и я. Бәгырькәем! Исән-сау кала, исән-сау!.. Ни карап торасыз, әйдәгез тизрәк! Батырлар янына, бәләкәй сакчым янына!..

В ә с и м ә. Әйдәгез, тизрәк, Коләхмәтем янына!

Г ө л з и р ә к Исән батырым янына! Сугышчылар янына, әйдәгез!..

*Чыгып йөгерәләр. Мирзашәех белән тирече керә.*

М и р з а ш ә е х *(ук-жәясен агач төбенә ташлый).* Уф... Бөркү, эссе. Тәмам хәл бетте.

Т и р е ч е. Бүген үтүе бик кыен

булды. Чытырманлыкка да сак куйганнар.

М и р з а ш ә е х. Тсс!

*Тирә-якны карыйлар.*

Т и р е ч е. Этле жан да юк.

М и р з а ш ә е х. Хатны алып килденме?

Т и м е р ч е. Килдем, менә.

М и р з а ш ә е х. Кирәкми. Исәннең үз кулына тапшырырсың.

Т и р е ч е. Юк, юк, син нәрсә! Күзенә чалынырга ярамый. Алар күп сөйләшеп тормый — башыңны бора да ата.

М и р з а ш ә е х. Нишләргә соң?.. Китер әле. *(Хатны алып куя.)* Монда күрми калмаслар. Кем китергәне кемгә кирәк?

Т и р е ч е. Шулай шул.

М и р з а ш ә е х. Сөйлә!

Т и р е ч е. Иделдән төшүче кяферләрне син әйткән борылышта саклап торып кырып бетерделәр.

М и р з а ш ә е х. Исән чәчләрен йолыкты.

Т и р е ч е. Син биргән исемлектәге кяферләрнең гаиләләре үтерелде, йорт-җирләре, мал-мөлкәтләре би казнасына күчте.

М и р з а ш ә е х. Казнасын онытмый, карт бирән.

Т и р е ч е. Исәннең атасы, анасы һәм сеңлесе моннан биш көн элек зиндан базында буып үтерелде.

М и р з а ш ә е х. Монысына ашыккан. Җинел котылганнар. Бөтен халыкның күз алдында акыртып газапларга иде.

Т и р е ч е. Гөлзирәк өчен бик борчылалар. Тизлек белән бер-бер чарасын күрергә боералар.

М и р з а ш ә е х. Сарайда боерып яту җинел. Минем урында булып карасыннар иде. Чабып ташларга дип кул кылычка үрелә, ә син көләргә мәҗбүр.

Т и р е ч е. Чап соң, җае чыкса.

М и р з а ш ә е х. Аның тирәсендә һәрвакыт кеше. Үзең әйткәндәй, шунда ук ботарлап ыргытырлар.

Т и р е ч е. Гөлзирәкнең үзен алып кач.

М и р з а ш ә е х. Булмый. Исән аны үзе куып җибәрсә, бөтенләй башка булыр иде.

Т и р е ч е. Ай-һай.

М и р з а ш ә е х. Исәне ташласа, мина карамый кемгә карасын Гөлзирәк? Әтисе белән минем алга кайтып тезләнәчәк.

Т и р е ч е. Бирсен Ходай!.. Ул чакта мине дә онытмассың инде, Аллаһы боерса, би улы?

М и р з а ш ә е х. Тсс! Монда би улы юк, чүлмәкче улы Мирзашәех кына бар... Даруны алып килдеңме?

Т и р е ч е. Килдем. *(Бәләкәй генә кәгазь төргәк бирә.)*

М и р з а ш ә е х *(аны кесәсенә салып).* Файдасы тияргә язсын. Менә сиңа тагын бу атнада кушылган һөнәрчеләр исемлеге. Гаиләләрен үзе карар, ә мал-мөлкәттән минем өлешкә дә нәрсә куярга хәтереннән чыгармасын.

Т и р е ч е *(исемлекне яшереп).* Мин үзем дә би-ик өлеш тиярдәй кеше инде.

М и р з а ш ә е х. Кайгырма, онытмабыз.

Т и р е ч е. Амин, Аллаһы боерса!

М и р з а ш ә е х. Ике күл арасындагы җикәнле сазлыкны беләсеңме?

Т и р е ч е. Беләм.

М и р з а ш ә е х. Аның бу ягында сакчылар сирәк. Чыгу белән Зыянгирга әйт — сазлык аша бәрсен.

Т и р е ч е. Аннан үтәрлек түгел бит.

М и р з а ш ә е х. Тал кисеп түшәсеннәр, такта, киез-фәлән.

Т и р е ч е. Бу юлы да, Алла ярдәм биреп, исән-аман ычкына алсам, әйтермен.

М и р з а ш ә е х. Ярый, бар. Юлың уң булсын.

Т и р е ч е. Бу арада күңелем шикләнә, шомлана.

М и р з а ш ә е х. Шомланса да нишләмәк кирәк. Тиречеләрең янына кайта алмыйсың. Хыянәтчеләрне берәү дә яратмый — кайтуыңа сарык

тәкәсе чалгандай чалып ташларлар.

Т и р е ч е. Юк, юк, Ходай күрсәтмәсен. Фәрештәнен «Амин!» дигән җиренә туры килмәсен!..

М и р з а ш ә е х. Ә минем янымда югалмассың. Әти карт аягын сузгач, абыйны зинданга ташлап үзем би булам. Гөлзирәккә өйләнәм. Карт бине типкәләп төшереп, ике мәмләкәтне бергә кушам. Аннан сон Болгар белгуарының бугазына ябышам. Аны бәреп тәхетенә менәм. Аннан чит халыкларны басып алам. Аннан... Аннан. Эх!.. Мин сине үземнең баш вәзирем итәрмен. Сарайда хыянәтчеләр бик кирәк. Бөтен Идел буенда миннән кала икенче шөһрәт иясе булырсың. Төшенәсенме?

Т и р е ч е. Амин, би улы!

М и р з а ш ә е х. Чүлмәкче улы — онытма! Ха-ха-ха!.. Карт җүләр кылларымны тартып карый имеш!. Киек-кош аулап, кәеф-сафа корып яшәргә яратам, дәүләт кирәкми, мин әйтәм. Ышанды карт җүләр!.. Ха-ха-ха!.. Йә бар. Хәерле юл! Шул билгеләнгән чакта килерсең.

Т и р е ч е. Хуш, Мирзашәех — чүлмәкче улы. *(Китә.)*

М и р з а ш ә е х. Хуш! *(Артыннан карап кала.)* Ху-уш!.. Бу ахмак күпне белә башлады. Кулларына капса, минем дә башны бетерер. Икенче килүендә шыпырт кына «Аллаһы әкбәр» итәргә кирәк үзен.

*Ук-җәясен алып икенче якка китеп югала. Раушания белән II-сакчы керә.*

II-с а к ч ы *(су эчә, тирләрен сөртә).* Менә булды-ы.

Р а у ш а н и я. Мин синен киләсеңне алдан ук белеп тордым.

II-с а к ч ы. Ничек?

Р а у ш а н и я. Төшемә кердең.

II-с а к ч ы. Ничек?

Р а уш а н и я. Күгәрчен булып.

II-с а к ч ы. Ничек?

Р а у ш а н и я. Ничек, ничек!.. Бик яраткан бер күгәрченем очып киткән икән, дим. Югалды дип и кайгырам, и кайгырам. Кайтты тәки. Алсуланып таң атканда иптәшләре янына пырхылдап очып төште.

II-с а к ч ы. Һм. Синен бүтән күгәрченнәрең дә бар идемени әле?

Р а у ш а н и я. Юк инде. Кыз баланың төшенә ни кермәс! Бердәнбер күгәрченем син генә.

II-с а к ч ы. Раушания!

Р а у ш а н и я. Әү.

II-с а к ч ы. Раушания!

Р а у ш а н и я. Әү дим бит!

II-с а к ч ы. Раушания... Мин сине...

Р а у ш а н и я. Йә, әйт инде, әйт!

II-с а к ч ы. Булмый. Башым әллә нишләп менә болай әйләнеп китте. Үзең бел инде!

Р а у ш а н и я. Эһ!..

II-с а к ч ы. Бигрәк җебегән нәрсә шул мин — күнелемдәгесен дә телем белән әйтә алмыйм.

Р а у ш а н и я. Нindирәк җебегән икәнеңне күрдек. Таш йөрәк икән, Ходаем: үтерерләр дә дип тормый, ичмасам. Млион дошман арасына ин алдан ук атылып кердең. Өч җайдакны кадап күтәрүеңне күреп котым алынып... сөенеп тордым.

II-с а к ч ы. Һөнәрем шул инде...

Р а у ш а н и я. Моннан болай сакланыбрак кыйлан. Үзеңне уйламасаң, мине уйла!

II-с а к ч ы. Гел сине генә уйлап йөрим инде.

Р а у ш а н и я. Уйлыйм, уйлыйм! Уйдан бүтәнне белмисең шул.

II-с а к ч ы. Нәрсәне?

Р а у ш а н и я. Бүтәнне.

II-с а к ч ы. Нәрсәне?

Р а у ш а н и я. Нәрсәне, нәрсәне!.. Үбешүне!.. Сугыш дип торып булмый бит инде — үбешәсе, кочышасы да килә.

II-с а к ч ы. Ә?!. Үпкәләмәссеңме соң?

Р а у ш а н и я. Башта үбеп кара.

II-с а к ч ы. Әгузе билла һиминә шайттан ирражим. *(Җиннәрен сызганып.)* Бисмилла иррахман

иррахим. *(Үрелеп бит очыннан үбә. Агачка тотынып тора. Кычкыра.)* Раушаниям, бәгърем, миңа кияүгә чыгасыңмы?

Р а у ш а н и я. Менә тиле баш! Синең белән үбешеп торып икенче егеткә чыкмам бит инде! Сиңа чыгам, Аллаһы боерса, чыгам, бик чыгам.

II-с а к ч ы. Әкәмәт көн әле бу! Кяферләргә кушылдым, Раушаниям белән кавыштым, кичәге дусларыма каршы сугышка кердем, гомеремдә беренче кат үбештем, җитмәсә, яраткан нечкә билемнең вәгъдәсен дә ишеттем.

Р а у ш а н и я. Ходай бәхетне бер бирсә өеп бирә ул.

II-с а к ч ы. Шулай икән. Бу болгавыр заманнар үткәч, гел бәхетле яшәрбез. Бик тырышсак, бәләкәйрәк кенә өй салып керербез. Син миңа ун-унбиш олан табып бирерсең.

Р а у ш а н и я. И, тилебәрән орлыгы ашадыңмы әллә?

II-с а к ч ы. Йә, алайсаң, дөньялар рәтләнгәнче унавы җитәр... Морзадан бераз чәчү җире алып торырбыз. Көз көне патшага, бигә, морзага, гаскәргә, гаскәр башлыгына, вәзиргә, би киңәшчесенә, муллага, мәчеткә түләсәк, бәлки үзебезгә дә тамак ялгарлык калыр.

Р а у ш а н и я. Бик әз түлисе була икән.

II-с а к ч ы. Әле бетмәде. Тәрәзә уйган өчен, мич чыгарган өчен, коедан су эчкән өчен, күпердән чыккан өчен, юлдан йөргән өчен...

Р а у ш а н и я. Житте, житте. Бигрәкләр бәхетле булабыз икән... Тагын би тәртәсенә җигелерлек булгач, ник сөнге күтәреп сугышып йөрисең, бәләкәй сакчы?

II-с а к ч ы. Ничек инде «ник»? Йөрәкне басар өчен. Биләр безне гомер буе тукмый, бинең үзен без дә бер тукмап карасак гөнаһ булмас.

Р а у ш а н и я. Коләхмәт әйтә, биләрнең берсен дә исән калдырмыйм, үтереп бетерәм, ди.

II-с а к ч ы. Тере исәр икән ул егетегез. Дөньяда бидән башка ничек яшәмәкче була? Җирне кемнән алып тора?

Р а у ш а н и я. Патшаның үзен дә үтерәм, ди.

II-с а к ч ы. Әстәгъфирулла!.. Икенче сөйләмә. Кеше-кара ишетмәсен. Патша белән бисез калсак, дөнья бетәчәк бит. Иганәне кемгә түләрбез! Шуңа да башы җитми икән мескеннең. Әйттем бит шыр исәр дип.

Р а у ш а н и я. И бәләкәй сакчым, икегезнең берегез исәр инде — кайсыгыз икән соң!..

*Коләхмәт тавышы: «Ә мин аны ботыннан тоттым да болгап агачка бәрдем!»*

II-с а к ч ы. Әнә, үзе килә. Бер бәхетсезне үтергән дә бугай инде — безгә ябышмасын.

Р а у ш а н и я. Ул үтерер. Әйдә, алай бик курыксаң, бит-кулларны юып меник.

II-с а к ч ы. Әйдә, Раушаниям!

*Җитәкләшеп китәләр, Колахмәт белән Вәсимә керә.*

К о л ә х м ә т *(су эчә, тирләрен сөртә. Сүзен дәвам итә).* Уф!.. Икенчесен сугып очырдым, өченчесен чәнечтем, дүртенчесенең муенын чабып өздем. Күрдеңме?

В ә с и м ә. Күрдем.

К о л ә х м ә т. Мин аждаһа шикелле ажгырып килеп чыккач, кая керер тишек тапмыйлар би гаскәрләре. Кубесенең куркудан «шарт» итеп йөрәкләре ярылды. Ишеттеңме?

В ә с и м ә. Ишеттем.

К о л ә х м ә т. Өермәдәй килеп тә чыктым, пыран-заран китереп кырып та салдым. Хәтерләдеңме?

В ә с и м ә. Хәтерләдем.

К о л ә х м ә т. Коләхмәт батыр булмаса эшләр харап иде, беләсеңме?

В ә с и м ә. Белүен беләм дә... Син бигрәк... Кай чакта...

К о л ә х м ә т. Әйтеп бетер, оялма!

В ә с и м ә. Кайчакта сөйли-сөйли кызып китәсең шикелле.

К о л ә х м ә т. Хым, эһем. Бәй, шулай түгелмени? Кая, алайсаң кызуымны бас әле. *(Кочаклап үпмәкче була.)*

В ә с и м ә *(тартыла)*. Әй!...

К о л ә х м ә т. Йә, йә, боргаланмый гына тор әле, яме. Әй дә түгел, мәй дә түгел. Рәхәтләнеп бер үбешмәгәч тә ник мин сине яратып йөрим! *(Кочаклап үбә.)* Менә ярады, әзрәк күңел басылды.

В ә с и м ә. Үбешеп, күңел басып йөрер заманмыни!

К о л ә х м ә т. Кайгырма. Озакламый без аларның бөтенесен үтереп бетерәбез: патшасын да, биләрен дә, Зыянгирләрен дә. Аннан инде безнең көн туа.

В ә с и м ә. Ул көн ничек булыр соң, Коләхмәт?

К о л ә х м ә т. Әйбәт!.. Э-э-э... Улмы? Ул... Иң элек бөтен түрәләрнең җанын җәһәннәмгә олактырып бетерәсең. Аннан: ирекле, хөр тормыш башлана.

В ә с и м ә. Ул хөр тормыш ничек була соң, дим?

К о л ә х м ә т. Безгә берәү дә комачаулый алмый, богау кидертә алмый. Теләсәк, без үзләрен богаулыйбыз.

В ә с и м ә. Кемне?

К о л ә х м ә т. Богавы булса — кешесе табылыр.

В ә с и м ә. Шуннан?

К о л ә х м ә т. Шуннан ашапэчеп, уйнап-көлеп, сәхра-сайранда гына яшибез. Эче бал эчеп, чәчәк иснәп кенә.

В ә с и м ә. Ә эш?

К о л ә х м ә т. Һәй, башың уйламый да инде! Элекке кебек кан-тир агызып эшләр өчен мирзаларны үтереп йөриммени мин! Эшләр өчен алалармыни хөррияткә!

В ә с и м ә. Ә кем эшләр соң?

К о л ә х м ә т. Ә-ә-ә... әле сугыш та кырылыш. Анысын уйларга вакыт эләкмәде.

В ә с и м ә. Хәзер уйлап әйт.

К о л ә х м ә т. Һе. Бик тиз. Табадагы борчакмыни ул ирекле тормыш — куырып кына алырга. Шулай да сиңа гына әйтсәм-әйтим — мин аның ничегрәк буласын, безнең өчен кемнәр эшләсен уйлыйм-уйлыйм, тик белеп житкерә алмыйм.

В ә с и м ә. Мин дә шулай шул. Исәннән сорарга кирәк.

К о л ә х м ә т. Жүләрләнденме әллә? Биләрне генә үтереп бетерим дә, вакыт ягы иркенәйгәч үзем дә серенә төшенермен. Кара аны, кешегә ычкындырма, Коләхмәт батырның шуна да башы житми икән, дип көләрләр.

В ә с и м ә. Ярый, ычкындырмам, Коләхмәт батыр.

К о л ә х м ә т. Син көлмә, сеңелкәш, сүзеңдә тормасаң — күрмәгәнеңне күрсәтермен.

В ә с и м ә. Әй Аллам, нишләрсең микән?

К о л ә х м ә т. Жиләк кебек ирennәреңнән менә шушы урмандагы агачлар вә аларның яфраклары санынча үбәрмен. Хәлдән таеп үләрсең.

В ә с и м ә. Их, рәхәт күреп үләселәрем бар икән әле!

К о л ә х м ә т. Син, кызый, Коләхмәт батырдан һаман көләсеңмени әле! *(Тотып үбә.)*

В ә с и м ә *(тартышып)*. Тора торгач бер амин дигәндәй... Кеше-кара килеп чыгар.

К о л ә х м ә т. Никахлангач мин сине гел үбеп кенә торачакмын. Патшаларны гына үтереп бетерим дә...

В ә с и м ә. Ярар, ярар, шулай итәрсең. Башта ләкин Иделдә юынып, су коенып мен.

К о л ә х м ә т. Су коену качмас, башта ашарга кирәк. Коләхмәт батыр, батыр калыйм, дисә, утырган саен бер сарык, бер казан ботка сыптырырга тиеш. Әйдә аш-сучылар янына.

В ә с и м ә. Юк, башта Иделгә!

Тартышалар.

К о л ә х м ә т. Юк, ашарга!

В ә с и м ә. Юк, юынырга!

К о л ә х м ә т. Ә-ә шулаймы? Син әле никахлашмас борын карыша башладыңмы, сеңелкәш!..

*Вәсиманe күтәреп ала да, үбә-үбә чыгып китә. Вәсиманең: «Уф, тыным бетте», — дигәне ишетелеп кала.*

*Исән белән Гөлзирәк керә.*

И с ә н *(керешли борылып сәхнә артындагыларга дәшә).* Әһлисафа, син хәзер барлык сакларны йөреп чык. Арганнарны алыштыр.

Т а в ы ш. Ярый, Исән батыр.

И с ә н. Чүлмәкче бабай, син мәҗрухларны кара. Хәзер үзем дә барырмын.

Т а в ы ш. Киттем, улым, тыныч бул.

И с ә н. Хәерле юл! *(Су эчә, тирләрен сөртә.)* Тамак янганда шушы суның рәхәтлеге!

Г ө л з и р ә к. Бүген тамак янарлык хәлләр булды. Атыңнан егылгач куркуымнан истән тая яздым.

И с ә н. Мина икенче ат китерделәр ич. Аңа ник истән тая яздың әле, ә?

Г ө л з и р ә к. Таймыйча...

И с ә н. Гөлзирәк! Син булмасаң мине ун кат үтерерләр иде инде, синең мәхәббәтең саклап килә. Сине күрсәм йөрәгемә гайрәт керә. Безнеке шикелле мәхәббәт дөньяда бик сирәктер. Ул бәхетле парларга гына эләгәдер. Иманым да, сулавым да син! Зинһар, хисләреңә бирелеп хәтәр урыннарга кермә, ук-кылычлардан курыкмыйм димә — курык. Сине югалтсам миңа яшәү юк.

Г ө л з и р ә к. Исән, минем өчен борчылма. Борчуларың болай да житәрлек, жаным. Син ничә йөз кешегә баш. Алар сине яраталар, синең арттан утка да, суга да керәләр. Шуларны уйла. Ә мин... Мин сине сөям. Син егылсаң, миңа да якты дөнья караңгы.

И с ә н. Син минем өчен зиннәтле сарайларыңны, рәхәт тормышыңны ташладың. Моның өчен мин сиңа гомерем буе бурычлы. Изгелекләреңә изгелек белән җавап кайтара алсам иде, Гөлзирәк.

Г ө л з и р ә к. Миңа сарайлар кирәкми, алар минеке түгел.

И с ә н. Сиңа монда бик кыенмы?

Г ө л з и р ә к. Сезгә ничек — миңа шулай.

И с ә н. Ләкин без мондый тормышка күнеккән, икенче төрлесен күрмәгән.

Г ө л з и р ә к. Шуның өчен сугышабыз. Теләгәнчә яшәү өчен.

И с ә н. Үзебез теләгән тормыш, синеңчә, ничек ул, Гөлзирәк?

Г ө л з и р ә к. Әйбәт.

И с ә н. Әйбәт төрлечә була.

Г ө л з и р ә к. Әйбәт инде.

И с ә н. Ярый. Беренчеләй, Коләхмәт әйтмешли, биләрнең, морзаларның нәсел-нәсәбен калдырмый кырып салдык ди. Шуннан соң нәрсә?

Г ө л з и р ә к. Биләр беткәч, икмәгеңне дә, әйбереңне дә талап алмыйлар.

И с ә н. Патшасыз, бисез тормыш ничек?

Г ө л з и р ә к. Әйбәт инде, әйбәт.

И с ә н. Мин дә әйбәт икәнен беләм. Тик ул «әйбәт» ничегрәк була — анысына зиһенем житми. Дәүләт икән, аның нинди дер тәртибе яшәргә тиештер, ләбаса. Патша шикелле мәмләкәтне тотып торган бер үзәк калырга тиеш. Ә киңәш-табыш итәргә озакламый Болгар патшасына да барып булмаячак, чөнки Коләхмәт аны кабыргасыннан тимер ыргак белән күккә асам дип кыҗырып йөри. *(Көлә.)*

Г ө л з и р ә к. Эш аңа житсә, бирәр башлы кеше табылыр. Ил белән киңәшербез, ил киңәшен тоткан абынмас.

И с ә н. Акыллы сүзләрең өчен рәхмәт яусын. Мин боларны сиңа гына, болай гына әйттем. Бүгенгесен уйларга кирәк. Һөҗүмне кагу кыен булды. Ә бит алар котырганнан котыра бара.

Г ө л з и р ә к. Ул минем өчен дә котыра.

И с ә н. Кем?

Г ө л з и р ә к. Би.

И с ә н. Үз янына мәңге кайтмасыңны анлый бит инде ул.

Г ө л з и р ә к. Әлбәттә. Тик кайсы би үз кызының, ул уйлаганча, коллар арасында качып яшәвенә түзәр? Бу хурлык аның өчен үлем белән бер. Тере килеш кайтара алмаса, үле гәүдәмне булса да йолып алмыйча тынычланмый инде ул.

И с ә н. Ә минем әткәй-әнкәй!.. Сеңелем!..

Г ө л з и р ә к. Алар кайсы илләрдә микән инде!

И с ә н. Анламассың: мин синең әтиеңә каршы сугышам, минекеләр, ул зинданга ташларга теләгәч, качып киттеләр, син минем янда үз әтиеңә каршы сугышасың, без икебез берберебезне өзелеп сөябез. Зил-зиләбә килеп, бөтенләй болганып беткән бу дөнья.

Г ө л з и р ә к. Язмышта шулай язылгандыр инде.

И с ә н. Бер очы чыгар-чыгуын. Ярый, мин яралылар янына киттем. Син нишлисең?

Г ө л з и р ә к. Без кер юабыз.

И с ә н. Эшем беткәч яныгызга төшәрмен. Гөлзирәк тә китәргә җыена.

*Мирзашәех керә.*

М и р з а ш ә е х. Гөлзирәк, минем өчен бер минут вакытың булырмы?

Г ө л з и р ә к. Тыңлыйм.

М и р з а ш ә е х. Сүземне уйладыңмы?

Г ө л з и р ә к. Уйладым.

М и р з а ш ә е х. Соң?

Г ө л з и р ә к. Миннән булмый, Мирзашәех.

М и р з а ш ә е х. Бик кызганыч, Гөлзирәк.

Г ө л з и р ә к. Сугышчылар мине үз кызлары шикелле якын күрә. Аларны ташлап китә аламмы?!

М и р з а ш ә е х. Алар сине яраткач, син дә аларны яратырга тиеш.

Г ө л з и р ә к. Яратканга күрә китмим дә.

Яраткач китәргә кирәк.

Г ө л з и р ә к. Анламыйм.

М и р з а ш ә е х. Хәзер ачыктаначык сөйләшергә була. Хәлебезне үзең күреп торасың. Көчебез кими. Ярдагы мәгарә мәҗрух адәмнәр белән тулган, азык-төлек бетте, корал житми, качып килүчеләр юк. Иң куркынычы шул — кешеләрнең күңеле үзгәрде. Шушы караңгы урманнан ычкынмаячакларын сизәләр.

Г ө л з и р ә к. Мин нишли алам?

М и р з а ш ә е х. Син аларны коткар. Би синең өчен үч ала бит. Синең аркада бер гөнаһсыз чибәр угланнар кырыла.

Г ө л з и р ә к. Ничек коткарырга соң?

М и р з а ш ә е х. Әйтәм бит, ташла безне, кайтып кит. Ул сине ярата — кичерер. Аннан безне эзәрлекләүдән туктар.

Г ө л з и р ә к. Туктар дип уйлыйсыңмы?

М и р з а ш ә е х. Безнең өчен дә гафу сорарсың.

Г ө л з и р ә к. Әтинең холкын беләм. Мин китсәм ул сезгә тагын да зәһәррәк каныгачак. Ул әле мин монда булганга тынычрак кылана.

М и р з а ш ә е х. Сүзем бетте, би кызы. Тик аяусыз бәйгедә җан биргән егетләрне онытма. Аларның каннары исәннәр өстенә төшә.

Г ө л з и р ә к. Ялгышасың, Мирзашәех. Егетләр үз теләкләре белән бәйгегә чыкты. Бәйге корбансыз, кансыз узмаганын аңлап, белеп чыкты. Авыр хакыйкать, нишләмәк кирәк!

М и р з а ш ә е х. Күңеленә авыр кагылсам, кичер. Мескен адәмнәрне үлемнән алып булмасмы дип әйтүем иде. *(Өстәл янына утыра. Яңа гына күргән шикелле, андагы хатны кулына ала, әйләндерә-әйләндерә карый.)* Бу нинди хат? «Кәферләр башлыгының үз кулына тапшырылсын» дигән. Исән онытып калдырды микән?

Г ө л з и р ә к. Кая әле? *(Хатны карый.)* Исән әле моны күрмәде. Кулын таныйм — безнең сарайдан. Пичәте дә әтинеке. Кем китерде микән моны?

М и р з а ш ә е х. Исән үзе куйгандыр.

Гөлзирәк. Юктыр. Хат ачылмаган.

Мирзашәех. Әллә ачып карыйсынмы?

Гөлзирәк. Исәнгә дигәч, Исән ачсын. Әнә үзе кайта, гомере озын икән.

*Исән керә.*

Гөлзирәк. Исән, сиңа хат бар.

Исән. Хат? Кем бирде?

Мирзашәех. Белмибез, өстәлгә куеп киткәннәр.

Исән. Кай җирдән?

Гөлзирәк. Сарайдан.

Исән: Сарайдан!.. Кем китерде икән? Димәк, безнең саклар аша үтеп йөриләр. *(Хатны ача, укый. Янадан укый башлый. Маңгаен ышкып уйлана.)*

Мирзашәех. Ни язалар?

Исән. Мә... укы.

Мирзашәех *(хатны укып чыга. Йөзендә хәйләкәр елмаю. Гөлзирәк ишетсен дигән теләк белән.)* Һм. Күнелле хәл түгел. Әле һаман зинданда утыралар икән.

Гөлзирәк. Кемнәр зинданда, кемнәр? *(Хатка кулын суза.)*

Мирзашәех. Юк, болай гына. *(Хатны Исәнгә бирә.)*

Гөлзирәк Исән, сез миннән нидер яшерәсез.

Исән. Бер сугышчы әсир төшкән иде. Би зинданында җәфалана.

Гөлзирәк. Ә нишләп миңа хатны күрсәтмисез?

Исән. Син ул егетне барыбер белмисең, Гөлзирәк, хафаланма.

Гөлзирәк. Исән, син борчылсаң, мин дә, бөтенебез дә борчылабыз. Куанычыбыз булса, бергә куанабыз.

Мирзашәех. Хак әйттең, би кызы: качышлы уйнаудан файда юк. Исәннең әти-әнисе, синең кебек зифа буйлы чибәр сеңлесе бинең салкын зинданында үлем көтеп ята.

Гөлзирәк. Йә Аллам! Колакларым ни ишетә! Дөресме бу сүзләр, Исән?

Исән. Дөрес.

Гөлзирәк. Син бит... син бит аларны качып өлгерделәр, котылдылар дигән иден?

Исән. Кызганычка каршы, котыла алмадылар.

Гөлзирәк. Шуны белеп, нинди газап, хәсрәт йотып сугышып йөрдеңме?

Исән. Хәсрәт бер миндә генәмени! Хәсрәт ил белән.

Гөлзирәк. Ичмасам бер сүз әйтсә, сиздереп караса иде!

Мирзашәех. Унайсыз бит, Гөлзирәк. Сез монда Таһир белән Зөһрә шикелле, ә анда синең атаң аларны богаулап тота. Тиздән җәллад кулына бирәчәк.

Гөлзирәк. Китер әле! *(Хатны алып укый, йөзендә тирән тетрәү һәм газап.)* Ул сине чакыра. Кайтсаң... Кичерүен сорасаң, әтиләреңне азат итәчәк... Юк, син түгел — миңа кайтырга кирәк.

Мирзашәех. Син күзенә күренгәч, бинең ачуы онытылачак. Бала бит, бердәнбер кызы.

Исән. Син ни сөйлисең?

Гөлзирәк. Ул хаклы. Бу афәтләр һәммәсе минем аркада.

Исән. Түгел, Гөлзирәк. Бәндәләрне байга һәм ярлыга син аермаган. Ач коллар көннәрдән бер көнне үзләре үстергән икмәкне барыбер сорарлар иде.

Мирзашәех. Әтиең сине чакырган, би алдына барып баш июеңне үтенгән. Би шуннан соң ирек бүләк итәр, дигән.

Исән. Әти берәүне дә көтми.

Мирзашәех. Аңламыйм — тамгасы әтиеңнеке түгелмени?

Исән. Тамгасы аныкы, ләкин сүзләре аныкы түгел.

Мирзашәех. Ничек?

Исән. Ул туры сүзле, дөрес кеше. Тереләй утка салсалар да үз сүзеннән кайтып, тезләнәчәк түгел.

Мирзашәех. Димәк...

Исән. Әйе, тамганы ул үз ирке белән салмаган.

Мирзашәех. Әмма зин-

дан һәм бүген-иртәгә жәза дигән нәстәкәйләр дөрес бит?

И с ә н. Дөрес.

М и р з а ш ә е х. Нишләргә уйлыйсың?

И с ә н. Авыр мина, Мирзашәех. Син нишләр идең?

М и р з а ш ә е х. Мин тәкъдирдән узарга тырышмас идем.

И с ә н. Мин аңа бирелсәм дә, би сүзендә тормаячак.

М и р з а ш ә е х. Алайса Гөлзирәкне кайтарырга кирәк.

Г ө л з и р ә к. Исән!?.

И с ә н. Йөрәгенне тынла, Гөлзирәк.

Г ө л з и р ә к. Әмма... ничек инде? *(Сүз таба алмый,)*

М и р з а ш ә е х. Исән синең китүенне тели.

Г ө л з и р ә к. Син чынлап шуны телисеңмени, Исән?

И с ә н. Әткәй-әнкәйдән дә, сеңлемнән дә, синнән дә калсам, бу дөньяда ничек яшәрмен, Гөлзирәк?

М и р з а ш ә е х *(үз алдына).* Бу дөньяда озак яшисең калмады инде, хәерче. *(Кычкырып.)* Ил эше өчен мәхәббәтне корбан итү олы йөрәкле угланнарның гына кулыннан килә.

И с ә н. Сина сакка барырга вакыт түгелме, Мирзашәех?

М и р з а ш ә е х. Минем сүзләрем турында уйла, Исән.

*Коралларын алып китә. Коләхмәт, кусәк белән төрткали-төрткали, әрлиәрли мәчет каравылчысын алып керә.*

К о л ә х м ә т. Атла аягынны, дошман, би тәлинкәсен ялаучы кабахәт! Исән батырга гына күрсәтәм дә үз кусәгең белән сугып дөмектерәм.

И с ә н. Нинди адәм бу, Коләхмәт?

К о л ә х м ә т. Би шымчысын каптырдым.

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Китсәнә, инәңнең башы! Ниткән шымчы булыйм мин, син үзең шымчы!

И с ә н. Син кем сон, бабай?

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Түбәнтау бие жирендәге Үгез күзе дигән авылның мәчет каравылчысы булабыз, Ходай кушса.

К о л ә х м ә т. Әйттем бит. Һи, мәчет күсесе!

И с ә н. Монда күптәнме? Нишләптер күргәнем юк.

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Күрмәссең шул Аллаһы боерса. Юлбасар шикелле кусәк күтәреп йөрүемә беренче генә көн... Бир кусәкне, маңка, имансыз үткәрәм бит!

К о л ә х м ә т. Курыкма, кусәгеннән аерылмассың — каберенә салырмын.

И с ә н. Нишләп мәчетенне каравыллап кына ятмыйсың?

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Каравылдан чыктым.

И с ә н. Нишләп чыктың?

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Әйттерерсең әлләни, инәңнең башы! Ләгънәт мөәздин кәкре башлы кәвеше белән — бу кыз булса да әйтим инде — менә шушы ят жиренә китереп торып типкәч, чыкмый нишлисең... Бир кусәгемне!

И с ә н. Монда ни өчен килдең?

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Тугыз кызны кияүгә бирәсе бар, инәңнең башы. Гел кыз булып тудылар, ахмаклар. Бирнәсез этем алсынмыни ул имансызларны. Ә сезнең хакта, байларны талап акчасын бүлешә, дип ишеттек... Бир кусәгемне, малай актыгы.

К о л ә х м ә т. Тегендә ни лыгырдадың, шуны әйт, боргаланма!

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Боргаланырга кайнар көлгә төшкән еланмы әллә мин? Арагызда кяферләр бар икән — чыелдатып чучка суйдылар да чупылдатып ашадылар. Тфү, тфү... Әльгаязе биллаһ, имансыз үтәрсең... Монда ничек ятыйм мин. Акча да өләшүче юк. Кайтам. Карак мөәздин үзе чучка булса да чучка ите жыймый. Китап та үз мөселманың типкән урын тәмугта янмас, дигән бугай... Бир кусәкне, эт малае, китәм.

К о л ә х м ә т. Менә, менә, чәй эчкәндә шулай дип коткы таратып утыра.

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Кара, маңка, корсагыңны киереп торган буласың. Китер әле күсәкне, үзеңнең арт сабагыңны укытып алыйм. *(Күсәген тарткалый.)*

К о л ә х м ә т. Үз башына котыра бу мәчет күсесе, үз башына, Алла бирса.

И с ә н. Җибәр, кайтып китсен.

К о л ә х м ә т. Кайтып китсен?!.

И с ә н. Безгә акча өчен йөрүчеләр кирәкми. Безгә хөррият өчен җан аямый торган каһарманнар кирәк.

К о л ә х м ә т. Ходаеңа шөкерана кыл, бу юлы кулымнан ычкындың.

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы *(күсәген алып)*. Башыңны сугып ярсам берни дә кыла алмассың, тәмуг эте... Һе... Акча өчен имеш! Алыгыз соң кызларымны бушка... Өеп бирәм. Икегезгә дүрт ярымшар тия.

И с ә н. Бабай, житәр. Безнең бүтән эшләр бар... Коләхмәт, халык белән киңәшергә кирәк. Хәл шәп түгел. Нишләргә?.. Әйдә!.

К о л ә х м ә т. Чәй эчкәннәрдер инде. *(Сызгыра.)* Э-эй, кем бар, килегез әле монда!

*Төрле яктан сугышчылар керә, кызлар күренә.*

И с ә н. Би гаскәре безне божрага алган, туганнар. Көннән-көн катырак кыса, көннән-көн арсландай ир-угланнар башларын сала, көннән-көн әзәябез. Уйлашыйк, нишләргә хәзер?

К о л ә х м ә т. Божраны ерып чыгарга да өермә кебек ил өстеннән үтәргә. Бөтен нәрсәне кырып-себереп, көлен күккә очырып барырга. Хаиннарның барысын да үтереп бетерергә!

И с ә н. Ә яралыларны Мәгарәдә ташлап калдырасыңмы?

К о л ә х м ә т. Яралыларнымы?.. Алар инде... үзебез белән алып чыгабыз.

И с ә н. Яралы туганнарыбызны без бер чакта да исебездән чыгарырга тиеш түгелбез.

II – с а к ч ы. Нишлик соң, Исән батыр?

Т а в ы ш л а р. Әйе, нишлик?.. Бәреп чыгарга кирәк... Уйлап эш итәргә, баш белән... Юк, ярый, ярамый... Әйт, нишлик?.. Жае ничек?..

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы. Йә Алла, бер тиенсезгә песи балаларыдай кырылып бетәбез икән... Йә Алла!.. *(Күсәген сөйрәп чыгып китә.)*

К о л ә х м ә т. Әйт сүзеңне, Исән батыр!

И с ә н. Туганнар! Урманда калсак, һәрберебез ун дошманга каршы арслан шикелле сугышса да безне җиңәчәкләр. Без әз. Иң дөрес юл — соңгы көчне җыеп камалыштан чыгу, яралыларны коткару. Яшермим, бу алышта бик күпләребез корбан булачак. Ләкин исән калганнарыбыз Идел буйлап югары күтәрелеп, үзебезне көтеп торган яңа сугышчылар белән кушылачак. Аннан соң хәл җыеп, Коләхмәт әйткәнчә, яңа көч белән дошманга ыргылачак. Минем уем шундый.

К о л ә х м ә т. Дөрес! Ләгыйньнәр өстенә ябырылырга һәм ботларыннан берәм-берәм баганага асып куярга!

Т а в ы ш л а р. Дөрес!.. Уйлашыйк... Әйтүе генә җиңел... Мин Исән батыр яклы... Бүтән юлың булмагач... Шулай кирәк... үләрбез... җиңәрбез...

М и р з а ш ә е х. Мине дә тыңлагыз әле, туганнар?

Т а в ы ш л а р. Сөйлә, сөйлә! Тыңлыйбыз.

М и р з а ш ә е х. Минем кем икәнемне бик яхшы белеп торасыз. Ничек сугышуымны да күрәсез. Шуңлыктан әйтергә теләгән сүземне әйтергә хакым бардыр дип уйлыйм.

К о л ә х м ә т. Йә, йә, сузма, әйтсәң әйт?

М и р з а ш ә е х. Исән батыр — чыннан да безнең батыр җитәкчебез. Аның кулындагы кылычы гына түгел, йөрәге дә корыч. Ул — ярлыябагайларга, колларга чын дус, биләргә, аларның куштаннарына яшен уты шикелле аяусыз...

И с ә н. Мирзашәех, телең әйткәнне колагың ишетәме?

М и р з а ш ә е х. Гафу ит, Исән, уемны яшерә торган гадәтем юк. Башым ни уйлый — телем шуны әйтә.

К о л ә х м ә т. Әйт. Зарыктырма!

М и р з а ш ә е х. Исән батыр дөрес әйтә: безнең бердәнбер котылу юлы — божраны ерып иреккә чыгу. Ләкин бу юлга безнең арабыздан бик күп гайрәтле ир-егетләрнең гәүдәләре түшәләчәк. Исән адәмнәр үз туганнарының канлы гәүдәләренә басып кына иреккә чыга алачаклар. Моның ни икәнен уйлыйсызмы?

II-с а к ч ы. Ә бүтән юл бармы соң? Белсәң, әйт!

М и р з а ш ә е х. Бүтән юл бар.

И с ә н. Нинди юл?

К о л ә х м ә т. Нинди юл?

М и р з а ш ә е х. Безнең арада Талап би кызы Гөлзирәк бар. Талап би, үзенең сөекле кызы кире сараена кайтса, урман тирәсеннән гаскәрен алачак, безне гафу кылачак һәм һичкемгә золым-җәбәр итмәячәк. Сүзем шул. Сөңге һәм уклардан үләргә, ат тояклары астында тапталырга теләмәгән кешеләр моны бик әйбәтләп уйласыннар.

Г ө л з и р ә к. Исән!

И с ә н. Гөлзирәк, тыныч бул... Бәлки бу юл да дөрестер. Сугышчылар әйтсен.

К о л ә х м ә т. Башым ни уйлый, телем шуны әйтә дисең дә бит — дөрес микән? Минемчә, башың уйлаганны телең әйтеп бетерми төсле.

М и р з а ш ә е х. Ничек? Бу ни дигән сүз, туганнар?

К о л ә х м ә т. Би гафу кылачак, җәбер-золым итмәячәк, дисең. Моңа башында мыскалга салырлык та акылы булмаган тинтәк адәм генә ышаныр. Ә син тинтәк түгел бит — акыллы егет. Ә акыллы егетнең юк-бар әкияткә ышануы гаҗәп тә, шикле дә.

И с ә н. Син боларны нидән чыгып әйтәсең?

К о л ә х м ә т. Чыгуын-чыкмавын белмим, әмма бу бәндә миңа ошамый. Хәтта исеме дә безнең агай-эненеке түгел — Мирзашәех. Үзе мирза, үзе шәех. Кол үз баласына үлсә дә андый исем куша алмый. Минем әти — Моткол. Бу бала да мәңгегә кол була инде, дип, мина да Коләхмәт дигән. Колларны да, шаһларны да исемнәреннән белеп була. Исем хуҗасының кем икәнен әллә кайдан кычкырып тора.

М и р з а ш ә е х. Ялган! Яла! *(Кылычын күтәрә.)* Йөрәгең дә телең шикелле үткен икән — чык уртага!

К о л ә х м ә т. Батырлыкны сатып алмыйлар: батыр — тумыштан батыр. *(Каршы чыга.)*

В ә с и м ә *(араларына төшә).* Коләхмәт, батыр йөрәкнең дә кирәк чакта йөгәндә торуы яхшы. Ил язмышы хәл ителгәндә үзара талаш кирәк эшме?

И с ә н. Вәсимә безнең сүзләрне авыздан тартып алды. Бу минутта кемнең кол, кемнең мирза икәнен тикшерергә безнең вакыт юк.

К о л ә х м ә т. Ярый, әҗәлең җитмәгән икән. Соңрак, икенче урында.

М и р з а ш ә е х. Икебезгә бер әҗәл — кемне сайлар! Соңрак, икенче урында.

Т а в ы ш л а р. Исән батыр, сине көтәбез, әйт уеңны... Күңелләрне күтәр, күзләрдә өмет нуры кабыз!

*Карт керә, бер читтәрәк сүзләрен тыңлап тора. Сәхнәдәгеләр аны күрмиләр. Күсәген җилкәсенә салып мәчет каравылчысы да кереп баса.*

И с ә н. Туганнар, абыйлар, сеңелләр! Арагызда миңа үпкәләүчеләр дә бардыр. Исән тыныч кына эшләп яткан сукачыларны сукасыннан, тимерчеләрне сандалыннан, көтүчеләрне куйларыннан аерды, котыртып үз янына чакырды, көрәшкә күтәрде, дип әйтә торгансыздыр. Якты көндә, якты кояш нурларында иркәләнеп яшәргә тиешле күпме кеше корбан булды, күпме аналар улыннан, күпме оланнар әтисеннән аерылды, күпме сабыйлар ятим, күпме киленнәр тол

калды, күпме авыллар көл булып очты, күпме кан заяга акты, күпме ачы яшь коелды, дип уйлыйсыздыр. Барысы да, барысы да шул Исән аркасында, барысына шул Исән гаепле дип әйтәсездер.

Юк! Күкләр, җирләр белән ант итеп әйтәм — юк! Халыкның күзе мөлдерәмә яшь белән тулып тама башлаган иде инде, халык күнелендәге аһ-зар ут булып кызган, көйри башлаган иде инде, халыкның каны ачу һәм үч белән ярсып кайный башлаган иде инде, халыкның кулы үзеннән-үзе кылычка үрелә башлаган иде инде!..

Ана, коры үләнгә дөрләп китү өчен бер очкын җиткән шикелле, бер чакыру, бер чаң гына кирәк иде. Ул чаң — мин булдым. Мин беренче булмасам да беренчеләр барыбер мәйданга чыгар иде. Гомер буе сыкранып яшәгән кешеләр бер көнне кулларына барыбер ук һәм җәя алырлар иде...

Дөрес, сезнең каршыгызда минем бик зур гаебем бар — мин сезгә һәр чакны җиңү генә китерә алмадым, бөтенегезне дә саклый алмадым. Көчле егетләребезнең байтагы бәйге кырларында мәңгегә күзләрен йомды. Әмма алар миңа үпкәләмәсләр! Батыр каны җирдә ятмас! Алар үз каннарының җирдә ятмаслыгын беләп үлделәр. Алар каныннан бу җир өстенә кайчан да булса бер кызыл гөлләр шытып чыгачак! Ышаныгыз, киләчәктә ул көн килер!.. Килер, ышаныгыз!..

Без биләрнең һәм ханнарның кем икәнен бик яхшы беләбез. Гөлзирәкне кайтарсалар, гафу кылам, дигән сүзләр — ялган! Моңа ышанса да бары аркасы камчы, кулы богау күрмәгән беркатлы адәмнәр генә ышаныр. Шуның өчен бөтенегез алдында ачык итеп әйтәм: моны Гөлзирәкнең үзенә калдырабыз. Ничек теләсә, шулай эшләсен. Яу кырында бөтен михнәтләрне җилкәсендә безнең белән уртак күтәреп йөрүе өчен без бүген аңа рәхмәт әйтергә тиешбез...

Ә сиңа, мәчет каравылчысы, сүзем шул: синең дошманнарың чучка ашаучылар да, тау һәм урман кешеләре дә түгел. Алар синең шикелле үк кол, хуҗаларына бил бөгә, фәкыйрь көн итә. Син нишләп үзең кебек җәбер-золымда гомер сөрүче туганнарыңа ачу тотарга тиеш? Кем сине бушка эшләтә, соңгы сыныгыңны талап ала, сине хайванга тиң куя — менә кемнәргә каршы кусәк күтәрергә тиеш син! Менә кемнәр — синең дошманың!..

Кем һаман миңа ышана, кем иректән авыз итәргә, әгәр үләргә туры килсә, үлгәндә дә аягүрә үләргә тели — хәзер шул яныма бассын! Кемгә иректән яки үлемнән бүтән юл юк -.кылычын кайрасын, җәясен тартсын! Без дошман бөжрасын өзәргә тиеш! Мин сезне бүген соңгы бәйгегә алып барам!..

К о л ә х м ә т. Алып бар, Исән батыр? Шунсыз безгә үлем!..

К ы з л а р. Без сезнең белән, кыю егетләр!

С у г ы ш ч ы л а р. Җиңү, йә үлем!.. Соңгы бәрелешкә!.. Җиңәргә!.. Исән батыр, соңгы сулышка хәтле без синең белән!.. Кылычлар үткен, җәяләр киерелгән!.. Җиңү, үлем!.. Үлем, җиңү!..

М ә ч е т к а р а в ы л ч ы с ы *(башкаларга килеп кушыла)*. Мин үз туганнарымны танымаска, инәңнең башы!.. (Кусәген күтәрә.) Йә җиңү, йә үлем!..

К а р т (алгарак чыгып). Ниятләрегез изге, юлыгыз дөрес, оланнар.

И с ә н. Бабай!?. Син бит тыныч кына яшәп, тыныч кына үләргә дип киткән идең?

К а р т. Бу фани дөньяда, Исән батыр, безнең ише адәмнәргә тыныч кына яшәрлек тә, тыныч кына үләрлек тә урын юк икән. Күпме эзләсәм дә андый урынны тапмадым. Изге көрәш кырында бәхетсез чал башымны салу өчен сезнең янга тагын килдем... Миңа да берәр кылыч бирегез, оланнар!

И с ә н. Рәхмәт, бабай!.. Дусларым!..

*Сугышчы йөгереп керә.*

С у г ы ш ч ы. Исән батыр!.. Ике күл арасыннан би гаскәре бәреп керде... Сакчыларны суйдылар...

И с ә н *(кылычын күтәреп).* Дусларым! Соңгы сынау сәгате сукты. Юлбарыслар кебек гайрәтле икәнегезне онытмагыз!.. Минем арттан!.. Жиңү, йә үлем!..

Г а с к ә р *(кылычын айкап).* Жиңү, йә үлем!..

*Сугышка, батырлыкка өндәүче көчле музыка.*

*Исән жыр башлый. Аны бүтәннәр күтәреп ала. Идел буен куәтле жыр күмә. Пәрдә ябыла, жыр пәрдә артында дәвам игә.*

*Көрәшчеләр жыры*

Бер иңрәү килә, бер чыңлау килә колакка,
Нәрсә дисәгез — богаулар чыңлавы.
Богаулар салынсын, өметләр кабынсын,
Китсен жиһаннан ятимнәр елавы!

Жир өчен, ил өчен,
Ирекле көн өчен
Көрәшкә, көрәшкә, көрәшкә, батырлар!

Бер гөрләү килә, бер күкрәү килә колакка,
Нәрсә дисәгез — күкләр күкрәве.
Күкләрне күкрәтик, яшеннәр яшьнәтик,
Иркен суласын ир-егет күкрәге!

Жир өчен, ил өчен,
Ирекле көн өчен
Көрәшкә, көрәшкә, көрәшкә,
батырлар!..

Бер жыру килә, жылы моң килә колакка,
Нәрсә дисәгез — ул безнең өметләр.
Йолдызсыз төн үтәр, жырлы бер чор житәр,
Өмет сүнмәсен йөрәктә, егетләр!

Жир өчен, ил өчен,
Ирекле көн өчен
Көрәшкә, көрәшкә, көрәшкә, батырлар!!.

*Икенче жырга сугыш авазлары: кылычка кылыч бәрелеп чыңлаган, ук сызгырган тавышлар, жиңүчеләрнең сөенеп кычкыруы, егылучыларның сызланулары килеп кушыла. Сугышчыларның сафы әкрен-әкрен сирәгәя, жырлаучылар кими.*

*Сафлар сирәгәйгән саен, жыр хәлсезләнә. Өченче жырны бернichә сугышчы гына башлап жибәрә, аның ахыргы юлларын ялгыз сугышчы дәвам итә. Соңгы сүзләрне әйтә алмыйча, ыңгырашып ул да тына. Жыр үлә. Оркестрда скрипка елый.*

II – күренеш

*I — күренештәге музыка дәвам итә, ялгыз скрипка матәм уйный. Пәрдә алдына кыз бала чыга. Аның артыннан ана чыга. Кыз бала әтисенең, ана улының үлүе турында ишеткәннәр, матәм киенгәннәр.*

*Сул яктан, һәлак булган иптәшен күтәреп, ике сугышчы керә.*

К ы з б а л а. Минем әткәмме? Минем әнкәем түгелме?

С у г ы ш ч ы. Юк, кызый, бу әле синең әткәң түгел.

А н а. Минем улыммы?

С у г ы ш ч ы. Юк әнкәй, синең улың да түгел.

*Сугышчылар чыга. Көрәштәш иптәшен күтәреп, тагын ике сугышчы керә.*

К ы з б а л а. Минем кадерле әткәемне алып киләсезме?

С у г ы ш ч ы. Юк, сеңелкәем, бу иптәшебез синең шикелле икенче кызның кадерле әткәсе әле.

А н а. Әллә минем улыммы?

С у г ы ш ч ы. Юк, йомшак күңелле ана, бу әле икенче ананың сөекле улы.

*Чыгалар. Тагын ике сугышчы күренә. Алар да корбан булган иптәшен күтәргән. Нидер сизенгән төсле, скрипка моңы көчәя төшә.*

К ы з  б а л а. Монысы да минем әткәем түгелмени, абыкай?

С у г ы ш ч ы. Синең әткәеңне дә хәзер алып киләләр, кызым.

А н а. Бу — ул... монысы инде... минем улым!

С у г ы ш ч ы. Күңелең сизә, бәхетсез ана. Бу егет — безнең батыр дустыбыз, синең улың.

А н а. Минем улым!.. Ана кешенең күңеле бер чакта да хаталанмый... Улым !.. Сез аны минә монда куегыз. Әкрен генә!.. Аркасын, кулбашларын авырттыра күрмәгез. Мин аның янында калыйм. Бераз ялгыз башым утырыйк. Күзем туйганчы соңгы тапкыр карыйм. Гыйбадәт кылыйм...

*Сугышчылар, ананың улын сак кына җиргә куеп, чыгып китәләр. Кыз бала әтисен эзләп сугышчылар каршысына китә. Ана улы янында ялгызы кала. Улының битен, күлмәк изүен ача, көрсенеп карап тора. Чәчләрен, кашларын сыйпый.*

А н а. Улым!.. Туп-туры йөрәк өстенә туры китергәннәр икән, балакаем! Сизми дә калгансыңдыр. Озак интекмәгәнсеңдер. Үлем ачысы йөзеңә чыгып өлгермәгән. Йоклап киткән төсле генә ятасың Матур төш күрәсең бугай — иреннәрең һаман елмайган шикелле... Балакаем! Әле кайчан гына иде соң бу? Бер атна элек кенә бит. Кадерле әнкәем, дидең, дусларым ак бәхет даулап ук белән җәя алган чакта ничек өйдә калыйм, дидең. Сөекле әнкәем, изге ниятебезнең ахыры уң чыкса, тәгам җыярга икмәгебез, кияргә киемебез булыр, дидең. Фатиханны бир, әнкәем, мин дә чыгыйм алыш кырына, мин дә басыйм гайрәтле угланнар белән җилкәгә-җилкә, дидең.

Җандай якын газиз оланының өзелеп-өзелеп әйткән сүзләренә кайсы ананың күңеле эремәс соң! Мин дә сина фатихамны бирдем. Йә бер тәңрем, миһербанлы тәңрем, бәгыремнән өзелеп төшкән балам белән тагын куанып күрешергә насыйп итсәнә, дип пакь теләкләр теләдем.

Туган туфрагың белән саубуллашып өйдән чыгып киткәндә, синең күзләрең таң йолдызы кебек балкып тора иде, лачын күзләре кебек үткен иде. Синең иреннәрең өзелеп-өзелеп әнкәем, мине көт, иртән дә көт, кич тә көт, мин сиңа бәхет алып кайтырмын, бердәнбер әнкәем, дигән иде. Синең кулларың бөркет канатларыдай көчле, аякларың кыр кәҗәсенекедәй житез иде. Син күл камышы шикелле зифа буйлы идең, йөзеңә бер карасаң, күзләр чагыла иде. Син Сөләйман пәйгамбәр кебек зирәк һәм акыллы идең...

Балакаем! Минә без тагын күрештек. Нигә син, улым, әнкәем, мин әйләнеп тә кайттым, дип күкрәгемә башыңны куеп иркәләнмисең? Нигә син карт әнкәңнең хәсрәт сарысы коелган йөзенә күтәрелеп карамыйсың? Нигә аның кара кайгы каплаган күңелен юатырлык сүзләр әйтмисең?! Әнкәең көтә, бер кара, улым, берәр сүз әйт, улым?!.

Юу-ук шул, ю-ук! Ачы күз яшьләре белән хәсрәтле йөзен юаюа әнкәң күпме көтсә дә, үлем мөһере япкан иреннәрең ачылмас инде, үлем шәүләсе төшкән күзләрең миңа мәңге көлеп карамас инде. Ул күзләреңдә шәфәкъ алсулыгы да, аяз таң нурлары да мәңге чагылмас...

Әткәң исән булса, хәзер аһ итеп синең икенче ягыңда утырыр иде. Каты сагышың әткәңнең көчле күкрәген пәрә-пәрә телгәләр иде. Ир адәмнең кайнар яшен күреп җирләр, күкләр иңрәр, аңа кушылып елар иде. Әмма әткәңә бүген җиңелрәк. Синең җансыз гәүдәңә карап газапланмый, мин шуңа сөенәм. Җирдә аңа сине күрүне, кулына алып сөюне насыйп итмәде. Ул, хәтта, синең туганыңны да ишетмәде. Хәзер инде күргәндер. Гөнаһсыз җаннарыгыз күктә кавышып елашкандыр...

Әткәң белән икегез — ике алтын канатым бар иде. Инде берегез дә юк. Ике канатымның икесен дә каердылар. Әткәңне бүтән мәмләкәтләргә каршы яуга кудылар.

Үтереп, имгәнгән гәүдәсен кошлар очып житмәс чит-ят жирләрдә ташлап калдырдылар. Ханнар-морзалар үзара нәрсә бүлешә алмадылар икән — белмим. Безгә әйтеп, бездән кинәш сорап тормыйлар. Жир тармы, алтын-жәүһәр житмиме патшаларга?!. Аларга кирәк алтын-жәүһәрләр өчен нишләп синең әткәң вафат булырга тиеш соң, улым? Синең зиһенең житәме? Минем зиһенем монда житми.

Адәм балалары бу жиһанга икмәк игү өчен, терлек үрчетү өчен, бакчалар утырту өчен, бала үстерү өчен саф күңел һәм изге ният белән туалар. Әмма ни аяныч — беләкләренә көч, йөрәкләренә дәрт керү белән үз туганнарын чаян шикелле чагарга тотыналар, бүреләр сурәтенә кереп, бер-берсенең бугазларына ябышалар. Бер-берсен харап итү өчен, ярыша-ярыша сөңгеләр чүкиләр, уклар очлыйлар, кылычлар коялар. Ни өчен? Нигә кирәк, кемгә кирәк соң болар?!. Адәм балаларына ни житми?! Син беләсеңме, улым? Мин монысын да белмим.

Кояш бөтен адәмнәрне тигез жылыта. Кояш нурын бүлгәләмиләр ич. Жир өстендә бөтен кешеләргә дә урын житәрлек. Ник Жир-ананы бүлгәлиләр?!. Бал кортлары, кырмыскалар бергә яши. Нигә бәндәләрең башына да шундый уй салмадың, тәңрем!?.

Син адәм балаларының тавышын ишетмисең, син үз колларыңның газапларын күрмисең. Күрергә теләмисең! Син каты бәгырьле, тәңрем! Гаскәр менгән ат тояклары астында жирләр иңри, тузаннары күтәрелеп күкне томалый, ук сызгыруларыннан, кылыч чыңлауларыннан һава калтырана, кеше гәүдәләреннән тигез урыннарда таулар өелә, кан белән болганып елгалар кызара, толларның, ятим-ятимәләрнең күз яшеннән ком өсләрендә күлләр жыела. Күрә торып шушы һәлакәтләргә чик куймагач — син миһербансыз икәнсең, тәңрем!..

Балаларыбызның балалары, оныкларыбызның оныклары гомер иткәндә дә шушылай булыр микәнни бу хәсрәтле Жир? Адәм балалары бер чакта да кояш яктысына, бал кортларына карап уйланмаслар микәнни?!.

Ул заманнарда да, синең әткәңне үтереп ташлаган шикелле, һич гаепсез арслан ирләрне тәк-дуамал үтерерләр микәнни? Сине харап иткән шикелле, ялгыз аналарның бер бөртек улларының жанын кыюдан тыелмаслар микәнни? Барлык аналарның да күңелләре бер төрле бит. Ул чакта да бәхетсез аналарның йөрәкләре менә минем йөрәгем кебек парә-парә телгәләнер бит, сулыгып-сулыгып елар бит?!

Тәңрем, карт ананың аһ-зарларына колак сал! Алай итмә! Миһербанлы бул! Кешеләр жиргә озын гомер өмет итеп, бәхет өчен туа. Үз балаларыңның өметләрен кисмә, бәхетләреннән аерма!..

...Балакаем! Салкын гәүдәң минем алдымда, жаның күктә. Әткәң белән бергә. Әнкәң ялгыз башы жирдә кала. Әмма мин бу шыксыз һәм салкын жиһанда озак юанмам. Жир безне яратмады. Үз баласы итеп иркәләмәде, үги итте. Озакламый ахирәттә күрешербез. Өчәүләшеп елашырбыз. Жирдә бәхетне тарсындың — ахирәттә бәхетебезгә тимә, Ходаем!..

Хуш, улым, хуш балакаем! Күзләреңнән соңгы кабат үбим... Бәхетсез әнкәем аерылып кала дип кайгырма! Мин сездән озакка аерылмыйм. Тиздән барып житәрмен... Озак тормам. Кавышырбыз... Кабер туфрагың йомшак булсын, гүрең иплe булсын, улым!.. Кыяматкә кадәр хуш... балакаем!..

*Сугышчылар керә. Ананы иплән кенә күтәреп бастыралар. Улын сак кына күтәреп алып чыгалар. Ана әкрен адымнар белән аларга иярә. Музыка көчәя, скрипкага быргылар кушыла.*

### III – күренеш

*I — күренештәге декорация. Күктә болытлар, Иделдә дулкыннар. Гөлзирәк өстәл янында чиста чүпрәкләр сайлый. Мирзашәех керә. Гөлзирәкне күреп баш киемен читкә ата, чәчләрен тузгыта, сугышта йончыган кыяфәт алырга тырыша. Гөлзирәккә сокланып һәм ымсынып карап тора.*

Мирзашәех. Гөлзирәк!

Гөлзирәк. Әләй, куркыттың! Син дә куркынган сыман.

Мирзашәех. Хәлләр куркудан үтте инде, Гөлзирәк.

Гөлзирәк. Аңламыйм.

Мирзашәех. Харап булып беттек бит! Үтерәм, үтерәм дип йөри торгач, Коләхмәт мәрхүмнең үзен үтереп ташладылар. Күбәләктәй гөнаһсыз җанлы ике кыз — Вәсимә белән Раушаниябез кайда? Бәләкәй сакчы, тирече карт? Чүлмәкчеләр? Башкорт атлылары?.. Берсе дә юк, берсе дә...

Гөлзирәк. Син аларны кызганасыңмы?

Мирзашәех. Әйе, алар минем дусларым, көрәштәшләрем иде.

Гөлзирәк. Көрәш кырында корбан булучылар кызганыч кешеләр түгел. Аларның кыюлыкларына сокланырга кирәк. Кеше бәхете өчен үлгән кешеләр белән горурланырга кирәк!

Мирзашәех. Моннан Коләхмәтләргә ни файда?

Гөлзирәк. Ул — җирдә калганнар өчен гыйбрәтле.

Мирзашәех. Сүзләрең дөрес, Гөлзирәк, тик...

Гөлзирәк. Нәрсә «Тик...»?

Мирзашәех. Аларның каннары кем өстенә төшә?

Гөлзирәк. Үтерүчеләр өстенә.

Мирзашәех. Һм!.. Алар тыныч кына тире илиләр, чүлмәк ясыйлар, тары, бодай үстерәләр иде. Шуннан бер егет килә дә әйтә: «Әйдәгез бигә каршы сугышка барабыз, байлыгын талап үзебезгә алабыз!» — ди. Тегеләр ышаналар, егет артыннан китәләр һәм кара урманда җан бирәләр. Кем гаепле моңа, йә, кем?

Гөлзирәк. Син егет дисеңме?

Мирзашәех. Кем соң?

Гөлзирәк. Тормыш.

Мирзашәех. Безнең арага сине дә тормышың куып китердеме?

Гөлзирәк. Юк, мине башта мәхәббәт китерде.

Мирзашәех. Башта?

Гөлзирәк. Соңыннан икенче олырак, изгерәк хис туды: сезнең ише гади адәмнәргә — мәхәббәтем, туып-үскән сарайларыма — нәфрәтем.

Мирзашәех. Син, нәфрәтеңә карамыйча, анда күптән кайтырга тиеш иден.

Гөлзирәк. Юк.

Мирзашәех. Мин теге чакта уйнап әйтмәдем: гүр ияләренең каны сиңа да төшә.

Гөлзирәк. Шомлы сүзләр сөйлисең, Мирзашәех.

Мирзашәех. Син кайтсаң безне би гафу кылып, өйләребезгә кайтара иде. Ә син мине тыңламадың. Бер гөнаһсыз йөзләрчә колларның гомерен кызганмадың.

Гөлзирәк. Мирзашәех!..

Мирзашәех. Әле дә соң түгел. Исән батырныкылар һаман да зинданда, без, гәрчә сирәк калсак та, һаман чолганышта. Тиздән безнең дә башны бетерәчәкләр. Акылыңа кил, Гөлзирәк. Кит! Аягына егыл. Елмай, ела, кичерүен үтен. Без инде бернәрсә дә кыра алмыйбыз. Безнең язмыш шушында аунап калу. Батыр исеме күтәреп үлгәнче, исемсез килеш бер көн булса да яшәү артыграк бит! Сөйгән ярың кочагында җан бирүдән сөймичә һәм сөелмичә бер сәгать якты дөньяда яшәү кадерлерәк бит!

Гөлзирәк. Үлем... Мәхәббәттән көчлерәкмени?

Мирзашәех. Син мәхәббәтне тагын табарсың.

Г ө л з и р ә к. Тагын-тагын табыла торган булгач — мәхәббәт түгел инде ул. Чын мәхәббәт бер табыла.

М и р з а ш ә е х. Синең чын мәхәббәтең әле кабынмаган. Чибәрлеге, акылы-зиһене, буе-сыны, байлыгы-шөһрәте белән бөтен Идел буенда бер Гөлзирәк белән ярлы бакырчының ярлы малае арасында чын мәхәббәт яши алмый. Сине икенче углан көтә. Ул сине алтын белән күмәр, йөргән юлларына асыл-ефәк түшәр, ул бөтен җиһанны яулап синең аяк астыңа ташлар. Бу кара урман, куркыныч төш шикелле, тора-бара онытылыр. Кайтып кит, Гөлзирәк, үтенәм синнән, Гөлзирәк! Үзең өчен, сине сөеп газапланучы бер җан өчен!.. Гөлзирәк!.. *(Кулларыннан тотмакчы була.)*

Г ө л з и р ә к *(ычкынып, гаҗәпләнеп)*. Син акылыңнан язгансың, Мирзашәех... Син куркыныч бүген... Тынычлан, утырып тор... Мин хәзер. *(Чүпрәкләрен алып чыгып китмәкче була).*

М и р з а ш ә е х *(алдына төшә)*. Мин сине кызганып әйтәм. Ул сине яратмый, алдый. Ул ике яклы пычак. Бигә үч итеп тота. Кызың миндә, сикерә алмассың, имеш...

Г ө л з и р ә к. Нәрсә?.. Кем яратмый?

М и р з а ш ә е х. Исән. Коләхмәт белән көлеп сөйләшүләрен әллә ничә тапкыр ишеттем. Би кызын барыбер куып җибәрәм, ул җүләр миңа чат ябышкан, ди. Үзеңне эт итеп кууын көтмә. Йөзенә төкер дә кит, Гөлзирәк?

Г ө л з и р ә к. Чынлап авырыйсың ахры, тынычлан. Син... дөрес сөйләмисең. Ялган! Ышанмыйм! *(Тиз-тиз атлап чыгып китә.)*

М и р з а ш ә е х *(артыннан омтылып, кычкырып кала)*. Гөлзирәк! Гөлзирәк!.. Җебегән малай. Кылыч каршында кысылган телең шул кыз алдында ачылдымы! Уеннан уймак чыгарын кем белгән. Яратып китәрмен дип кем уйлаган! Үзең пешергән ботканы үзең аша инде, җүләр... Гел яннарында булырга кирәк. Күз алдымда әләкли алмас...

*Китмәкче була, ләкин тавышлар ишетеп туктала. Бер сугышчы сөңгесе белән төрткәли-төрткәли Зыянгирны алып керә.*

З ы я н г и р. Төртмә дим, туктале, сөйләшик әле. Бәлкем сиңа ат кирәктер, ә? Миндә бар атлар. Биримме? Көмеш ияре белән, ә? Алтын да өстим. Бер чүлмәк... икене, ә? Күмелгән алтыннарым күп минем, ә? Төртмә әле син!..

С у г ы ш ч ы *(төртә)*. Әйдә, күп лыгырдама!

З ы я н г и р *(Мирзашәехне күреп)*. Мирзашәех!.. Карале, син бит бу?! Валлаһи син!.. *(Мирзашәех читкә борылып тора, дәшми.)* Танымадыңмы әллә? Зыянгир мин.

*Мирзашәех дәшми.*

Уразай Мәликләрдәге яз бәйрәме исеңдәме? Асыл угланнар бәйгесендә җинүче иң оста мәргән бит мин... Зыянгир... Мәликнең төпчек кызы минем нәфис билемә энҗе кәмәр бәйләде бит. Исеңә төштеме? *(Мирзашәех дәшми.)* Мирзашәех әфәнде!

*Мирзашәех дәшми.*

Аңлашыла. Син дә болар белән икән. Үз алтыннарың гына җитмәгәч, бүтән биләрне суярга чыккансың икән. Әмма шуны бел — озакламый базар мәйданында башың чабылачак. *(Сугышчыга.)* Әйдә, төрт җилкәгә, алып кит мине тизрәк бу адәм яныннан.

С у г ы ш ч ы *(төртә)*. Тыңлыйм һәм буйсынам, хөрмәтле йөзбашчы. Атла, каһәр суккан черек кисмәк!

*Чыгалар.*

М и р з а ш ә е х. Авырткан башка тимер тарак. Монысын тагын ничек җәһәннәмгә олактырырга?

*Исән керә. Сул кулын муенына асып бәйләгән. Бераз аксый. Киемнәре ертылган.*

И с ә н. Мирзашәех, син монда күптәнме? Гөлзирәкне күрмәдеңме?

М и р з а ш ә е х. Юк, күрмәдем.

И с ә н. Ярга күзәтчеләр куйдыңмы?

М и р з а ш ә е х. Куйдым.

И с ә н. Кайда булыр ул?

М и р з а ш ә е х. Борчылма, табылыр.

И с ә н. Кем?

М и р з а ш ә е х. Гөлзирәк.

И с ә н. Ә-ә, мин аның өчен борчылмыйм.

М и р з а ш ә е х. Ни өчен соң?

И с ә н. Тагын пыр туздырдылар. Икенче тапкыр.

М и р з а ш ә е х. Әйе, әхвәлебез шәп түгел.

И с ә н. Әйт әле, нишләп алар гел көчле булып чыга, нишләп без һаман җиңеләбез?

М и р з а ш ә е х. Белмим, Исән.

И с ә н. Мин дә белмим. Без аларны мәңге җиңә алмабыз микәнни? Гадел түгел бит бу, дөнья болай корылырга тиеш түгел!

М и р з а ш ә е х. Тиеш түгел.

И с ә н. Нишләргә соң? Гаделсезлекне ничек бетерергә?

М и р з а ш ә е х. Бәлки көрәшеп маташмаскадыр?

И с ә н. Юк, көрәшергә! Тик нишләп ялгышабыз?

М и р з а ш ә е х. Минемчә, төп хатабыз нәкъ әнә шул көрәш. Туфрак алтын ялтыравын томалый аламы? Күсәк кылычны кисәме? Ә безнең туфрак белән күсәктән бүтән нәрсәбез бар?.. Сорарга, үтенергә кирәк. Иелгән башны кылыч кисми.

И с ә н. Гомеребез буена сорыйбыз. Колакларына да элмиләр. Иелгән баш кисү өчен тагын да уңайрак. Шулай булганга безнең башларны кыеп кына торалар.

М и р з а ш ә е х. Болай кыймыйлармы? Күпме гомерләр өзелде, тездән кан агыздылар. Димәк, алар көчле, дөреслек алар ягында. Язмыштан узмыш юк. Коралларны салырга вакыт.

И с ә н. Исән батырның муены иелми — киселсә киселә. Өченчесендә җиңәрбез.

М и р з а ш ә е х. Әллә өченче кат күтәрелергә ниятлисеңме? Кем белән, ничек? Утыз-кырык сугышчы беләнме?

И с ә н. Әйе. Төнлә Иделнең теге ягына китәбез.

М и р з а ш ә е х. Шуннан?

И с ә н. Анда урманнар куе. Хәл алырбыз, корал әзерләрбез, кешеләр җыярбыз. Көрәшкә атлыгып торган угланнар һәркайда күп.

М и р з а ш ә е х. Тагын кырып салачаклар.

И с ә н. Салсалар, тагын калкынырбыз. Без хакыйкатьне табарга тиеш, ләбаса.

М и р з а ш ә е х. Үтерсәләр?

И с ә н. Килер буыннар табар.

М и р з а ш ә е х. Матур хыял!.. Тик безгә бүгенге көн турында уйларга кирәк. Әти-әниеңне онытмагансыңдыр бит?

И с ә н. Ничек онытыйм ди!

М и р з а ш ә е х. Гафу сорасак, би безне гафу кылып өйләребезгә кайтарыр, синекеләрне азат итәр.

И с ә н. Ә «гафу»ны кем сорар, синме?

М и р з а ш ә е х. Бинең үз кызы.

И с ә н. Гөлзирәкме?!

М и р з а ш ә е х. Ул кызны күптән җибәрергә кирәк иде. Мин аннан шикләнә башладым, тәшвишкә төштем.

И с ә н. Син ни сөйлисең? Уйнап әйтәсеңме?

М и р з а ш ә е х. Хәлебез уйнарлык түгел, Исән. Би кызының мәхәббәтенә ышану хата түгел микән? Сезнең арада нинди уртаклык бар?

И с ә н. Мәхәббәт бай белән ярлыны аермый.

М и р з а ш ә е х. Әмма аның уйфикере бүтән, аны син аңламыйсың, йөрәк хисләре алдаучан.

И с ә н. Мин Гөлзирәкне беләм.

М и р з а ш ә е х. Мин дә беләм дип йөри идем.

И с ә н. Боргалама!

М и р з а ш ә е х. Син, ник без җиңеләбез, алар җиңә, дип сорадың.

И с ә н. Әйе, сорадым.

М и р з а ш ә е х. Алар безнең һәр адымыбызны, хәтта ни уйлавыбызны алдан белеп торалар. Димәк, безнең арада шымчы бар.

И с ә н *(Мирзашәехнең якасыннан алып)*. Кемгә пычрак ягасың, кара йөрәк? Фәрештә шикелле кыз өстенәме?!. Үтерәм!..

М и р з а ш ә е х *(ычкына)*. Коләхмәт урынына син калдыңмы?.. Безнең арада би улларыннан, би кызларыннан кем бар? Ул! Үзең кебек кол егетләр бигә сатылып, шымчылык итеп йөрерме? Кемнән шикләнәсең? Миннәнме? Мәгарәдәге әрвахларданмы?

И с ә н. Күңелемдә сезгә тырнак очыдай шик сакласам да — сезне хурлар идем.

М и р з а ш ә е х. Авыр-авырын. Ләкин минем сүзләрдә хаклык бар.

И с ә н. Белмим. Коточкыч сүзләр әйтәсең. Самими сөю хисе бөркегән ягымлы күзләр! *(Кычкырып.)* Юк! Дөрес түгел! Ник йөрәгемә салкын хәнҗәреңне тыгып айкыйсың, ә?

М и р з а ш ә е х (тыныч). Сөю хисе бөрки дип йөргән күзләренә җентекләбрәк кара, зәһәр елан агуы бөркемәгәе!

И с ә н. Җитәр! Тагын бер сүз әйтсәң, телеңне тартып өзәм.

М и р з а ш ә е х. Агу дигәннән, сарай әһелләре агу белән дә шаяра. Сак бул!

И с ә н *(хәнҗәрен алып)*. Бас каршыма, кабахәт адәм! Оҗмах хурыдай кызның җанын рәнҗеткән өчен үз җаныңны җәһәннәмгә җибәрәм. Ал хәнҗәреңне!

М и р з а ш ә е х *(изүен аера)*. Мә чәнче! Иң ышанычлы дустыңны үтер! Бер кансыз би кызын яклап фәкыйрь чүлмәкченең фәкыйрь оланын үтер! Шәһит киткән туганнарыбыз, бу мыскылга чыдый алмыйча, тар ләхетләрендә йөзтүбән әйләнсеннәр. Их син, газраил күзенә керфек какмый караган егет! Хыянәтче кызның сырпалануы чуерташ йөрәгеңне эретеп балавызга әйләндердеме!?.

И с ә н. Тукта, җитәр!..

М и р з а ш ә е х. Саташуыңнан үзең тукта! Көрәштәшең сүзен аяк астына салма. Ул моннан хәзер үк китсен. Би кызын яратам дип атаананны харап итәргә синең хакың юк. Ата-ана хакы җирдәге бөтен мәхәббәтләрдән дә артык. Ата-ана мәхәббәте барлык мәхәббәтләрдән дә кайнар... Би кызының татлы теленә ышанма, татлы телнең төбендә агу була. Яратмыйм, кит, диген, ку!

И с ә н. Күкрәгемә хәнҗәреңне тыгып айкасаң җинелрәк тоелыр иде. Хәнҗәр бер үтерә — сөйгәненнең хыянәте мең тапкыр үтерә.

М и р з а ш ә е х. Ул хыянәтнең инде мең сугышчыны юк итүен онытма!

И с ә н. Идел агуыннан туктаса, өстемә күк җимерелеп төшсә, җиде кат җир астыннан җәһәннәм калыкса, бу хәтле аптырамас идем.

М и р з а ш ә е х. Син миңа ачуланма. Мең татлы ялганнан бер ачы хакыйкать кыйммәтрәк.

И с ә н. Әйе... әйе...

*Гөлзирәк керә.*

Г ө л з и р ә к. Ни булды сезгә? Икегез ике читтә үпкәләшкән малайлар кебек торасыз.

И с ә н. Юк, болай гына. *(Су эзли, чүлмәк буш.)*

Г ө л з и р ә к. Су беткәнмени? *(Чыгып кружка белән су алып керә.)*

Т а в ы ш. Гөлзирәк, үскәнем, менә боларны кара әле.

Г ө л з и р ә к. Кая?

*Суын өстәлгә куеп чыга. Исән, үз уйларына чумып, әрле-бирле йөри. Мирзашәех кесәсеннән кәгазь пакет ала. Суга тиз генә нидер сала, читкә китә. Гөлзирәк керә.*

Г ө л з и р ә к. Иптәшләренең ярасын бәйләргә үз күлмәкләрен салып юып китергәннәр.

И с ә н. Ә-ә! *(Суын алып эчмәкче була.)*

М и р з а ш ә е х. Сабыр ит. *(Кулыннан кружканы ала.)*

И с ә н. Син нәрсә?!.

М и р з а ш ә е х. Әй, кем бар? Зыянгир йөзбашын китерегез!

*Ике сугышчы Зыянгирны алып керә.*

М и р з а ш ә е х. Исән батырдан сине коткаруын үтендем. Ул мине тыңлады.

З ы я н г и р. Ээ... ээ... Асыл углан Мирзашәех... Зыянгир батыр колың булыр... Мин сине теге...

М и р з а ш ә е х *(аны бүлдереп).* Батыр, батыр! Тешең тешкә тими. Кәнизәкләрне аунатканда гына батыр сез. Мә эч, хәл керер.

З ы я н г и р. Рррәхмәт, рррәхмәт, онытмам. *(Кружканы алып эчеп җибәрә. Кинәт бөгелеп төшә, киерелә, сузыла, газаплана, ике куллап эченә тотына.)* Ааыы... ааыы... Нишләттегез?!. Эчемә эрегән кургаш койган шикелле... Ааыы.. *(Сискәнеп.)* Агу! Агу эчерделәр... Мине агуладылар. Ааавы! *(Бөгелеп чайкала-чайкала йөри, чыгып китә. Сәхнә артында дөпелдәп җиргә ауганы ишетелә.)*

Г ө л з и р ә к. Йә, Аллам, ни булды бу? Исән! Мирзашәех!

*Исән дәшми, аптырап тора.*

М и р з а ш ә е х. Бумы — бу — сарайларда гына очрый торган яман уеннарның безнең арага да килеп керүе дигән сүз. Ярый, мин саклар тирәсендә булырмын. *(Исәнгә мәгънәле генә карап чыгып китә. Сакчылар да чыга.)*

Г ө л з и р ә к. Исән?!

И с ә н *(кружканы ала, гаҗәпләнеп карый, ашыгып кире куя, артка чигенә).* Белмим, белмим...

Г ө л з и р ә к. Исән, ник дәшмисең? Мин куркам!

И с ә н. Мин дә куркам. *(Гөлзирәк янына килә. Анын кулларыннан алып, нидер күрергә теләгәндәй, текәлеп күзләренә карый. Күкрәгенә сыенырга теләгән Гөлзирәкне этәреп читкә китә.)* Юк!.. Юк!..

Г ө л з и р ә к. Исән! Мин хәзер акылымнан язам. Нәрсә сөйләшә идегез? Әйт тизрәк!

И с ә н. Без... сине... кайтарып җибәрү турында сөйләшә идек.

Г ө л з и р ә к. Һич башыма керми... Ничек?..

И с ә н. Гөлзирәк! Бүген-иртәгә соңгы бәрелеш. Үзеңне харап итмә, кит безнең яннан!

Г ө л з и р ә к. Син ни сөйлисең, Исән... батыр?!.

И с ә н. Шулай. Хәзер үк кит!

Г ө л з и р ә к. Чынлап... әйтәсеңме?

И с ә н. Чынлап... Хуш, Гөлзирәк!

Г ө л з и р ә к. Чәчләребез чәчкә бәйләнгән — аларны кисәрлек үткен кайчылар юк, икебезгә бер бөтен бәхетебез бар — аны аерырлык зөлфәкарь кылычлар коелмаган, ике йөрәктә ике гөнаһсыз мәхәббәтебез бар — аны суытырлык салкын җилләр юк, үлемебезне дә тәкъдирдә бергә язган — үлемне үтерерлек үлемнәр юк, Исән батыр!

И с ә н. Кит, Гөлзирәк! Чөнки... чөнки безнең гөнаһсыз мәхәббәтебезне суытырлык зилзилә җилләре айкала бүген.

Г ө л з и р ә к *(тетрәнеп).* Үткен кылычлар да коелган дисеңме?

И с ә н. Әйе... Чәчләребез дә киселгән...

Г ө л з и р ә к. Мин китәм, Исән батыр... Синнән аерылгач, әтием сараенда яшәсәм ни дә, тар ләхеттә ятсам ни... Миңа барыбер.

И с ә н. Кичер мине, Гөлзирәк!

Г ө л з и р ә к. Кичерү сорарлык гаебең юк. Күңелеңдәген яшерми әйтә алуың өчен рәхмәт яусын.

И с ә н. Үзеңә... рәхмәт! Барысы өчен дә!

Г ө л з и р ә к. Әти-әниләренне зинданнан йоларга көчем житсә, мине һаман да көрәшче икән бу кыз дип искә төшерегез! Хуш, Исән! ..

И с ә н. Хуш, Гөлзирәк!..

*Бер-берсенен кочагына атылырга теләп, карашып торалар. Ләкин тыелалар. Гөлзирәк әкрен генә чыгып*

*китә. Исән аның артыннан ташлана. Туктый, кычкырырга тели. Сикереп өстәлгә менә. Ачу белән кружканы тибеп очыра. Жиргә төшә, Кинәт картаеп, бөкрәеп агачка сөялә. Жилкәләре калтырый, җылыймы, көләме — билгесез.*

*Мирзашәех керә. Исәнне күреп туктый, Йөзенә тантаналы бер явызлык җәелә. Хәнҗәрен ала. Аны артына яшереп тоткан килеш, тавышсыз адымнар белән Исәнгә якынлаша. Тиз генә хәнҗәрен күтәрә.*

Гөлзирәк *(йөгереп килеп керә. Коты очып)*. Исән, саклан!

*Исән ялт борыла. Мирзашәех хәнҗәрен яшерә, ләкин Исән аны күреп кала.*

Исән. Син... син ни кыланасын?!

Гөлзирәк. Ул әшәке кеше! Ул сине арканнан кадарга теләде!..

Мирзашәех. Шымчы кыз!.. Синең үзеңне күптән кадарга кирәк иде.

Исән. Гөлзирәк, син нишләп китмәдең?

Гөлзирәк. Ул чүлмәкче улы түгел, Түбәнтау биенең улы. Мине яучылаган адәм... Исән, саклан!..

Мирзашәех. Ялган! Ниткән би улы ди мин!

Гөлзирәк. Ышанма, Исән! Хәзер генә бер тиречене әләктерделәр. Моның янына килгән.

Мирзашәех. Бернинди тиречене дә белмим.

*Күсәген күтәреп мәчет каравылчысы керә.*

Мәчет каравылчысы. Карале, Исән батыр, йомышым сиңа төште бит әле, инәңнең башы. *(Мирзашәехне күреп аптырап кала. Аннан билен бөгеп баш ия.)* Кичер карт алашаны, Алла хакы өчен? Сукыр тавыкның шул инде — күрми торам.

Исән. Ник аңа баш иясең, бабай?

Мәчет каравылчысы. Һе, ими кара! Шулай итмәсәң, ике бот арасындагы җан жиргә тибеп җибәрә торган яман гадәте бар аның.

Исән. Кем соң бу?

Мәчет каравылчысы. Белмисенмени? Безнең би малае Мирзашәех бит бу... Карале, энем, ни эш майтарып йөрисең безнең арада — гыйфрит кебек гайрәтле угланнар арасында? Каләш эзләмисендер бит?

Исән. Дөресме бу?

Мирзашәех. Дөрес! Әйе, мин бу, мин! Сезнең алдыгызда мөхтәрәм бинең гаярь угланы Мирзашәех басып тора. Тезләнегез, тезләнегез, мәшрик коллар!.. Сезгә әле жир кирәк булдымыни — әнә, усак төпләрендә бик күбегез жир алды. Икмәк теләндегез — авызыгызга кара туфрак тутырдык. Хөррият яуладыгыз — хәзер гүрегездә борылып та ята алмыйсыз. Сезне Ходай кол итеп яраткан — мәңге кол булырсыз, мәңге, мәңге! Безне асылзат иткән — без мәңге асылзат булырбыз, мәңге, мәңге!.. Ничек яратса, мәңге шулай торачак! Таң нурын сүндереп буламыни, кояшның юлын кирегә борып буламыни, шакшы коллар?!.

Исән. Без таң нурына сез каплаган кара пәрдәне алып ташлау өчен күтәрелдек. Таң нуры — бөтен адәмнәрнеке! Чык, кабахәт! Сине дә усак төбе көтә.

Мәчет каравылчысы. Ямансызның башын күсәк белән үзем сугып ярыйм әле.

Мирзашәех *(кинжалын күрсәтә)*. Кит, тинтәк карт!

*Мәчет каравылчысы күсәген ташлап чыгып йөгерә. Каравы-ыл!.. Суялар!..*

Мирзашәех *(Исән каршысына чыга)*. Син пычрак колларың белән аксөяк кызына үрелергә җөрьәт иттең, кол. Өметләремне кистең. Чутлашыр көн житте.

Исән. Әйе, маңгай тирләре, камчы эзләре хисап сорый!

*Сугышалар.*

Мирзашәех. Камчыларның сабын ходай безнен кулга салган.

Исән. Безнең йөрәкләргә нәфрәт уты салган. Ул ут бер заман камчыларыгызны да, үзегезне дә яндырачак!

*Сугышалар.*

Мирзашәех. Жирдә бер генә — безнең генә хакыйкать бар, колларның хакыйкате юк!

Исән. Коллар хакыйкатьне үзләре яулап алыр!

Мирзашәех. Сезне эт урынына асып бетерәчәкләр!

Исән. Бүтәннәр калыр. Халыкны үтереп бетерерлек көч юк!

*Сугышалар.*

Мирзашәех. Әти-әниеңне, сеңелеңне буган шикелле, сине дә дөмектерәчәкләр.

*Исән яшен суккандай катып кала. Кулыннан хәнжәр төшә.*

Гөлзирәк. Исән!..

Исән. Газраильләр сез!.. *(Көрәшәләр. Исән Мирзашәехнен үз хәнжәрен алып чәнчи. Мирзашәех егыла.)*

Мирзашәех *(терсәкләренә таянып калкынырга итә).* Коллар... Ләгъ-нәтләнгән кол-лар... Ха-ха-ха-ха! *(Үлә.)*

Гөлзирәк *(Исәннен күкрәгенә капланып).* Исән!..

Исән *(аны кочаклап).* Гөлзирәк!..

Гөлзирәк *(елый).* Синең әтиләрең!.. Минем әти бит. Минем!.. Ерткыч!..

Исән. Елама, Гөлзирәк! Минем әтине синең әтиең түгел, бер мескен колын бай би үтерде. Менә ничек.

Гөлзирәк. Мәхәббәтебез нишләр?

Исән. Мәхәббәтне зинданга ябып та, буып та булмый, Гөлзирәк!

Гөлзирәк. Рәхмәт, Исән!

*Шау-шу ишетелә.*

Тавыш. Исән батыр, би гаскәре! Иделдән меңәләр!..

Исән *(Гөлзирәкне үбеп).* Менә соңгы бәйге дә житте. *(Кылычын ала.)* Икмәк һәм су өчен, һава һәм кояш өчен!..

Гөлзирәк. Исән, мин дә сезнең белән!

Исән. Безнең белән, Гөлзирәк, бергә, Гөлзирәк!..

Гөлзирәк *(хәнжәр алып).* Бергә, Исән, мәңгегә!

*Чыгып йөгерәләр. Сугыш тавышы көчәя. Бераздан би гаскәрләре Исән белән Гөлзирәкне сугыша-сугыша сәхнәгә чигендереп кертә. Исән белән Гөлзирәк, биек ярга басып, төрле яктан һөҗүм итүчеләргә каршы аркага-арка терәп сугышалар. Би сугышчылары берәм-берәм качалар.*

Исән. Хәлең бармы?

Гөлзирәк. Басып тора алам әле.

Исән. Үлемне аяк өсте каршылыйк, Гөлзирәк?

Гөлзирәк. Үләбез дә мени, Исән?

Исән. Үләбез, Гөлзирәк.

Гөлзирәк. Бик аз яшәдек бит әле. Яшисебез калды!

Исән. Хыялларымны үти алмадым. Бар адәмнәрнең бәхетен тигез итмәкче идем — ничек икәнен белмәдем.

Гөлзирәк. Бездән соң туачак оланнар моны белерләр, Исән!

Исән. Белсеннәр иде, Гөлзирәк!

Гөлзирәк. Нинди жиләс жил, Исән! Нинди зәңгәр күк, ак болытлар! Идел нинди матур, нинди киң!

Исән. Кояш нинди якты, жиһан нинди иркен!

Гөлзирәк. Ә без китәбез, алардан мәңгегә аерылып китәбез.

*Әкрен музыка башлана. Ялгыз скрипка.*

И с ә н. Кара язмышка, кара заманга ләгънәт әйтеп китәбез!

Г ө л з и р ә к.
Кара ташлар очрар җир өстендә.
Кара язмыш, кара тәнебез ул.
Кызыл ташлар очрар җир өстендә,
Хаклык эзләп йөргән кәнебез ул.

Җир-әнкәнең йомшак күкрәгенә
Күпме көрәшчеләр егылган.
Кызыл ташлар бик күп батырларның,
Кызыл ташлар бик күп матурларның
Кызыл каны белән юылган.

И с ә н.
Безнең гомер җиһан гомерендә
Тамчысы тик кояш нурының.
Безнең фәләк сезнең йөрәкләрдә
Алыр әле үзенең урынын.

Без китәбез, сау бул, килер заман!
Без китәбез, сау бул, киләчәк!
Куенында үсәр оланнарың
Сина хөрлек яулап бирәчәк.

И к е с е б е р г ә.
Киләчәкнең горур адәмнәре,
Без китәбез инде, хушыгыз!
Онытмагыз шәһит киткәннәрне,
Исемнәрен җырга кушыгыз!

Без эзләгән иркен көннәр җитәр,
Ул көннәрнең кадерен белегез!
Җир өсләрен чәчкә белән бизәп
Көлә-көлә эшләп йөрегез!

Г ө л з и р ә к.
Җылый-җылый түгел —
жырлый-жырлый
Без төшәбез салкын суларга.
Без башлаган җырлар сезгә кала,
Дәвам итеп, ярсып җырларга.

И с ә н.
Безне сагынсагыз, май аенда
Идел буйларына килегез.
Дулкыннар сезгә җыр җырлар,
Ул җырларда яңрар безнең җырлар -
Шуны белегез!

*Сөңгеләрен алга сузган би гаскәре төрле яктан тавышсыз гына боларны камый.*

Г ө л з и р ә к.
Без китәбез,
Яз җиледәй сөю хисебезне,
Якты сәгадәтле өметебезне
Мәңгелеккә алып китәбез.

И к е с е б е р г ә:
Күзгә төннәр аяз көн булыр дип,
Кара язмыш җинелер, хур булыр дип,
Бар адәмнәр тигез, хөр булыр дип,
Киләчәкнең горур кешеләре.

Г ө л з и р ә к. Сезгә
И с ә н. Сезгә
И к е с е б е р г ә. Сезгә
Ышанып китәбез!..

Т а в ы ш. Могтәбәр би боера: коралларыгызны ташлагыз!

Г ө л з и р ә к, И с ә н. Ху-шыгыз!..

*Кочаклашып Иделгә ташланалар. Болыт күтәрелә, карангылана. Иделдә давыл кубарга чамалый. Өмет авазлары белән көчәя барган музыкага дулкыннар тавышы кушыла. Еракта гөрелдәп күк күкри. Куркынып калган би сугышчыларын яшен яктыртып җибәрә.*

*Пәрдә.*

*30 гыйнвар — 24 май 1966 ел.*



Булат
Ибраһимов

# МӨКАТДӘС САЗ ТЫНДЫ УЙНАВЫННАН

## Тукайга ияреп

**Ә пар атлар күптән чабып узды,**
**Һәм һава да бетте үпкәдә.**
**Кисекбаштай тәгәри безнең тормыш,**
**Кичә шулай, бүген, иртәгә.**
**Аллага да килә таянасы,**
**Кайда диеп безнең якты юл?**
**Без китмибез шапшак караңгыдан,**
**Сарыкортлар суза күккә кул.**
**Урманның да китте шүрәлесе,**
**Качып китеп барды авылдан.**
**Калаларда быел хәер сорый,**
**Былтыр, мескен, шашып акылдан.**
**Су анасы суларны ят итте**
**Табалмагач алтын тарагын.**
**Аналарын күралмый ятимнәр,**
**Заман эзли алтын карагын.**
**Караңгыда өер-өер бүре,**
**Кайнашалар учак тирәли.**
**Кәҗә белән сарык бер капчыкта**
**Туган телне суза, әллә-ли.**
**Кергә батты, төссезләнде тормыш,**
**Читлегеннән очты кошлары.**
**Мөкатдәс саз тынды уйнавыннан,**
**Заман өзде аның кылларын...**
**Ә пар атлар күптән чабып узды,**
**Һәм һава да бетте үпкәдә.**
**Кисекбаштай тәгәри безнең тормыш,**
**Кичә шулай, бүген, иртәгә.**

---

Булат ИБРАҺИМОВ (1990) – *яшь шагыйрь; Казан федераль университеты студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә.*

* * *

Сине сагынып, бәлкем, яңгыр явар
Аяз күкне чәлпәрәмә ватып,
Һәм яңгырлар карга әверелгәч
Син кайтырсың кебек... тик кайтып
Салкын карлар барыбер кайнар булмас,
Боз сөңгесе купмас йөрәктән.
Җәйләр буе сайраган кошларны
Сары яфрак куа тирәктән...
Әйдә, китсен, җанда калган җылы,
Һәм шартласын хисләр диңгезе.
Ул диңгездә энҗе бөртегенең
Булганлыгын беләм тик үзем.
Минем күзем хәзер чит тәрәздән
Чит бер күккә зәңгәрлеген түгә.
Тәннән чыгып киткән җанның
Кайтканы юк... кайтмый икән нигә?..
Салкын урамнарның юлларында
Җил исергән дусты төн белән,
Таңнар атыр тиздән,
Таңнар атыр,
Кояш чыгар күккә, мин беләм...
Тик әлегә күктә куе болыт,
Ә артында аның салкын ай.
Сары ай да агарынып калган,
Кайгыларга баткан, мескенкәй.
Әй, ай дустым, әйдә, ярыл әле,
Тын дәрьяга сикер, йә Һиндка.
Су астында калсын гөнаһлы җир,
Су астында калсын, тынлыкта...
Ә әлегә күктә куе болыт,
Сине сагынып шашкын яңгыр ява.
Туңган юлны чәлпәрәмә ватып
Җанның соңы булып тамчы тама.

***

Буранлы кыш урталары иде,
Ишек шакый берәү ашыгып:
Нәни кызчык туды, ишетәсеңме,
Син бит аны көттең зарыгып.
Җил җыр көйли аңа...
Ә ул анда толымнарын җилгә таратып
Олы юлдан олы юлга бара,
Шатлык–кайгыларын яңартып.
Җил җыр көйли аңа...
Ә ул инде күптән сабый түгел,
Җиткән кыз.
Ак күлмәген киеп узып бара,
Ак күлмәген кигән,
Тышта көз.
Көзләрдән соң җиргә ак кар ява,
Сафлык ява, пакьлек коела,
Менә шулай әкрен генә җирдә
Тормыш елгалары уела.
Җил җыр көйли аңа,
Һәм чәчләрен шаян малай кебек тарткалый.

Төнге күктән күзен кысып кына,
Ялт-йолт итеп сары ай карый...
Буранлы ай урталары иде,
Ишек шакый бирәү ашыгып.
Чәчәк бәйләмнәре кѳтеп тора,
Ишек ачылганны, зарыгып.

## Сугыш бара

Яралы күңелләр,
Яралы язмышлар...
Баш хирург, кайда син?
Йѳрәккә туктаусыз аталар,
Саф җаннар авалар тузанга.
Ә заман томанда
Ал канын югалта.
Сугыш бара,
Үзе белән сугышырга
Сугыш бара.
Соңгы яугир булып,
Соңгы сулышында.
Калтырана туплар,
Һәм машина асларында
Изге - яман уйлар,
Канга батырылып кыйналганнар.
Бу кылганнар изге гамәл түгел,
Кылынганнар безнең теләк түгел,
Без эт кебек буйсынучан гына.
Патша курчак уйный хыялында...
Яңгыр ява.
Томандагы ак мамыкны юа
Замананың ал каныннан.
Безнең нәсел нинди ханнан килә,
Без нинди тамырдан?
Сугыш бара.
Үзе белән сугышырга сугыш бара,
Соңгы яугир булып,
Соңгы сулышында.
Ә урамда коеп яңгыр ява,
Үткәннәрне шыпырт кына
Юып бара.

# ГЫЙЛЕМ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ УЧАГЫ

Татар халкының үз ана телендә вакытлы матбугат чаралары булдыру өчен алып барган йөз елга сузылган көрәше XX гасыр башында, ниһаять, җиңү китерә: Россия империясендә яшәүче аз санлы халыкларга, шул исәптән татарларга да матбугат иреге бирелә. 1905 елгы Беренче рус инкыйлабыннан соң татарлар яшәгән күп төбәктә татар телендә төрледән-төрле газета-журналлар нәшер ителә башлый. Күтәргән проблемаларның колачы, жанр төрлелеге, авторлар даирәсенең киңлеге, әбунәчеләр саны ягыннан караганда, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты үз чоры таләпләренә тулысынча җавап бирә. Әйтергә кирәк, менә чагыштырмача кыска вакыт аралыгында ирешелә.

Беренчедән, вакытлы матбугат барлыкка килгәнче үк Каюм Насыйриның татар телендә календарьлары, Габдерәшит казыйның альманахлары дөнья күрә, кульязма газета-журналлар, яшерен листовкалар чыгып килә һәм алар яна гына мәйданга килгән татар вакытлы матбугатын техник һәм рухи яктан тәэмин итүгә унай йогынты ясыйлар.

Икенчедән, бу чорда башка төрки телләрдә чыгып килгән басмалар белән тыгыз хезмәттәшлек иткән һәм матбага эшендә шактый тәҗрибә туплаган татар зыялылары, матбугат иреге бирелүгә, бик тиз арада җиң сызганып эшкә керешеп китәләр.

Өченчедән, заман сулышын тоеп, ул чорда татарлар алдында торган гаять җитди проблемаларны тирәнтен аңлап һәм аларны басма матбугат аша халыкка җиткерергә сәләтле публицистларның тулы бер плеядасы матбугат мәйданына чыга. Шуна күрә дә татар вакытлы матбугаты дөньяга килүгә нәкъ менә публицистиканың төп жанрга әверелүе һич тә гаҗәп түгел. Менә шушы алшартлар татар вакытлы матбугатына тиз арада киң җәелеп китәргә һәм популярлашырга мөмкинлек бирә дә инде.

Татар телендә чыккан газета-журналларда милләтне йокыдан уяту, аны дөньяның алдынгы милләтләре дәрәҗәсенә күтәрү, милли үзаң тәрбияләү, унай традицияләребезне саклап калу һәм үстерү, җәмгыятьнең яман чирләрен фаш итү темалары кызыл җеп булып сузыла. Газета-журналлар, озакка сузылган көрәштә яулап алынган матбугат ирегеннән мөмкин кадәр нәтиҗәле файдаланып калырга ашыккандай, тормышның, яшәешнең барлык тармакларын колачларга омтыла.

Әлбәттә инде, мәгърифәт-мәгариф мәсьәләләре дә игътибардан читтә калмый. 1883 елда Бакчасарайда И.Гаспралы нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә төрки-татар телендә чыга башлаган «Тәрҗеман» газетасында да; беренче татар газетасы буларак тарихка кереп калган «Нур»да да; 1907 елның гыйнвар-мартында Мәскәүдә татар телендә нибары биш кенә саны чыгып калган «Тәрбиятел-әтфәль» («Балалар тәрбиясе») дип аталган фәнни-педагогик, әдәби журналда да (нәшире һәм мөхәррире – З.Шамил, сәркатибе – Ф.Әмирхан); Оренбургта чыгып килгән «Шура» (1908 – 1918), «Мөгаллим» (1913 – 1914), «Карчыга» (1906 – 1907); Казанда нәшер ителгән «Ан» (1912 – 1918) журналларында да уку-укыту проблемаларына киң урын бирелә. Ә инде «Әл-гасыр әл-җәдит» («Яңа гасыр»)

(1906) журналында, «Әл-ислах» газетасында (1907), «Тәрбия» (1908) журналында мәктәп-мәдрәсәләрдә яңача укыту мәсьәләләре үзәк урыннарның берсен ала. Әмма бу өлкәдә проблемалар шундый күп тупланган була ки, җәмәгатьчелек игътибарын шуларга юнәлтү, аларны хәл итү юлларын билгеләү өчен махсус басма булдыру зарурлыгы килеп туа. Менә шул ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатыннан, 1913 елның 21 февраленнән (яңа стиль белән 6 марттан) «Мәктәп» журналы нәшир ителә башлый. Нәшире һәм мөхәррире Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров булган бу журнал тулысы белән укыту-тәрбия мәсьәләләренә багышлана. Ш.Әхмәров журнал тирәсенә татарның танылган әдипләрен, галимнәрен, күренекле җәмәгать эшлеклеләрен, педагог-мөгаллимнәрен туплый. Тәҗрибәле мөгаллимнәр Ш.Бикколов, С.Кәмал, Г.Баттал, Н.Хуҗа, Р.Хәнәфи; русча-татарча мәктәпләрдә «учитель»ләр булып эшләгән М.Корбангалиев, Т.Мәхмүдев, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ф.Агиев һәм башкалар журналда үз мәкаләләре белән актив катнашалар. Авторлар арасында М.Акчурина, Ф.Сөләймания, М.Мозаффария кебек мөгаллимәләр дә була. Әлбәттә инде Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Һ.Атласи, З.Вәлиди, Һ.Максуди кебек әдипләр, галимнәр дә «Мәктәп»не хуплап каршы ала, беренче саннарыннан ук аның белән хезмәттәшлек итә башлый. Журналны оештыруда мәртәбәле дин галимнәре, мәдрәсә мөдәррисләре дә актив катнаша.



*«Мәгариф» журналы редакциясе хезмәткәрләре. 2013 ел.*

Журнал иң әүвәл киң җәмәгатьчелекнең игътибарын мәктәпләрдә фәннәрне заманча укытуга, укыту программаларын камилләштерүгә, мәктәп-мәдрәсәләр тарихын, сәнәгать һәм һөнәр мәктәпләре эшен яктыртуга һәм укыту-тәрбия эшенә кагылышлы башка бик күп проблемага юнәлтә, татар халкының тарихына, мәдәниятенә, диненә, иҗтимагый хәленә кагылышлы мәсьәләләрне күтәреп чыга.

Кызганыч, «Мәктәп» журналының нибары 25 саны гына чыгып кала. Әмма ул үзенең шул саннары белән дә татар мәгариф системасын тамырдан үзгәртеп кору юнәлешләрен күрсәтергә, алдынгы карашлы мөгаллимнәрнең, педагогларның, әдипләрнең фикерен киң катлам халыкка җиткерергә өлгерә.

1918 елның 7 ноябрендә «Мәгариф» журналының 1 нче саны дөнья күрә. «Мәктәп»нең беренче саннарыннан ук үз язмалары белән актив катнашкан Галимҗан Ибраһимов «Мәгариф» журналын оештыручы, аның беренче мөхәррире була. «Мәгариф» журналы «Мәктәп» журналы башлаган традицияләрне уңышлы дәвам итә, эшне яңа чор таләпләре югарылыгында оештырырга омтыла. Соңрак ул төрле исемнәр белән нәшир ителә. Байтак вакыт «Башлангыч мәктәп», «Совет мәктәбе» исемнәре белән басыла. 1990 елның сентябреннән яңадан «Мәгариф» исеме белән чыга башлый.

Журнал бүген дә үзенең мәсләгенә тугрылыклы булып кала. Ул республикабызның гына түгел, Россия Федерациясенең татарлар күпләп яши торган утызга якын төбәге укытучыларының һәм тәрбиячеләренең якын ярдәмчесенә һәм киңәшчесенә әверелде. Журнал битләрендә уку-укыту, яшь буынга тәрбия бирүнең иң актуаль проблемалары күтәрелә; тәҗрибәле укытучыларның дәрес үрнәкләре бирелә;

«Мәгариф» дәүләт проектын гамәлгә ашыру буенча республика мәктәпләрендә, уку йортларында тупланган унай тәҗрибә гомумиләштерелә; белем бирүне профильләштерү шартларында укыту-тәрбия эшен оештыру, анын сыйфатын күтәрү; мәктәптә яна технологияләрдән файдалану турында язмалар басыла. «Заман һәм мәгариф сәясәте», «Туган тел һәм әдәбият», «Рус балаларына татар теле һәм әдәбияты», «Русское слово», «Чит телләр», «Башлангыч мәктәп», «Мәктәпкәчә тәрбия», «Гыйлем дөньясында», «Тәрбия һәм өстәмә белем», «Сорагыз — җавап бирәбез» һәм башка рубрикалар белән бирелгән материаллар арасыннан яшь буынга белем һәм тәрбия бирү проблемалары белән кызыксынган һәркем үзенә кирәкле язманы таба һәм файдалана ала.

«Мәгариф» — республикада иң күп тиражлы басмаларның берсе. Аны укытучылар, тәрбиячеләр генә түгел, галимнәр, ата-аналар да яратып укый, яшь буынга белем һәм тәрбия бирү эшендә актив файдалана. Журнал республикабызның иҗтимагый-сәяси тормышында барган вакыйгаларны да читләтеп үтми.

Мәгълүм булганча, 2012 ел илебездә — «Россия тарихы елы»; республикабызда — «Татарстанның тарихи-мәдәни мирасы елы», « Коръән елы» дип игълан ителгән иде. Былтыр 1812 елгы Ватан сугышында җиңүнең 200 еллыгын да билгеләп үттек. Әлеге темаларны халку итеп яктырту максатында, махсус рубрикалар булдырылды, журналның һәр санында диярлек танылган галимнәребезнең, тәҗрибәле укытучыларның һәм тәрбиячеләрнең татар, рус, инглиз телләрендә мәкаләләре, дәрес эшкәртмәләре биреп барылды.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы»н үтәү йөзеннән, журналда, татар һәм рус телләрендәге язмалардан тыш, чуваш, мари телләрендә дә дәрес эшкәртмәләрен бирүне дәвам итәбез.


«Татарстаннан читтә татар мәгарифе» рубрикасы белән бирелгән язмаларда Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребезнең телебезне, мәдәниятебезне саклап калу, үстерү буенча алып бара торган эшчәнлеге киң яктыртыла.

2013 елда Казанда булачак Универсиадага әзерлек уңаеннан, республикабыз башкаласында төзелә торган спорт корылмаларының сурәтләре; бу мөһим вакыйганың эчтәлеге, әһәмияте турында кызыклы язмалар, белешмә материаллар биреп барыла.

Әлбәттә, Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек мәсьәләләре журналның игътибар үзәгендә тора. Имтихан биреләсе һәр фән буенча татар, рус телләрендә, чит телләрдә үрнәк дәрес эшкәртмәләре, программаларга өстәмә материаллар басылды һәм алар республикабыз укытучылары тарафыннан хуплап каршы алынды.

Быел журналыбызның беренче саны чыгуга 100 ел тула. Тарих өчен әллә ни күп вакыт та түгел. Әмма татар мәгарифе тормышында аның тоткан роле бәһаләп бетергесез. Шул чорда ул берничә буын мөгаллимнәренең, укытучылар һәм тәрбиячеләренең чын мәгънәсендә өстәл китабына әверелде, аларга якын дус һәм остаз булды. Журнал, тирә-юньгә җылылык бөркеп торган тылсымлы учак сыман, менә инде бер гасырга якын укытучыларны, тәрбиячеләрне, галимнәрне үз тирәсенә туплап, бөтен татар дөньясына гыйлем һәм мәгърифәт нуры сирпеп тора, яшь буынны халкыбызның гүзәл традицияләре үрнәгендә һәм заман рухында тәрбияләүдә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Ул алга таба да укытучыларның, тәрбиячеләрнең, мәгариф системасы хезмәткәрләренең, ата-аналарның якын дусты һәм ышанычлы таянычы булып калыр.

**Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ,**
*«Мәгариф» журналының баш мөхәррире,*
*тарих фәннәре кандидаты*



*1979 елның июль аенда Татарстанда Совет әдәбияты көннәре узды. Бу әдәби бәйрәмдә СССРның төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килгән күренекле язучылар катнашты. Кунаклар һәм бер төркем татар язучылары КПССның Татарстан өлкә комитеты бинасы янында. Фоторәсемне җентекләбрәк карагаңда байтак таныш шәхесләрне танырга мөмкин.*



*Әхмәт Фәйзинең вафатына дүрт көн калган көндә алынган соңгы рәсеме. Утыралар (сулдан уңга): Абдулла Әхмәт, композитор Мансур Мозаффаров, Нури Арслан, Әхмәт Фәйзи, Риза Ишморат. Аккош күленең язучылар дачасында. 1958 елның августы.*



*Шагыйрь Сибгат Хәким (уңда) һәм диктор Эльс Гаделев Маркиз утравында. 1984 ел.*



*Замандашлар: шагыйрьләр – Наис Гамбәр һәм Җәүдәт Дәрзаманов. 1998 ел.*

# ТӘРҖЕМӘЧЕЛЕК — ЗАМАН ТАЛӘБЕ

Сүземне утыз ел дәвамында француз әдәбиятыннан төрек теленә роман-хикәяләр тәрҗемә иткән төрек әдибе, фәлсәфәче мәрхүм Җәмил Мәричнең әдәби тәрҗемә турындагы фикерләре белән башларга телим: «Тәрҗемә ул — яралту, минемчә, шигырь кебек, нәсер кебек, хәтта алардан да кыенрак. Әйе, тәрҗемә әдәби жанрлар арасында иң авыры — башка җирлектә һәм башка чорда туган уй-фикерне үз җирендә терелтү. Тәрҗемә — яулау, яулау гына түгел, уй һәм хисләрнең катлаулы дөньясын баетучы казаныш ул». Әнә шулай әдәби тәрҗемәгә иң хак, иң гадел бәя биргән олы остаз.




Әдәби тәрҗемә, бер караганда, бала табу белән бер. Ана кеше ничә бала табуына карамастан, бер баланы да дөньяга тулгаксыз китерми. Әлеге әсәрләр дә, күләменә-иенә карамастан, уй-газапларсыз, интегүсез дөньяга килми. Туып кына бетсә бер хәл: аннары кайта-кайта ыспайлап чыгарга туры килә. Тәрҗемәче бер үк вакытта көзге ролен дә башкара. Аның төп эше — әдип әсәрен чын мәгънәсендә түкми-чәчми башка халыкларга җиткезү. Шуңа күрә үзе алда күренми, ул арткы планда, аның аша әдипләр башка илләрдә танyла. Аларның мәшһүрләшүе тәрҗемәчегә дә сөенеч китерә. Тәрҗемәчеләр әдәбиятның иң тыйнак эш атларыдыр әле, кем белгән...

Әмма төрки телләрдән тәрҗемә итүгә килгәндә, төрки дөнья галимнәре, бигрәк тә безнең төрек галимнәре әлеге эшне тәрҗемәгә санамыйлар. Тәрҗемә сүзе урынына «күчереп язу» мәгънәсенә килә торган «актарма» сүзен куллану ягында. Алар: «Ничек инде, без кардәшләр бит. Кардәшләр арасында тәрҗемә буламыни ул?» — дигән карашта торалар. Моңа нигез итеп түбәндәге сүзләрне китерәләр: «Үктәбер инкыйлабына кадәр Истанбулда басылган бер әсәр Казанда, Казанда басылган һәр әсәр Истанбулда укылган». Ә моның сәбәбен төрек галимнәре әлеге инкыйлабка кадәр татар теле белән төрек теленең бик якын булуы белән аңлатырга тырышалар. Ягъни татарның көндәлек сөйләм теле төрекчәгә бик якын булган. Ә соңгы житмеш елда тел бик нык үзгәргән. Бу хакта әдәбият галиме Фоат әфәнде Галимуллин «Табигыйлеккә хилафлык» дигән хезмәтендәге «Төрекләр һәм без»[1] мәкаләсендә болай дип яза: «1917 елга кадәр төрек телен белмәүче татар зыялылары, галим-голәмаләре, шагыйрьләре булмаган диярлек. Мәктәп-мәдрәсәләрдә гарәп, фарсы телләре белән бергә төрек теле дә укытылган. Кардәш төрек халкының теле барлык төрки милләтләр өчен әдәби тел буларак та хезмәт иткән. Г.Тукай иҗатының да башлангыч чорындагы кайбер шигырьләре 80-90 проценка төрек телендә язылган. Г.Кандалый, Г.Чокрый, З.Шәмсетдин, М.Гафури, Дәрдемәнд, Р.Фәхретдин һәм башка каләм әһелләре дә төрек телендә иркен эш иткәннәр. Чөнки татар мәдрәсәләрендә, бигрәк тә «Хөсәения», «Галия» кебекләрендә Төркиядә белем

[1] Галимуллин Ф. Табигыйлеккә хилафлык.- Казан: Татар. Кит.нәшр., 2004. - 156-157 б.

алган хәлфәләр дә укыткан. Шуна күрә дә алар төрек теленә өстенлек биргәннәр. Уку китапларының да күбесе төрек телендә булган». Моннан аңлашылганча татар халкы төрек телен тумыштан ук түгел, мәдрәсәдә махсус белем алганнан соң белгән. Әмма татар халкы йөз ел элек тә бүгенге татар телендә сөйләшкән һәм аралашкан. Мин фәкыйрегез 1891 елны Төркиягә хиҗрәт кылган татарларның телен өйрәнгәндә, алар белән аралашканда менә тагын бер кат тап булдым. Икенчедән, төрек теле 90 ел инде төрки милләтләр өчен әдәби тел булып хезмәт итүдән туктаган. Шуңа күрә бүгенгесе көндә бик табигый рәвештә татар халкы гына түгел, аның галимнәре, язучылары, шагыйрьләре дә төрек телен белми. Шулай ук төрек халкы, галимнәре, язучылары, шагыйрьләре дә ... татар телен белми. Бу ачы хакыйкатьне таныырга мәҗбүрбез. Бүгенгесе көндә төрек теле татар халкы өчен чит тел, татар теле төрек халкы өчен чит тел. Моңа кадәр, әлеге хакыйкатьне танымау сәбәпле, тәрҗемә өлкәсендә эзлекле эшләр алып барылмаганын күрәбез. Дөрес, без — төрекләр, угызлар буларак, телләре безнеке кебек угыз булган гагаузлар, аннан әзәрбайҗаннар һәм кырым татарлары белән гомер-гомергә тәрҗемәсез-нисез аралашып яшәгәнбез. Ә татарлар — кыпчак. Ә угыз белән кыпчак тәрҗемәсез, ягъни берсе-берсенең телен махсус өйрәнмичә аралаша алмый, язганнарын аңламый. Димәк, бу өлкәдә тәрҗемә зарур. Бу хакыйкатьне күптән инде аңлаган булсак, шушы егерме өч ел вакыт эчендә татарчадан төрекчәгә, төрекчәдән татарчага әдәби әсәрләр тәрҗемә итүче белгечләр әзерләнгән булыр иде.

Тәрҗемәчеләрне ничек әзерләү мәсьәләсенә килгәндә, камил тәрҗемә өчен тәрҗемәченең икенче телдән ана теленә тәрҗемә итүе зарур. Дөнья тәрҗемә стандартларында бу шулай куелган. Бу очракта төреккә татарныкын, татарга төрекнекен тәрҗемә итәргә туры килә. Моның өчен билгеле бер сандагы төрек студенты Казанда татар филологиясе бүлегендә белем алса, татар студентлары шулай ук Истанбулда яисә Әнкарада төрек филологиясе буенча укыса, бу эш мөмкин булыр иде. Чөнки чит телне камил рәвештә өйрәнер өчен шул илдә яшәп белем алып, шушы тел вәкилләре белән аралашудан да кулайрак чара юк. Мондый проектны илләр үзара килешү нигезендә генә тормышка ашыра ала. Бу беренче һәм иң нәтиҗәле, иң төпле адым булыр иде. Икенче мөһим адым — сүзлекләр мәсьәләсе. «Туганлыгыбыз аркасында» бу өлкә дә читтәрәк калган. Сүзлекләр булмавы бик зур киртә булып тора. Икенче яктан, рус теле, инглиз, алман телләре чит тел булганлыктан, Төркиядә күптәннән инде саллы-саллы сүзлекләр булдырылган. Шулай ук әлеге телләргә тәрҗемә итүче билгечләр дә җитәрлек. Сүз уңаеннан шуны әйтәсем килә, Чыңгыз Айтматов әсәрләрен рус теле урынына ана телендә — кыргызча иҗат иткән булса, төрек укучысы мөгаен аны белмәгән дә булыр иде. Рус теленнән төрек теленә һәм төрек теленнән рус теленә тәрҗемә итү җайга салынганлыктан, рус әсәрләре төрекчә, төрек әсәрләре русча даими рәвештә дөнья күрә.

Сүзлек дигәннән, мин бу очракта татар теленең өч томлык аңлатмалы сүзлеген төрекчәгә, төрек теленең аңлатмалы сүзлеген татарчага тәрҗемә ителүен күз уңында тотам. Менә өстәп Нәкый ага Исәнбәтнең ике томлык фразеологизмнар сүзлеген төрекчәгә тәрҗемә ителүе, төрекчә фразеологизмнар сүзлеген татарчага тәрҗемә итү бик тә зарур. Мин боларның барысын да ничә ел инде интегә-интегә татарчадан төрекчәгә тәрҗемә итү тәҗрибәсеннән чыгып әйтәм. Әлеге эшне, әлбәттә, булачак тәрҗемәче белгечләр генә камил рәвештә башкара ала.

Мин бүгенгесе көндә татар әсәрләрен чит телләргә тәрҗемә итү эшен җәелдерү һәм эзлекле хәлгә китерү өчен Төркия Туризм һәм мәдәният министрлыгының 7 ел инде уңышлы рәвештә эшләп килгән бик тә кызыклы проекты белән таныштырырга телим. Ул проект «Теда проекты» дип атала. Аның максаты — төрек әдәбияты, мәдәнияте турындагы әсәрләрне төрекчәдән тыш телләргә тәрҗемә итүчеләргә һәм шул илләрдә нәшер итүчеләргә акчалата булышу. Әсәр нинди телгә тәрҗемә ителсә, шул илнең нәшриятында дөнья күреп, сатуга куелырга тиеш.

Моның өчен аерым шәхесләр, шулай ук университетлар, җәмгыятьләр, вакыфлар, нәшриятлар һ.б. оешмалар үзләре сайлаган әсәр белән министрлыкка мөрәҗәгать итә алалар. Министрлыкта моның өчен махсус комиссия эшли, алар тәкъдим ителгән әсәрне хуп күрәләр икән, йә нәшриятка китапны бастырыр өчен тулысы белән акча

түлиләр, йә тәрҗемәчене канәгатьләндерерлек акча бирәләр. Шул проект нигезендә 7 ел эчендә төрек әсәрләре 41 телгә тәрҗемә ителгән, 50 илдә басылып чыккан һәм алар әлегә барлыгы 748 китап.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, камил тәрҗемә ана теленә генә була ала. Ягъни татар әсәре инглиз теленә тәрҗемә ителә икән, татар телен камил белүче инглиз кешесе, алман теленә тәрҗемә ителә икән, татар телен камил белүче алман кешесе кирәк һ.б. Икенче яктан, татар әсәре кайсы телгә тәрҗемә ителә икән, шул телдә сөйләшүче халыкның илендә дөнья күреп, шунда сатуга куелырга тиеш. Алга таба андагы укучыларның, әдипләрнең, тәнкыйтьчеләрнең фикерләрен белеп торырга кирәк. Китап бер очтан тегендә сатылып торганда, икенче яктан, шушы чит ил нәшриятлары белән сөйләшеп, китапны әзме-күпме сатып алып, Казандагы «Нур» кибетенә куярга була, минемчә. Анда «Чит илдә тәрҗемәдә чыккан татар язучыларының әсәрләре» дигән бер почмак булдырылса, әлеге китапларны теләгән кеше шуннан сатып та алыр иде. Бу алым, тәрҗемәдә чыккан әсәрләргә карата аеруча кызыксыну да уятыр һәм чит телне өйрәнүчеләргә чагыштырып өйрәнергә дә ярдәм итәр иде. Моның бәрабәренә әлеге китаплар күпләп Татарстан мәдәният министрлыгында, Язучылар берлегендә булса, шул илдән килүче кунакларга мәнә дигән бүләк тә була алачак. Өченче яктан, Милли китапханәдә берничә данә булса, ул мәңгелек сакта торыр иде.




Тәрҗемә өлкәсендә китапка кадәр тагын үтемле алым — ул да булса әдәби журналларны файдалану. Төрки халыклар үз журналларында кардәш халыкларның әдәбиятын яктыртып, үз халыкларын алар белән таныштыра алалар. Хикәяме ул, повестьме, шигырьме, бер прозаикмы, әллә шагыйрьме — Төркиядә моның өчен «Кардәш каләмнәр» дигән махсус журнал чыга. Анда төрки халыкларның әсәрләре даими рәвештә төрекчә бирелеп килә. Тагын «Несе Өykü» журналы да күптән түгел төрки халыкларның хикәяләре өчен махсус саннар әзерләгән. Соңгы декабрь-гыйнвар саны хәзерге татар хикәясенә багышлап чыгарылган. Төркиядәге журналлар нигездә шулай эшләп киләләр.

Мин якын киләчәктә «Казан утлары» журналының битләрендә дә моңа охшаш күркәм чаралар оештырылачагына ышанам. Башка татар журналлары да бу эшкә рәхәтләнеп алынырлар дип уйлыйм. Монда ике мәсьәлә бар: беренчесе, төрек телен камил белүче татар тәрҗемәчеләре булдыру; икенчесе, аларга тиешенчә каләм хакы түләү. Мин бу очракта төрекчәдән татарчага хикәяләр[2] һәм пьеса[3] тәрҗемә итеп бастырган, төрек телен камил белүче Казан федераль университетының төрки филология кафедрасы доценты Асия ханым Рәхимованы әйтә алам.

Сүземнең ахырында сезне соңгы җиде-сигез елда төрекчәгә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күргән татар әсәрләренең исемлеге белән таныштырып үтәсем килә. Алар түбәндәгеләр:

1. «VASIYET» исемле җыентык. «Замбак» нәшриятында 2005, 2006 һәм 2012 елларда өч басмасы дөнья күрә. Анда кергән әсәрләр профессор Хатыйп Миңнегулов тәкъдиме белән сайланып, китап аның кереш сүзе белән чыга. Тәрҗемәчеләре — Фатих Кутлу, Хамза Әрсой, Надир Тамәр Аслан. Җыентыкка кергән әсәрләр: Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык»; Шәриф Камал «Буранда», «Уяну»; Фатих Әмирхан «Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый»; Галимҗан Ибраһимов «Табигать балалары»; Мирсәй Әмир «Мөстәкыйм карт йокысы»; Фатих Хөсни «Сөйләнмәгән хикәя»; Миргазиян Юныс «Безнең өй өянкеләр астында иде».

2. Разил Вәлиевнең «MAVI HÜZÜN»(«ЗӘҢГӘР САГЫШ») җыентыгы «Da»

[2] «Кил әле, таныш булыйк» исемле җыентык (13 хикәя, романнардан өзекләр). – Казан: «Тамга» нәшр., 2005.
[3] Нәҗип Фазыл Кысакүрәк. Мәрхәмәт (Рәис Бәй). Пьеса. – Казан: «Тамга» нәшр., 2009.

нәшриятында 2007 елда дөнья күрә. Тәрҗемә итүчеләр — Фатих Кутлу, Харун Тосун. Бу китаптагы «Дуслык учагы» дигән шигырьгә композитор Кәмал Кутлу төрекчә көй язды. Шулай итеп, әлеге җыр сүзләре төрекчәгә тәрҗемә ителеп, ана төрекчә көй язылган беренче татар җыры булып тарихка кереп калды.

3. Аяз Гыйләҗевнын «BIR AVUÇ TOPRAK» («ӨЧ АРШЫН ҖИР») повесте Фатих Кутлу тәрҗемәсендә һәм профессор Хатыйп Миңнегуловның кереш сүзе белән «Сүтүн»нәшриятында 2008 (2 басма), 2011 елларда басылып чыкты. Аяз Гыйләҗевнын Фатих Кутлуга васыяте буенча тәрҗемә ителде. Ходайның хикмәте — әсәрнең чыгуы мәрхүмнең 80 еллыгына туры килде һәм ул 2012 елда Ауразия Язучылар берлегенең «Төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә» номинациясендә җиңү яулады. Повесть турында төрек матбугатында дүрт тәнкыйть мәкаләсе дөнья күрде.

4. «HECE ÖYKÜ» журналының «Хәзерге татар хикәясе» дигән 54 нче номерлы махсус «декабрь-гыйнвар» саны. Фатих Кутлу тәрҗемә иткән хикәяләр Әлфәт Закирҗановның кереш сүзе белән чыкты. Анда ун автордан берәр хикәя урын алды, алар түбәндәгеләр: Айгөл Әхмәтгалиева «Җиде ят», Асия Юныс «Бәби мунчасы»; Аяз Гыйләҗев «Күлмәк»; Галимҗан Гыйльманов «Күнел күзен күрәме?»; Дания Гайнетдинова «Бәхет яшьләре»; Зөлфәт Хәким «Чын ярату»; Марсель Галиев «Балачак әсирлегендә»; Рабит Батулла «Хәерче Габәш»; Рәмзия Габделхакова «Китүчеләр»; Ркаил Зәйдулла «Ак эт».

5. Аяз Гыйләҗевнын «CUMA GÜNÜ, AKŞAM...» («Җомга көн, кич белән...») әсәре Фатих Кутлу тәрҗемәсендә һәм Миләүшә Хәбетдинова кереш сүзе белән «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда дөнья күрде. Әлеге хезмәт алдан ук планлаштырып куйган төсле Аяз аганың сиксән биш еллыгына туры килде (тәрҗемә дүрт ел барды).

6. «Тавышсыз курай» (хәзерге татар әдәбиятыннан хикәяләр) җыентыгы «Бәнгү» нәшриятында 2013 елда басылып чыкты. Әлеге китапта «Hece Öykü» журналының 54нче номерына кергән, өстә телгә алынган 10 хикәядән тыш Рабит Батулланың «Тавышсыз курай» әкияте һәм Әсгать Салахның «Соңгы вальс» повесте урын алды.

**Фатих КУТЛУ,**
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы,*
*тәрҗемәче, язучы, филолог*

---

*Киләсе санда укыгыз*

Нәбирә
Гыйматдинова

## ҮЗЕМ ГЕНӘ БЕЛӘМ

БӘЯН

— Бу авылда ни йомышың бар?
— Шунда... берәүләр кил дигән иде, — диде Сәлимә, җәелмичә генә.

Җәелмәде шул. Чөнки җәелерлеге юк иде. Бүген аның тормышы тоташ ялганнан гына гыйбарәт. Сукбай Сәлимә. Урамга аны марҗа килен сөрде. Киемнәрен бүктәре белән подъездга чыгарып бәрде. Ә монда хатын күршеләренә матур ялганнан челтәр үрә: имеш, таш ызбаның ни сулар һавасы, ни иркенлеге юк. Яшәсеннәр яшьләр үзләренчә, имеш...

# ТЕЛЛӘРНЕҢ КҮПТӨРЛЕЛЕГЕ – БӨТЕН ДӨНЬЯ БАЙЛЫГЫ

### ХАЛЫКАРА ПЕН-КЛУБНЫҢ КЫРЫМ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

*Узган ел Кырымда – Украинаның Симферополь (Акмәчет) шәһәрендә Халыкара Пен-клубка караган Урал-Алтай төркеменең дүртенче корылтае булып үтте. Ул «Әдәби тәрҗемә һәм аз санлы халыкларның тел-тәрҗемә хокукы» дип аталды. Алдагы елларда шушындый ук конференцияләр Төркия, Венгрия һәм Монголиядә узган. Кырымдагы корылтайны Уйгыр ПЕН-үзәге һәм кырым татарларының Милли Мәҗлесе оештырды. Әлеге чарада кырымтатар язучылары, галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре, Уйгыр ПЕН-үзәге вәкилләре, төрле милләтләрнең Төркия, Корея, АКШ, Канада, Испания, Япония, Швеция, Финляндия, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстаннан килгән ПЕН-үзәк делегатлары катнашты. Татар ПЕН-үзәген аның директоры, язучы Әхәт Мушинский белән без икәү тәкъдим иттек.*

## Халыкара ПЕН–клуб турында кыскача



*Халыкара ПЕН-клуб Президенты Джон Сол һәм Ленар Шәех.*

Халыкара ПЕН-клуб – төрле әдәби жанрларда иҗат итүче профессиональ язучыларны һәм журналистларны берләштергән бәйсез халыкара оешма. Ул 1921 елның 5 октябрендә инглиз язучысы Кэтрин Эми Доусон Скотт һәм язучы Джон Голсуорси башлангычы белән Лондон шәһәрендә оеша. Аның исеме авторучка (PEN) сүзен барлыкка китергән өч инглиз сүзенең баш хәрефләрен бергә кушып ясалган: «poet» (шагыйрь), «essayist» (эссесист), «novelist» (романист). ПЕН-клуб бөтендөнья язучыларының хокукларын яклый, цензурага каршы торып, сүз һәм шәхес иреге өчен көрәш алып бара, нахакка гаепләнеп, ягъни сәяси эзәрлекләүләргә дучар булып, репрессияләнгән һәм төрмәләрдә утырган каләм әһелләренә ярдәм итү юлларын эзли. ПЕН-клуб канаты астына кергән ПЕН-үзәкләр исә милли тел һәм милли әдәбият нигезендә формалаша. Бүген 102 илдә 144 ПЕН-үзәк эшләп килә. Дөнья буенча аларда 10 мең әгъза исәпләнә, шулар арасында ике Нобель премиясе лауреаты бар. Россиядә бары ике ПЕН-үзәк – Рус һәм Татар ПЕН-үзәкләре эшли.

## Беренче көн

Симферополь шәһәренең тимер юл вокзалына килеп төшүгә, без корылтай делегатлары тукталырга тиешле «Мәскәү» кунакханәсенә юнәлдек. Безне конференцияне оештыручылар һәм Уйгыр ПЕН-үзәгенең Президенты Кайсар Абдурасул Өзхун каршы алды. Ул Татар ПЕН-үзәгенең күптән көтелгән кунак булуын житкерде. Әхәт Мушинский Финляндиядән килгән дусты Юкка Маллинен белән кочаклашып күреште. Үзара сөйләшә, таныша, төрки дөньяның төрле илләреннән, ерак континентлардан килгән вәкилләре белән аралаша торган арада кунакханәдә Халыкара ПЕН-клубның Президенты, канадалы Джон Рэлстон Сол, ПЕН-клубның генераль секретаре, япон язучысы Хори Такеаки пәйда булды.

Кичкә таба корылтайда катнашучылар кунакханәнең беренче катында җыелышты. Игътибарымны Австралиянең Аделаида шәһәреннән килгән Уйгыр ПЕН-үзәге

вәкилләре — апалы-сенелле Сөенгөл Чанышева һәм Сафия Вәлиева җәлеп итте. Җан тартмаса, кан тарта дигәндәй, алар безнең милләттәшләребез булып чыкты. Әтиләре ягыннан бабалары Ибраһим Апас районының Урта Балтай авылыннан, әниләренең әтисе Әхмәтнәҗип Сафин Кукмара районының Арпаяз авылыннан икән. 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң Кытайга күченеп китәргә мәҗбүр булганнар.

Сөенгөл ханым медицина университетында белем алган, студент елларында Кытай сәясәтенә каршы эш алып барган яшерен оешмада катнашкан. 23 яшендә кулга алынган һәм ун ел буе төрмәләрдә утырган, аннары сигез ел дәвамында каты күзәтү астында яшәгән. Кытайда «җепшеклек» дәвере башлангач, 1981 елда илдән чыгып китү җаен караганнар — барлык бертуганнары, балалары белән Австралиягә күченеп киткәннәр. Бер-берсенә таянып, кайгы-хәсрәтләрне урталай бүлешә-бүлешә аякка басканнар. Күченеп, дүрт ел узгач, әтиләре, моннан ике ел элек әниләре вафат булган. Сөенгөл ханымның тоткынлыкта узган еллары хакында уйгыр телендә «Күз яшеннән дымланган туфрак» исемле китабы дөнья күргән.



*«Жазушы» нәшрияты директоры, шагыйрь Есенгали Раушанов, Татар ПЕН-үзәге директоры, язучы Әхәт Мушинский, шагыйрь, дипломат Акбар Рыскулов (сулдан уңга).*

— Әти-әнием мине, гел сөенеп яшәсен дип, Сөенгөл исеме кушкан, ләкин язмыштан узып булмый шул... — диде ул, моңсу карашын өскә күтәреп. Мин аның күзләрендә тирән сагыш күрдем, ләкин зар чаткылары тапмадым.

Сафия Вәлиева Австралиядәге татар диаспорасы эшчәнлегендә катнаша, татар телендә шигырьләр яза, әсәрләре, көйгә салынып, күренекле татар җырчылары башкаруында халык күңеленә юл ала килә. Фән Вәлиәхмәтов репертуарындагы «Үремче» җыры туган шәһәрен сагынып, кайталмыйча газиз булудан иҗат ителгән.

Апалы-сенелле Сөенгөл һәм Сафия ханымнар берничә мәртәбә Татарстанда, Казанда булганнар, Бөтендөнья татар конгрессы корылтаенда делегат буларак катнашканнар, ата-бабаларының туган ягына сәяхәт кылганнар, нәсел җепләрен эзләгәннәр, ләкин таба алмаганнар. Үзләре дөньяга килгән Кытайга гына кайту мөмкинлеге юк — анда алар өчен юл ябык.

## Икенче көн

Корылтай иртәнге якта данлыклы Бакчасарай шәһәрендә, Дәүләт-Сарай тарихи-архитектура комплексында урнашкан «Ларишес» кырым тарихы музеенда ачылды. Ул төрки телдә һәм инглиз телендә алып барылды. Милли ПЕН-үзәк вәкилләреннән тыш, тантанада кырым татарларының Милли Мәҗлесе рәисе, Украина Радасы депутаты Мостафа Җәмилев, Кырым татарларының Бөтендөнья конгрессы президенты Рефат Чубаров, кырымтатар язучылары һәм галимнәре катнашты.

— Исмәгыйль Гаспралы без хәзер утырган бинада мәктәп ачты, төрки дөньяда беренче газетаны — «Тәрҗеман»ны чыгара башлады, — диде Рефат Чубаров. — «Телдә, фикердә, эштә берлек» — аның безгә калдырган васыяте.

Корылтайда Халыкара ПЕН-клуб Президенты Джон Сол, «Урал-Алтай» төркемен оештыручы Кайсар Өзхун, шагыйрь, Казахстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты, «Жазушы» («Язучы») нәшрияты директоры Есенгали Раушанов, шагыйрә, сценарист, Үзәк Азия ПЕН-Үзәге Президенты Далмира Тилепбергенова, Кыргызстаннан килгән шагыйрь, дипломат, педагог Акбар Рыскулов һ.б. чыгыш ясады. Үзебезнең чыгышны татар, рус һәм инглиз телләрендә без Казанда ук әзерләп килгән идек. Аны татар телендә катнашучыларга җиткерү миңа тапшырылды. Башта Татар ПЕН-үзәгенең эшчәнлеге белән таныштырып үттем, аннары татар әдәбиятын башка телләргә, бигрәк тә рус, инглиз, төрек телләренә тәрҗемә итү, төрки-

татар басма китабы тарихы турында сөйләдем. Үзебезнең ПЕН-үзәк исеменнән конференциянең чикләрен киңәйтергә, аны «Идел—Урал—Алтай» дип атарга тәкъдим иттем. Чыгышның инглизчәсен Юкка Маллинен житкерде.

Кыргызстаннан килгән Турсун Ислам исемле өлкән яшьтәге язучы уйгырларның тарихы, Кытайның аларга каршы алып барган сәясәте турында китап чыгарган.

— Бездә сәяси китаплар бастырырга рөхсәт юк, шуңа китабым Казахстанда рус телендә дөнья күрде. Инглизчәгә тәрҗемә итеп, Төркия нәшриятында да калдырдым. Басылу мәсьәләсе хәл ителеп ята, — диде ул.



*Корылтайда катнашучылар*

1952 елда Кытай эчендә урнашкан Уйгырстанда 3 % кытай яшәсә, бүген аларның саны 40%тан да артып китә. Кытай хөкүмәте, җиң сызганып, уйгырларның телен, динен юкка чыгару юнәлешендә генә эш алып бармый, алар янына күпләп кытайларны күчереп утыртып, уйгырларны ассимиляцияләргә, ягъни «эретеп» юкка чыгарырга тырыша, каршы чыгучыларны, террорист дигән ярлык тагып җәзага тарта икән...

Тәнәфес вакытында 1500 елда нигезләнгән «Зынҗырлы» («Чылбырлы») мәдрәсәсен карап чыктык, янәшәдә генә урнашкан беренче кырым ханнарының төрбәсенә, Исмәгыйль Гаспралының каберенә зират кылдык. Мәдрәсәдә 1905 елда «Кәримовлар басмаханәсе»ндә дөнья күргән Сөембикә манарасы рәсеме, Бакый Урманченың шамаиле дә урын алган.

Күңелне куандырган нәрсә шул булды: безне зурлап «Казан татарлары» дип йөртәләр, хөрмәтләре, унай мөнәсәбәтләре сизелеп тора. Үзара сөйләшеп утырганда Есенгали Раушанов:

— И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан! — дип Тукайның «Пар ат» шигыреннән өзек сөйләп китте, аннары яттан «Туган тел»не яңгыратты, «Сарман буйлары»н җырлады.

Есенгали агай үтә шук, мут кеше булып чыкты. Гел шаярта, һәр сүздән кызык мәгънә таба, шул ук вакытта житди дә була белә. Казахстанның «Жазушы» нәшриятында ел саен 200—250 исемдәге китап басыла икән. Дәреслекләрнең уртача тиражы 20 мең, иң күп дигәндә — 100 мең дана.

Казахстанның Алмата шәһәреннән килгән журналист, филология фәннәре кандидаты Һәдия Әхмәтовага бу сирәк исемне, татар кызлары белән бәйле хатирәләрен искә алып, әтисе куштырган. Һәдия ханым үз исемен дә, Муса Җәлилнең «Һәдиягә» дигән шигырен дә бик ярата. Шигырьнең рус теленә тәрҗемәсен бер сулышта яттан сөйләп күрсәтте.

Акбар Рыскулов ике ел буе кыргыз тарихы белән бәйле роман иҗат иткән. Язганнары — өч китап, өч том.

— Өйдән чыкмадым да диярлек, яздым да яздым. Сакалым Карл Марксныкы кебек булып бетте, — диде ул елмаеп.

Сөенгөл ханым Чанышевалар XX йөз башында Казанда «Кәримовлар басмаханәсе»ндә дөнья күргән китаплардан укып үскәннәр.

— Телебез — Тукай теле, ләкин хәзерге Казан татарларының теле үзгәргән, шуңа бер-беребезне аңлауда кыенлыклар туа, — бу аның фикере.

Чыннан да, элекке СССРга кергән төрки халыкларның телләренә рус теле төрлечә

йогынты ясаган. Нинди дәрәҗәдә булса да, алар барыбер бу тәэсиргә бирешкән. Кыргызстанда яшәүче 5,5 миллион халыкның 1 миллионнан артыгы кыргызча сөйләшми, башкалалары Бишкәктә бер генә кыргыз мәктәбе эшли. Татарстанда да татар мәктәпләре ябыла башлады. Тора-бара безнең башкалада да, советлар вакытындагы кебек, бердән-бер милли мәктәп кенә калырга бик мөмкин... Татар халкы әкренләп татарчалы-русчалы катнаш телгә күчеп бара. Болай дәвам итсә, киләчәктә төрки халыклар берсен-берсе бөтенләй аңламаячак кына түгел, ә Урта гасырларда бүлгәләнеп, вакланып беткән шикелле, берәм-берәм юкка да чыгачак. Хәзерге вакытта кырым татарларының хәле бигрәк тә аяныч. Аларның үткәне, бүгенге яшәеше турында өченче көнне сөйләштек.

## Өченче көн

Иртә белән без кунакханәнең кече конференцияләр залында, түгәрәк өстәл артында очраштык. Бүген туган телләрнең дөньякүләм глобальләшү мохитендәге торышы һәм үсеш мөмкинлекләре, халыкларның бер-берсен ныграк аңлавын төрле милләт әдәбиятларыннан тәрҗемәләр ярдәмендә тәэмин итү кирәклеге турында сөйләнелде. Төп басым кырымтатар теленә ясалды.

Кырым татарлары 1944 елда совет хөкүмәте тарафыннан туган җирләреннән тулысынча депортацияләнгән. Сталин алып барган сәясәт нәтиҗәсендә 238 мең кеше күчереп утыртылган, шуларның яртысы өч ел дәвамында юк ителгән дип исәпләнелә. Кырым татарларына үз ватаннарына әйләнеп кайту, туган телләрендә аралашу тыелган, моның белән килешмәүчеләр төрмәләргә ябылган. Узган гасырның 80 нче еллар ахырында, Советлар Союзы таркалгач кына, аларга кире ватаннарына әйләнеп кайтырга күпмедер юл ачылган һәм бүген Кырым Республикасы халкының 13 %ын, ягъни 268 меңен кырым татарлары тәшкил итә. Аларның милли балалар бакчалары да, урта мәктәпләре дә юк. Зур авырлыклар белән ачылган 15 кырымтатар башлангыч мәктәбе милләт таләбен 16%ка гына канәгатьләндерә. Калган балалар рус һәм украин телле уку йортларында белем алырга мәҗбүр. Кырымтатар теле ЮНЕСКО тарафыннан куркыныч янаган Дөнья телләре атласына кертелгән.

Кырымтатар язучылар берлеге сәркатибе, «Йылдыз» журналының баш мөхәррире Дилявер Осман яшь каләм ияләренең әдәбият мәйданына килүенә тоткарлык ясый торган төп сәбәп итеп яшьләрнең нәкъ менә туган телләрен камил белмәвен атады.

Минемчә, кырымтатар теленә яный торган юкка чыгу куркынычы аңлашыла да. Ассимиляция күбрәк руслашу юнәлешендә бара. Украиннар үзләре дә күбрәк русча аралаша. Бу күренеш Симферопольдә бигрәк тә көчле. Шәхсән мин үзем украин телендә сөйләшкән кешене ишетмәдем дә, күрмәдем дә бугай. Телевидение сөйли, газета-журналлар чыга, ләкин халыкның күңелендә башка нәрсә, мин сөйлимен япун белән кытайны, син сөйлисең Хөббениса түтәйне дигән кебек, уенда башка тел, авызында туган телне икенче урынга күчереп куя торган башка сүз. Дөрес, кырым татарлары мөмкин булганны да, мөмкин булмаганны да эшләргә тырыша. Шуңа Урал-Алтай корылтаеның чираттагысы бирелә үткәрелә дә. Кырым татарлары, туган телләрен яклап, бар дөньяга кычкыра. Бу яктан, безнең татар, Сибгат Хәким шигырен бераз үзгәртеп әйтсәк, әле йоклый, татар уянмаган...

– Хәзерге дөньяда 100ләп телгә юкка чыгу куркынычы яный. Милли телләрнең, әдәбиятларның, мәдәниятләрнең сакланышы беренче чиратта бездән – язучылардан тора. Икътисад, сәясәт тә зур көч, ләкин тел, мәдәният алардан да югарырак көч, – диде корылтайны йомгаклап Халыкара ПЕН-клубның Президенты Джон Сол. Ул кырым татарларының егерме ел дәвамында туган телләрен саклау һәм үстерү юнәлешендә башкарган эшләрен югары бәяләде. Есенгали Раушанов Казахстанда чыга торган әдәби журналның бер санын тулысынча кырымтатар әдәбиятына багышларга вәгъдә бирде.

Корылтай барышында уйгыр һәм кырымтатар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау буенча ике резолюция кабул ителде. Шулай ук Кырым татарларының ПЕН-үзәген булдыру турында да тәкъдим яңгырады.

– Ике көн дәвамында барган сөйләшүләрдән, киңәшләшүләрдән, проблеманы ныклап, төптән өйрәнүләрдән соң, бу – мөмкин эш, – диде Джон Сол.

Ике резолюция дә Халыкара ПЕН-клубның тәрҗемә һәм лингвистик хокуклар

Комитеты 2011 елда кабул иткән «Лингвистик хокукларның Жирон манифесты»на таянып эшләнде. Анда «Телләрнең күптөрлелеге – ул бәяләү һәм саклау зарури булган бөтен дөнья байлыгы», дип акка кара белән язылган, ягъни һәр тел, анда ничә кеше сөйләшүенә карамастан, шул телдә сөйләшүче халык, аның мәдәнияте ихтирамга һәм яшәүгә лаек.

## Дүртенче көн

Бу көнне без Бакчасарайга сәяхәт кылдык, Кырым ханнарының сараен карадык, Пушкинны илһамландырган фонтан янында булдык. 1945 елда Сталин, Рузвельт, Черчилль катнашында Ялта конференциясе үткәрелгән тарихи урынга – Ливадиягә юл алдык, Кара диңгездә су коендык. Эш беткәч, уйнарга ярый, дигәндәй, Кырымдагы кайбер истәлекле урыннар белән таныштык, автобус тәрәзәсеннән булса да атаклы Аю-даг тавын, данлыклы «Артек» лагере биләмәләрен күрдек.



*Австралиядән килгән милләттәшләребез Сафия Вәлиева һәм Сөенгөл Чанышева (сулдан уңга)*

Бакчасарайдагы миллилек күңелне аеруча дулкынландырды. Монда вакыт та, тарих үзе дә мәрхәмәтлерәк кыланган кебек. Урта гасырлар рухы тулысынча диярлек сакланган. Кырым ханнарының мәһабәт сараена карап, Казан ханлыгы дәверен күз алдына китердем, кызыгып та куйдым. Ник дигәндә, аларның тарихи үткәне күзгә бәрелеп тора. Казып, эзләп, актарып азапланасы юк, рәхәтләнеп тотып, капшап карарга була. «Менә күрдегезме?!» – ди алар күкрәк кагып, ә бездә Казан ханлыгы чорыннан, бина нигезләреннән кала, бернәрсә дә юк. Кайбер тарихчы галимнәр фикеренчә, хәтта Сөембикә манарасының беренче өч каты гына XVI гасырга карарга мөмкин (бусы да мөмкин генә!). Кырым татарларына, бәлкем, ханнардан калган гайрәт, нинди генә очракта да баш бирмәс көрәшче рухы көч бирәдер. Һәрхәлдә, заманында Кырым һәм Казан ханлыклары алар кулында булган.

Кырым татарларының эзсез юкка чыгасылары килми, Исхакыйча әйтсәк, алар тартыша, ата-бабаларының каны тамган бер уч туфрак өчен дә тарткалаша, чөнки тарихи тамырлары нык, бу ожмахка тиң җирләргә алар хуҗа. Үлемгә хөкем ителгәннән соң да, беренче мөмкинлек булу белән, кырым татарлары ватаннарына күчеп кайтканнар һәм, туган җирләренә таянып, кабат аякка басканнар бит.

Минемчә, дөнья күләмендә зур тизләнеш белән барган глобальләшү шартларында безгә аерым-аерым яшәү мөмкин түгел. Төрки халыклар, элек мәҗбүриләп югалтылган бәйләнешләрен янадан торгызырга, уртак фикергә килергә һәм берләшергә тиешләр. Үз дәүләте булганнар да, булмаганнар да. Татарны да, казахны, кыргызны, уйгырны да, төрекне, үзбәкне дә (барысын да санап тормыйм) уртак тамырлар, тел, дин, тарих, әдәбият, мәдәният бергәлеге бәйли. Шуңа безгә аралашуы да, аңлашуы да җиңелрәк. Бер-беребездән ераклашу әлегә ул кадәр куркыныч дәрәҗәдә түгел.

Кайтыр юлга җыенган бишенче көнне без, Татар ПЕН-үзәге вәкилләре һәм Уйгыр ПЕН-үзәге Президенты Кайсар Өзхун Симферополь инженер-педагогика университетына чакырулы идек. Биредә ел дәвамында үзен яхшы яктан күрсәткән кырымтатар студентларына, язучыларына, мөгаллимнәренә, мәдрәсә укучыларына премияләр тапшырылды. Кунакханәгә кайтышлый без корылтай көннәрендә тамчы да буш вакыты булмаган, бар утырышларны да үзе алып барган Кайсар Өзхун белән рәхәтләнеп аралаштык. Без – татарча, ул уйгырча. Бер-беребезне аңлауда кыенлыклар тумады кебек. Күтәрелгән мәсьәләләр күп, ләкин аларның барысы да бер үзәк проблема – безнең милләтләрнең яшәеше, киләчәге турында иде.

Хушлашканда Кайсар киләсе корылтайларның берсен Казанда уздырырга тәкъдим итте. Хәер, конференция барышында бу хакта күп сүзләр яңгырады.

**Ленар ШӘЕХ**

# АГЫМСУДА ЭЛЕКТР ТАШКЫНЫ

Әле кайчан гына, күп дигәндә бер-ике гасыр булыр, бәндәләр электрның ни икәнен дә белмәгәннәр. Патша, корольләр дә шәм яктысы белән канәгатьләнергә мәҗбүр булганнар. Авылларда, шәм булмаган җирдә, аны чыра алыштырган. Тора-бара мәгыйшәткә керосин лампасы килеп керде. Җитешле кеше өендә ул — якты, фәкыйрьнекендә сүрәнрәк яна иде.

Хәзер исә хәятне электр энергиясеннән башка күз алдына да китереп булмый. Аны файдалану даирәсе көннән-көн арта бара. Хәтта гади көнкүрештә генә дә кулланылыш тармакларының исәбе-хисабына чыгарлык түгел. Улазга гына сүнеп торса да, зур кыенлыклар килеп чыга. Ихтыяҗ арта, бәясе күтәрелә бирә.


*Су тегермәне*

Бөек Ватан сугышына кадәр Татарстанда башлыча җылылык электр станцияләре корыла. Аннан соңгы елларда зур гидроэлектростанцияләр алгы планга чыга. 1955 елда Куйбышев электр станциясе сафка баса. 1979 елда Түбән Кама ГЭСының 1нче, 2нче агрегатлары файдалануга тапшырыла. Барлыгы 16 гидроагрегат елына 1,3—2 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе бирә. Турбиналар аркылы ургылып чыккан су ташкыны әллә кайларга кадәр бөтерелеп, кайнап бара.

Матбугатта игълан ителгән мәгълүматларга караганда, Куйбышев ГЭСы су өслегенең мәйданы 6,15 мең квадрат километр тәшкил итә, — Европада иң зур сусаклагыч бу. Түбән Кама буасының мәйданы 1084 квадрат километр. Икесенең тулай су өслеге 7099 квадрат километр килеп чыга. Ошбу территориягә Андора, Лихтенштейн, Люксембург, Мальта, Сан-Марино, Бахрейн, Мальдивия Республикасы, Сингапур, Гонконг, Бермуд утраулары, Виргини утраулары (Британия), Биргини утраулары (АКШ) — унике дәүләт иркен кереп утыра ала. Әле аннан соң да 473 квадрат километр мәйдан артып кала. Бәгъзе бер урыннарда диңгезнең киңлеге утыз чакрымга сузыла, бер ярдан икенчесе күренми, су офык белән тоташа. Шул төбәктәге уңдырышлы басу-болыннар, урман-куаклыклар, зиратлар су астында калды, йортлар, каралтылар күчерелде. «Авыллары су астында калгач...» шигырендә Равил Фәйзуллин болай дип язды:

*Акчарлак!*
*Бәргәләнмә ул дулкында!*
*Әти чардуганы өстендә!..*

Куйбышев плотинасы янындагы суның тирәнлеге 41 метр, Түбән Кама су саклагычында 1978—1981 елларда су 62 метрга кадәр күтәрелде. Тигез җирдә елганы күтәрү, җирне кадерсезләү, исраф итү дөнья халыкларында хупланмый, итәк кисеп җиң ямау кебегрәк карала. Франсуа Рабле (1494—1553), мәсәлән, «Гаргантюа һәм Пантагрюэль» романында бер инсанның, урман кисеп, юан агачларны яндыруын, шуның көлен сату хисабына көн күрүеннән көлә. Урманкырларны юк итү хисабына электр энергиясе җитештерү дә шундыйрак хәлне

хәтерләтә. Кайбер мәмләкәтләрдә җирне океан, диңгезләрдән тартып алу чарасын күрәләр.

Хикмәт җирдә генә дә түгел. Әле әйтеп киткән зур масштаблы югалтулар, драматизм кешеләр күңеленә тирән яра сала.

Шул ук вакытта чамадан тыш куәтле станцияләргә генә йөз тоту, Гигантомания, зурдан кубу практикасы асылда ГЭСлар төзүне бөтенләй туктатуга китерде дип әйтергә була.

Бүтән җирдә ничектер, безнең Пучы якларында агым көче башлыча тегермән төзүдә кулланылды. Тегермәннәр арасында инешкә корылганнары да бар. Андыйларны күргәч, кечкенә болак авыр ташны ничек әйләндерә ала икән? — дигән сорау да туа иде. Ләкин, болай уйлаганда, аның эчке мөмкинлекләре искә алынмаган, күрәсең. Анда елга ярларыннан чыкмаслык кына итеп күтәрелгән су горизонталь турбинага, ятып торган канатларына төшә. Ул калаклардан читкә акмасын, куәте кимемәсен, куласага гына хезмәт итсен өчен чарыкның баш-башын томалап, ябып куялар. Турбина милкенә килеп кергәч, су басымы бик актив, йогынтылы көчкә әйләнә, чарыкка җан кертә. Тагын шунсын да истән чыгармыйк: вал яхшы майланган, кытыршылык, каршылыклар бетерелгән подшипникка урнаштырыла, ул турбинага кагылу белән, әйләнергә тора. Шуларның бөтенесе механизмны кеше ихтыярына буйсындыра, күндәм, карусыз итә.

Пучы халкы гадәттә Билтески һәм Матвеевка (Кәҗә авылы) тегермәннәренә йөри иде. Аларның һәр икесе Ык елгасына корылган. Ык — инеш түгел инде, мул сулы дәрья. Биредә агымның кирәк кадәресе генә турбинага юнәлдерелә дә, артканы, үзе бер елга кадәресе, бүтән үзәнгә борып җибәрелә.

Безнең авыл янында зур су юк. Бар булганы — Сарашлы инеше. Шуңа күрә бүтән авыллар янындагы елга, күлләргә кызыгып карый идек. Хәзер генә ул Пучы белән Әнәкнең текә ярлы урыннарында мелиорация министры Минтимер Шәймиев инициативасы белән тирән сулы, балыклы капиталь плотиналар төзелде.

Ыкның куәте, ике җәпкә аерылып китүе, чарыкны бик җиңел әйләндерүе, файдалы эшкә яравы безнең ише малайлар күңелендә соклану, горурлану тойгылары, якты хисләр уята иде. Үсә төшкәч, шушы пейзаж, хыялый детальләр белән бизәлеп, төшләргә керә торган булып китте.

Тегермән алды мәйданында атлар, арбалар тезелеп китә, агай-эне, үзара гәпләшеп, сабыр гына чират көтә.

Таш арасыннан ларга коелган җылы онны кыска саплы агач көрәк белән капчыкка тутыру аеруча күңелле, рәхәт шөгыль була торган иде.

Элегрәк елга буендагы һәр авыл янында диярлек тегермән корылган. Аны төзүне борынгы бабаларыбыз йорт җиткерү кебек гадәти, фарыз эшкә санаганнар булса кирәк. Ул тирә-юньгә үзенә бер төрле ямь, хозурлык биреп торды. Аның тирәсендә яшьләр еш кына кичке уеннар оештырдылар, җырлап-биеп күңел ачтылар.

Тегермән буасының суы, язгы ташуны исәпләмәгәндә, беркайда да җир өстенә чыкмады, җәелмәде. Шул ук вакытта плотиналар, халык ышануынча, суның качуына, елганың саегуына юл куймады.

Тора-бара эстафета гүяки электр станцияләренә тапшырылды. Ошбу процесс Балтач районының Таузар иле авылында шактый үзенчәлекле оештырыла. Биредә тегермән гүяки киң күңеллелек, юмартлык күрсәтә, Хәтнә елгасының бер өлешен электр станциясе белән бүлешә ул: суның бер тармагы электр энергиясе җитештерүгә китә, икенче җәбе тегермәннең үзенә юнәлә. Аларның икесен дә берьюлы эшләтергә дә була, һәркайсын аерым-аерым эшләтү мөмкинлеге дә калдырыла.


Хәтнә — зур елга түгел. Шулай да моңа корылган станция 25 киловаттлы энергия биреп тора, Таузар иле өйләрен, урамнарын, ферманы яктырта, радиоузел шуның көче белән эшли.

Ошбу объектларның урнаштырылышында да үзгәлек бар. Алар агымсу өстендә түгел, елгадан читтә, коры җирдә корыла. Һәммәсе әзер булгач кына су арык буйлап турбиналарга җибәрелә.

Бу станция узган гасыр уртасында биш еллап хезмәт күрсәтә. Картлар электр өчен колхозчылардан акча түләтелмәде кебек дип сөйлиләр.

Хәтнә станциясе Балтач районында тәүге электр корылмасы иде. Аннан соң Шушма елгасында Янгулда, Салавычта, Лызи авылларында иллешәр киловаттлы станцияләр корыла. Биш елдан соң алардан файдаланмый башлыйлар, ә Хәтнә елгасы, мөһим йомышы бар кебек, ашыга-ашыга чаба бирә.

Татарстан — тарлавыклар җире түгел. Ләкин тирән ярлы елгалар бер дә юк дип әйтеп булмый. Казансу, мәсәлән, баштан алып ахыргача ике ягы да текә ярлар эчендә ага. Аны яр биеклегендә күтәргәндә дә суы читкә чыкмый. Бу чакта инде елгада бик зур көч тупланган була. Тик шулай да андый ук елгалар җөмһүриятебездә күп түгел. Әмма берсе дә өстәл өсте кебек тигез җир буйлап акмый. Һәркайсының күпмедер биеклектәге яры бар. Мондыйларга станция корганда суны аз гына, яр биеклегендә генә күтәртү дә җитә. Турбина өчен суның зур биеклектән төшүе генә лазем түгел. Анда басым, авырлык үзе мәсьәләне уңай хәл итә. Кечерәк ГЭСлар төзүне нәкъ менә шундыйлардан башлау хәерле булыр кебек күренә.



*Шушма суының кушылдыгы Хәтнә елгасы*

Турбиналарны эшләтү турында сүз барганда гадәттә югарыдан төшкән су басымына гына игътибар ителә. Елганы күтәрмичә, бары агым көчен генә файдалану мөмкинлеге бөтенләй искә алынмый. Шундый берьяклы караш аркасында бу көнгә кадәр агым басымына гына көйләнгән бер ГЭС та корылмады. Хәтта тау елгаларының агымы да бу эшкә көйләнмәде. Докторлык диссертациясен яклау мәшәкатьләре белән йөргәндә миңа күп тапкыр Алма-Атыга барырга туры килде. Анда Иҗат йорты янында гына тирән ярлы, текә үзәнле, зур куәткә ия шарлавык ага. Уйгырлар шул суның бер өлешен, сөзәгрәк арыкка юнәлдереп, җир өстенә чыгаралар һәм басуны сугару өчен файдаланалар. Бу — бик зирәк, акыллы фикерләү нәтиҗәсе.

Әлеге елга бер үк вакытта арзанлы электр ташкынын бирү вазифасын да күндәм башкара алган булыр иде. Чөнки аны күтәртеп тору да кирәкми. Житез, куәтле агым болай да текә тарлавыктан төшә. Ләкин аңа мондый эш йөкләнмәгән.

Турбинаны агым көченә җайлаштырганда киң канатлы чарыкны бастырып, вертикаль куялар. Техникада бу яңалык түгел. Түбән Кама ГЭСында турбиналар нәкъ шул рәвешле урнашкан. Аерма тик шунда гына: Түбән Кама станциясендә су өстән коя, күтәрелмәгән елгада исә турбинаны агым көче генә хәрәкәткә китерә. Һәр ике очракта да чарыкның ярты ягы ябып, каплап куела. Агым аның эчендәге канатларга кагылмый уза, су икенче якка, ачык канатларга килеп бәрелә. Канатлар, кузгалып, агымга юл бирә. Монысы артыннан ук агым арттагы канатлар белән очраша. Су турбинаны әйләндерүдән гайре бер тарафка да китеп котыла алмый. Аңа бер-бер артлы канатларны әйләндереп кенә агымын дәвам иттерергә була.

Шулай да агым көче белән эшли торган турбина әйләнеше югарыдан төшкән басым белән хәрәкәткә килүче чарык әйләнешеннән кайтышрак. Әмма аның үз мөмкинлекләре, үз өстенлекләре бар. Иң зур өстенлеге — су бастырып, басуларны, урман-болыннарны исраф итмәү.

Турбиналар урнаштыру хисабына елга бермә-бер тарая. Су, «Нигә минем ирекне чиклисез?» — дигәндәй, ярсып, куәтлерәк ага башлый. Бакчада су сиптергәндә шлангның башын бераз кысып карагыз, су еракка китмәсме? Киң дәрьяда шлюз хисабына да агым бераз кысыла төшә. Бу чаралар вал әйләнешен күпмедер тизләтүгә китерә.

Монда тагын шестернялар ярдәмгә килә. Әгәр тотрыклы әйләнеш бар икән,

төрле зурлыктагы тештәкләр әйләнеш тизлеген күп тапкыр арттыра алалар. Моның ни икәне инженерларга гына түгел, һәр шоферга, велосипедчыга яхшы таныш. Шулай итеп, тизлекне арттыру мәсьәләсе бик җиңел хәл ителә.

Киңрәк дәрьяда янәшә берничә турбина куела. Дәү чарыкларны урнаштыруда ара-тирә Таузар иле төзүчеләренең тәҗрибәсе дә ярап куярга, ягъни станция төзелеше дәрьядан читтә башкарылырга мөмкин.

Димәк, су электр станциясен коруның, турбиналарны урнаштыруның ике ысулында да принципиаль яңалык юк. Аларның һәркайсы инде күп тапкыр сыналган, эшкә яраклы икәнлеге күптән исбатланган.

Үзгәлек — башкада. Елганы күтәрткәндә буа йөзәр чакрымга сузыла. Бу арада инде башка станция куеп булмый. Ә суны күтәртмичә, агым көче белән эшли торган станцияне исә адым саен тезеп чыгарга була.

Карап торышка җил куәтенә көйләнгән генераторның да гайрәте әллә ни түгел. Аның эшчәнлеге әле һава торышы, үзгәреше белән дә бәйләнгән. Ләкин, шуңа да карамастан, һаман яңалары төзелә тора. Күрәсең, үзләрен аклыйлардыр. Күпләрнең эш нәтиҗәсен бергә кушкач, хәйран куәтле энергия барлыкка килә булса кирәк. Тамчы тама-тама күл була.

Моңарчы эшләп килгән энергия чыганакларының һәммәсе дә икенче бер нәрсәне киметү, юкка чыгаруга нигезләнгән: йә алар газ, мазут, ташкүмер ягу бәрабәренә эшли, йә җир мәйданы су астында кала.

Интернет мәгълүматларына караганда, Зәй ГРЭСының бер блогы сәгатенә кырык тонна мазут яндыра, унике блокка тәүлегенә 11520 тонна, егерме миллион җиде йөз утыз алты мең сумлык ягулык кирәк була. Айлык, еллык күләмне исәпләсәң, бик зур саннар килеп чыга.

ТЭЦ, ГРЭСлардан ургылып чыккан төтен һавага тарала.

Ягулык материалларының берсе дә файдаланган саен артып, үсеп тормый. Кими генә баралар. Һәркайсының чиге бар. Җир дә чиксез түгел. Ул әле су астында калудан башка юллар, шәһәрләр төзү өчен дә даими кимеп тора.

Тик акыл белән, хәстәрлек белән эш иткәндә гидростанцияләр генә нәрсәне дә булса киметүне, юкка чыгаруны таләп итми. Аларның энергиясе бушка килгәнгә охшап тора. Су үзе дә кимеми. Дәрьялар миллионлаган еллар буена тын гына агып торганнар, саклап тотсаң, әрәм-шәрәм итмәсәң, Арал диңгезе язмышына дучар кылмасаң, яр буйларына агачлар утыртсаң, тирә-юнендәге урманнарны кисмәсәң, алар әле алга таба да иншалла ил-көнгә күп еллар күндәм хезмәт итәрләр дип өметләнергә була.

Принципта җил дә кимеми. Тик шулай да аңа мөнәсәбәттә дә артын-алдын уйлап эш итү хәерле. Сугыштан соңгы елларда Алма-Атының читендә, тирән тарлавыкта куәтле плотина корылды. Аның вазифасы силне токтарлау, хәлсезләндерүдән гыйбарәт. Укучыларга ул күбрәк Медео катогы буларак таныштыр. Төзеп бетергәч, аның башка бер нәтиҗәсе дә билгеле булды. Алма-Аты таулар арасындагы иңкүлеккә, чокырга утырган. Шуңадыр.

*Алма-Атаның таулары,*
*Өзелә камыт баулары, —*

дип тә җырлыйлар. Монда һаваның алмашынып, җилләп торуы бик мөһим. Ә менә теге плотина гигант тарлавыктан исә торган җилне күпмедер дәрәҗәдә бикләп, буып куйган, калага үтә торган һаваның күләмен беркадәр киметкән. Кайберәүләр башкаланың Астанага күчерелү сәбәбен дә әнә шунда күрә. Билгеле, рельеф үзгәлегенең ролен дә истән чыгарып булмый.

Әйе, урыны белән җил дә дефицитка әйләнеп куя икән.

Татарстанда унар, йөзәр, бишәр йөз чакрымнарга сузылган ярты меңгә якын дәрья бар: Идел, Чулман, Агыйдел, Нократ, Ык, Зөя, Олы Чирмешән, Иж, Шушма, Илләт, Дала Зәе, Казансу, Мишә, Актай, Гөбенә, Тәмте, Сарман, Кече Мишә, Кече Чирмешән, Чишмә (Шушма), Минзәлә, Сөн, Кичү һ.б. Күбесенең исеме җырларга беркетелгән, халыкның рухи хәятендә кадерле урын алган. Алар хозурлану объекты, күңелгә рәхәтлек бирүче, иркәләүче, юатучы күренеш буларак вөҗүдкә кереп калган. Шулай да елгаларны, дәрьяларны милли байлык

дип санау нишләптер гадәткә кермәгән. Боларның һәркайсының куенында электр ташкыны, алтын ага. Әмма аны күрер өчен күңел күзе кирәк шул. Менә шушы йөзәрләгән агымсуларның тик берсе — Чулман гына электр энергиясе бирүгә хезмәт итә. Калганнары моның ни икәнен дә белми. Милли байлыкның бу тармагы, аның иң зур өлеше әле үзләштерелмәгән.

Гәрчә агым көче белән эшли торган станциянең җегәре искитәрлек булмаса да, бу бит әле, ни дисәң дә, өстәмә энергия. Аны булдыру өчен зур күләмдә мазут, газ, ташкүмер, торф яндыру да кирәк түгел, һава да бозылмый, атмосферага экологик зыян килми.

Электр станциясе кору су тегермәне төзүдән катлаулырак түгел. Тегермән кебек, аны һәр елга буенда бастырып куярга була. Белгеч күзәтчелегендә аны эшлекле, булдыклы аерым фермер да корып, арзанлы энергиясеннән файдалана ала. Мин кайчак болай дип тә уйлап куям: гидроэлектростанцияләрне күпләп сафка бастырган тәкъдирдә алар хәтта ягулык станцияләрен дә, ТЭЦ, ГРЭСларны да алыштыра алмас иде микән? Алыштырса, бик күп ягулык материалы янга калыр, җан ияләре дә иркен сулап куяр иде.

Түбән Кама ГЭСы никадәр генә куәтле булмасын, энергиясе промышленностьның, хуҗалыкның бар тармакларына да җитеп бетми. Өсти тору сорала. Бу җәһәттән кайбер эшем ияләре аның сусаклагычын тагын шактый күтәрергә, ягъни яңа җирләрне су астында калдырырга, бәндәләрне кабат ярсытырга киңәш итәләр иде. Әле шунысы да бар: чамадан тыш куәт тә хәвефсез түгел. Моның шулай икәнен Сайан-Шушенск ГЭСындагы коточкыч афәт тә раслады. Заманында моннан тыш тагын Чулман (Кама) һәм Агыйдел бассейннарында бер-берсеннән шактый якын арада үтә хәвефле, хәтәр атом электр станцияләрен кору планы да баш калкыта башлаган иде. Менә шулай: аяк астындагы ышанычлы, файдалы, хәвефсез чыганакларны шәйләмибез, инсанны борчый торган гамәлләргә барып тотынабыз. Югыйсә якында гына мул сулы Нократ ага, Зәй, Ык елгалары да промышленность үзәкләреннән ерак түгел.

* * *

Бәгъзе пошмас җаннар мәсьәләгә башкача да карарга мөмкин. Ягъни:

— Нигә безгә өстебезгә артык мәшәкать йөкләргә? Әле бит югарыдан да күрсәтмә төшмәде, — дип фикер йөртүләре ихтимал. — Моңарчы яшәдек бит әле агымсуларга тимичә дә...

Яшәвен яшәдек. Ләкин нәкъ менә шундый психология аркасында ифрат зур байлыгыбыз бу көнгәчә файдаланылмый ята. Кече һәм урта энергия чыганаклары төзелмәде, төзелгәннәре дә сүтелде. Түбән Кама ГЭСы фонында аларның дәрәҗәсе бик нык түбәнәйде. Әйтерсең, бездә бер галим, инженер юк. Әгәр елгасыз төбәктән килеп чыккан берәр эшмәкәр шушы хәлне күрсә, моңа бик нык гаҗәпләнер иде.

Хәзер төрле илләрдә электр энергиясе бирердәй башка чыганакларны (әйтик, Кояшнымы яки бүтәннеме) файдалану юлларын эзлиләр. Нишлисең бит, әгәр аларда бездәгедәй дәрьялар агып торса, Кояшка ук үрелмәсләр иде.

Нефть, газ сатып кына, запасларын киметә барып кына ерак китә алмыйбыз. Елгаларны эшкә җигү исә ышанычлы, тотрыклы, перспективалы гамәл. Күп санлы агымсуларның куәте тулысынча үзләштерелгән тәкъдирдә һәркайсының җегәрен бердәм энергетика системасына тоташтырырга мөмкин. Ул тулысынча җөмһүрият милке булачак. Яңа ГЭСлар челтәре Республикабызның экономик куәтен ныгытачак. Энергиянең артыгын күрше мәмләкәтләр белән бүлешергә, сатарга була. Хәзер бит бездә социализм түгел. Баеп китүдән курыкмаска була торгандыр.

Энергия муллыгы җөмһүриятебез эчендәге электрга түләү бәясен дә киметәчәк дип фараз кылам. Боларга өстәп киң мәйдандагы зур төзелеш күпсанлы яңа эш урыннары булдырачак. Шулай да дәү масштаблы ошбу гамәлне кузгатып җибәрү өчен зирәклек, тәвәккәллек, ихтыяр көче сорала.

**Фәрит ХАТИПОВ**

# ТОРМЫШЫМ СӘХИФӘЛӘРЕ

## Язмыш күпере

Хатирәи сүзне бер сәяхәтемнән башлап җибәрмәкче идем дә, әтием сөйләгәннәр искә төште. Аның сәяхәтләре янында минеке бөтенләй тоныкланып кала икән ләбаса.


*1914 елгы фото*

Әтием Юныс 1877 елны туган. Күп кенә кордашларымның бабалары да аннан яшьрәк... «Бабалар» дигәч, бабамны да читләтеп үтәсем килмәде инде. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре аның турында, ягъни «мелла Габделвәли бине-әл-Вәлид бине Максуд бине... әл-Кәчеви хаҗи» хакында матур сүзләр язып калдырган. (Мостафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К.,1989, 246 б.) Минем күңелгә менә болары аеруча сөендерде: «Туры сүзле... Алдан күрүчәнлеге белән, китаплар тикшерү, хакыйкатьне эзләүдә көчле фикерле булуы һәм эшчәнлеге белән аерылып тора иде...» Әмма сөенү артыннан көенү дигәне дә килде. Кем соң мин, аның оныгы, Мәрҗани булып Мәрҗанине дә сокландырган шәхес янында? Шушы авыр хис шигырь юллары булып та әверелде:

*...Якын да ара, ерак та.*
*Әтиемә син – ата.*
*Төпчегеңнең төпчегемен –*
*Арада гасыр ята.*
*Упкын ята! – Баласы мин*
*Таһарәтсез дөньяның...*

Бабам канаты астында озак яши алмый әти, ятим кала. (Мин дә 11 яшьтә – әнисез, 15 яшьтә әтисез калдым.) Әстерхандагы бер байга кибеткә малай (өйрәнчек) итеп бирәләр аны.

Беренче олы сәяхәте диңгез-океаннар аша була. Солдатка алынгач, Кытай ягына Африканы көньяктан уратып алып баралар аларны (ул вакытта Сүәеш каналы булмый әле). Мәчет хәтле кит балыкларын күрүен, гарәпләрнең ыргыткан акча артыннан төпкә хәтле чумуларын сөйләгән иде әти.

Тарихка теркәлмәгән Кытай сугышы хатирәләре дә бар иде әле аның. Астан ягылганга, кытайларның сәкеләре җылы булганлыгын ничектер рәхәт итеп сөйләгән иде ул. Ә менә мылтыктан атуларын көлеп тасвирлады. Оп-озын мылтыкның көпшәсен бер яугир икенчесенең җилкәсенә сала. Аткач, аннан табык кукәе хәтле ядрә очып чыга. Тисә - аяктан ега, тимәгән хәлдә исә шартлау-фәлән булмый. Ә менә японнарның хәрби осталыгы турында сокланып сөйләде (күп тә үтми, 1905 елгы рус-япон сугышы башланып китә). Рус гаскәре туплардан юньләп файдалана да алмый: атлар белән тарттырып кирәкле җиргә китереп житкергәнче японнар үз тупларыннан атып атларын да, тупчыларын да кырып бетерә торган була. Япон тупларын исә руслар күрми дә: алар тау артыннан ата, ату төгәллеген тау башындагы төбәүчеләр тәэмин итә...

Әтиләрне Россиягә поезд белән алып кайталар: ул вакытны поезд юлы салынган була инде...

1914 елгы герман сугышында әтине ротаның писарь-каптенармусы итәләр. Җибәрергә дип тупланган хат өемен карап чыгалар да, конверт тышына ин матур итеп язган солдатны куялар бу эшкә. Русча язарга исә әтием кибет малае чакта өйрәнә. Әстерхан урамнарында йөргәндә күргән язуларны... бармагы белән кесә төбенә күчереп яза торган була ул... Бу хатирәне дә әтием өйрәткәнчә эрерәк хәрефләр белән һәм җинел таныла торган итеп язарга тырышам менә.

Бер тапкыр ничектер рота командиры урынына кала ул. Һәм, роталары оборонада ятканда, боларны бөтен яклап уратып алып, «Рус, сдавайся!» дип кычкыралар. Һәм әтием: «Бросить оружие!» дип команда бирә. Менә шушы хәлне озак гафу итә алмадым мин. Өметсез хәлдә плен төшүнен дөньяда гап-гади нәрсә саналуын күп сонрак белдем.

Әтине Германиядә бер игенчегә бирәләр. Хуҗалары ярата аны. Ләкин ул качарга ниятли. Тагын бер әсирне дә күндерә әле. Хуҗаның кызы әтигә компас һәм карта табып бирә. Һәм алар бер төнне тәвәккәлләп чыгып китәләр. Төнлә - баралар, көндезләрен иген басуында качып яталар. Һәм төннәрдән бер төнне зур елга аша салынган күпергә килеп терәләләр (Рейн күпере булса кирәк). Күпер буеннан буена прожекторлар белән яктыртылып тора (ул чакта бомбага тотудан куркасы юк әле). Теге якта — Австрия, ул сугыштан чыккан була инде. Күпернең ике башында, пыяла будкалар эчендә, ике сакчы. Күрсә, тегесе дә, бусы да ата.

Әтиемнең юлдашы бераз уйланып тора да, кире кайтып китә. Әтием исә, бисмилласын укый да, шуышып күпергә кереп китә һәм... туган ягына, Арча районының Кәче авылынача кайтып житә.

Язмыш күпере була бу. Әтинеке генә түгел, минеке дә. Әти чыгып житә алмаса, ошбу хатирәләр язылмас иде... Әти юлдашы белән кире кайтып китсә дә, дөньяга килер идем микән әле мин? Ә менә берәр Генрих-фәлән туарга мөмкин иде: теге алман кызы әтине яраткан бит ул.

Абыем Равил әтинен бөтен үткән юлларын кызыл карандаш белән дөнья картасына төшергән иде. Исәпләде дә әле. Юныс Габделвәли улы 40 мең чакрымнан артык, ягъни Жир шарын урарлык юл узган булып чыкты.

## Онытылмый торна тавышлары...

Инде менә үземнең 1489 чакрымлы сәяхәтемнең бер көне турында язып карыйм әле. 1982 елны булды бу. «Татарстан яшьләре»ндә эшләгән чак. Корырак чыккан газетабызга бераз ямь өстәргә теләп, СССРның 60 еллыгын сылтау итеп, «Татарстан яшьләре»нең жәяүле экспедициясе» дип оештырдым мин бу сәяхәтне. Жинел генә булмады чыгып китү. «Урак өстендә күңел ачып йөрергә ниятли», - дип, моны өзәргә омтылучылар да табылган. Каләмдәшем, инде мәрхүм Сәмигулла Хәйретдинов белән баш мөхәррир Харис Әшрәфжановка рәхмәт инде.

Урман эчендәге 12 генә өйле «Волговерховье» авылы янында «бәби Идел»не имезеп торган сап-салкын саз суы белән битемне югач, кызык өчен әле бер ягына, әле икенче ягына атлап чыгып, Идел буйлап китеп бардым инде. Көнгә 50-60 чакрымлап бара торгач, бер атнадан Калинин шәһәренә килеп життем (революциягә кадәрге һәм хәзерге исеме — Тверь). Икенче көнне, жомга көн бу, кунакханәдә юл репортажы язып утырдым, ял иттем. Юлда жыйган себерке белән мунча да кереп кайттым әле.

Кич буе, аннары төне буе яңгыр койды. Соңгы көннәрдә яңгыр шактый бимазалаган иде, ярый әле баш өстемдә түбә бар дип сөенеп яттым. Яңгыр суының мина юл мажарасы әзерләве башыма да кереп карамады. Иртән, мин юлга чыккач, бераз сибәләп торды да, басылды тагын. Бүген асфальт юлдан Конаково дигән калага барам. Аяк асты әйбәт, ял да иттем бит инде, дәртле генә атлыйм шулай. Шактый гына баргач, артка борылып карасам (нигә борылганмындыр инде. Бу борылуның «әҗере» зур булды!), жил-жил атлап бер ир-ат килә. Үтелгән 380 чакрымлап юлда очраткан нибары өченче жәяүле иде бу. (Жәяү йөрүне оныткан халык!) Тизлекне киметтем. Бераздан мыш-

мыш килеп куып житте теге. Юлы 5-6 чакрымлык кына икән. Кая баруымны белгәч, «Кимрыга (мин Конаководан соң барасы шәһәр) туры юл бар ич!» — диде ул, һәм шуннан барырга үгетли башлады. Ә мине үгетлисе дә юк. Авыл юлыннан, табигать кочагында баруга ни житә! Көн шулай бозылып ятканда 2-3 сәгать кенә булса да вакытны оту да кызыктыра иде... Башта кырдан бардым, аннары юл урман эченә алып кереп китте. Куе, чын урман иде бу... Ул кошлар сайрый, ул мин жырлыйм! (Миңа шул урманда гына жырларлык!) Әмма... берәр сәгатьләп дәртле генә атлагач, бу машина юлының әкренләп юл сыйфатларын жуя башлавын искәрдем. Башта аның урта өлеше югалып, тәгәрмәч юллары гына ике киң сызык булып аермачык күренеп тора иде. Аннан бу «аермачыклык» та кими барып, эз дигән нәрсә бөтенләй юкка чыкты. Бары агач үсмәгән буш ара гына, яшел тасма булып, алга таба сузыла иде. Теге агай миңа, бәлкем, үзе балачакта йөргән юлны өйрәтеп жибәргән булгандыр ул?

Ә бераздан юлны мин... өскә, андагы бушлыкка карап кына таба ала башладым. Әйе, мантыйкка һич тә туры килми торган эш иде бу. Өстә ботаклар бер-берсенә тоташа яза бит, ачыклык аста күренеп торырга тиеш ул. Әмма мин ярты сәгатьләп инде юлны өстәге ачыклыктан чамалап барам! Менә ул өске «юл» да югалды, дөресрәге, мондый «юлларны» хәзер күп табып була башлады. Шуларның берсе буенча китеп барып, аннары кире килеп, икенчесе буенча барганнан соң анысын да жуйгач, адашканлыгымны аңладым.

Сәфәремнең беренче көнендә урманда адашып алган идем инде мин. Ул чакта кинәт еракта әтәч кычкырып жибәрде, шул тавышка барып, батыр партизанка Лиза Чайкинаның туган авылы Руногa килеп чыккан идем. Бу юлы да озак кына колак салып тордым, әмма урман кошлары тавышыннан гайре берни дә ишетмәдем. Шунда әтием Юныснын сөйләгәне искә төште. Армиядә чакта Маньчжурия урманында адашкан булган ул. Агач башына менеп карагач кына юлны тапкан. Мин дә биек бер каен башына менеп киттем. Чайкалып торган очына кадәр менсәм дә, шундый ук агач башларыннан гайре һични күрмәдем. Юлны инде компас буенча чамалап дәвам иттем... Бераздан аяк асты чупырдый башлады — су! Башта сакланып кына, аякны чылатмаска тырышып атласам, бераздан моның хажәте калмады — су, артканнан-арта барып, ботинканың өстеннән кερә иде инде. Рюкзакны бер агач төбенә куеп, аннан Калинин өлкәсе картасын алдым. Картаны жәеп тә өлгермәдем, инде күптән ияреп килгән черки болыты яман гөжләп биткә ябырылды. Мин үзем юл тоткан юнәлештә еш-еш зәңгәр сызыкларны гына искәреп өлгердем: кайдадыр алда — сазлык. Шөкер, монда аяк асты каты. Үзәнсу урын булып, яңгыр суы гына жыелган, күрәсең...

Юнәлешне көнчыгышка табарак үзгәрттем дә, атлаудан йөгерүгә күчтем. Чөнки урман эче карангылана башлаган иде инде — төнгә кадәр урманнан чыгып өлгерергә кирәк... Ә су гел арта гына бара. Инде йөгереп булмый башлады...

Минем эчтәге «психолог» уяу: ара-тирә үз-үземә читтән күз салам. Әлегә канәгатьмен: һичнинди каушау, үкенү галәмәте сизелми. Киресенчә, кыенлык арта барган саен каяндыр ныклык резервлары да табыла тора...

Караңгылык та куера, су да арта. Инде менә тездән булды... Инде — бил турында — күкрәккә таба үрли. Ярый чокыр-фәлән очрамый тагын!

Кайдадыр еракта торна кычкыра башлады. Ничектер сузып, моңлы итеп кычкыра. Ошбу су дөньясында әлеге юеш, сусыл тавыш бик табигый яңгырый иде. Ул гүяки бу саф табигатьнең мине инде нығытып, жибәрмәслек итеп кочып алганлыгын искәртә иде. Күпме еллар үткәч тә һаман колагымда яңгырып тора әле бу тавыш... Шул мәлгә кайтып уйланам да, уйланган саен гажәпләнәм: ничек курыкмадым, тыныч кала алдым икән? Тагын бер ярты сәгатьтән дөм караңгы булачак иде бит. Аннары нишли ала идем соң мин? Биштәремне күтәреп, берәр агачка сөялеп су эчендә төн үткәрәсе кеше идем бит мин. Суыктан яки арудан көзән жыера башламаса тагын. Яктыргач та юлны таба аласыңмы әле.

Тәмам караңгыланып бетте дигәндә генә бер утрауга тап булдым: киңлеге бер метр, озынлыгы 7-8 метр чамасы. Өскә менеп атланган «убырлы карчыкны» — рюкзакны дөпелдәтеп жиргә куйдым да, агач ботаклары сындыра башладым. Мин монда төн үткәрәчәкмен, учак ягачакмын!

Учак кабыза алыр идемме, юкмы — моны белми калдым — аермачык булып эт өргән

тавыш ишетелде! Беренче мизгелдә үк юнәлешне чамалап алдым, икенче мизгелдә рюкзакны кидем, өченчесендә мин ашыгып су ера идем инде... Ә су кимегәннән-кими барып, бераздан бөтенләй бетте. Урман да сыегайды, 10-15 минуттан анын читенә йөгереп чыктым. Алда, 300-400 метрларда кара булып авыл өйләре шәйләнә иде, ә кырый өйдә ут яна иде. Тизлекне арттырдым: тәрәзәдәге ут сүнгәнче барып өлгерергә кирәк. Утсыз өйнең ишеген ачтыру кыен булачак! Бераздан исә шып туктап калдым: алда... су иде. Тик мине хәзер су белән куркытырмын димә — кердем дә киттем. Әмма бераздан туктарга мәҗбүр булдым — су нык тирәнәя бара. Инде нишләргә? Шунда су эчендәге бер печән чүмәләсен күреп алдым, рюкзакны шунын өстенә куйдым. Куен кесәсендәге акча янчыгын рюкзакка салдым да (документлар рюкзак эчендәге папкада), чалбар-ботинкадан, штормовкадан килеш йөзеп киттем. 15-20 метрлап йөзәсе булды. Хәзер туп-туры теге нурлы тәрәзәгә карап йөгерәм. Шакыдым. Бер апа күренде. Юлчы икәнемне әйттем, кунарга кертүен үтендем. Апа исә «Нет!» диде дә, тәрәзә пәрдәсен япты. Шунда кинәт, беренче тапкыр, төннен салкын булуын, бөтен киемнәремнен дә лачма су икәнен һәм... арыганлыгымны тойдым... Юк, ничек тә бирешмәскә, хәрәкәт итәргә, җылынырга кирәк булачак!.. Көтмәгәндә тәрәзәгә икенче бер кеше капланды — ир-ат. Кем булуымны, нишләп йөрүемне сорашты да, кемдер белән кычкырып бәхәсләшә башлады. Аннары ишеккә килергә кушты...

Күк томан артындагы бу көннең ядкаре булып «Татарстан яшьләре»ндә ошбу юллар теркәлеп калган:

«Кимрыга туры юл эзләү мажарасы мине урманга сыенып утырган Всесвятское авылына алып килде. Печәне күкрәккә житкән чәчәкле аланнар, кечкә тынлыкта янгыраган торна тавышы, су эчендә калган печән чүмәләләре... Табигать биредә 3-4 гасыр элек ничек булса, шул килеш сакланып калган, күрәсең. «Урман халкы» да житәрлек икән. «Солы басуында кабан дунгызларын күрергә була, ә авылда бүреләр кунак булгалый», —диделәр.

— Бер кичне Белка озак шыншыды, — дип сөйләде Клавдия Андреевна. — Әнисе Стрелканын өргән-ниткәнен ишетмәдем. Икенче көнне иртән чыксам — Стрелка юк. Ни булганын эзгә карап белдем. Бүреләр чакырып алган аны — печән кибәненә хәтле үзе килгән. Килеп житүгә ташланганнар. Урманга бүре эзләре генә керә — сыртка салып алып киткәннәр...

Белка инде үзе дә көчле, шаян эт булып үсеп житкән (урманнан мин ул өргән тавышка чыктым да инде)... Клавдия Андреевнанын ялга кайткан кияве Илья авыл янында ук диярлек аю белән очрашуы турында сөйләде».

Ә хәзер әле мин чәй эчеп утырам. «Вино эчеп җылыныр идең дә, эчеп бетердек шул», — диделәр табындашлар. Ана, кыз, кияү — кызып алгангамы, бик иркен сөйләшәләр — әйтергә ярамаган сүзләр дә ычкынгалый.

Өйгә керә алуым бер могҗиза булса, кунак сыман табын янында утыруым икенче могҗиза иде. Чөнки, документ-фәлән сорагач, берни дә күрсәтә алмадым мин. «Рюкзакта, ә рюкзак чүмәлә өстендә» диюемә... ышанганга салыштылар. Бу төнне йоклый алдылармы икән? Алар урынында булсам, мин үзем йоклый алмас идем. Анын каравы, үз урынымда бик рәхәт йокы бүстем. Урыным исә мич башында иде, ә мич... җылы иде! Юеш салкынлыкны кысрыклап, җылы һаман эчкәрәк, түргәрәк үтә барды... Бер заман «тып-тып-тып» иткән тавышка уянып киттем. Бу шулай итеп... минем маңгайдан тир тама икән!

Иртән Илья мине рюкзакны алып кайтыйк дип иярттеп китте. Авылнын икенче башында асылмалы күпер бар икән... Табып кына булмый бит рюкзакны. Инеш ташып, су эчендә торып калган чүмәләләр күп икән ул... Берәрсе күреп алып киткән булса тагын? Ул чакта бит мин... чит-ерак җирдә бер тиен акчасыз һәм бер документсыз торып калам! Инде Ильянын күз карашында да шикләнү-сагаю галәмәтләре сизелә башлады...

Өмет тәмам киселде дигәндә, ниһаять, күреп алдым мин аны. Биштәрем печәнгә бата төшкән икән. Бу юлы ул инде минем җилкәгә убырлы карчык булып түгел, нәни балам кебек менеп атланды!

Кайтып керү белән тутәйнен кулына акча тоттырдым. Анын күнеле булуы йөзенә чыкты. Ильяны исә акча белән бәхилләү дөрес булмас дидем. Акчасы да аз бит әле

аның. Казанга кайткач бүләк-фәлән җибәрер өчен адресын язып алдым.

Соныннан юлда уйлап бардым: үткән көндә нииндидер бер сәерлек, сер бар иде сыман. Теге агай белән без нәкъ тиешле урында — тиешле юлга җитәрәк кенә очраштык бит. Әйтерсең лә шул туры юлны күрсәтер өчен генә килгән ул! Юлның юкка чыгуы, урман эчендә шул кадәр су булу да гаҗәп инде... Әйтерсең лә мине — кычытмаган җирен кашып, тиктомалдан маҗара эзләп йөргән кешене, сынамакчы булганнар... Ә аннары очраклыкларның нәкъ миңа кирәк булганча тезелүен күр! Утрау табылу... Белканың кинәт кенә өрергә уйлавы. Юкса бүтән өрмәде дә, үзе дә күренмәде бит. Ул йөрсә, мин тәрәзә янына килә дә алмас идем әле... Суның бетүе... Урманнан чыгу... Ягылган мич... Мин барасы Конаководан хатыны белән Ильяның кайтып төшүен күр тагын — нәкъ шул көнне!.. Бу бәләкәй авылдагы бүтән бер генә өйгә дә керә алмастыр идем мин. Ильялар миңа җан өшеткеч нәрсә сөйләделәр. Шушы авыл кияве буранда авыл янында гына төне буе адашып, кычкырып йөргән. Ишеткәннәр, әмма аваз салучы табылмаган. Катып үлгән мескенкәй...

## «Колшәриф» астында «Бисмилла» бар

1996 елның 20 феврале. Колшәриф мәчетенә нигез ташы кую тантанасына дип килгән идем мин бирегә. Ләкин, Шәймиевнең ашыгыч эше килеп чыгыпмы, моны киләсе көнгә күчергәннәр икән. Зур итеп корылган чатыр астында да, аннан читтә дә эш бик кызу бара иде. Үзбушаткыч машиналар килеп-китеп тора, моточүкечләр дөпе-дөпе эшли. Кремльне кызыл каскалы «төрек гаскәре» яулап алган. «444 ел элек кайда идегез соң сез, кардәшләр?» — эчтән генә ачынып шулай дип уйлап куйдым: 1552 елны иң хәтәр мәлдә дә төрек солтаны Сөләйман I Кануни Казан ханлыгына ярдәм итмәгән.

Нигез буласы урыннар казылып, бетон салуга әзерләнгән, кайбер җирләрдә бетон салу башланган да инде...

Тиктомалдан гына килмәгән идем мин бирегә. Күңел тартканга килгән идем. Карап йөри торгач, нинди олы, изге эшнең шаһиты булуымны бөтен күңелем белән тойдым. Мона үземнең дә катышлы буласым, нәрсәдер эшлисем килеп китте. Ләкин нәрсә эшли ала идем соң? Бер бик тә мәгънәле олы теләк язып, нигезгә шуны булса да салып калдырыйм әле —башка кинәт әнә шундый уй килде. Ашыгып кесәләремне актардым, ләкин анда кәгазь әсәре дә, ручка-карандаш та юк иде. Ә теге ният көчәйгәннән-көчәя барып, инде тәмам әсәрләндем. Әрсезләнеп, шундагы төзелеш түрәләреннән дә сорап карадым — алар да тапмады. Юк икәнен белә торып, янә кесә актара башладым. Шунда уң кулым пиджакның куен кесәсендәге каты бер нәрсәгә килеп төртелде. Элек тә төртелгәндер инде ул, ләкин ручка да, кәгазь дә булмагач, игътибар итмәгәнмендер. Тартып чыгардым мин моны. Һәм кинәт шаккату белән аралаш сөенеч күңелдә салют булып атылды! Матурлап бизәлгән түгәрәк металлга төшерелгән «Бисмилла» иде бу! Аны миңа соңгы елларда Төркиянең бер университетында укыткан галимебез Фәрит Хәкимжанов бүләк иткән иде. Шуны, олы бер дулкынлану кичереп, Казансу ягындагы нигез траншеясының Сөембикә манарасы ягыннан караганда сулдагы өлешенә илтеп салдым мин. Уң якта эшләгән, бетон тигезләгән төрек егетенә дәштем әүвәл, аңа күрсәтеп салдым. Ул хуплап елмайды. Чигенеп килгән машина берничә минуттан «Бисмилла» өстенә дә бетон бушатты.

Теге егет белән бераз сөйләшеп тордык, шул көнне бер блокнотыма аның исемен дә язып куйган идем әле... «Бисмилла» хакында Фәрит Хәкимжановка да әйттем, әлбәттә.

Икенче көнне теге нигез тантанасы булды ул, анда чыгышлар ясалды, догалар укылды, нигез ташы астына киләчәк буыннарга хат салып калдырылды.

Ләкин «Колшәриф» астында «Бисмилла» да бар әле. Бу минем өчен генә мөһим түгелдер, бүтәннәр дә белергә тиештер — шуны уйлап яздым инде моны.

**Рәфикъ ЮНЫС**

# БӨЕК АУРАЗИЯЧЕНЕҢ БЕР ЯЛГЫШЫ

*«Мин гомерем буенча
татарларны якладым...»*
Лев Гумилев

Л.Н.Гумилев турында сөйләшкәндә татар галимнәре һәм зыялылары, беренче чиратта, аның татарлар турында язган унай фикерләренә игътибар итәләр. Билгеле, бу тарихчының борынгы төркиләр буенча үз вакытында үткәргән тикшеренүләрен дә онытып булмый, чөнки халкыбыз тарихының башлангыч чоры да шул дәвергә, Үзәк Азия төркиләренә барып тоташа. Әмма без бу язмалар белән генә чикләнсәк, үзен «соңгы аурazияче» дип исемләгән Л.Н.Гумилевка тулы бәя бирү мөмкин булмас иде. Чынлыкта, ул язган хезмәтләрнең башка якларын да истә тотсак кына, аның концептуаль фикерләвенә кагылган, монарчы татар дөньясында әле ныклап өйрәнелмәгән үзенчәлекләрен дә билгеләп үтү мөмкин булачак.



Нәкъ менә шуны истә тотып, бу язмада урыс аурazиячеләре тарихи мәктәбенә караган Л.Н.Гумилевның урыс-татар мөнәсәбәтләренең Алтын Урдада ислам дине кабул итү белән бәйләнгән якларына ясаган анализын тәшвишләп тикшереп үтү кирәк дип табылды, чөнки әлеге эшне башкарып чыккач кына «соңгы аурazияченең» каршылыклы шәхес икәнлеге ачыла. Ә бу нәтиҗә әле өстән-өстән генә һәм бик турыдан фикер йөртергә күнеккән хәзерге дәвер татар җәмгыятенә файдалы булыр дип уйлыйм. Чынлап та, безгә инде идолларга табынудан туктарга, үз мәнфәгатебездән чыгып мөстәкыйль фикер йөртә башларга вакыттыр.

Башта ук кисәтеп куям – карала торган мәсьәләләр гадиләрдән булмаганга күрә, аларны анализлаганда бер генә нечкәлекне дә төшереп калдырырга ярамый. Билгеле, монда Л.Н.Гумилевның фикерләвен бик төгәл бирү дә таләп ителә. Менә шушы шартларны башкарганда гына бу мәкаләдә куелган бурычларны үтәп чыгып була дип уйлыйм.

Этник башлангычның тарихта тоткан урыны турындагы концепциясен эшләгәндә Л.Н.Гумилев Алтын Урдада урыс-татар мәсьәләсенә юлыга. Ул турыда үз дәвере совет гуманитар фәне өчен бөтенләй ят булгән карашлар әйтеп (алар урыс аурazиячеләре тарафыннан XX йөз башларында әйтелгән фикерләрнең дәвамы булган), бу тарихчы шактый гына катлаулы проблемаларга барып «төртелә». Аның иң әһәмиятлесе – Алтын Урдада дәүләт дәрәҗәсендә ислам динен кабул итү һәм аның нәтиҗәләре мәсьәләсе.

Л.Н.Гумилевны аңларга була, аның концепциясе буенча «бөек урыс» (великоросс) этносы формалашуы нәкъ менә Жучи Олысында ислам кабул ителгәннән соңгы вакыйгалар нәтиҗәсендә башланган, шуңа күрә бу галим күрсәтелгән мәсьәләне берничек тә әйләнеп үтә алмаган. Аның гомуми нәтиҗәсе мондый: ислам дине кабул ителгәннән соң, Алтын Урдада фундаменталь үзгәрешләр булып, алар урыс-татар мөнәсәбәтләрен тамырдан үзгәртәләр: әгәр дә 1312 елга кадәр, ягъни, Алтын Урдада ислам кабул ителгәнче, бу дәүләттә урыслар «Урда» белән симбиозда булсалар, исламлашудан соң алар арасында башта (Үзбәк хан белән Мамай бәккә кадәр) «хәрби союз» гына кала, аннан соң ике арада «күп гасырлык сугышлар» (Л.Н.Гумилев билгеләмәсе) чоры башлана, ягъни соңгы процесс 1380 елгы Куликов сугышыннан соң алга чыга.

Әгәр дә Л.Н.Гумилевның карашларын барлап чыксаң, ахыр чиктә аның урыс Аураазиячеләре мәктәбе өчен хас булган бер глобаль мәсьәләдә абынганын ачык күреп була. Ул да булса, Аурразия киңлегендәге цивилизацияләрнең, беренче чиратта, христиан (православ) һәм ислам дөньясының үзара мөнәсәбәтләре проблемасы. Эш шунда ки, урыс аурразиячеләре мәктәбе вәкилләренең концептуаль карашларының иң «нечкә» җире, Аурразиядә формалашкан Русия-Аурразия чикләрендә яшәгән аерым цивилизациянең (ул алар исәбе буенча Көнбатыш та, Көнчыгыш та түгел, ә үзаллы цивилизация) рухи нигезе дип фәкать тик көнчыгыш христиан (Византия, ягъни православ христианлыгы) динен генә тануларыы. Башка диннәр, шул исәптән ислам дине дә, шушы төп рухи көчнең «зонтигы» астында гына яшәп, аның әйдәп баручы, бу пространствоны рухи яктан берләштерүче икәнлеген белеп яшәргә тиеш дип табылуда. Ягъни православ дин иң «яхшы», »уңай» дип кенә түгел, ә Аурразия цивилизациясенең үсешен тәэмин итүче рухи көч тә булып чыга.

Л.Н.Гумилевның бу четерекле мәсьәләгә карашы нинди булган соң? Карап карыйк, ләкин онытмыйк, без тарихчы-этнолог белән эш итәбез, шуңа күрә аның фикерләвен без тарихи вакыйгаларга ясаган анализы аркылы гына күрә алабыз. Әгәр дә Л.Н.Гумилевның безне кызыксындырган мәсьәлә буенча әйтелгән төп фикерләрен җыйсак[1], түбәндәгене күрәбез. Аның уе буенча, XIV йөз башларына кадәр Олуг Урдада (Алтын Урдада) «күчмә» (дала) яки «монгол-төрки» суперэтносы яшәгән. Билгеле бер вакыттан соң, ул үз үсешендә акматик (үзгәрешләр) фазасына житеп, XIV йөз башларында таркалу чорына керә башлаган[2]. Тарихчының фикере буенча, моның ике төп сәбәбе булган: беренчедән, шушы чорга монголларның үзара алып барган сугышлары аркасында, этносны үстерүче пассионарлык энергияле шәхесләр күпләп кырылып, бу энергия җәмгыятьтә бик нык кими; икенчедән «абориген» халыклар да (монда Л.Н.Гумилев фикеренчә болгарлар һәм кыпчаклар да керә) инде «реликт» этносларга әйләнгән булганнар һәм алар Алтын Урдада мөстәкыйль роль уйный алмаганнар.

Нәкъ менә шушы хәлиткеч чорда Үзбәк хан дәверендә ислам дине Алтын Урданың рәсми (дәүләт) дине итеп кабул ителә дә. Әлеге сәяси актны бәяләгәндә Л.Н.Гумилев Үзбәк ханның «дала олысын сәүдәгәрләр солтанлыгына» әйләндергәнен күрсәтеп, бу дәүләтне хәтта «якын Көнчыгышның мәдәни көченә нигезләнгән периферияләге экстремистик солтанлык», дип тә атый. Мондый бәя бирү Л.Н.Гумилевның гомуми карашлары белән бәйле. Аның фикере буенча, 1312 елга кадәр «дала суперэтносында» көнчыгыш христианлыкның бер төре — несториан агымы өстәнлек иткән. Шуңа күрә дә исламлашуга кадәр урысларга бу суперэтнос белән рухи яктан каршылыкка керү кирәк булмаган, киресенчә, алар Урда белән «симбиоз» хәлендә яшәгәннәр. Ә инде 1312 елдан соң ситуация тамырдан үзгәргән, чөнки ислам дине кабул итү суперэтник дәрәҗәдә сәяси юнәлешне генә түгел, ә бөтен мәдәни якны да, хәтта тормыш тәртибен һәм кешеләрнең үз-үзләрен тотышларын да үзгәрткән. Алай гына да түгел, 1312 елга кадәр ислам дәүләт эчендәге башка диннәр төсле үк «түзелгән» бер конфессия генә булса, хәзер инде ул «дала суперэтносыннан» аерылган башка, ягъни мөселман суперэтносына керүне күрсәтүче индикаторга әйләнгән. Ниһаять, тарихчы-этнолог үзенең төп нәтиҗәсен ясый: исламлашу нәтиҗәсендә Алтын Урда «химерага» әйләнә башлый. Аның фикеренчә, процесс 1312 елдан башланып, Мамай Урдасы дәверендә иң югары ноктасына җитә. Нәрсә күз алдында тотыла бу очракта? Л.Н.Гумилев «этник химера» төшенчәсенә берничә аңлатма бирә:

1. Бу төрле мәдәниятләрдән, диннәрдән торган, икътисадый һәм сәяси юнәлешләрдә бер-береннән аерылган этносларның көч нигезендә тотылган, яшәүләре өчен берни инди уңай нәтиҗә китерми торган берләшмә.

2. Социаль организм буларак мәдәни, этник, социаль һәм башка элементларның табигый рәвештә түгел, ә механик юл белән оештырылган, шуңа күрә нормаль үсешкә ирешә алмый торган берләшмә.

---

[1] Ул фикерләрне Л.Н.Гумилевның өч хезмәтеннән карарга була: Год рождения 1380… // Декоративное искусство СССР.- 1980.- № 12; Древняя Русь и Великая Степь. – М., 1992; Черная легенда. Друзья и недруги Великой Степи. – М.: Айрис Пресс, 2006.

[2] Ләкин бу галимнең язмаларын укыганда бер әйбер бик үк аңлашылып бетми: бу таркалу Л.Н.Гумилев «монгол сферасы» (монголосфера) дип аталган бөтен монгол дөньясында башланганмы, әллә Җучи Олысы эчендә генә «монгол-төрки» суперэтносында барганмы? Тарихи мәгълүматларга таянып уйласак, тегесендә дә, бусында да мондый процесслар башланган дигән фикергә килеп була.

3. Бу кешеләрнең ясалма берләшмәсе, анда бердәмлек «унификация» юлы белән генә тотып торыла. Монда бер халык икенчесенә симпатия белдерми, ә өченче халык, гомумән, аларның икесенә дә дошман була.

Күренә ки, Л.Н.Гумилев Алтын Урданың исламлашуына тискәре бәя бирә. Ләкин аның мондый бәясе «химерага» әйләнгән җәмгыятьтәге башка, язмышын ислам динен кабул иткәч кире якка алып кереп киткән күренешләрне өйрәнүеннән дә килеп чыккан. Нинди күренешләр турында сүз бара соң? Алар түбәндәгеләр:

1. Дәүләттә тәхеткә килү системасы үзгәреп, аксөякләрне күпләп үтерү күзәтелә, ягъни ахыр чиктә бу бер гаепсез кешеләрнең юкка чыгуына гына түгел, ә бөтен дәүләт организмының тотрыксызлыгына да китерә. Шуның өстенә ул иҗтимагый тормышта иртәге көнгә ышанычсызлыкны көчәйтә, әхлаксызлыкны арттыра һәм психик яктан тискәре үзгәрешләргә (неврозлыкка) китерә.

2. Җучи олысы эчендә «социаль һәм тел ягыннан, хәтта мәдәни яктан да бердәмлек (бигрәк тә ислам дине кабул ителгәч) күзәтелүгә карамастан», аерым этнос оешмый, чөнки Урта Идел буендагы «борынгы этнослар» (беренче чиратта, болгарлар һәм кыпчаклар күз алдында тотыла) һәм алар эченә Монголия, Джунгария якларыннан «килеп кергән» этник элементлар кирәкле пассионар этәргеч ясый алмыйлар. Сәбәбе инде күрсәтелде: монгол сферасы «үзенең пассионар энергиясен үзара сугышларда әрәм итеп бетерә. Ә Л.Н.Гумилев фикеренчә, бер социаль система эченә яулап алу юлы белән көчләп кертелгән этнослар фәкать тик югары пассионарлык булганда гына бер этник берләшмәгә әйләнгәннәр.

3. Шуның өстенә «монгол-төрки суперэтносы» төрле мәдәниятләрнең (Кытай, Тибет, мөселман яки фарсы мәдәниятләренең) төрле юнәлешләрдәге йогынтысы астында калып «ашала».

4. Дини өлкәдә элекке чорда күзәтелгән толерантлык югала, дини нигездә булган каршылыклар көчәя.

5. «Монгол-төрки суперэтносы», ягъни, татарлар эчендә эчке бүленеш барлыкка килә. Л.Н.Гумилев фикеренчә, Туктамыш хан үзе һәм аның «Күк Урдадан» чыккан гаскәрләре әле ислам динен кабул итеп бетермәгән булганнар, ә бу исә Аксак-Тимер белән аның бәрелешүенә «бөек дала суперэтносы» (Туктамыш хан ягы) белән «Якын Көнчыгышның бөек шәһәр» (Аксак-Тимер ягындагылар) мәдәниятләре арасында барган көндәшлек рәвеше бирә. Тулаем алганда, Туктамыш хан дәверендә Алтын Урдада Үзбәк хан һәм Җанибәк хан вакытларында кабул ителгән ислам динендәге шәһәр халкына таяну күзәтелми. Ә бу исә дәүләтнең «химерага» әйләнүен дәвам иттерә.

Нәтиҗәдә 1360 елларга «монгол-төрки суперэтносы» чатнау фазасына керә һәм Алтын Урданың бөтен этник системасы, аның этник нигезе юкка чыгып бару сәбәпле, тотрыксызлык хәленә җитеп, аерым этносларга «ярыла», хәлбуки аларның гомуми «татар» исеме калса да. Шулай да Л.Н.Гумилев Җучи Олысындагы социаль организм таркалуының төп сәбәбен җәмгыятьтә барган «пассионарлык дәрәҗәсе»төшү белән бәйләсә дә, ул бу даирәдә пассионарлыкның бөтенләй юкка чыкмаганлыгын, әле XVI гасырда да анда «аерым пассионарлык утрауларының» сакланганлыгын күрсәтә. Ләкин аның гомуми нәтиҗәсе барыбер үзгәрми: дин өлкәсендә Үзбәк хан дәверендә үткәрелгән реформа, ягъни исламны дәүләт дине буларак кабул итү, Алтын Урданың «химерага» әйләнүенә китерә. Шулай итеп, галим уйлавынча, Җучи Олысында исламның ныгып урнашуы аның язмышында тискәре роль уйнаган.

Бу фикер белән килешеп буламы соң? Юк, аның белән берничек тә килешеп булмый, чөнки Л.Н.Гумилев ясаган нәтиҗә тарихи түгел, ә сәяси-идеологик. Әйтик, ул Куликов сугышына бәя биргәндә, беренче чиратта, аның «бөек урыс» этносы оеша башлауга этәргеч булганлыгын алга чыгара, ягъни вакыйгаларны урыс күзлегеннән карап бәяли. Нәкъ менә шушы караш буенча 1380 елгы вакыйганы ул «урыс белән татар арасындагы бәрелеш түгел, ә яшь алырлык этнослар белән «химера» (Мамай Урдасын ул шулай билгели – Д. И.) арасындагы бәрелеш» дип билгели һәм ул «химераның» Русь үсеше һәм «Бөек дала» үсеше юлында торганлыгын күрсәтә. Әйе, урыс күзлегеннән бу шулайдыр да. Һәм бу очракта Л.Н.Гумилевның Туктамыш ханнан Русьның союзнигын ясавын да аңларга була, фактта, бу ике көч чынлап та Мамай бәк Урдасына каршы бергәләп хәрәкәт итә. Ләкин уйлап карыйк, аларның максатлары бер булганмы соң?

Юк, тагы бер тапкыр юк. Туктамыш хан Алтын Урданың бердәмлеген торгызу өчен көрәшкән, ә Дмитрий Донской Мамай Урдасы белән урыс берлеген саклау өчен сугышкан. Шуны да онытмаска кирәк: Мамай бәкнең төп биләмәсе Кырым булып, Алтын Урдада таркалу процессы башлангач, ул шушы төбәкне үзенә база итеп алып хәрәкәт иткән һәм беренче чиратта Иделнең уң ягын берләштерергә тырышкан. Шулай булгач, ул Кырым ханлыгының иртә туган бер артык яралгысын ясап яткан түгелме соң? Л.Н.Гумилевның Туктамыш хан 1380 елны Дмитрий Донскойга һәм урысларга «ярдәмгә һәм аларны коткарырга» килүе турындагы фикере белән берничек тә килешеп булмый, чынлыкта, инде күрсәткәнчә, бу хан бердәм дәүләтне сакларга гына тырышкан.

Бөек Ауразияченең кайсы якка тартканлыгын күрү өчен аның фикерләвенең очын табу житә. Ул болай дип яза: «Көнчыгыш Аурапа һәм Аурaзия далаларындагы этносларны яна суперэтник бердәмлеккә» — Русиягә берләштергән Урыс дәүләте кысаларында «русия суперэтносы» барлыкка килә. Ахыр чиктә нәкъ менә шушы яңа «суперэтнос» эчендә калган ислам җәмгыятьләре язмышы турында галим бер сүз дә әйтми, әйтсә дә, аларның рухи яшәешләренең нигезләрен ачмый, ләкин исламның Бөек дала киңлекләренә ясаган тискәре йогынтысын күрсәтергә онытмый. Димәк, ул иске буын аурaзиячеләренең фикерләү кысаларында кала. Ислам дине тискәре нәтиҗәгә китергәч, ул бу «русия суперэтносы» өчен рухи көч була алмый түгелме соң? Шулай булып чыга бит. Ә алай булгач, бу җирлек өчен рухи таяныч булып калырлык бер генә көч кала, ул да булса, христиан дине, ягъни православие. Бу очракта Л.Н.Гумилевның диндар шәхес булганлыгын да онытырга ярамый.

Л.Н.Гумилевның Үзбәк хан заманындагы исламлашуга тискәре бәя бирүен юкка чыгарып булыр иде, чөнки аның бу турыдагы аргументларының һәрберсен башкача аңлатырга мөмкин, ләкин бу очракта безнең каршыда андый бурыч тормый. Тулаем алганда, галим, тар, дөресрәге берьяклы карашлардан чыгып, Русия өчен бик әһәмиятле булган мәсьәләне күздән ычкындыра: нәкъ менә 1312 елдан соң Аурaзия киңлекләрендә яшәргә сәләтле яңа бер этномәдәни берлек — төрки-мөселман җәмгыяте барлыкка килә һәм ул соңыннан «русия суперэтносы» эченә керсә дә, бер үк вакытта бөек ислам цивилизациясенең (Л.Н.Гумилев терминологиясе буенча — «Якын Көнчыгыш бөек шәһәр мәдәниятенең») аерылгысыз өлеше булып та кала. Ягъни XIV йөз башларыннан Аурaзиянең төп өлешендә ике цивилизация бергә үсә башлый — ислам һәм христиан (православ) цивилизацияләре. Ә алар исә икесе дә бертигез дәрәҗәдә генә карала ала. Алтын Урда таркалып, аның урынына яңа төрки-мөселман этнослары барлыкка килгәч тә, аларның рухи-мәдәни нигезләрен ислам дине һәм мәдәнияте тәшкил иткән. Менә шушы нигез аларны үзара һәм бөтен ислам дөньясы белән бәйләп тора да. Шуңа күрә «Бөек даланың төрки-монгол суперэтносы» варислары яшәгәндә, ә аларның күпчелеге Үзбәк хан дәвереннән соң мөселман өммәтенә керәләр, Русияда XIV йөз Алтын Урдасының мирасы буларак калган «туу табы» (???) берничек тә юкка чыга алмый. Бу төркем инде бүген дә Русия эчендә шактый күп санлы, ә алга таба тагы да күбәячәк (БМО бәяләве буенча 2050 елга Русиядә мөселманнар халыкның 37-40 % тәшкил итәчәк). Шуның өстенә, БДБ кысасында якынаю барган саен, ә бу якынаю Русия өчен бик әһәмиятле, Аурaзия киңлекләрендә ислам кыйммәтләренең әһәмияте артачак. Шуны да истән чыгармыйк — бүген илдә «традицион ислам» дип күтәрелгән җирле ислам кыйммәтләре беренче чиратта Алтын Урда дәвереннән калган исламның үзенчәлекләре белән бәйле. Билгеле булганча, нәкъ менә шушы үзенчәлекле ислам перспективада илдә бик тә кирәк булачак.

Кызганыч ки, православие дине тоткан Л.Н.Гумилев, иске аурaзиячеләр концепциясе кысасында калып, әлеге гаять әһәмиятле мәсьәләне күрмәгән. Шушы нәтиҗәдән чыгып, татарга даими теләктәшлек күрсәтүенә карамастан, без бу шәхеснең чикләнгәнлеген дә күрергә тиешбез. Чөнки галим үз халкының һәм мәдәниятенең баласы һәм ул урыс мәнфәгатеннән чыгып фикер йөрткән. Бу начар да, яхшы да түгел, ә хакыйкать. «Соңгы аурaзиячегә» бәя биргәндә бу турыда истән чыгармаска кирәк.

**Дамир ИСХАКОВ,**
*РТФА (РАЕН) академигы,*
*тарих фәннәре докторы*

# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Үзенең анлы гомерен татар халкының рухи янарышына, фәнни потенциалын үстерүгә багышлаган, киңкырлы җәмәгать эшлеклесе булып танылу алган шәхесләр арасында Галимҗан Нигъмәти исеме аерым бер хөрмәт белән искә алына. Татар әдәбияты үсешенә житди йогынты ясаган эзләнүчән галим кыска гына гомерендә үзеннән бай фәнни һәм тәнкыйди мирас калдыра.



Галимҗан Нигъмәти 1907 елның 26 июлендә Уфа өязе Өйдерәкбаш авылында (хәзерге Башкортостанның Благовар районы Өйдерәкбаш авылы) ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Галимҗанга ике яшь чагында, аның әтисе гаиләсен ияртеп Уфа шәһәренә күчә. Соңрак, 1940 елда Сталин лагереннан кызына язылган хатта мондый юллар бар: «Сезнең минем яраткан туган Уфамда яшәвегезгә бик шат. Анда минем балачагым, яшьлек елларым үтте, анда мин әле синең яшеңдә пьесалар яза башладым, ә соңрак шигырьләр иҗат итү белән мавыктым».

Гади эшче булып көн күргән Әмирҗан агай, тормышы авыр булуга карамастан, улын укытырга тырыша. Башта Галимҗан ирләр мәдрәсәсендә белем ала. Әтисе биредә урам себерүче, мич ягучы, гади эшче булып эшләү сәбәпле, Галимҗан уку өчен түләүдән азат ителә. Башлангыч белем алгач, Галимҗанны әтисе Уфаның алдынгы мәдрәсәләреннән берсе булган «Галия»гә урнаштыра. Монда белем алу өчен түләргә кирәк булгач, мәдрәсә директоры Зыя Камали тәкъдиме белән Галимҗан дәресләрдән соң бай балаларын өйләренә барып укыта башлый. Ә 17-18 яшьләрдә ул шәкертләргә әдәбияттан белем бирә.

«Галия» мәдрәсәсе Россиядә алдынгы мәдрәсәләрдән санала, әлеге уку йортыннан танылган укытучылар, язучылар, журналистлар, дәүләт эшлеклеләре, галимнәр чыга. Биредә шәкертләр билгеле бер күләмдә ирекле була: театрга, синематографка, концертка йөрергә, музыка коралларында уйнарга рөхсәт ителә. Драма, хор, музыка түгәрәкләре, кыллы оркестр эшли. Ирек үз-үзенә карата хөрмәт хисе үсешенә тәэсир итә, шәкертләр халык язмышы, милли мәдәният, фән белән янып яшиләр. Мәдрәсәдә белем алучылар спектакльләр куялар, әдәби кичәләр, бәхәсләр оештыралар. Бу елларның шаһитләре мәдрәсәдә шәкертләр тарафыннан И.С.Тургеневның «Акчасызлык» пьесасы татарча тәрҗемәдә куелуын искә алалар. Аны татарчага тәрҗемә ителгән пьесалар җыентыгыннан шәкерт Галимҗан сайлап ала. Мәдрәсәдә язучының юбилей кичәсен оештыручы да ул була. Бу кичә турында Уфа газеталарында язып чыгалар.

Яшь Нигъмәтине башкалардан аерып торучы сыйфатларыннан берсе – китапка мәхәббәт. Казан педагогика институтында аның белән бергә эшләгән Мәһинур Фәйзуллина болай искә ала: «Мин Нигъмәтине 1924 елдан бирле, ул Мәскәүдә Коммунистик университет тулай торагында яшәгән вакыттан беләм. Ул балачактан ук китаплар ярата. «Галия» мәдрәсәсендә укыганда Тургенев томнарын алырга хыялллануы, бу томнарга карап сәгатьләр буе китап кибете каршында басып торуы, акча җыеп сатып алгач, ничек шатлануы хакында сөйләде. Нигъмәти кая гына барса да, китаплар сатып ала иде. Аның китапханәсендә Шекспирның 1914 елда басылган томнары бар иде. Соңрак ул бу бөек язучының совет чорында басылып чыккан томнарын алды. Әлеге ике басманы чагыштырып өйрәнүен мин бүгенгедәй хәтерлим». Үзенең белемен күтәрү буенча даими эшләү, мәгълүматлы булу Галимҗан Нигъмәти эшчәнлегенең методологиясен дә билгели: киң чагыштырулар, милли әдәбиятны дөнья мәдәнияте аренасына кертеп өйрәнү һ.б.

Галимҗан Нигъмәтинең әдәби күзаллавы үсешендә танылган язучы, галим, педагог Галимҗан Ибраһимов зур роль уйный. Ул 1915 елның көзеннән алып 1917 елның Февраль инкыйлабына кадәр «Галия» мәдрәсәсендә укыта, татар әдәбияты курсын алып бара. Галимҗан Ибраһимов үзенең педагогик эшчәнлегендә шәкертләрдә мөстәкыйль фикер йөртү үсешенә игътибар итә. «Галия» мәдрәсәсендә Галимҗан Нигъмәти шигырьләр һәм пьесалар яза башлый, «Ай» исемле кульязма журнал, соңрак «Парлак» исемле әдәби-иҗтимагый кулъязма журнал чыгара. Аларда Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич, Сәйфи Кудаш, Чөнәкәй, Шамун Фидаиләр үзләренең әсәрләрен бастыралар.

1918 елның декабреннән Галимҗан Нигъмәти Көнчыгыш фронтның Бишенче Кызыл Армия политбүлеге органы «Кызыл яу» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Ә 1921 елның язында ул Мәскәүгә килә һәм Көнчыгыш эшчеләренең Коммунистик университеты каршында оештырылган курсларда белем ала. Бирелә А.В.Луначарский, Л.Б.Красин, тарихчы М.Н.Покровский, көнчыгыш белгечләре А.А.Губер, И.М.Рейснер, Б.З.Шумяцкий укыта. Нигъмәти белән бергә Коммунистик университетта Сафа Борһан, Ярлы Кәрим, Мәхмүт Максуд, Фатих Сәйфи, Нәкый Исәнбәт, Латыйф Гомәрев, Исхак Еникеев һ.б. укый. Г.Нигъмәти, Х.Ишбулатов, М.Максуд әдәби түгәрәк оештыралар, алар катнашында гектографта әдәби журнал басыла. Бирелә шагыйрь Һади Такташ та үзенең әсәрләрен бастыра.

1922 елның сентябрендә Г.Нигъмәти Дәүләт журналистика институтында укый башлый, бирелә шулай ук Гобәйдулла Кушаев, Шакир Рәмзи һәм Казан газета-журналлары буенча булачак хезмәттәшләре укый. Алар В.Л.Львов-Рогачевский һәм П.С.Коганның әдәбият тарихы буенча, Н.К.Иванов-Грамен һәм Ф.Г. Мускатблитның публицистика теориясе буенча гаять тирән эчтәлекле лекцияләрен тыңлыйлар.

1923 елда Үзәк башкарма комитеты аппаратында милли матбугат буенча политбүлек оеша. Г.Нигъмәти бирелә 1923 елның 15 октябреннән татар-башкорт матбугаты буенча инструктор булып эшли башлый. Аның кул астында Төрекмәнстан, Кыргызстан, Татарстан, Башкортстан, Крым һәм РСФСРның башка автоном республикаларында чыгучы татар-башкорт басмалары була. Бу чорда Г.Нигъмәти газет-журналларда мәкаләләр бастыра башлый, ә 1925 елда әдәби күренешләрне чагылдыру кинлеге, сәнгати-эстетик юнәлеше белән аерылып торган «Әдәбият мәйданында» китабы дөнья күрә. Гомумкешелек һәм миллилек мәсьәләләрендә уртаклыкка нигезләнгән стилен билгеләп, автор бөтендөнья сәнгатен чагылдырудан әкренләп милли әдәбият күренешләренә күчә һәм Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Һ.Такташ иҗатларын тикшереп бәяли.

1926 елның ноябрендә Г.Нигъмәти Казанга кайта һәм республиканың үзәк газетасы «Кызыл Татарстан», шулай ук «Яналиф» журналының мөхәррире итеп билгеләнә. Монда ул шулай ук Татар дәүләт китап нәшриятының баш мөхәррире булып эшли. Татарстан язучылары берлеген оештыру эшен башлап йөри, ул оешкач, 1928 елның маенда Ф.Сәйфи, Г.Толымбай, Г.Кутуй һәм К.Тинчурин белән бергә Язучылар берлегенең бюро составына керә.

Нәшрият мөхәррире булып эшләгәндә Г.Нигъмәти татар әдәбиятын өйрәнүгә һәм саклауга күп көч куя, Дәрдемәнднең сайланма әсәрләр җыентыгын бастыруда башлап йөрүчеләрдән берсе һәм аның турында кереш мәкалә язучы була. Г.Нигъмәти шәхесенең тагын бер үзенчәлекле сыйфаты булып яшь татар язучылары һәм шагыйрьләре хакында кайгырту тора. Яшь язучылар иҗатында, иң беренче чиратта, яналыкка, күзаллау кинлегенә, яңа сәнгати алымнар табуга игътибар итә. 1929 елда Хәсән Туфанның беренче шигъри җыентыгын бастырып чыгара, кереш мәкаләне дә үзе яза. Һади Такташ иҗатын пропагандалый, әле киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир һәм башкаларның киләчәген дөрес билгели.

1929 елның көзендә Г.Нигъмәтинең тормышында һәм эшчәнлегендә тагын бер мөһим этап башлана: ул Көнчыгыш педагогика институтында (1934 елдан Казан дәүләт педагогика институты) XX гасыр башы татар әдәбиятын укыта башлый, 1934 елда профессор дәрәҗәсен ала. Аның элекке студентларыннан һәм аспирантларыннан берсе, филология фәннәре докторы, профессор, күренекле әдәбият белеме галиме һәм язучы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Хатип Госман

Г.Нигъмәти белән беренче очрашуны болай искә ала: «1935 елның 1 нче сентябре. Без – Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә яна гына кабул ителгән студентлар. Аудитория. Һәркем үзенә урын сайлады. Беренче дәрес була. Кыңгырау. Барысы да тын калдылар. Көтәбез. Ишек ачылды. Без көткән кеше керде һәм туктап тормыйча гына башын селкеп исәнләште, кафедра янына үтте... Каршына папка куйды. Ике куллап кафедрага тотынды. Тыныч кына карашы белән аудиторияне күзәтеп чыкты. Ашыкмый. Күрәсең, сүз сайлый... Менә, ниһаять, тыныч һәм үтемле тавыш яңгырады:

— Сәнгать – образлар ярдәмендә дөньяны үзләштерү чарасы...

Ниндидер зур сер ачкандай бу фикер кинәт минем аңымны яктыртып үтте. Күңелдә соклану хисе катыш аңлаешсыз шатлык. Шундый халәттә минем аңым, минем рухи дөньям лекторның сүзләренә ияреп китте, мин әле моңа кадәр миңа билгесез булган яңа, кызыклы, төшенчәләргә бай булган дөньяга кердем һәм югалдым...

Үзенең эрудициясе белән ул безгә үрнәк иде. Әлбәттә, профессорның үз белгечлеге буенча киң диапозонлы эрудициягә ия булуы табигый хәл. Ләкин белгеч тыңлаучыларга хәтер байлыгын кайсы ягыннан ача бит... Монда иң кыйммәте шул ки: эрудиция байлыгы лекторның үз фикерләренә, хисләренә, ышаныч символына әйләнә. Лекторның яшерен иҗади көчләре уянганда гына, җанын, эчке дөньясын кушканда гына, тыңлаучы каршында аңа билгеле фактлар яңача, көтелмәгәнчә ачыла».

Г.Нигъмәтинең педагогика институтына күчүе һәм педагогик эшчәнлеге әдәби-иҗади түгәрәк эшчәнлегенә яңа сулыш өрә. Бирелә Сибгат Хәким беренче чирканчык ала, Хәсән Хәйри, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман, Хәмит Ярми, Афзал Кудаш һәм башка бик күп булачак галим-филологлар каләм чарлый.

Бу елларда Галимҗан Нигъмәти үзен сәләтле галим-әдәбият белгече, татар әдәбияты тарихы һәм теориясе хезмәтләре авторы буларак та таныта, күренекле әдәбият тәнкыйтьчеләренең берсенә әверелә. Инкыйлабка кадәрге татар язучыларының иҗатын өйрәнү буенча кыска гына вакыт аралыгында ул саллы гына хезмәт куя (Г.Ибраһимов, Г.Тукай, М.Гафури, Дәрдемәнд һ.б.); әдәбият һәм сәнгать методологиясе буенча хезмәтләр яза; совет язучыларының иҗаты хакында мәкаләләр бастыра (К.Нәҗми, Г.Толымбай, Х.Туфан һ.б.). Галим үзен татар әдәбияты гына түгел, ә рус (хәзерге һәм классик) һәм көнбатыш (классик) әдәбияты белгече буларак та күрсәтә. Л.Н.Толстой, А.М.Горький, А.П.Чехов һ.б. иҗатларына багышланган мәкаләләре дөнья күрә. Күп галимнәр билгеләвенчә, Г.Нигъмәти хезмәтләренә хас булган төп сыйфатларның берсе – әдәбиятны һәм сәнгатьне төрле яклап өйрәнү һәм аларга хас үзенчәлекләрне ачыклау омтылышы. Юкка гына аңа 1930 елларда Татар дәүләт академия театрының әдәби советын җитәкләүне ышанып тапшырмыйлар.

Читтән караганда барысы да Г.Нигъмәтигә яңа иҗади уңышлар һәм үрләр вәгъдә итә кебек. Әмма язмыш үзенчә һәм бик хаксыз хәл итә. Чынлыкта, талантның туры юлы юк, ә объектив һәм субъектив киртәләр генә бар. Кешегә аларның һәрберсен дә үз көчләре белән генә үтү мөмкин түгел. Узган гасырның 30 нчы еллар ахырында Г.Нигъмәтинең иҗади эшчәнлеге һәм, гомумән, тормышы вакытсыз һәм фаҗигале рәвештә өзелә. Галим, тәнкыйтьче, публицист, шул чор татар фәненең һәм мәдәниятенең күп кенә күренекле вәкилләре белән беррәттән, репрессия балтасы астына эләгә, нахакка «пантюркизм һәм панисламизм» да, шул чорда кулга алынган Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Хәсән Туфан, Фатих Сәйфи, Сәлах Атнагулов, Гомәр Толымбай һ.б. белән аралашуда гаепләнеп төрмәгә ябыла. Фәнни һәм иҗади фикерләү киңлегенә ия булган, әдәбиятны җанлы, милли әдәбиятлар системасы белән бәйләнештә үсүче организм буларак кабул итүче, татар әдәбиятын комплекслы, рус һәм дөнья әдәбияты контекстында, шулай ук сәнгать һәм мәдәниятне тулаем өйрәнүгә омтылучы шәхескә карата моннан да мәгънәсезрәк гаепне уйлап табу мөмкин түгелдер.

1920 еллар татар әдәбият белемендә, алдарак рус академик әдәбият белемендә барлыкка килгән яңа мәдәни-тарихи мәктәп формалаша. Әлеге мәктәпнең күренекле вәкилләре Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Ж.Вәлиди, Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллин хезмәтләрендә, ә алар арасында Г.Нигъмәти хезмәтләре мөһим урыннарның берсен алып тора, төрле алымнарның һәм ысулларның синтезы кирәклеге ассызыклана.

Алар тарихи-функциональ методта, компаративистик, мәдәни юнәлешләрдә чагылыш тапкан синтезның модельләрен, вариантларын тәкъдим итәләр. Ләкин татар филологиясендә зур югалтулар аркасында 1930 елларда бу процесс өзелә. Бары тик дистә еллардан соң гына, 1960 елларда, Г.Нигъмәтинең һәм башка татар галимнәренең 1920-1930 еллардагы фәнни мирасы, югарыда телгә алынган укучысы, Казан университеты профессоры Х.Госман, шулай ук М.Хәсәнов һ.б. тарафыннан дәвам ителә. Х.Госман 1920-1930 еллар әдәбият белеме галимнәренең тәҗрибәсен дәвам итәргә һәм аны XX гасыр уртасы фәнни казанышлары яссылыгында кулланырга омтыла. Профессор М.Хәсәнов татар әдәбиятында «тыелган тема»ларны өйрәнүне башлый, реабилитацияләнгән татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатының тирәнлеген, әһәмиятен ачарга омтыла. Бу юнәлештәге эзләнүләр бүгенге көндә дә дәвам итә.

Г.Нигъмәтинең фикерләре киләчәк буын язучыларны, галимнәрне милли әдәбиятның үз кысаларына гына бикләнеп ятуы һәлакәткә алып килүен, алга таба төрле мәдәниятләрнең, традицияләрнең үзара бәйләнештә булуларын тикшерүнең әһәмиятен, киңкырлы әдәби мирасны комплекслы өйрәнүнең кирәклеген искәртеп, бүген дә актуаль яңгырый. Татар әдәбияты тәнкыйтен өйрәнүдә һәм бүгенге әдәби хәрәкәтнең күп кенә проблемаларын хәл итү өчен киләчәк буыннар әле озак еллар дәвамында татар халкының күренекле улы – галим, публицист, тәнкыйтьче һәм педагог профессор Галимҗан Нигъмәти мирасына мөрәҗәгать итәчәк.

**Искәндәр ЯРМӘКӘЕВ,**
*Казан федераль университеты профессоры*

---

## *Киләсе санда укыгыз*

Наил Шәрифуллин

### БЕЗ БЕТӘБЕЗ ИНДЕ, СЕЗ КАЛАСЫЗ

КҮПТӘН ОЧСЫЗЛАНГАН КЫЙММӘТЛӘР, БЕРКЕМ ЯРЛЫКАМАС ГӨНАҺЛАР ХАКЫНДА


Глобализация, унификация, урбанизация, эмансипация, башка бик күп шундый "...ция"лар, идеаллар дефициты, бушлык тудырган, гөнаһлы рәхәтлекләре белән күпләрне ымсындырып, кеше затының бар булган рухи маякларын, кыйбласын каплап торган Көнбатыш... Ә бит тыштан барысы да яхшы сыман: ялтырап торган гипер һәм супермаркетлар, ыспай киенгән кешеләр, чиста урамнар, зиннәтле машиналар. Әмма эчтә шөбһә, бушлык. Чөнки инанулар, мәгънәле ориентирлар юк. Акча белән мал, алар артыннан чабу инану була алмый. Ул шайтан коткысы гына була ала...

# ӘДИП ГАЛИМ ТУРЫНДА ГАЛИМ ӘДИП

*Үткән ел язучы, галим, тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе Тәлгат Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» исемле роман-эссесенә ике битлек кенә кереш сүз язган идем. Нәшрият графигына бәйлелектән ашыгыбрак язылды. Әйтергә теләгән фикерләремне кәгазьгә төшереп бетермәдем шикелле. Минем байтак гомерем бу ике шәхес һәм әсәрдә бик җылы сурәтләнгән Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Ф.Миңнуллиннар белән аралашып үтте. Менә шулай уйланып йөри торгач, өстәмә язмам туды. Китапка кереш сүз булып барганын да, язманың яңасын да, укучыларга тәкъдим итәргә булдым.*

I

Тәлгат Галиуллин Мөхәммәт Мәһдиев турында күләмле әсәр язган. Бу гамәл табигый хәл булып кабул ителә. Алар — автор да, әсәр каһарманы да — замандашлар, галимнәр, язучылар, дуслар, фикердәшләр... Чордашлар булсалар да, Мәһдиев Галиуллиннан җиде-сигез яшькә өлкәнрәк. Бакыйлыкка күчкәненә дә ике дистәгә якын вакыт үтеп бара. Дөнья кичкәннәр турында хәтер янарту, иҗат рухларын яңа буыннар күнеленә салып калдырырга тырышу - савaплы, кешелекле гамәл.




Иң әүвәл әсәр авторы Тәлгат Галиуллин турында берничә сүз. Минемчә, иҗаты әлегә тулысынча бәяләнеп бетмәгән шәхес ул. Дөрес, әдәбият фәнендәге хезмәтләре өчен Татарстан фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы дигән гыйльми дәрәҗәсе бар. Язучы буларак та Галиуллинның абруе кагылгысыз. Әйтик, «Сакманов» трилогиясе аны бүгенге көннең әйдәп баручы прозаиклары рәтенә күтәрде. Дөресен әйтергә кирәк, хәзерге татар әдәбиятында Тәлгат Галиуллин кебек олпат әдипләребез сирәк. Әдәби-иҗтимагый тормышыбызда ярты гасырдан артык үзенең шифалы йогынтысын сиздереп килә ул. Заманында — 70нче елларда — Советлар иленең югары уку йортлары арасында иң яшь ректор булуы гына да күп нәрсә аңлата. Эпик пландагы әсәрләрдән тыш, документаль жанрда язылган, төгәлрәге, истәлек-хатирәләр, эссе-уйлануларны эченә алган берничә китап авторы да ул. «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы»н шуларның дәвамы дип санап була.

Бездә хәзер теге яки бу язучы турында күбрәк йә юбилей, йә берәр премиягә тәкъдим итү уңаеннан язып чыгалар. Китап яки аерым бер яңа әсәр турында фикерләрне сирәгрәк ишетәсең. Соңгы чорга хас яңа бер күренеш: күренеклерәк берәр шәхес вафатыннан соң, ашык-пошык истәлек китап-альбом чыгару. Әлбәттә, мондый очракта мәрхүм турында гел яхшы сүз генә сөйләнелә... Югарыда әйтелгәннәр, өлешчә М.Мәһдиев шәхесенә дә кагыла. Т.Галиуллинның бу әсәре, нindидер «уңай» белән түгел, күңел теләгеннән, иҗади ихтыяҗдан чыгып язылган. Шуңа күрә дә документальлек һәм анализлау-бәяләү ягыннан бу әсәр әдип турында моңа кадәр дөнья күргән язмалардан нык аерыла, объективлыкка якынлык сизелә, чөнки ул «еракка китебрәк», күпмедер вакыт аралыгы үткәч иҗат ителгән. Язу

Галиуллин Т. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.– 192 б.

алымы да беркадәр «мәһдичә»рәк. Галиуллин романнарында гадәттә кануни сюжет линиясе урын ала, ә бу әсәрдә, хронологик эзлеклелек сакланса да, вакыйга-эпизодлар «оялап», аерым бүлекисемнәр белән бирелгән.

Мөхәммәт Мәһдиев. Бу исемне ишеткәч, күпләр күңелендә ниндидер аклык пәйда була дип уйлыйм мин. Шундук сине әллә нинди хисләр бөтереп ала: горурлык та, кимсенү дә, кайкаһә дә, сагышлану да... Димәк, язучының сүзе синен үзәгенә үтә алган! Димәк, якынлык, рухи уртаклык бар! Нидән ул дисәк, әйтәм: безне берләштерә торган ике нәрсә бар: берсе — авыл, икенчесе — тел. Авыл димәктән, Мәһдиевне кемдер «авыл пәйгамбәре» дип тикмәгә генә атамаган инде. Ә тел? Мәһдиев теле — әйтәсе дә юк, тылсымлы тел ул! Гомумән, сугыштан соңгы татар авылы кешеләрен табигый рухы-сүле белән шулай оста тасвирлаган бүтән берәр язучы булды микән бездә? Бәлки ул, Фатих Хөснидер? Бүгенгеләрдән иптәшкә, бәлки, Фоат Садриевтыр?.. Әмма Мәһдиев, барыбер, кабатланмас үз биеклегендә калыр инде. Тәлгат Галиуллин бу әсәрендә М.Мәһдиев турында укучыларның (конкрет исемнәрен әйтеп) фикерләрен теркәп куйган. «Эч пошканда, үзенне кая куярга белми бәргәләнгәндә, Мәһдиев томын кулына алып, теләсә кайсы битен күз йомып ачып, берничә битен укуга, бик эссе көнне салкын су белән коенгандай, иркенәеп, сихәтләнеп, «яңа дөнья»да яшәп алгандай, унайланып китәсен». Бу сүзләрне хуплап, меңәрләгән укучылар рәхәтләнеп кул куярлар иде. Әйе, Мөхәммәт Мәһдиев халыкның үзенеке итеп кабул ителгән сөйкемле сөяге иде. Дөньяда табигать тудырган гаҗәеп зур талант ияләре бар. Татарда да бар андыйлар. Тик аларның сирәге халык күңелендә «эри» ала. Бу очракта бер якны да гаепли алмыйсың: талант иясен дә, гади халык вәкилләрен дә. Ә хикмәти сер барыбер кала бирә... Хәер, галиҗәнап Вакыт дигәннәре бар икәнен онытмыйк! Әйтик, илле-алтмыш елдан соң кемнәрнең кемнәргә бәясе ничек булыр бит әле!

Әсәр «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» дип атала. Дөресен әйтим, исемнең җисеменә тәнгәллек дәрәҗәсе мине беркадәр уйга калдырды. «Йолдызлык» дигәч, бер бик якты зур йолдыз һәм аның янындагы кечерәк, тоныграк йолдызлар, йолдызчыклар күз алдына килә. Ә әсәрдә төп герой, төп каһарман янәшәсендә кемнәр сурәтләнә соң? Гомәр Бәширов, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов... Уйласаң, боларның һәрберсе төп якты йолдыз булып, үзләре йолдызлыклар тәшкил итәрлек шәхесләр түгелме соң? Роман-эссе бер тын белән утырып язылган әсәр түгел; ул — озак еллар җыелып килгән уй-фикерләрнең эссенциясе. Китапка кергән бүлекләрнең кайберләре моннан байтак еллар элек язылган. Автор аларны яңадан карап, эшкәртеп, баш герой турындагы язмалар тирәсенә туплап «монтаж»лаган. Шулай итеп, автор өчен, чыннан да «Йолдызлык» барлыкка килгән. Хәер, хикмәт исемдә түгел, иң мөһиме — шул чор (60-80 нче еллар) татар әдәбиятының үсеш процессын, шул үсешнең төп юнәлешен билгеләгән байтак язучыларның, галимнәрнең җанлы портретларын күреп була бу әсәрдә. Роман-эссеның көче документальлектә. Күреп торабыз, кирпеч калынлыгындагы романнар чоры үтеп бара. Үз заманында калын-калын романнар авторы Лев Толстой бабай бу хакта моннан йөз ел элек, киләчәк әдәбият реаль чынбарлык мәгълүматларга корылган әдәбият булачак, дигән фикер әйткән. Шуның дөреслеккә чыга баруына шаһитләр без бүген. Тәлгат Галиуллинның бу әсәре белән танышкан укучы авторның теге яки бу вакыйгага, шәхескә биргән бәя-билгеләмәләре белән килешмәскә дә мөмкин. Монысы да табигый: язучы иң соңгы инстанциядәге хакыйкатьне әйтүгә дәгъва да итми бит.

## II

XX йөз татар прозасының күренекле вәкиле, публицист, тәнкыйтьче, галим-педагог Мөхәммәт Мәһдиев иҗаты, ерактан күренеп торган якты маяк кебек, күпләрне үзенә җәлеп итеп тора. Куәтен, гыйльми көчен, акыл сәләтен милләтенә хезмәт итүгә багышлаган М.Мәһдиев җәмәгатьчелекне үзенә игътибарсызлыкта гаепли алмый иде кебек. Аның әсәрләре, шәхесе белән илһамланып иҗат мәкаләләре язган А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, Ф.Миңнуллин, Ә.Гаффар, Р.Мөхәммәдиев, Р.Зәйдулла һ.б. тавышына яңа, яшь галимнәр каләменнән төшкән тикшеренүләр килеп

кушылды. Ниһаять, әлегәчә әйтелгән фикерләрне, күзәтүләрне искә алып, еш кына беркадәр шуларга да таянып, Тәлгат Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» исемле, документальлек белән фәннилекне, булган хәлләрне хыял уены белән баеткан роман-эссесе укучыларга тәкъдим ителә.

Әсәрнең каһарманы һәм авторы белән күптәннән аралашып, бер үк мохит сулышы белән яшәп, иҗатларын да яхшы үк күзаллаган булсам да, кереш мәкаләмне язар алдыннан, бу ике затны нинди уртак мәүзуглар, шатлык-кайгылар, уй-ниятләр, рухи җепләр якынлаштырган икән дигән соалыгә җавап эзләп шактый уйландым. Бер караганда, барысы да гап-гади, ап-ачык кебек. Якынча бер үк чорда яшәгәч, тормыш агышын, милләт язмышын аңлаулары холык-гадәтләрен, рухи дөньяларын, иҗади эзләнүләрен бер агымгарак боргандыр дигәнрәк фаразым да тулы хакыйкатьне ачып җиткерми кебек тоелды.

Икесенең дә язучы һәм галим булулары, җәмәгать эше белән (берсе — КДУның берләштерелгән профком рәисе, икенчесе - ректор, декан...) мәгърифәт нурын, татар кавеменең олы тарихын, сүз сәнгатебезнең илаһи көчен, сурәт байлыгын яшь буын күңеленә сеңдерү вазифасын бергә алып бару юлындагы фидакарьлекләре аларны тәсбих төймәләредәй бер җепкә тезгәндер дигән нәтиҗәгә килдем.

Туган телебезнең язмышы, киләчәге кыл өстендә эленеп торган XXI гасыр башында, аны инкыйраз упкынынннан коткарып калу өчен көрәшнең алгы сафында булган укытучыларның, журналистларның, гомумән, милләт гаме белән яшәүчеләрнең шактый өлеше аң-белем, әхлак дәресләрен шул ике шәхестән яисә алар укыткан мөгаллимнәрдән алганлыкларын да онытмыйк.

М.Мәһдиев иҗатына, шәхесенә һәм аның иң якын каләмдәшләренә багышланган әсәргә бәя бирүгә алынуыма, бу олуг затларның үзара таләпчән дуслыкларының шаһите (бәлки иң соңгыларының берседер) булуым этәргеч тә, хокук та бирде. Язучылар берлегенең идарә утырышында да, районнарга укучылар белән очрашуларга чыкканда да, кинәт оешкан ирләр мәҗлесендә дә Мөхәммәт абый белән Тәлгат Нәби улының һәрвакыт янәшә, җилкәне җилкәгә терәп, колакны колакка куеп сөйләшеп туймаслыкларын күп тапкырлар күрергә насыйп булды.

Бу сокландыргыч мөнәсәбәт Мөхәммәт абыйның Т.Галиуллинга, ул Алабугада яшәгәндә язган хатларында, үз китапларына багышламаларында, бигрәк тә Нәбиулла абый язмышын үзәккә алган ифрат җылы һәм әчкерсез «Картайма әле, ветеран» очеркында аеруча ачык чагыла. Кунак ашы кара-каршы дигәндәй, Тәлгат Нәби улы М.Мәһдиев иҗаты турында тикшеренүләрен үзе исән чакта ук башлап, вакытлы матбугатта бастыра килеп, дустының намена зур бүләген - «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» роман-эссесен тәкъдир итә.

Автор М.Мәһдиев мирасын фәнни категория буларак өйрәнүнең киң аспектлы юлын тапкан: язучының тормышкөнитешенә кагылышлы вакыйгаларны, көлкеле вә гыйбрәтле хәлләрне үзәккә алган истәлекләр «Без - кырык беренче ел балалары», «Кеше китә - җыры кала» бәяннары, «Фронтовиклар», «Мәңгелек яз» романнары турында мәктәп, югары уку йортлары укучыларына тәкъдим итәрлек фәнни анализ белән аралашып, бер-берсен тулыландырып тора.

М.Мәһдиев иҗатын автор, милли тамырларга бәйле рәвештә, татар кешесенең үзанын, характерын, гореф-гадәтләрен сүз-сурәтенә, ягъни менталь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә өйрәнү методикасына өстенлек бирә. Мөхәммәт Сөнгат улы кебек шәхес, сокландыргыч телле иҗат турында катлаулы, артык фәнниләштерелгән, корама тел белән язарга ярамаганны истә тотып, роман-эссе авторы гади, аңлаешлы, шул ук вакытта образлы, алда әйткәнемчә, Мәһдиев фикерләвенә якын өслүбкә өстенлек бирә. Г.Бәширов, Ф.Миңнуллин мирасларына багышланган уй-фикерләрендә, жанр хасияте таләп иткәнчә, үзенең фәннәр докторы, профессор, докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе икәнлеген дә «сиздереп» ала.

Язучы иҗатында тел иң мөһиме дигән хакыйкатьне нигез итеп алып, автор Мәһдиевнең тел-сурәт үзенчәлекләрен өйрәнүгә зур әһәмият бирә. Аерым алганда, язучы лексикасының төрле катламнарын, җөмлә төзелешен, сүз-мәгънә тәгаллеген, хис белдерү нечкәлекләрен, юмор, ирония алымнарын кайта-кайта,

бүлектән-бүлеккә күчерә-күчерә өйрәнүе шуңа инандыра.

Т.Галиуллин М.Мәһдиев иҗатын югары бәяләсә дә, бер могҗиза итеп, гомуми әдәби үсеш барышыннан аерып карамый, аны үзәккә алып, XX гасырның икенче яртысының әдәби панорамасын тудыра. Аерым алганда, автор М.Мәһдиев «Ачы тәҗрибә» истәлекләр китабында искә алган, бәя биргән язучылар (С.Хәким, М.Галиев, Батулла, М.Хәбибуллин һ.б.), галимнәр (Х.Госман, И.Нуруллин, Я.Агишев, А.Яхин, М.Бакиров һ.б.) эшчәнлегенә, аларның мирасына үз мөнәсәбәтен сиздереп барырга тырыша, берсен дә рәнҗетмичә, шул ук вакытта истә калырлык детальләр белән үреп бара.

Мондый киң караш-бәя өчен әдәбимәдәни халәтебезне яхшы белүнең төп шарт икәнлеген искә төшереп тормастан, роман-эссе авторының бер караудa кечкенә генә күренгән вакыйга аша арадаш күренешләрне тасвирга алып керү осталыгына игътибар итәсе килә. Менә ул Язучылар берлегенең кабул итү бүлмәсен бизәп торган, татар прозасының йөзек кашлары А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Г.Ахунов төшерелгән «Өч баһадир» дигән фотосурәтнең, үзләре бакыйлыкка күчкәч, дивардан юкка чыгуын рәнҗеп кабул итә. Ошбу рәсемне искә төшерү авторга алар яшәп иҗат иткән чор татар әдәбиятына гомуми күзәтү ясау, олуг затларыбызның исемнәрен, әсәрләрен искә алу, фотога алынган каләм әһелләренең холкынфигылен, менәзен-характерын ачу, иҗатларын яңачарак бәяләү мөмкинлеген бирә.

«Юмор - табигать бүләге» дип аталган бүлектә «Без - кырык беренче ел балалары» бәянының көлү сәнгатенә алып килгән яңачалыгын ачу аша автор XX гасырда, аеруча Тукай, Бабич, Г.Афзал иҗатларында юмор белән сатирик фикерләүнең дөнья мәдәнияте ирешкән югарылыкка күтәрелүен дәлилли, ә М.Мәһдиев юморы халыкчанлык чагылышының югары үре итеп бәяләнә.

Т. Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» әсәрен кабат укыганда, сурәтләү объектын артык идеаллаштыру, күтәребрәк кую юкмы, дигән шөбһә дә күңелне тырнап узгандай булды. Мин бу шигемә дә аңлатманы үз аңымда таптым: әгәренки язучының бөтен иҗатын кабул итеп, шәхесен ихтирам итмәсәң, укучы калебен биләрлек әсәр дә, гадәти бер мәкалә дә яза алмыйсың. Икенче тарафтан, роман-эссе авторы Мәһдиевнең сюжет эзлеклелеген санга сукмау, вакыйга җебен бер үзәк каһарман тирәсендә туплый белмәү (бәлки, теләмәү), драма әсәрләрен таныту, сәхнәдә урын даулау өчен Дон-Кихотчарак көрәшү маташыкларын да яшерми, комфорт ярату, иркәләнү кебек йомшаклыкларына да күз йоммый, аның гадәти яшәештәге кимчелекләреннән якын итеп көлгән урыннар әсәрне бизиләр, Мөхәммәт абыйның кабатланмас образын күңелдә уеп калдыралар.

Ниһаять, Мәһдиев кебек киң колачлы, күп яклы, тирән мәгънәле иҗатның кемнәрдер бер канатын, әйтик, назик, мамыклы, шигъри телен якын итсә, икенче берәүләр аның тормыш низагъларын юмор, ирония белән сурәтләү осталыгына мөкиббән китәргә мөмкин. Кемнәрдер Мәһдиевне халык иҗатының, бигрәк тә лирик җырларының фәлсәфи эчтәлеген, сәнгати матурлыгын ачып биргән галим буларак хөрмәт итсә дә бик табигый. Ә инде хатын-кыз психологиясен, рухи дөньясын, дөнья бизәкләренең матурлыгын шундый осталык вә тирәнлек белән сурәтләүдә XX йөзнең икенче яртысы татар прозасында, үзе әйтмешли, едва ли, тагын берәү бардыр.

Һәр укучының, аны яхшы белгән кешеләрнең Мәһдиевкә үз бәясе, һәркемнең үз Мәһдиеве булырга мөмкин. Тәлгат Галиуллин «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» әсәрендә бу олуг шәхесебезне, аның мирасын үзе аңлаганча, үзе кабул иткәнчә кәгазьгә төшергән. Кемдер аның белән бәхәсләшергә, берише урыннарын кабул итмәскә мөмкин. Фикер төрлелегеннән башка үзаң һәм зәвык үсеше була алмый. Язучылар, гомумән зыялылар арасындагы ихласи дуслык, аңлашып яшәү шундый әсәр кебек яисә башкарак рәвештәге иҗат җимеше бирсә, татар сүз сәнгатебез отар гына иде. Якын дустының әсәре Мөхәммәт абый рухына дога булып барсын! Шулай буласына бер кәррә дә шигем юк.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

# ЯЗМЫШ ТУРЫНДАГЫ СЕР

Н.Гыйматдинованың 2010 елда дөнья күргән өчтомлыгы хакындагы сүземне «Хатыннар сагышы» повестендагы үзенчәлекле, гыйбрәтле күренеш белән башлыйсым килә: «... Аның үз дөньясы бар иде. Бәләкәй генә, жыйнак кына дөнья... Ае-йолдызы белән... Карбураннары, жилянгыры белән... Аңа анда жинел һәм рәхәт иде... Ул бу дөньяда кануннар төзүче патша да, шуларны карусыз үтәүче хезмәтче дә иде». Әдибә әсәрләреннән торган тупланманы укып-өйрәнеп чыкканнан соң, ижатчының шәхси портреты да әнә шундый булып күз алдына килеп баса.




Танылган шагыйрь һәм прозаик Ркаил Зәйдулла болай дип яза: «Нәбирә – бәхетле язучы, татар әдипләре арасында бүген ул иң күп укыла торганы». Бу чыннан да шулай: аның жыентыклары китап киштәләреннән тиз арада таралып бетә. Әйе, яратып укылуның серен белә Нәбирә ханым: аның геройлары нечкә күнелле, сизгер, хис-кичерешләргә бай, якты сагышлы, матурлыкны бәяли алыр дәрәжәдә тәрбияле, олы мәхәббәтләрен гомер буе йөрәк түрендә саклап йөртүчеләр. Аның һәр герое: «Бәхет эше икән ул мәхәббәт», – дип кабатлый, һәр повестенда «жиденче буын әбиләрдән кан белән күчкән хәтер чылбырының бүгенгесе белән тоташу күренеше» тасвирлана. Әдибәнең һәр әсәре яшәеш концепциясе кебек кабул ителә.

«Хатыннар сагышы» әсәрендә дус хатыннар язмышы тасвирлана. Ниса Әхмәрова образына игътибар итик. Язучы ханымның яшәеш фәлсәфәсе «төче ялганга караганда – ачы хакыйкать кыйммәт!» – дигән гап-гади канунга нигезләнә: «Ниса теле белән көрәшмәде, әчке халәте белән һәр ялганга, һәр икейөзлелеккә каршы чыкты». «Эшсезлектән арган журналистлардан» горур хатын хәзерге жәмгыятьтә кыргый булып тоелган ялган сөймәү гадәте, китап укырга хирыслыгы белән аерылып тора. «Жәмгыятьтә борын чөярлек бәләкәй генә статус – ир хатыны» булу бәхете ана әлегә тәтемәгән: «табигать мәрхәмәтсез: ул хатын-кызны сайлау мөмкинлегеннән мәхрүм итә, шуңа дөньяда бәхетсез хатыннар, сагышлы хатыннар күбәя». Ә менә бай ир хатыны Сандугач исә дустының кемгәдер кирәк булуына кызыгып карый, чөнки аның «өч кешелек гаиләсендә һәркемнең үз урыны». Сандугач авылын, үткәнен, бәхетсез мәхәббәтен сагынып сызлана, ире Бәдри Саматовичны хезмәтче Рокыя апаның гомер буе яратып яшәвен ул очраклы гына белеп ала... Икътисад бүлеге житәкчесе Шакирә исә улын Самат Азаматовичның «акчаларына» өйләндерү хыялы белән яши. Улы «ничек инде ул, ирегенне сат та, коллыкка төш», – дигән фикердә тора, башка юл сайлый.

Өч хатынның язмышын хикәяләүче субъектив герой автор тавышын ишеттерүче буларак кабул ителә: «Адәм баласына тынгы юк: ул гомере буе көйсез жанын көйләп яши. Яраларымны тизрәк дәвалыйм, хаталарымны тизрәк төзәтим дип өметләнә. Ә жан, үчеккәндәй, мәшәкать арты мәшәкать өстәп тора. Чөнки ул фани дөньяныкы түгел. Аны шушы ыгы-

Гыйматдинова Н. Повестьлар. Өч томда. I том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.– 469 б.

зыгылы һәм гөнаһлы Жиргә вакытлыча гына очыртып җибәргәннәр һәм җан, бу тарлыктан, бу кысанлыктан туеп, һаман каядыр билгесезлеккә ашкына».

Табигать күренешләре Н.Гыйматдинова әсәрләрендә мөһим функция үти. Мисалга «Икебезгә дә авыр» повестенда сюжетка керергә әзерләүче пейзаж элементына игътибар итик: «Бу төн бик караңгы иде... Әйтерсең җиһан, күктә йолдызларын кабызырга онытып, йокларга яткан. Айдан саран гына яктылык сирпелсә дә, күңел сөенер иде. Кайчагында төн кояшы бер иптәш кебек була. Тик төпсез «Тоба»ны анысы да яктырып та кинәндерми шул: янгырлы төннәрдә дөньяга чыраен сытып, болытлар арасына чума». Урман, бүреләр — мифологик мотивларны барлыкка китерүче символлар. Төркиләрдә изге саналган бүреләр — «җан саклар өчен Тобага төшеп утырган», ярты гомерен чокырда уздырган Зәмзәмиянең дуслары. Үзен мәңгегә ялгыз иткән «бәндәләр буйсынган законнар белән, бәндәләр үтәгән гадәтләрне үтәргә ярамаган чокыр»да көн күрүче хатын сыкрана, зар елый: «Анын «өстәгеләр» белән уртаклыгы калмаган». Повестьта герой әнә шулай серле, могҗизалы чынбарлыкта сурәтләнә, төгәлрәге, кеше күзеннән читтә торган, шом тудырган гап-гади чокырга сакраль мәгънә салына. Әтисе Хәбир күрсәткән башка чынбарлык анын кызын да кешеләр җәмгыятендә хөкем сөрүче гаделсезлектән коткара, киләчәк язмышын билгели. «Чәчләре арыш саламы төсендәге кызны күтәп картайган» Вәгыйзьне дә үзгә чынбарлыкның бер вәкиле итеп күрәбез.

Н.Гыйматдинова әсәрләрендә дөньяны хис аша танып-белү, мәхәббәт ярдәмендә хакыйкатькә якынаю турындагы фикер лейтмотив булып тора. Әдәбият сөючеләр арасында әдибәнен «Бер тамчы ярату» повестен укып сокланмаган, спектакль вариантын тамаша кылмаган укучы аздыр. Динсез, имансыз халыкнын яшәеше абсурд чигендә тасвирлана. Мондый халәттә авыл гомерен — татар яшәешен саклап калу хакында гына кайгырту дөрес. Габдерәхим дип авылга кайткан, сөйгәнен күрү бәхетенә ирешкән Рабига шул хакка мәхәббәтен корбан итә, әнисенең алкаларын — әрнү катыш бәхетен — ирнең хатыны — рус кызына бүләк итеп калдыра. Шуның белән автор укучыны үз карашына инандыра: «Кәмеш Ярда тормыш уты алар мәңгелеккә күчкәч тә сүнмәскә тиеш. Димәк, авыл гомерен яшь хатынның карынындагы бала гына озайтачак».

Тормыш — уен, үлем аңа чик куя. Гомернең чиклелеге турындагы уйланулар Н.Гыйматдинованың «Тамыр» әсәрендә мәхәббәт фәлсәфәсенә бәйле тәкъдим ителә. Берсен-берсе сөйгән ярлар — тамырлары уртак парлар бу яшәештә кавыша алырмы, әмма шунысы хак: «бәндә туганнан бирле юлда. Туфрактан яралган, туфракка кайта. Ә туфрак бөтен җирдә дә туфрак! Төсе генә бүтән».

Әдибәнең күпләргә мәгълүм «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Күкчәчәк», «Парлы ялгыз» әсәрләрендә җир тормышындагы әрнү-сагышлы сөю романтик, драматик пафос белән тасвирлана. Укучы Бакир-Вәсилә, Күкчәчәк-Мирсәлим язмышлары өчен сызлана, аларның җаннары үрсәләнгәндә тыела алмый елый да.

«Тәкъдир» әсәре яшәү һәм үлем турындагы фәлсәфи уйлануларны үзәккә ала. Утыз биш яшьлек талантлы артистка «әкрен генә үлеп баручы» Нәзирәнең җан халәте ул уйнаган образ — сөйгәненең Әфганстанда үлгәнлеге хакында ишеткән Нуриянеке белән тәңгәл: «Мин исә сәхнә уртасына тезләндем дә сулыгып-сулыгып еларга тотындым. Бәгыремнән актарылган авазлар, һәр хәрәкәтемне күзәткән залны тетрәндереп, бер мәлгә сулышсыз итте. Андый мизгелләр сирәк туа, бит монда ике хатынның фаҗигасе бергә кушылган иде». Ире хыянәтен кичергән Нәзирәгә язмыш мәрхәмәтле кебек, хатын, үзен җуйган хәлдә, Саматны очрата, яшәү серен ача, ләкин «тәкъдирдә язылган роль катлаулырак» булып чыга. Нәзирә сөеклесе белән кавышканнан соң яңа, тагын да авыррак сынау кичерә. Хатынга Чечня сугышында башын салган Саматның улы нәни Саматны тәрбияләргә, тәүге мәхәббәте Илһамның таянычын тоеп яшәргә язган икән. Автор уйланулары яшәеш мәгънәсе кебек кабул ителә: «Бер уйласаң, тормыш үзе дә сәхнә, тик аерма шунда гына: син анда үзенне уйныйсын».

Н.Гыйматдинова әсәрләрендә өметләрнең өзелүен, рухи бушлыкны кичерү кешене яңа сынау — яшәүне, матурлыкны юкка чыгаручы үлемне кабул итәргә

әзерли, дигән мотив алга чыгарыла. «Ачкыч» әсәрендә әлеге фәлсәфә дәвам иттерелә. Хикәяләүче сөйләме буларак тәкъдим ителгән автор фикере мондый: «...бәндәнең күкрәге бик-бик тар итеп яратылган. Тәкъдир бизмәнендә һәркемгә үз өлеше генә үлчәп бирелә. Шуңа канәгать бул, шуңа шөкрана кыл, димәк». Авыл мулласы Йосыфның кан туганы Шакир авылдагы изге урынны ата-баба ядкаре Әүлия тавын бозып, йорт салдыра, таудагы суырлар адәм ыңгырашуы белән җылый. Озак та үтми, Шакир, җыйган барлык мөлкәтен комарлы уенда оттырып, йөрәк белән егыла, үлә.

Автор хикәяләүче теле белән фәлсәфи проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра, күз алдына «иман йортларының саны артып, бәндәдән иман югала башлаган замана» – XX гасырның 90 еллары килеп баса: «Илдәге үзгәрешләрдән явызланган нужа бабайның табиб, укытучы, галимә хатын-кызларны, дыңгычлап, сыйфатсыз чүпрәк-чапрак төялгән кул арбалары тарттырып, көтүләре белән урам базарларына куган көннәре иде. Дөньяда яңа төрдәге сәүдә туып маташа иде: монда әлегә берәүнең дә сату-алу тәҗрибәсе юк, монда һәммәсе дә тигез: алдашырга-алданырга, тәмәке тартырга, пыяла чәркәләрне чәкәштереп аракы эчәргә дә барысы бергә өйрәнәчәк, соңрак кына, иләктә иләнгәч, кемдер батачак, кемдер яначак, ә кемдер акчага коеначак иде». Илсөярнең дусты Дамирә теле белән бу хакыйкать даими кабатлана, ул кызын ялагайлану, директорга төчеләнү, ясалма елмаю, ясалма көлү, гайбәт ташу талантына өйрәтергә тырышып карый. Әмма «иҗат колы» Илсөяр ни йорты, ни гаиләсе, ни акчасы булмаган мескен булып яши. Шакир белән танышу «халыкны җырлары белән елаткан» кызны үзгәртә, ир йорт ачкычын артистка Илсөяргә васыять итә. Ләкин Илсөяр йортны инде саттым, инсафлы, тыйнак Йосыфны үземнеке иттем дигәндә, Дамирә бу изге тауны бозып, халыкны рәнҗетеп салынган йортны алудан чиркануын әйтә... Милләте, газиз халкы өчен янып-көйгән Нәбирә Гыйматдинова әхлаксызлыкны, динсезлекне каракош дип тамгалый, ак торналарның – күңелләге изгелекнең юкка чыгуына, «уңган халкының кырылганлыгына» сызлана. Минсаралар тавышы болынны кисеп үтә: «Татар – үз-үзен санламаган халык! Һәркайсы үзенчә бәхетле һәм бәхетсез дә».

Н.Гыйматдинова повестьларында тәкъдим ителгән чынбарлык сурәте кеше гомере, аның чикләнгәнлеге, язмышның алдан билгеләнгәнлеге турында уйланырга, мәхәббәтне төп кыйммәт буларак күтәрергә, милли яшәешебезне яңадан бәяләргә ярдәм итә. Әдибәнең повестьларындагы милли яшәеш концепциясен бер героеның сүзләрен бераз үзгәртеп, «милләтемнең туфрагы кипмәсен, дисәң, коеннан су ташып сип», – дип атап булыр иде.

**Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,**
*Казан федераль университеты доценты*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Жогып

Иске Жогып авылы Әтнә районында, район үзәге Олы Әтнә авылыннан 27 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Яңа Шашы авылыннан — 2, Арча тимер юл станциясеннән — 54, Казаннан 88 чакрымда урнашкан.

Авыл атамасы байтак тарихи чыганакларда очрый.

XVIII гасыр мәгълүматларын эченә алган Д.А.Корсаков белешмәсендә авыл Югуп дип күрсәтелгән. Халкы йомышлы татарлар булган, алар Югары Шашы авылыннан килеп утырганнар дип билгеләнгән. 1859 ел мәгълүматларын туплаган белешмәгә караганда, Шашы ярына утырган Шашы авылындагы 44 хуҗалыкта 136 ир-ат һәм 144 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдән күренгәнчә, Югуп авылында татарлар яшәгән. 1908 елда басылып чыккан белешмәдә авылда 521 татар кешесе көн иткәнлегe әйтелә.

Олылар сөйләвенә караганда, авыл болай оешкан.

Авылны нигезләгән беренче кешеләр Күңгәрдән, Түбән Шашыдан һәм Нократтан килгәннәр. Жогып авылы бик матур урынга урнашкан булган. Элекке вакытларда авыл су ягына гына төзелгән. Авыл инешенең суы мул булган, тирә-якта кара урман шаулап утырган. Мамыш авылы белән ике арада үтеп чыккысыз сазлык җәелеп яткан (әле дә ул тирәләрдә кечкенә баткаклыклар бар һәм торф чыга). Чәчүлек җирләрне зурайту хаҗәте тугач, урманнарны кисәннәр, сазлыкның да кырыйларын чистартып сөргәннәр. Нәтиҗәдә, урман беткән һәм сазлык та кипкән. Яр буйларында агачлар үсмәгәч, елгалар да саеккан.

Жогып атамасының барлыкка килүен авыл олылары болай аңлата.

Авыл төзелгәнче бу урында көтүлек була. Ничектер, бер көтүче юкка чыга. Бу көтүчене бай бик нык эзләткән, чөнки ул аңа хезмәт хакын алдан түләгән була. Әмма күпме эзләсәләр дә көтүчене таба алмаганнар. Соныннан халык аны таралышып эзләгән. Бер-берсе белән очрашкан саен: «Юкмы?» — дип сораганнар. Ә тегеләр «ю-уу-к ич», — дип җавап биргәннәр. Бу сүз үзгәрә-үзгәрә Жогып сүзенә әверелгән.

Болай аңлату халык этимологиясе генә, әлбәттә.

1934 елны авылның кайбер кешеләре читкәрәк күчеп, Яңа Жогып авылын нигезлиләр. Хәзерге вакытта Яңа Жогып беткән, аның зират урыны гына билгеле. Шул елдан соң төп авыл Иске Жогып дип йөртелә башлый.

Авыл матур урынга урнашкан. Аның ике ягыннан Акташ һәм Таллык исемле инешләр ага. Акташ елгасы башланган урын бик ямьле. Ул ап-ак ташлар арасыннан тибеп чыккан чишмәдән башлана. Исеме дә шуңа нисбәттән барлыкка килгән. Ул урында табигый һәйкәлләр — мәгарәләр, куышлыклар бар. Ә Таллык елгасы кырыенда бик күп таллар үсә. Авылның тагын бер гүзәл җире — Кара күл. Ул бик

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

сай, ләкин суы беркайчан да кипми. Кара күлдән көнбатышкарак киткәч, үтеп булмаслык сазлыклар башлана.

Акташ белән Таллык кушылган урында бик матур бер урын Яшелчә дип йөртелә. Элек монда яшелчә үстергәннәр, исеме дә шуннан калган. Хәзер анда яшелчә үсми, бары яшеллек кенә калган.

## Кибәч

Кибәч авылы Питрәч районында, район үзәге Питрәч авылыннан 54 чакрым ераклыкта, Казаннан 66 чакрымда урнашкан.

Кибәч атамасы тарихи белешмәләрдә шактый искә алына.

XVIII гасыр мәгълүматларын үз эченә туплаган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Кибәче авылында 122 керәшен татары көн иткән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдә билгеләнгәнчә, Кибәч авылында керәшен татарлары көн күргән.

Авыл оешуы турында мәгълүмат аз. Авыл урнашасы урында элек урман үскән, урман эченнән елга аккан. Заманасында бер кеше шушы суга һәм урманга якын җиргә килеп утырган. Тора-бара монда башка кешеләр дә килеп урнаша башлаган.

Авылга ни өчен Кибәч дигән исем куйганнар?

Олылар бу турыда болай сөйли. Авылның Түбән очында сазлык булган һәм ул бик озак вакытлар бер дә кипмәгән. Ә бервакыт кешеләр аның кимегәннән-кими баруын сизә. Бу күл янына килгәч "кибә ич", "кибә ич" дия торган булганнар. Шуннан соң авылга Кибәч исеме кушылган, сазлык та кибеп беткән. Билгеле, бу халык этимологиясенә нигезләнгән фараз гына.

Авылның урта бер җирендә тирән елга бар. Аны Бала елгасы дип йөртәләр. Кайчандыр, бик көчле язгы ташу вакытында көчле агым бер баланы агызып алып китә, аны беркем дә коткарып кала алмый. Хәзер бу елга тагын да тирәнәйгән. Авыл кырыенда тагын: Захар елгасы, Аю елгасы, Кызлау елгасы, Әтрәч елгалары ага. Захар елгасында кайчандыр Захар исемле кеше баткан һәм елганы аның исеме белән атаганнар.

Авылның тирә-ягында калын урманнар. Аларны халык түбәндәгечә атап йөртә: Сәрдә урманы, Әби урманы, Кәҗүнни урманы, Нарат урманы, Кормаш урманы. Әби урманы атамасын җирле халык болай аңлата. Урманга әби алпавыт хуҗа булган. Ул усал карчык булып, һәрдаим атка атланып йөргән, бер генә кешене дә урманга рөхсәтсез кертмәгән.

Авылдан бер чакрымнар ераклыкта керәшен зираты бар. Зиратның тирә-ягы тотып алынган. Елга ике тапкыр (яз һәм көз көннәрендә) халык зиратка бара. Зиратка барыр алдыннан һәр кеше мичкә яга, төрле тәмле әйберләр пешерә. Шул ризыкның бер өлешен табакка тутырып, махсус ашъяулыкка төреп зиратка алып баралар, һәр кеше үз туганын аның кабере янында ризык чәчеп-түгеп искә ала. Баштарак барып кабер өсләрен чистарталар, себерәләр. Зиратка барыр алдыннан мунча ягып үзләрен чисталыйлар, чөнки зиратка ак һәм пакь килеш бару зарур.

## Киекле

Киекле авылы Нурлат районында, район үзәге Нурлат шәһәреннән 16 чакрымда, Чистайдан 102 чакрым ераклыкта урнашкан.

Киекле атамасы байтак тарихи белешмәләрдә искә алына.

XVIII гасыр мәгълүматлары теркәлгән тарихи белешмәдә күрсәтелгәнчә, Бормәт авылында (Киекле авылы икенче төрле Бормәт дип тә йөртелә) 176 ясаклы татар яшәгән. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә билгеләнгәнчә, Олы Чирмешән суы ярына утырган Бормәт (Киекле) авылындагы 198 хуҗалыкта 591 ир-ат һәм 593 хатын-кыз көн күргән, мәчет эшләгән. 1898 елда басылып чыккан тарихи белешмәдән Бормәт (Киекле) авылында 2577 татар кешесе көн иткәнлеге күренә.

Олылар авыл оешуны болай сөйли.

Элек бу урыннарда беркем яшәмәгән һәм монда кара урман үскән. Казанның аргы ягындагы Тау иле авылыннан Бормәт, Корман һәм Богдан исемле өч кеше бу урынга килеп, урнашырга урын карый башлыйлар. Богдан чуаш була, ул таудан соң бераз баргач, тигез урынны сайлап йорт төзи, авыл нигезли. Бу авыл исеме

Богдан бабай хөрмәтенә Богдашкино дип йөртелә. Бормәт бабай таудан бераз баргач елга буенда тигез урынны ошата һәм Бурмәт авылына нигез сала. Корман бабай Корманай авылын оештыра.

Хәзер авыл Киекле дип йөртелә. Бормәт исеме урысча вариантта Бурметьево рәвешендә кулланыла.

Ни өчен Киекле?

Олылар әйтүенә караганда, бу тирәләрдәге урманнарда төрле-төрле киекләр күп яшәгән, шуна нисбәтле рәвештә авыл Киекле дип йөртелә башлаган.

Авылдан якын гына Зур Чирмешән елгасы агып үтә. Анда элек 6 ташны әйләндерә торган зур су тегермәне эшләгән. Аннан соң ул 4 ташка, бераз вакыттан соң 2 ташка калган, ә соныннан бөтенләй беткән. Олы Чирмешәнгә Киекле елгасы, Камышлы суы, Түбетә елгасы, Чаллы елгасы, Тархан елгасы, Тарлау елгасы, Төп алан елгасы, Көймә борыны елгалары коя.

## Урман Асты Шонталысы

Бу авыл Алексеевск районында, район үзәгеннән 33 чакрым ераклыкта, Шонталы суы буена урнашкан. Урман асты Шонталысы авылы — җирле үзидарә советы үзәге. Анын карамагына тагын Арбузов-Баран авылы керә.

Урман асты Шонталысы Д.А.Корсаков җыентыгында (XVIII гасыр) Пүчинкә, Иске Шонтала дип бирелә һәм анда 114 керәшен, 12 ясаклы татар яшәгәнлеге күрсәтелә. Авылнын Шонталы суы буенда булуы әйтелә. А.Артемьев китабында авылнын Иске Шонтала пүчинкәсе (Урман асты Шонталысы) дип йөртелүе һәм андагы 64 хуҗалыкта 262 ир-ат һәм 274 хатын-кыз көн итүе турында мәгълүмат бирелә. Авылда бер мәчет эшләгән. 1898 елгы китапта Урман асты Шонталысында ислам дине тотучы татарлар белән бергә керәшеннәр һәм мордвалар яши дип күрсәтелә.

Авылда төп халык — ислам нәселе, шулай ук исламга чыккан мукшы һәм чуаш нәселләре дә бар. Мордвалар авылда әле дә яши, ләкин саннары күп түгел.

Риваятьләргә караганда, авылнын беренче утырган урыны хәзергесеннән елга буйлап көнбатыштарак булган. Анда, хәзер Кызылъяр дигән урында чүлмәк ватыклары, кеше, хайван сөякләре чыккалап тора. Авылнын элекке исеме Иске йорт булган. Халык ни сәбәптәндер елга буйлап 2 чакрым чамасы өскәрәк күтәрелеп урман эченә урнаша. Кешеләр яшәү өчен бик уңайлы урын сайлаган: авыл Шонталы елгасынын ике ягына урнашкан. Эчәргә суны чишмәләрдән алганнар. Шул чишмәләрнең берсе — Билал чишмәсе янында зур гына карт тал үскән. Ул талнын эче куыш булган. Бу тал аяз, җилсез көннәрдә дә шаулап, шом өстәп торган. Мондый талнын барлыгын бүтән авылларда да белгәннәр һәм авылны Урман астындагы шомлы таллы авыл дип йөрткәннәр. Шулай итеп, авылга Урман асты шомлы таллыгы дигән исем бирелә. Ә вакытлар үтү белән Урман асты сүзе сакланып кала, ә шомлы таллыгы дигән сүзләрдә «м» урынына «н» кулланыла башлый, таллы сүзеннән бер «л» төшеп кала. Хәзер авыл Урман асты Шонталысы исемен йөртә. Атаманын килеп чыгышын болай аңлату халык этимологиясенә нигезләнеп фикер йөртүнең бер мисалы гына. Киләчәктә, авыл тарихы турында тарихи мәгълүматлар шактый күп тупланыр һәм фәнни нигезгә корылган мәгънәсе ачылыр дигән өметтә калабыз.

Авылнын тирә-юне матур, табигате бай. Урманы, елга-күлләре, чишмә-кизләүләре бар. Мәктәптә тарих музее ачылган. Анда авыл тарихына нисбәтле шактый материаллар һәм мәгълүматлар урнаштырылган.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Һ

**НИЯЗБАЕВ** Габделрәүф Хәким улы (3.12.1881, Оренбург губернасы, Каргалы бистәсе — 1920), драматург. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1906 елда «Шимбәчеләр» әдәбият, театр һәм музыкаль сәнгать сөючеләр түгәрәге әгъзасы була, татар театрының беренче спектакльләрендә катнаша. Соныннан Урта Азия якларында укытучылык итә. 1919 елдан соң мәгариф оешмаларында, Башкортстан АССРның Мәгариф комиссариаты инспекторы булып эшли. Н.ның «Беренче таң» (1918), «Бөрадәрән Галимовлар» (1918) пьесалары «Сәйяр» труппасы тарафыннан Казанда куела. «Кызыл истикъбаль өчен көрәш», «Гөлбостан», «Кара көннәр» һ.б. пьесалар авторы.

Әдәб.: Гобәйдуллин Х. Габделрәүф Ниязбаев // Казан утлары. 1967. №4.

*А.М.Ахунов.*

**НОВЕЛЛА** (итал. novella — яналык), эпик жанр, «яналылык», үткен, парадоксаль сюжет, композицион төгәллек б-н аерылып торган хикәянең бер төре. Италиядә Янарыш чорында барлыкка килә, соныннан 19 йөздә Англия, Франция, Испаниядә «яңадан» туа. Аның чәчәк атуы романтизм чорына туры килә (П.Мериме, Э.По, Ги де Мопассан, О'Генри). Рус әдәбиятында Н. А.П.Чехов, Л.Н.Андреев, И.А.Бунин, В.В.Набоков, И.Э.Бабель, М.М.Зощенко, Ю.М.Нагибин, А.Г.Битов һ.б. исеме б-н бәйле. Шәрык һәм татар әдәбиятларында Н. сюжетның парадоксальлеге һәм тасвирлау үзенчәлеге б-н тартмалы композициягә корылган кыйсса һәм хикәяткә якын тора (Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләре һ.б.). 20 йөз татар әдәбиятында Н.га еш кына психологик («Уяну», «Буранда», «Сулган гөл») һәм сатирик («Депутат», «Сәмруг кош», «Холера вакытында») Хикәяләр авторы Ш.Камал мөрәҗәгать итә. 20 йөзнең 1 нче яртысында бу жанрда Ш.Мөхәммәдов («Аз гына хата булган», «Судта»), Ф.Әмирхан («Хәзрәт үгетләргә килде», «Сәмигулла абзый»), Г.Гобәйдуллиннар («Вәсвәсә», «Исерек», «Шомлы көн», «Хәзрәт икегә бүлә») язган. Бүгенге татар әдәбиятында Н. киң таралыш тапмый, ләкин аерым чалымнары Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин, Г.Сабитов, М.Юныс, Ф.Шәфигуллин, Р.Харрасова хикәяләренә хас.

Әд.: Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Ганиева Р.К. Татарская литература: Традиции, взаимосвязи. К., 2002; Хатипов Ф.Х. Әдәбият теориясе. К., 2000.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**НОГМАН** (Ногманов) Мостафа Ногман улы (22.12.1912, Казан губ. Царёвокошай өязе (хәзерге Арча р-ны) Кызыл Яр ав. — 4.9.1976, Казан), шагыйрь, тел белгече, филол. фәннәре канд. (1964). Көнчыгышны өйрәнү ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1951). 1931 елдан башта Татарстан авыллары мәктәпләрендә, сонрак Таҗикстанда балалар укыта. 1935-37 дә Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда сәркатип вазифаларын башкара. 1937-41 дә Дүшәмбе пед. ин-тында укый. 1945-47 дә «Пионерская правда» г-тасының Татарстандагы үзхәбәрчесе булып эшли. 1953-57 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1957-59 да Казан ун-тының фәнни китапханәсендә шәрекъ кульъязмаларын өйрәнү бүлеге мөдире. 1960 тан Казан ун-тында фарсы һәм иске татар телләре укытучысы. «Давыллы еллар лирикасы» дигән беренче җыентыгы 1941 елда басыла. «Апрель җилләре» (1954; русчага тәрҗемәдә «Грозовое лето», М., 1963, 3 басма 1977), «Кокушкино таңнары» (1964) җыентыклары В.И.Ленинның Казан чоры эшчәнлегенә багышланган. «Таң йолдызы» (1959), «Каеннар шаулый» (1967), «Иртәнге җырлар» (1973), «Акчарлаклар оча Иделдә» (1982) җыентыклары укучыларга яхшы билгеле. Н.ның шигырьләре нечкә лиризмы, моңлы булулары белән аерылып тора. Композиторлар Р.Яхин («Онытальмыйм», «Бөдрә таллар»), С.Садыйкова («Актаныш таңнары», «Арча кичләре»), шулай ук А.Ключарев, М.Мозафаров,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтовлар белән берлектә иҗат иткән җыр һәм романслары бүген дә популяр әсәрләр рәтендә. Н. шулай ук Н.Хикмәт, Рудакый, Г.Хәйям, А.Кадыйри әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 17-18 гасырлардагы кульъязма рус-татар сүзлекләрен өйрәнә. Югары уку йортлары өчен фарсы, иске татар телләре буенча уку-укыту әсбаплары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Сөнгатев М. Яшьлек хыялларын җилкән итеп // Казан утлары. 1982. №12.

*Г.М.Габделхакова.*

**НУРИ** (Нуретдинов) Зәки Шәрәфетдин улы (24.12.1921, Буа кантоны Татар Төкесе ав. – 28.2.1994, Казан), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). Мәскәүдә А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары Әдәби курсларны тәмамлый (1957). Бөек Ватан сугышында катнаша, мәшһүр К.Заслонов җитәкчелек иткән белорус партизаннары берләшмәсендә башта дошман объектларын шартлатучы, соңыннан разведка отряды башлыгы булып хезмәт итә. 1944-46 да Орша шәһәр советы башкарма к-ты рәисе урынбасары. 1946-49 елларда Татарстан урман хуҗалыгында эшли. 1949-51 дә «Яшь сталинчы» г-тасында мөхәррир урынбасары, 1951-55 тә Татарстан китап нәшриятында балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе мөдире. 1957-63 тә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе җаваплы сәркатибе, 1971-74 тә аның рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе президиумы әгъзасы (1970-75). 1964-71, 1974-82 елларда «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире. Н.ның беренче шигырьләре республика газета-журналларында, сугышка каләр нәшер ителгән кумәк җыентыкларда басылып чыга. Беренче җыентыгы («Шигырьләр») 1945 тә дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең нык ихтыярлы, батыр булуларын сурәтләгән «Дан юлы» (1949), «Чын көнелдән сөйләшү» (1955), «Күтәрелү» (1956) поэмалары, «Без яшибез Иделдә» (1951; русчага тәрҗемәдә «Мы живём на Волге», 1956) җыентыклары авторы. Н.ның сугыштан соңгы иҗаты гражданлык пафосы белән сугарылган, публицистик янгыраешка ия. Халыклар дуслыгы, интернационализм кебек сыйфатлар «Ел буе яз» (1958), рус теленә тәрҗемәдә басылган «Есть цветы у нас» (1969), «Еллар һәм юллар» (1971), русчага тәрҗемәдә «Навстречу дружбе» (М., 1976), «Килә дә китә яз» (1978), «Күнел яктысы» (1980), русчага тәрҗемәдә «Озарённость»(М., 1981) җыентыкларында төп темалардан санала. Юмор һәм сатира әсәрләре, шулай ук балалар өчен язылган шигырьләрендә фольклор мотивларына зур өстенлек бирелгән: «Лирика, юмор, сатира» (1963), «Елмаябыз, көләбез» (1966), «Бу безнең китап» (1967). Н. шулай ук Бөек Ватан сугышы елларында Белоруссиядәге партизаннар хәрәкәте турында «Үлгәннәр дә үч алды» (1962; рус теленә тәрҗемәсе «И мёртвые мстили», 1976) исемле хикәяләр җыентыгы, Түбән Кама шәһ. төзүчеләре хезмәтенә багышланган «Батырлар һәм матурлар» (1965) исемле очерклар җыентыгы авторы да. Төрле халыкларның фольклор әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп «Күңелле китап» (1969, 2 басма 1979) һәм «Алтын хәзинә» (1973) исемле китаплар бастырып чыгара; А.Твардовский, Н.Некрасов, С.Щипачёв, Мәхтумколый, Я.Колас, Я.Купала әсәрләрен тәрҗемә итә. Аның китаплары рус, казакъ, әзәрб., белорус, мари, якут телләренә тәрҗемә ителгән. 1961-68, 1974-78 дә ТАССР ЮС депутаты. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Халыклар Дуслыгы, «Почет Билгесе» орденнары, медальләр белән бүләкләнгән. Орша шәһ. Почетлы гражданины.

Әд.: Хисамов Н. Заман һәм шагыйрь // Казан утлары. 1975. №2; Мөхәммәдиев Р. Иманлектән башланган юл // Якутлар табыладыр вакыт белән. К., 1983.

*Г.М.Габделхакова.*

**НУРМӨХӘММӘТОВ** Таһир Мирзагаллән улы (14.4.1930, Казахстан ССР Семипалатинск ш. – 25.9.1999, Казан), тәрҗемәче, ТАССР, РФ атказанган мәдәният хезмәткәре (1980, 1992). 1953 елда Казан. пед. ин-тын тәмамлаганнан соң Татарстан китап нәшриятында эшли, 1990 елдан «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә. Рус теленнән татар теленә А.Н.Рыбаковның «Кортик» («Хәнҗәр», 1961), «Бронзовая птица» («Бакыр кош», 1961) повестьларын, Р.Гүнтәкиннең «Чалы кошы» (1970) романын, Р.И.Фраерманның «Дикая собака Динго, или Повесть о первой любви» («Кыргый эт Динго, яки Беренче мәхәббәт турында хикәя», 1973) повестен, Г.Н.Троепольскийның «Белый Бим Чёрное ухо» («Акбай Караколак», 1975) повестен, В.П.Астафьевның «Последний поклон» («Бәхилләшү», 1980), «Кража» («Талау», 1983), «Звездопад» («Сүнмәс йолдызлар», 1983) повестьларын, «Царь-рыба» («Патша-балык», 1986) романын, Г.Н.Паустовский, А.И.Куприн, С.Жамал, Э.Сетон-Томпсон повесть һәм хикәяләрен тәрҗемә итә.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**НУРУЛЛИН** Вакыйф Нурулла улы (1.5.1935, Балык Бистәсе р-ны Югары Әшнәк ав. туа), язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972, 1985). Казан ун-тын тәмамлагач (1962) «Казан утлары» ж-лы редакциясендә эшли. 1977-88 дә Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире. 1992 дән ТР Милли музеенда әдәбият бүлеге мөдире. «Шинельсез солдатлар» (1968) исемле беренче повесте балачаклары авыр сугыш елларына туры килгән авыл малайлары турында. Сугыш чоры һәм аннан соңгы еллардагы татар авылларын сурәтләү Н.ның алдагы әсәрләренең дә төп темасына әйләнә: «Күпер чыкканда» (1971; Казан телестудиясендә шул исемдәге телеспектакль, 1974), «Әгәр син булмасаң...» (1975; русчага тәрҗемәсе «Если бы не ты...», М., 1979), «Аккан су юлын табар» (1979), «Һәлакәт» (1983; русчасы «Расплата», 1984) «Ике урам арасы» (1985), «Сагынырсыз әле...» (1989) повестьлары, «Яшьнәп үткән яшьлек» (1977; русчага тәрҗемәдә «Грозовая молодость», 1980; Казан телестудиясендә шул исемдәге телеспектакль,1977) док. повесте. Татар теленә Ф.Булатовның «Записки генерала» («Генерал язмалары», 1963) истәлекләрен, Р.Мостафинның «По следам оборванной песни» («Өзелгән җыр эзеннән», 1982) китабын тәрҗемә итә. Аның әсәрләре таҗик, әзәрб., казакъ, төркмән, чуаш телләренә тәрҗемә ителгән.

Әс.: Повести. М., 1982; Бабье лето: Повести. М., 1989; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1991; Җавап бир, кеше! Повестьлар. К., 2001; Әсәр син булмасаң: Повестьлар. К., 2005.

Әд.: Мөхәммәдиев Р. Тормышның үз моңын тоеп // Якутлар табыладыр вакыт белән. К., 1983; Миннуллин Ф. Ягымлы геройлар // Затлылык. К., 1989; Галимуллин Ф. Җавап бирер чак // Казан утлары. 1994.№4; Вәлив М. Чынлыкка омтылу // Гамәл дәфтәре. К., 2003.

*Г.М.Габделхакова.*

**НУРУЛЛИН** Ибраһим Зиннәт улы (18.4.1923, Самара губернасы Мәләкәс өязе Парау а. – 1.7.1995, Казан), әдәбият галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1968), проф. (1970). 1943-45 елларда туган авылы мәктәбендә укыта. Казан ун-тын тәмамлый (1950), ш.у. укыта (1953-90). Хезмәтләре 20 йөз башы һәм совет чоры татар әдәбиятына, иҗади методлар теориясенә, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Ш.Камал, И.Гази, М.Әмир, С.Кудаш, Ә.Еники, Г.Ахунов, Н.Фәттах һ.б. иҗатларына карый. Язучының иҗади процессын һәм шәхесен өйрәнү Н.ның әдәби әсәрләренең дә төп темасы булып тора. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләренә аның «Тукай Петербургта» (1965), «Аның йолдызы» (1973) пьесалары; «Габдулла Тукай» (1979, рус теленә тәрҗемәдә «Тукай», М., 1977; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1982), «Фатих Әмирхан» (1988, рус. теленә тәрҗемәдә «Прометей из Ново-Татарской слободы», 1991) исемле әдәби-биографик китаплары багышланган. Н. – урта мәктәп һәм вузлар өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗәле Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әс.: Тукай эстетикасы. К., 1956; XX йөз башы татар әдәбияты. К., 1966; Реализм турында. К., 1974; Әдәбият теориясе. К., 1977; Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. К., 1983; Путь к зрелости. К., 1971.

Әд.: Нуруллина Р.М. Ибрагим Зиннатович Нуруллин. 1923-1995. К., 2000; Ибраһим Нуруллин: Истәлекләр. К., 2008.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# КИҢЛЕК ДӘРТЕ

## МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ МУЗЕЕ ОЕШУГА 20 ЕЛ

«Офыкларын киңәйтү дәрте кайнап тормаган тормышның мәгънәсе юк. Тирәлекнең бөтен тулылыгын тою, чиксезлеге, киңлеге белән ләззәтләнә алу мөмкинлеге генә кешене чын мәгънәсендә шәхес итә. Бербөтен горизонт йомшак кына безнең белән бер уңайга тирбәлә башлый... Сулышлар кушыла. Дөнья киңәя...».

Танылган испан сәнгать белгече Луис-Ортега-и-Гассет тарафыннан әйтелгән әлеге сүзләр безнең күңелләребезне 90нчы еллар башында, милли тарлыктан һәм басынкылыктан рухи иреккә омтылган чорларда, һәм моның чагылышы буларак, бөтен тарихи һәм мәдәни мирасыбызны бер җиргә туплый алырлык татар милләте музеен булдыру эшенә керешкәндә биләп алды. «Бөтенлек һәм тулылык» дигәндә вакыйгаларның бер-бер артлы агышы яисә кыйммәтле мирас кыйпыкларының санаулы җыелмасы түгел, ә бәлки сакланган һәм бүген кайтарып алырлык иң гүзәл кыйммәтләр тулы, дөньякүләм музейлар рәтендә торырлык, Лувр, Эрмитаж, Акропольләрне хәтерләткән милли хәзинә образы күзалланды. Без аны үзара «милли әһрам» дип атадык. Әһрам сүзе гарәп теленнән «изге урын», зиннәтле мохит, рухи мәгънәсе буенча музейга якын «иң кадерле урын» төшенчәсе буларак тәрҗемә ителә.

Безнең алдыбызга элеккеге Ленин мемориалын катлаулы һәм мавыктыргыч үзгәртү процессында, аның җайга салынган заллары структурасын, ансамбльлеген саклаган хәлдә, җимерми, ватмый, «идеологик монстр»дан нәзакәтле мәдәният әһрамын тудыру мәсьәләсе килеп басты. ТР Министрлар кабинетының 1992 ел 16 сентябрь карары шушы бурычны хәл итүгә юнәлтелгән иде. Фәнни-теоретик якны галимнәр — тарихчылар, этнологлар, археологлар, сәнгать белгечләре тарафыннан эшләнгән концепцияләр тәэмин итәргә тиеш иде. Гомум максат — музей ысуллары белән татар цивилизациясенең моделен тудыру. Дөнья фәне практикасында «цивилизация» сүзе иң әүвәл нигезендә тел, югары үсешкә ирешкән мәдәният, билгеле бер дин формасы, дәүләтчелек тибы, технологик үсеш һәм байлык туплау кимәле яткан алдынгы һәм язма шәһәр мәдәниятенә карата кулланыла. Менә бу шактый четерекле фәнни-тикшеренү мәсьәләсен, гуманитар мәсьәләне безгә тарихи-мәдәни, сәнгати музейга хас күпкырлы, күп профильле жанр аша хәл итәргә кирәк иде.

Музейның үсеше Милли мәдәният үзәге кысаларында барды һәм баштарак шәһәрнең төрле музейларыннан килгән белгечләр арасында мөстәкыйль музей тарафдарлары күп иде. Тора-бара музейның киңрәк мәдәният орбитасында булуының өстенлекләрен аңлау килде. Гасырлар дәвамында өзек-төтек барган җыю нәтиҗәсендә түгел, ә бәлки билгеле бер карашлар системасын туплаган самими, туып килүче милли музей өчен бу урын уңышлы сакланып калу чарасы иде. «Казан» милли мәдәният үзәгенең эш төрләре динамикасы музейны да гел хәрәкәттә тотты — аның төзелә башлаган экспозицияләре беркайчан буш тормады. Музей залларының әле берсендә, әле икенчесендә колачлы күргәзмәләр оештырылды: «Сәнгать җәүһәрләре»(1992), «Буыннар хәтере»(1994), «Болгар ватаныбыз тарих дулкынында» (1996), «Татар дөньясы» (1997), «Ислам сәнгате» (1998), алар музей эшенә, аның җыелмасы чарлануга зур этәргеч бирделәр. Болар арасында тюрколог һәм сугыш кораллары белгече М.Горелик эшләреннән оештырылган «Евразия яугирләре» күргәзмәсе зур роль уйнады. Күргәзмә монарчы озак еллар өстенлек иткән, татарлар фәкать китаплы, сәүдә итүче, барлык газапларга да түзем халык буларак кына танылганнар

дигән карашны жимереп, тамашачыны XII —XV гасырлар татар яугирләре белән таныштырды. Мәдәният үзәгенен Күргәзмәләр залында исә бертуктаусыз хәзерге татар нәкыше осталары И. Зарипов, Ә. Фәтхетдинов, М. Шәйдуллин, И. Рафиков, Ф. Халиков һәм башкаларнын ижади күргәзмәләре барды. XX гасыр сәнгатен барларга, анын киләчәген араларга юл ачылды. Әнә шулай Милли мәдәният үзәге кысаларында, гадәттән тыш энергетика һәм мәнфәгатьләр кисешкән урында, шаулап узган ижтимагый-сәяси һәм халыкара акцияләр, презентацияләр, күргәзмәләр, фольклор бәйрәмнәре һәм фестивальләре пәрдәсе астында, киләчәк Әһрамны формалаштыру буенча күзгә күренми торган четерекле эш барды. Музейнын төп үзенчәлеге — илебезнен төрле төбәкләрендә һәм дөньянын барлык континентларында яшәүче татар халкынын дәүләтчелеге һәм мәдәнияте тарихы музее булачагы ассызыкланды.



*Казан капкасы Дәрвазә.*

Шуны да онытмаска кирәк: ул вакытта дөнья жәмәгатьчелеге өчен музейлар бер-ике гасыр эчендә жыелган тарихи әйберләр яки үткән буыннарнын кыйммәтле хәзинәсен саклау урыны яисә буйсындырылган халыкларнын трофейлары жыелмасы булудан күптән туктаган иде. Бүгенге заман музее — иксез-чиксез мәгълүмат туплау урыны, «идеяләрнен югары органик агымын» (Платон һәм Гегель) тәэмин итүче гадәтләр, идеаллар дингезе ул. Алар артында халыкнын рухы, гүзәллек хакындагы төшенчәләре, «дөнья кору», «яши белү» сәләте һәм, гомумән, буыннан-буынга тапшырыла торган мөкатдәс традицияләр ята. Бу чорда цивилизацияләрне көлдән күтәрүгә юнәлтелгән музей-реконструкцияләр барлыкка килеп (Гомер Троясы, Төркия; Аттила Империясе, Венгрия; Борынгы Вавилон, Гыйрак), экспозицияләрне төзүдә «тоташ бербөтенлеккә», бердәм образлылыкка омтылу алга чыкты. Бу фактлар «Татар халкы һәм анын мәдәнияте» экспозициясен төзегәндә дә яна мөмкинлекләр, ижади борылышлар, нииндидер кинлек, ирек атмосферасы барлыкка килүгә сәбәп булды.

Әйтик, Россия һәм Татарстан музейларынын күпчелегендә төбәкчел принцип кулланыла. Милли тарих һәм сәнгать истәлекләре теге яки бу төбәкнен шактый кин тасвирламасына иллюстратив материал буларак кына бирелә. Бу төбәктә яшәүче борынгы, мәдәниятле этноснын бөек хәзинәсе, тарихи мирасы инкарь ителә. «Тоталитар заман музейларына капма-каршы буларак, бүгенге суверен дәүләтләрдә этносларнын рухи-матди үсешенен барлык чорларын һәм феноменнарын, халыкнын ижат даһилыгы чагылышларын, анын мәдәниятенен искиткеч күп төрлелеген игътибар үзәгендә тотучы кин мәгънәдә «мәдәният антропологиясе» музейлары барлыкка килергә тиеш»,— дип язды сәясәтче галимнәр (Р.Әмирханов.«Татар ижтимагый фикере үсеш»). Шуна күрә безнен «музеум» да, ягъни «музалар әһрамы» да, антик заманнардагы кебек, бер үк түбә астында Татарстанда һәм диаспорада яшәүче татарлар мәдәниятенен барлык төрләре — музыка һәм театр, тарих һәм әдәбият, корымчылык һәм сынчылык, нәкыш, сәнгать үрнәкләре тупланган «күнел йортына» әйләнергә тиеш.

Шул ук вакытта музей төзелешенә янача караш халык турындагы барлык мәгълүматны тәкъдим итү, анын кабатланмас казанышларын күрсәтү белән берррәттән, татар мәдәниятенен кыйммәтләрен түбәнәйтеп күрсәтүче иске һәм атеистик концепцияләрдән арыну, әлеге мәдәниятнен барлыкка килүен һәм анын төзелешен хасил итүче борынгы төрки нигезен торгызудан, мөселмани, шәркый тамырларын ачыклаудан гыйбарәт.

Шулай итеп, татар халкынын дәүләтчелеге һәм мәдәнияте формалашунын төп

чорлары түбәндәге бүлекләрдә чагылыш тапты: «Татар этносының борынгы һәм урта гасырлар мәдәнияте», «Бердәм татар этносы формалашу һәм милли мәдәният оешу » (XVI гасыр-XVIII гасыр ахыры), «XX гасырда татар халкы һәм аның культурасы». Концепциягә милли мәдәниятнең бербөтенлеге һәм күптөрлелеге, аның күп тамырлы башлангычы һәм экстерриториаль асылы, төрки-мөселман цивилизациясенең аерылгысыз өлеше булуы (X — XVI гасырлар) һәм яңа дәвердә гомумкешелек рухи мирасына, дөнья мәдәнияте контекстына юнәлтелүе идеясе керде («Тат-арт» күргәзмәләре).

Вакыт һәм тарих образын торгызу мәсьәләсе вакыйганы катламнар яссылыгында күзаллау, тирән тарихи фикерләү нәтиҗәсендә гасырларның үзгәрүчән чагылышлы төпкеленә үтеп керү, чын ядкәрләрне, борынгы риваятьләрне дивар бизәмнәре, рельефлар, витражлар аша күрсәтү, табышлар һәм төсләр полифониясе махсус электрон технологияләргә таянып хәл ителәчәк.



*Музейның бер күренеше.*

Заман һәм яңа фикерләр йогынтысында гасырларның рухи янгырашын, гүзәллеген бирергә тырышып, без сәясиләштерелгән дәүләтчелек һәм халыкның этник-сәяси тарихы музее идеясеннән акрынлап милли хәзинә һәм Казанның меңьеллыгы музее идеясе ягына күчә башладык.

Эш башланды! Ләкин?!. Халкыбызның драматик тарихы нәтиҗәсендә күпсанлы мирасыбыз: язма чыганаклар һәм мәдәният ядкәрләре җуелган. Алар Балтыйк буеннан Кытайгача сузылган күченү юлларында халыкның үзе белән бергә таркалган, ят коллекцияләргә, башка музейларга килеп кергән. Заманында төбәкләр һәм республикалар хакимиятләре, музей оешмалары тарафыннан күтәрелгән реституция — рухи-матди җәүһәрләрне ватаннарына кайтару мәсьәләсе Россия хөкүмәтендә яклау тапмады һәм «Музейларның презумпциясе» (коллекцияләрнең бүленмәве һәм кагылгысызлыгы) законы белән хәл ителде.

Нәтиҗәдә, үзгәртеп корылучы музейның тупланмаларын булдыру мәсьәләсе көн кадагына куелды. Ул җыю-туплау эшчәнлегенең көчәюенә, теле-радио һәм музей марафоннары уздыру, бабаларыбыз яшәгән борынгы җирләргә, Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда шәһәрлекләренә, Россиядә татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә бертуктаусыз экспедицияләр оештыру, «татар әйберләрен» эзләп, Россиянең иң эре музейларында һәм архивларында тикшеренү эшләрен җәелдерү кебек чараларга этәрде. Күп кенә кадерле җәүһәрләр Эрмитаж, Рус музее, Кремльнең Кораллар палатасы фондларында сакланган булып чыкты. Бу очракта нишләргә? Җәүһәрләрнең фоторәсемнәре белән чикләнергәме, әллә яңадан торгызып, «коеп» куяргамы? Мәсәлән, Мономах бүреген һәм «Казан тажы»н?! Күп кенә низаглар, аңлашмаучылыкларга тап булсак та, төп нөсхәләрне (оригиналларны) туплау үзәк мәсьәлә булып кала барганда, андый зур символларның реконструкцияләрен — шәп сыйфатлы кабатланмаларын эшләү юлы хупланды. Эрмитаж, Кораллар палатасы, Дәүләт тарих музее кебек атаклы музейлар белән уртак эшчәнлек алып бару, фәнни-тикшеренү мәнфәгатьләре, фәнни фаразлар — болар барысы да татар халкының «Казан тажы», «Тәхет» кебек раритетларын

өйрәнү һәм аларның нөсхәләрен эшләү. Казанның тарихи топографиясен, карталарын ясау өчен нигез булды.

Музей үсешендәге икенче юнәлеш —тарихи ядкәрләрне туплау юнәлеше үз нәтиҗәләрен бирде. Кыска гына вакыт эчендә музейда татар тарихын, халыкның тарихи үсеш юлындагы сәүдә-икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрен чагылдырган шактый уникаль экспонатлар җыелды. Менә аларның кайберләре: Кама аръягының көнчыгышында, Агыйдел елгасы буенда табылган VIII—IX гасырлар соңгы сасанилар чоры көмеше хәзинәсе («Чулман хәзинәсе»), дөньякүләм әһәмияткә ия «Каратун хәзинәсе» (Туктамыш хан чорында Алтын Урданың сигез шәһәрендә сугылган акчалар), Г.В.Токминның металлдан, сөяктән h.б. эшләнгән, менләп данә исәпләнгән коллекциясеннән сугыш кирәк-яраклары, кораллар, Идел Болгарстаны көнкүреше предметлары, шул исәптән XVI гасыр көбәсе һәм XVII гасырга караган ике шишәк, шулай ук XIX —XX гасырлар татар этнографиясе һәм гамәли сәнгате материаллары, кульязма һәм басма китаплар. Төркиләрнен килеп чыгышын мифлаштырган мәгълүм «Маклашеевка җайдак бикәче», сорау билгесе рәвешендәге болгар алтын алкалары, кеше рәвешендәге борынгы гаҗәп гүзәл металл миниатюр сын, чит ил авторларының XVIII —XIX гасырлар басма гравюралар коллекциясе, шулай ук XX гасыр башына караган кабатланмас Казан графикасы (Ф. Таһиров, К. Чеботарев h. б.). Соңрак музей туплапмаларына академик А.Каралинның гаять сирәк очраучы «Сөембикә ханбикә улы Үтәмешгәрәй белән» парсунасы (персона сүзеннән) кергән коллекциясе, Ю.Котляровның Шаляпинга багышланган җыелмасы, Б.Урманченың шәхси музее өчен әсәрләре коллекциясе өстәлде. Татарстан һәм татар диаспорасының хәзерге заман сынлы сәнгате осталарының коллекциясе формалашты.

«Борынгы Казан» күргәзмәсе (Россиянең һәм Татарстанның 14 музее катнашты) катлаулы гомуммузей панорамасына тематик зур әсәрләр, бөтен стенаны алып тора торган дивар бизәмнәре кертелә алуын раслады. Шулар арасында Ф. Халиковның тарихи темага язылган катлаулы сюжетлы, күп сынлы, XVI гасыр Казанының кайнап торган тормышы сурәтләнгән романтик-монументаль «Нурлы Казан» панносын әйтеп китәргә кирәк. Тарихи-революцион темага багышланган Ленин мемориалы панноларын нәфис итеп эшләнгән, кабарынкы, заманча стиль белән иҗат ителгән, тарихи һәм бүгенге көнгә багышланган зур дивар бизәмнәре, сыннар белән алмаштыру мөмкинлеге туды. Күп тә үтми зал диварларында «Төрки дөнья. Ефәк юлы» (Р.Миңлебаев, В.Шәйхетдинов), «Алтын Урданың күтәрелеше һәм таркалуы» (Р.Кадыйров, И.Гаянов), «Идегәйнең зирәклеге» (С.Гыйләҗетдинов) h.б. урын алды. Шулай итеп, элеккеге мемориалның зур нәкыш әсәрләренә тиңдәш картиналар барлыкка килде; сыннар («Чыңгыз хан», «Ант», «Батыр» — К.Җәмит) калкып чыкты; витриналар, заллардагы кечкенә аудиторияләр, хәтта китап киштәләре — барысы да яңа шартларга яраклаштырылды. Бушаган экспозиция мәйданчыкларында «Казан идарәчеләре залы», «Казан китапханәсе», «Татар мәгърифәтче галименең эш бүлмәсе», «Татар театры», «Милли уен кораллары», «Көмеш гасыр көзгесендә», «Казанның җанлы күренеше» h. б. мизансценалар хасил булды. Бүгенге дөньякүләм атказанган зәркән осталарыбыз эшләгән гүзәл «Казан таҗы» (Ш. Хәялиев, Ш. Латыйпов), «Казанның алтын тәхете» (Ш. Хәялиев, И. Васильева) бу экспозиция күренешләренең үзәген тәшкил итә. Алар еракта ук татарның осталыгын, металл белән эш итә белүен, гүзәл орнаментлар дөньясын тулысынча күзалларга мөмкинлек бирәләр. (Соңгылары «Борынгы Россия Музеумының тарихи тасвирламалары »(1807), «Кораллар палатасының тарихи тасвирламасы» (1835) мәгълүматлары нигезендә эшләнде). Әлеге басмаларда Таҗ һәм Тәхетнең татар ханнарыныкы булуына какшамас дәлилләр бар; аларның типологик тышкы күренеше һәм эшләү ысуллары да моңа ишарә итә.

Хәзер музейда 50 мең экспонат! Бу бик зур байлык! Бары 20 ел эчендә шундый зур сәнгать тупланмасы булдыру — сирәк очрый торган факт! Моның артында хезмәткәрләрнең ташып торган энергиясе һәм... татар тарихи мирасының, сәнгате, мәдәниятенең бетмәс-төкәнмәслеге, байлыгы, күләмлелеге. Шулай итеп, күпкырлы музей эшенең фәнни-фактологик, сәнгати-бәянлау, иҗади башлангычлар, аерым раритетларны торгызу белән бер комплекска үрелүе нәтиҗәсендә, 90нчы еллар

ахырында, татар тарихында беренче буларак, Милли мәдәният музее үсеп чыкты. Әлеге яна музей коллекциясе белән Татарстанда, Россиядә (Мәскәү, Екатеринбург, С.Петербург һ.б.) Венгриядә, Төркиядә, Гарәп Әмирлекләрендә, Финляндиядә, Франциядә (ЮНЕСКОның штаб-квартирасы, Париж, 2001) һәм башка ил-өлкәләрдә таныштылар. Казанның мең еллыгы алдыннан — яңа терәк элементлар, корымчылык детальләре, шәһәр күренешләре белән баеган экспозиция, ниһаять, «галәмгә», шәһәр кинлегенә чыкты. Бу чорда «Борынгы Казан сабантуе» (С.Гыйләҗетдинов, Р.Кадыйров)картинасы, Казан әдипләре сыннары, башкаланың төрле чорларын яктырткан нәкыш әсәрләре, «Казан һәм казанлылар» дигән зур фотокомпозиция (Г. һәм Е.Логвиновлар) иҗат ителде. Әлеге монументаль-сәнгать әсәрләре дә, билгеле бер шартлылыкны эчләренә алган хәлдә, тарихи фактлар нигезендә иҗат ителгәннәр. Аларның асылында Казанның геосәяси (географик урыны һәм сәяси дәрәҗәсе) урыны, аның мәдәниятенең Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чсаларында формалашуы белән бәйле конкрет материаллар ята. Гугген-хейм галереясен хәтерләткән бормалы экспозициянең икенче катында — бүтән материаллар белән берлектә, кул һөнәре сәнгате, алтын-көмеш, күн әйберләр, алтынлап чигү!... Әнче катта — 90нчы елларда иҗади үзгәлеге белән дөньяны кузгаткан «татар авангарды»! Аларны иҗат итүдә Казан рәссамнары белән берлектә Уфа, Мәскәү, Казакъстан һ.б. төбәкләрдә яшәгән татар рәссамнары катнашты (Г.Тукай премиясе лауреаты К.Муллашев, Чыңгызхан төркеме һ.б.). Хәзерге вакытта «алиһәләр»пантеонын шагыйрь Мөхәммәдьяр «Нуры содур» поэмасында тасвирлаган Казанның легендар алтын капкасы — «Дәрвазә» ача.

*Тарихның тукыз йөз кырык сәксендә*
*Мөбарәк мөхәррәм айның уникесендә;*
*Болгар шәһре Казан дәруазәсендә,*
*Кеше күбдер хирә дәруазәсендә.*

Капканың өстендә илаһи язу: «Аллаһы Тәгалә бербөтен килешү йортына чакыра һәм теләгән кешесен дөрес юлдан алып бара...»

Ярославльдәге Иоанн Предтеча храмының «Казан могҗиза тудыручыларының патша капкасы» (XVIIгасыр) - Казаннан бүләк сыйфатында җибәрелгән, дигән легенданы искә алып, Гарәп Шәрыгындагы мөселман капкаларына һәм михрабларына охшатып, без капка образын гомумиләштердек һәм шәһәргә керү урыны итеп торгыздык. Капканың ике ягында — шәһәрнең иминлеген һәм хәзинәсен саклаучы ике яугир.

Музей - ул үткәннәрне торгызу, тарихи процессны күрсәтү, шәхесләрне сурәтләү урыны гына түгел. Иң әүвәл халыкның тарихи мирасын, яшәү көчен, киләчәккә омтылучы «югары рухият»не тапшыру урыны ул. 1000 еллык Казан тирәсендә тармакланган Милли мәдәният музее — халык һәм шәһәр мәдәнияте традицияләренең буыннан-буынга күчүе һәм тотрыклылыгы, татар цивилизациясенең дәвамлылыгы чагылышы. ЮНЕСКОның музейлар бүлеге әгъзасы Ив Джонс Казанга сәяхәт кылган чакта безнең музейны Көнчыгыш Европаның иң матур музейларының берсе дип атады.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече,*
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

# МӘГЪРИФӘТ ЮЛЫНА МАЯКЛАР КАГУЧЫ

ЗАКИР ҺАДИНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

XIX йөз ахыры — XX йөз башында яшәп, иҗатында чорның реаль картиналарын мәгърифәтчелек идеологиясенә нигезләнеп чагылдырган әдипләрнең берсе — Закир Һади. Иҗатының төп өлеше 1903-1908 елларга карый. Әсәрләре басылып чыгуга ук җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә. Г.Тукай «Мәктәптә әдәбият дәресләре»(1910) исемле уку китабына З.Һадиның «Мәгъсүм» хикәясеннән өзек урнаштыра. Г.Ибраһимов та «Яңа әдәбият»(1914) хрестоматиясендә аның әсәрләренә урын бирә. Ф.Әмирхан «Җиһанша хәзрәт» повестен күтәрелгән мәсьәләләр, аларның хәл ителеше, Җиһанша образы бирелеше ягыннан югары бәяли. Мәгърифәтче әдипнең тормышын, иҗатын өйрәнүгә Ж.Вәлиди, Г.Сәгъди, М.Гайнуллин, И.Нуруллин, Г.Халит, Ф.Мусин, С.Хафизов, Р.Әхмәтов, Ш.Садретдинов, Х.Миңнегулов, Ф.Бәширов һ.б. зур хезмәт куя.

* * *

Закир Һади 1863 елда Бәләбәй өязе (хәз. Башкортостанның Шаран р-ны Ярәмкәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Әтисе игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнә, кыш көннәрендә балалар укыта. Башлангыч белемне Закир әтисеннән ала. 12-13 яшьләрендә (1875) аны Тымытык мәдрәсәсенә укырга бирәләр, анда 10 ел укый. Әсәрләреннән күренгәнчә, мәдрәсәдәге укыту-тәрбия тәртипләре булачак әдиптә ризасызлык уята. Монда анарда җылы истәлек калдырган кеше Хөснелгата Муратаев исемле хәлфә була.

Мәдрәсәдә укуын тәмамлагач, дөнья күрү, бераз акча эшләп алу максатында 1885 елны Мәкәрҗә ярминкәсенә бара. Анда бер байга ялланып хезмәт итә. Бераздан укыту эшенә күчә. Монда рус телен өйрәнә башлый һәм рус мәдәнияте белән танышу мөмкинлеге ала. Шул вакытларда Касыйм шәһәреннән ерак түгел Татар бае авылында яңа ысул белән укыта торган мөгаллимнәр әзерләү курслары ачыла. З.Һади шунда укый башлый. Аны тәмамлагач, Мулта авылында мөгаллимлек итә. Шул вакытларда иҗат эшенә керешә. Бер-бер артлы «Бәхетле кыз»(1904), «Бәхетсез кыз»(1904), «Официант»(1905), «Хәер-дога»(1906), «Мәгъсүм»(1906) кебек әсәрләре языла. Аның берничә шигыре «Вакыт», «Йолдыз», «Казан мөхбире» газеталарында басылып чыга.

З.Һадиның дөньяга карашлары формалашуга йогынты ясаган сәбәпләр арасында түбәндәгеләрне күрсәтеп була: 1) мәгърифәтчелек идеяләре чагылыш тапкан татар әдәбияты, аерым алганда, М.Акъегетзадә иҗаты; 2) җәдитчелек хәрәкәте идеологларының берсе булган И.Гаспралы һәм ул мөхәррирлек иткән «Тәрҗеман» газетасы; 3) бу чорда җитди яңарыш дәвере кичергән төрек әдәбияты. Аеруча күренекле язучы Әхмәт Мидхәт әсәрләре татар укучылары арасында уңыш казана.

Беренче рус инкыйлабы елларында ул Одессада яши. Монда мөселман балаларын укыта. Әдип инкыйлаб күтәргән мәсьәләләр белән кызыксына. З.Һадиның рус-япон сугышы турында поэма, яһүдләргә каршы погромнар турында повесть язганлыгы билгеле. Әмма кулъязмалары сакланмаган. 1906 елда яңадан Мулта авылына кайтып,

мөгаллимлек итә башлый. 1908 елда берничә ай Казанда була. Монда Ф.Әмирхан, Г.Тукай кебек әдипләр белән аралаша, «Яңа әсхабе кәһәф», «Жиһанша хәзрәт» повестьларын бастырып чыгара. 1914-1918 елларда З.Һади Харьков шәһәрендә яши, балалар укыта. 1918 елны туган авылы Ярәмкәйгә кайта. 1919-1920 елларда Бурсык авылында укытучы булып эшли. 1921 елгы ачлык вакытында Касыйм ягына китә һәм Бимсала авылында төпләнеп кала, калган гомерен балалар укытып үткәрә. 1933 елда вафат була.

* * *

З.Һади иҗаты XIX йөз ахыры белән XX гасыр башы әдәбиятын бәйләп торучы күпер ролен үти. Әсәрләре яңа гасырга чыккач язылсалар да, аларда мәгърифәтчеләрнең идея-эстетик карашлары урын алган. Шул ук вакытта тәнкыйди реализмга хас, ягъни яңа чор әдәбиятында үзәк билгеләрдән саналачак үзенчәлекләр дә күренә. З.Һади үзе яшәгән, яхшы белгән авыл тормышын, андагы төрле социаль катлаулар тормышын, хатын-кыз язмышының төрле якларын, яшь буынны тәрбияләүне, уку-укытуның торышын, дин әһелләрен һ.б. төрле яклап күрсәтә.

Әсәрләре артында без әдипнең артталык, наданлык, әхлаксызлык, авыр тормыш өчен тирән борчылуын, халкына ярдәм итү теләгең күрәбез. Хикәя-повестьларында тәрәккыят, мәгърифәт яклана, үрнәк итеп куела. Әдәбиятның вазифасын да әдип шунда күрә. З.Һадиның мәгърифәтчелек карашлары беренче әсәрләрендә хатын-кыз язмышына бәйләп ачыла. «Бәхетле кыз» хикәясендә автор татар реализм әдәбиятының башлангычында торган М.Акъегетзадә фикерләрен үстерә. Гайшә үзе теләмәгән кешегә барудан котылып, алдынгы карашлы, әхлаклы Габбаска кияүгә чыга һәм аның ярдәмендә үзе дә мөгаллимә булып житешә. Әсәрдә Габбас муллага бәйле вакыйга-күренешләрне сурәтләүгә зур урын бирелә. Аның кечкенәдән тәрбияле, зирәк булып үсүендә әти-әнисенең, бигрәк тә Хөсни абыстайның роле зур була. Гомумән, З.Һади гаиләдә хатын-кыз ролен, урынын укучыга тәфсилләп сөйли. Габбас яхшы хәлфә Кәримдә белем ала, аннан Казандагы алдынгы мәдрәсәдә дөньяви белемнәр үзләштерә, сәүдә белән шөгыльләнә, русча укырга, язарга өйрәнә һәм язучы әйткәнчә, «кайда куйсаң да ярарлык галиҗәнап бер зат» булып житешә. Мулла булгач, Габбасның эшчәнлеге романтик буяулар белән сурәтләнә. Аның үгет-нәсихәте ярдәмендә кешеләр күзгә күренеп үзгәрә. Идеаллаштырылган Габбас һәм Гайшә образлары Сәлим мулла һәм Ибәт абызагайга каршы куела. Каршылык яңалык тарафдарларының җиңүе белән тәмамлана. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше дә игътибарга лаек. Автор тормыш-көнкүреш детальләреннән, пейзаж һәм портрет характеристикаларыннан уңышлы файдалана. Халыкчан тел, гыйбрәтле фикерләр, мәкаль-әйтемнәр дә әсәрне баета. Хикәянең бөтен пафосы оптимистик рух белән сугарылган. Әдип мәгърифәтнең көченә ышана.

«Бәхетсез кыз» әсәрендә хатын-кызның аянычлы, фаҗигале тормышы сурәтләнә. Баланың кем, нинди булуы, бәхете турыдан-туры аның гаиләсенә, әти-әнисенә бәйле дигән карашны үткәрә автор. Хәнифәнең бәхетсезлегенә сәбәпче булarak гаиләдәге шартлар һәм авылда хөкем сөргән тәртип, гореф-гадәтләр сурәтләнә. Дөрес, автор кызның шәхесенә, үз язмышын үзе хәл итү мәсьәләсенә тукталмый. З.Һади әдәпсез, надан руханиларга нәфрәтен юнәлтә. Аң-белем, мәгърифәт, тәрбия аша халыкны һәртөр фаҗигадән саклап калуга өмет итә.

«Мәгъсүм» хикәясендә З.Һади иске типтагы мәдрәсәнең шәхесне рухи һәм физик зәгыйфьләндерүен ышандырырлык итеп сурәтли. Әсәр герое Мәгъсүм тәрбияле гаиләдә туып-үсә. Әтисе тирә-якта дан тоткан, белемле, нәсихәтле кеше була. Әнисе Хәят абыстай да аның өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Әтисе вафатыннан соң, малайның балачагы әнисе белән үтә. Өйдә әдәп-әхлак, мөлаем мөнәсәбәт, игътибарлылык хөкем сөрә. Әдип Мәгъсүмне һәм Хәят абыстайны табигать белән янәшә куеп сурәтли. Моның белән малай күңеленең сафлыгын, чисталыгын кат-кат искәртә. Ана улын укытып, мулла итү теләге белән кайчандыр ире укыган Шәриф мулла мәдрәсәсенә укырга бирә. Мәгъсүм гаять тә

начар, тәртипсез мохиткә эләгә. Мәдрәсә заманнан артта калган, монда наданлык, көнчелек, әхлаксызлык хөкем сөрә. Хәлфәләр дә шундый ук. Егеткә дәрес бирүче Шәфигулла хәлфә турында «хәзрәткә хезмәт идәрәк, надан булса да, хәлфә исеме бирелгән, күп шәкертләрнең яшь вакытларыны йилгә йибәргән иде» дип яза автор.

Мәгъсүмнең мәдрәсәдәге танышлары бозык эш-гамәлләре белән ана бары начар үрнәк күрсәтәләр. Алар йогынтысында Мәгъсүм көнелендә үзгәрешләр башлана, аның йомшак табигате кырыслана, кешелекле сыйфатлары кими, башкалар кебек ук тәртип боза, каршы әйтә, ярамаган гамәлләр белән шөгыльләнә башлый. Үсеп егет булган Мәгъсүм, дусларына ияреп, күрше авылга маржа кызлары янына йөри башлый. Бервакыт аларны саклап торучы мужиклардан качып, салкында озак ятарга туры килә. Ул суык тидерә һәм авырый башлый. Үз өендә бер ел авырып ятканнан соң, Мәгъсүм вафат була. Яшь егетнең вакытсыз үлеменә нәрсә сәбәп соң? Хикәя тулысы белән шуңа җавап булып тора. Төп сәбәп: мәдрәсәдәге укыту-тәрбия шартлары, хәлфәләрнең наданлыгы, әхлаксызлыгы, үз вазифаларын тиешенчә үтәмәүләре. Моны китап укучыга тулырак аңлату өчен әдип икенче бүлекчәдә элекке мәдрәсә тормышын сурәтли. Без Бәдрелхәят абыстай һәм Фәхриислам хәзрәтнең яшь вакытлары белән очрашабыз. Мәдрәсәдәге шартлар, аларның әйләнә-тирәсендәге кешеләрнең әдәплелеге яшьләргә тәрбияле булып үсәргә мөмкинлек бирә. Бу вакыйгада автор идеалы чагыла.

З.Һади кеше һәм тирәлек мөнәсәбәтен реалистик позициядә торып хәл итә. Әлеге хикәядә язучының осталыгы арта бару да күренә. Әдип геройларның рухи халәтен биргәндә табигать күренешләреннән, психологизм алымыннан уңышлы файдалана. Образ портретлары, характеристикалары да инде тулырак, ачыграк, индивидуальрәк итеп бирелә.

Иске мәдрәсәләр тормышы З.Һадиның «Яна әсхабе кәһәф» («Яңа тау куышы ияләре») хикәясендә аеруча ачык сурәтләнә. Исеменнән күренгәнчә, мәдрәсәне караңгы тау тишегенә тиңли, шунда укып, гомерләрен әрәм итүчеләрне «яңа тау тишеге кешеләре» дип атый. Әсәрдә авторның иронияс‌е, урыны белән сарказмы ачык сизелә. Хикәя башында ук ак сакаллы картның биргән кинәшләре, сөйләгән сүзләре игътибарга лаек. Аның идеалы — «икешәр остабикә берлә дөньясыны теттереп торучы, өшкереп-төкереп тә тамагын туйдыручы» мулла тормышы. Моңа ирешүнең юлын да күрсәтә: «Ширыяздан хәлфә, хәзрәткә кучер булып, фатихасын алды да, хәзер үзе, ишан булып, мөритләр җыя».

З.Һади идеаллаштырылган тормышны да сурәтләп китә. Ул моның белән әлеге мәдрәсәнең реаль тормыштан никадәр аерылып торуын ассызыклый. Икенче яктан, әлеге үзгәрешләр әдипнең хыял-максаты булып та тора. Автор үз карашларын уңышлы сурәт чаралары, алымнары ярдәмендә укучыга җиткерә. Шулай да әсәрдә сурәтләрдән бигрәк сөйләп китү еш очрый. Хикәя азагында авыл кешеләрендәге үзгәрешләрне күрсәткәндә, аның сәбәпләре дә ачылмыйча кала.

«Җиһанша хәзрәт» повесте — күләме ягыннан да, күтәрелгән мәсьәләләрнең сәнгатьчә чишелеше, образларның ачылышы ягыннан да З.Һадиның иң уңышлы әсәре. Иске мәдрәсәдәге укыту-тәрбия эшләрен, надан, әхлаксыз руханиларның эш-гамәлләрен фаш итү, тәнкыйтьләү әлеге әсәрдә үзәктә тора. Ф.Әмирхан «Әль-ислах» газетасында басылган рецензиясендә болай яза: «Чын татар тормышыннан алынып язылган әсәр... Ишанлык мәсьәләсе татар матбугатында бик күптәннән бирле язылып килсә дә, ул турыда мөкәммәл әсәр барлыкка килгәне юк иде әле». Әсәрдә Җиһанша исемле малайның ничек итеп тирәлек, тәрбия тәэсирендә икейөзле, мәкерле, надан, кешелексез, бөтен яналыкка каршы кеше булып формалашуы тасвирлана. Әдип биографизм принцибына мөрәҗәгать итә, ягъни геройның бала вакытыннан алып үлеменә кадәрге тормышы укучы күз алдыннан үткәрелә. Җиһаншаның атасы Дәүләтша, урта хәлле авыл крестьяны, улын муллалыкка әзерли: «Минем улым мулла булыр, яшел чапан киеп йөрер, ул ишектән килеп кергәндә, халык аягүрә торып каршы алыр, кунак итәр», — ди. Малайның беренче остазы Фатыйма абыстай да бу фикерне үстерә. Әлеге

теләк Жиһаншаның иң зур теләгенә, хыялына әверелә, чөнки авылда иң рәхәт яшәүче, сый-хөрмәт күрүче кеше — мулла. Яшьтән шундый тәрбия алып, үзсүзле, кире, тәрбиясез булып үсә. Мәдрәсәдә укыганда бу сыйфатлары тагы да ныгый, чөнки андагы «укытучы-мөгаллимнәр» дә — күбрәк үзләрен кайгыртучы, теләсә нинди юл белән байлык тупларга, дәрәҗә алырга омтылучы кешеләр. Жиһанша «кычкырышырга осталыгы илә бәрабәр инсафсызлыгы аркасында хәлфәсеннән дә өстен» булып чыга. Ниһаять, теләгенә ирешә - «атаклы» ишан була, үз тирәсенә күп санлы мөритләр туплый. Үзенә каршы төшкән муллаларның кайсын алдалап, кайсын куркытып юлыннан алып ташлый. Аның «ишанлыгы мөдәррислегенә, мөдәррислеге ишанлыгына ярдәм» итә. Әсәрдә Жиһанша ишан алдакчы, надан, холыксыз, мәкерле кеше итеп сурәтләнә. Шатлык, уныш килгән кешеләр турында ул «хәер-догам тиде» дип, кайгы, бәхетсезлек килгән кешеләр турында «минем бәддогам төште» дип сөйләнә. Аның тереклек һәм кәсеп турында белгәннәре «чүпрәкче Фәтхи агайдан» артык түгел. Ул фәнни казанышларга каршы тора, газета-журналлар укымаска куша. Әлеге кеше үз балаларын да тәрбияли алмый, алар шулай ук әдәпсез булып үсә.

З.Һади Жиһанша ишан кебекләргә каршы планда Хәсән мулла образын сурәтли. Кайчандыр Жиһанша мәдрәсәсендә укып йөргән, аны ташлап шәһәрдә белем алган бу егет авылга кайтып балалар укыта башлый. Ул янача белем бирә, дөньяви фәннәр белән таныштыра, рус телен өйрәтә, китапханә ачып, халыкка китап һәм газеталар укый. Хәлфә мәгърифәт ярдәмендә кешеләрнең аңын, фикерен үзгәртергә керешә. Башка әсәрләрендәге кебек, хатын-кыз язмышын З.Һади монда да читләтеп үтми. Нәкъ менә Фәхрелбәнатка мөнәсәбәттә Жиһанша ишан белән Хәсән мулланың сыйфатлары ачыла, алар үзара каршылыкка да керәләр. Фәхрелбәнат шәхес ирешкән югары куючы, шактый белемле, акыллы, тапкыр, кыю кыз булып сурәтләнә. Дөньяга карашлары ягыннан алар Хәсән белән фикердәшләр.

Жиһанша ишан һәм аның кебекләрнең чын йөзен ачуга автор өстәмә эпизодлардан да уңышлы файдалана. Газетада басылган материаллар да Жиһанша кебекләрнең типик булуын күрсәтә. Әдип геройларның кичерешләрен тулырак бирү өчен табигать күренешләрен бирә. Бу үзенчәлек З.Һадиның бөтен әсәрләренә дә хас. Геройларны характерлауда әдип каршы кую алымын куллана, аларны йә үзләреннән, йә әйләнә-тирәдәгеләрдән фаш иттерә. Әсәрләренең теле тасвирлы, сөйләм теленә якын, мәкаль-әйтемнәр дә күп («Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала»). Персонажларны индивидуальләштерү максатында портретларына житди игътибар бирелә.

Шулай итеп, З.Һади ижаты татар әдәбиятының реализм юлыннан торган саен ныграк адымнар белән баруын күрсәтә. Әдип үз чорының караңгы якларын фаш итеп, мәгърифәт юлына маяклар кага. Кеше белән тирәлек мөнәсәбәтен тасвирлауда әдәбиятны яңа казанышлар белән баета.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

## Фатих Сәйфи–Казанлының тууына 125 ел

Язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) 1888 елның 22 мартында хәзерге Татарстан Республикасының Әлки районы Карамалы авылында туа.

Мөхәммәтфатих әүвәл Казанның мәхәллә мәктәпләрендә башлангыч белем ала, аннары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.

Әдипнең инкыйлабкача әдәби иҗатына «Мөкатдәс хезмәт» (1907), «Безнең заман» (1909), «Ямьсез тормыш» (1915), «Җәмәгать хадиме» (1916) исемле пьесалары карый. Аның әсәрләре ул вакытта Казанда чыккан «Ялт-йолт», «Мәктәп», «Ак юл», «Аң» журналларында, «Йолдыз», «Тормыш» (Уфа) газеталарында дөнья күрә.

ТАССР төзелгәч, Ф.Сәйфи-Казанлыны, тәҗрибәле журналист һәм сәләтле оештыручы буларак, хакимият эшенә җәлеп итәләр. 1925 еллардан башлап ул татар язуын гарәп графикасыннан латин графикасына күчерү хәрәкәтендә актив катнаша, Татарстан Яңалиф җәмгыятенең рәисе һәм «Яңалиф» (хәзерге «Казан утлары») журналының җаваплы мөхәррире була.

Дәүләт оешмаларында, газета-журнал идарәләрендә җаваплы эшләр башкару, төрле уку йортларында лекцияләр уку белән бер үк вакытта, Ф.Сәйфи-Казанлы иҗади хезмәтен дә туктатмый. Аның «Зимагур», «Крушниклар», «Двор өендә», «Елан токымы», «Кызыл эшелон» исемле хикәяләре, «Корбый иптәш» повесте, «Өч нарат» романы дөнья күрә, шулай ук «Дошманнар», «Зәкуан мулла шәҗәрәсе», «Зөбәрҗәт» исемле пьесалары языла.

Ф.Сәйфи-Казанлы бу елларда татар классик әдәбиятын җыю һәм бастырып чыгару юлында да күп эшләр башкара. Аерым алганда, ул Г.Тукайның — өч томлык (1929-1931), Г.Камалның — ике (1929-1930), Дәрдемәнднең бер томлык (1929) тупланмаларын төзеп чыгара, Г.Камал, Ф.Әмирхан, С.Сүнчәләй иҗатларына багышланган махсус китап язып бастыра («Өч татар классигы турында», 1930).

...Ф.Сәйфи-Казанлы 1936 елның 16 сентябрендә кулга алына. 1937 елның 3 августында СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе үзенең ябык утырышында әдипнең «җинаять эше»н карап, аны иң югары җәзага — атарга хөкем итә. Хөкем карары ике көннән соң — 1937 елның 5 августында гамәлгә ашырыла. Күмелгән урыны Казанның Архангел зиратында дип фараз ителә.

## Мөхәммәт Галинең тууына 120 ел

Язучы, әдәбият галиме, тәрҗемәче Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Мөхәммәтгали улы Галиев) 1893 елның 24 мартында хәзерге Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Олы Елга авылында туа. 1912 елдан 1915 елга кадәр Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Ул Беренче бөтендөнья сугышында катнаша.

Октябрь вакыйгаларыннан соң М.Гали ике ел үз авылларындагы башлангыч мәктәптә балалар укыта. 1919 елның башында Казанга килеп, Мәркәз мөселман Хәрби коллегиясе тарафыннан чыгарылган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә корректор булып эшкә урнаша. Аннары шул ук редакциядә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип һәм газетаның редколлегия әгъзасы вазифаларын башкара. 1921 елның мартында газета чыгудан туктагач, ул «Эшче» газетасына күчә, 1921 елның җәеннән «Татарстан хәбәрләре», соңрак «Безнең байрак», ә 1926 елда «Крәстиян гәзите» редакциясенә күчеп, алты ел шунда әдәби хезмәткәр булып эшли.

1931 елда М.Гали Казан университетының география факультетына укырга керә, укуын уңышлы тәмамлагач (1933), берникадәр вакыт Казан педагогия институтының география кафедрасында ассистент булып хезмәт итә, рабфакта, Казан техникумнарында география фәненнән дәресләр бирә, «Спартак» аяк киемнәре комбинаты каршындагы олы яшьтәгеләр мәктәбендә татар әдәбияты укыта.

1945 елның ахырларыннан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында кече гыйльми хезмәткәр һәм кульязмалар бүлегенең мөдире булып эшли.

М.Гали — шактый бай әдәби һәм гыйльми мирас калдырган шәхес. 1914-1915 елларда «Аң» журналы битләрендә аның бер төркем хикәяләре басыла («Кунак көткәндә», «Җиләккә барганда», «Аулак өйдә», «Авыл егетләре», «Сабан туенда»).

Утызынчы елларда М.Гали драматургия жанрында актив эшли. Аның «Печәнчеләр, яки Бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939) һәм «Каюм Насыйри» исемле биографик-тарихи пьесалары бар. Соңгысы, Хөсәен Уразиков катнашында язылып, 1945 елда Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулу бәйрәме көннәрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела.

Мөхәммәт Галинең «Г.Камал», «Тукайның Уральскидагы тормышы», «Шагыйрь баскан эзләрдән» исемле хезмәтләре, татар иҗтимагый фикере һәм әдәбиятының күренекле вәкилләре Гали Мәхмүдов, Ибраһим Хәлфин, Акмулла, Сәгыйть Рәмиевләрнең тормыш һәм иҗатлары турындагы күләмле мәкаләләре фактик материалга бай һәм фикри яктан заманы өчен шактый объектив яссылыкта язылулары белән аерылып тора. Ул шулай ук атаклы замандашлары Г.Тукай, Г.Камал, Ш.Камал турында истәлек язмалары һәм тәрҗемә китаплар авторы буларак та билгеле. Ул И.Тургеневның «Аучы язмалары», Жюль Вернның атаклы «80 мең километр су астыннан» романын татарчага тәрҗемә итә.

Ул 1952 елның 6 маенда үпкә авыруыннан Казанда вафат була.

## Әхмәт Фәйзинең тууына 110 ел

Күренекле шагыйрь, прозаик, драматург, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм публицист Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин) 1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә дөньяга килә.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Ә.Фәйзине Оренбургтагы Шәрык педагогия институтына укырга җибәрәләр. Шунда ул яшь татар язучылары түгәрәгендә актив катнаша, беренче тапкыр М.Җәлил белән очраша һәм дуслаша. Ләкин 1921-1922 еллардагы ачлык афәте Ә.Фәйзигә институтны тәмамларга мөмкинлек бирми: 1922 елның декабрендә ул, укуын ташларга мәҗбүр булып, Урта Азиягә китә, Төрекмәнстан кышлакларында һәм шәһәрләрендә укытучы, һәвәскәр театр артисты булып эшли.

1928-1930 еллар арасында Ә.Фәйзи Мәскәү, Казан шәһәрләрендә, Татарстанның Арча төбәгендә матбугат һәм мәгариф оешмаларында хезмәт куя, ә 1931 елда Мәскәүгә күчеп, шуннан соңгы гомеренең күп өлешен профессионал язучы сыйфатында уздыра.

Ә.Фәйзи - татар поэзиясендә интеллектуаль шигырь традицияләрен үстерүгә һәм баетуга күп хезмәт куйган шагыйрь. «Чор турында җыр» (1932), «Флейталар» (1934), «Эзләр» (1939), «Давыл җыры» (1943), «Дулкыннар ни сөйлиләр» (1945) исемле җыентыкларындагы лирик һәм публицистик шигырьләрендә, поэма һәм балладаларында бу поэтик сыйфатлар бик ачык төсмерләнә.

Әдип шулай ук күп кенә сатирик хикәяләр, пьесалар авторы буларак та заманында популярлык казана.

Әхмәт Фәйзи күп кенә комедияләр («Каеннар яфрак ярганда», «Беренче елмаю»), сатирик пьесалар, тарихи-биографик драмалар («Тукай», «Пугачев Казанда») иҗат итә, театр сәнгатенең синтетик жанрларын (музыкаль, комедия, опера һәм балет өчен либреттолар) үзләштерү юлында уңышлы адымнар ясый. 1939 елда Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең беренче сезонын Н.Җиһановның Ә.Фәйзи либреттосына язылган «Качкын» операсы белән ачып җибәрә. Н.Җиһановның «Җәлил», М.Мозаффаровның «Зөлхәбирә» опералары, Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балеты шулай ук Ә.Фәйзи либреттоларына иҗат ителгәннәр.

Театр сәнгате өлкәсендәге иҗади казанышлары өчен Ә.Фәйзи 1953 елда — Татарстанның, 1957 елда «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Аның әдәби мирасында «Тукай» романы үзенә аерым урын били. Ике китап итеп уйланылган бу эпопеяны әдип 1947 елда яза башлый һәм беренче китабын 1950 елда тәмамлый. Шул ук елны роман «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында, ә 1952 елны Татарстан китап нәшриятында аерым басма булып чыга. Берничә тапкыр урыс телендә, аннары казакъ, үзбәк һәм болгар телләрендә дә нәшер ителә. Бу романы өчен Ә.Фәйзи 1958 елда язучылардан беренче буларак Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Әхмәт Фәйзи — әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәләрендә бай мирас калдырган язучыларның берсе. Язучы шулай ук киносценарийлар («Тукай», «Тарих рычагы», «Пәйгамбәр Әйүб һәм итекче Сафа»), балалар өчен тезмә һәм чәчмә әсәрләр («Бал корты», «Ак аю», «Тискәре Ишми», «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте» һ.б.), әдәби тәрҗемәләр авторы буларак та билгеле. Аерым алганда, әдип А.Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясен (1937), «Братья разбойники» («Юлбасар туганнар», 1937) поэмасын, Н.Гогольнең «Тарас Бульба» повестен (1953), Т.Шевченко, В.Маяковский, А.Барто һәм башка шагыйрьләрнең күп кенә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Ул 1958 елның 11 августында вафат була.

### Башта ук шулай диярга иде!..

Салих Батталның Фоат исемле энесе дә бар иде. Шушы Фоатның Фәрит дигән улы хәзерге заман телерадиотехникасынын остасы. (Күп еллар инде Татарстан телевидениесендә эшли.)

Бервакыт Салих Батталның телевизоры күрсәтми башлый. Моның ише чакта аптырап тормый — пләмәшен, ягъни Фәрит Батталны чакырып китерә. Хөрмәтле абзасының өендә нинди генә техника көйсезләнсә дә, Фәритебез шундук сафка бастыра да куя!

Фәрит телевизорны да тиз төзәтә. Китәр алдыннан абзасына бер киңәш тә бирмәкче була. Салих Батталны телевизор артына чакырып китерә дә:

— Менә бу «АПЧГ» дигән боргычны күрәсеңме, абый? Телевизорың сүрәнрәк күрсәтсә, әнә шуны уңга-сулга боргалап көйлә.

Текә холыклы әдипнең кашлары күтәрелеп китә:

— Нәрсәне аңлата инде ул АПЧГ дигән нәмәстәң?

— «Автоматическая настройка частот гетеродина» дигән сүз ул...

Мондый катлаулы кәлимәдән әдипнең башы әйләнеп куя, чырае чытыла:

— Нәрсә диден, нәрсә?!

Абзасының бу терминны аңламаячагын һәм исендә дә калдыра алмаячагын белгән Фәрит шундук икенче аңлатма бирә:

— «Антон Павлович Чехов — Гений», дигәнне аңлата бу «АПЧГ»...

Салих Батталның йөзе кояштай балкып куя. Ә үзе бик тә ләззәтле итеп көлеп җибәрә:

— Башта ук шулай диләр аны! Антон Павлович белән без барысын да көйләрбез! Моннан соң гүтер-мүтерләрең белән башымны бутама, яме...

### Бик мөһим хатирә

Бер язучы Фәнзаман Батталга мактана икән:

– Гомер үтә, парин...Мемуарлар, истәлекләр язарга вакыт. Менә мин үткән гомерем турында хатирәләр китабымны язып бетерәм инде. Анда синең белән булган уртак вакыйгалар да тәфсилләп язылды.

– Син Брежнев заманында миннән йөз сум акча алып торган идең. Шуны ни өчен бирә алмый йөрүең турында да берәр бүлек бардыр инде, алайса?.. – дигән Баттал.

### Гадәт хикмәте

Авызыннан тәмәке өзелгәнен яратмаса да, Нияз Акмалның кесәсендә күп вакыт тәмәке булмый. Фәнзаман Баттал исә һич тә тәмәкесез йөрми. Икесе очрашуга, беренче сүз итеп, Акмал тәмәке сорый. Исәнләшүен дә ике-өч тапкыр суыргач кына исәнләшә. Еллар буе шулай дәвам иткәнлектән, аны күрү белән Фәнзаманның кулы кесәсенә керә дә китә икән... Шартлы рефлекс кебек...

Беркөнне Фәнзаман телевизорын кабызып та җибәргән, экрандагы кешене күрүгә, кесәсеннән җәһәт кенә сигарет чыгаруын сизми дә калган. Баксаң-күрсәң, Нияз Акмал телевизордан шигырь укып тора икән...

### Гадел бәягә иртәрәк...

Язучы Рахмай Хисмәтуллинның Түбән Камада яшәгән чагы. Әдәби берләшмәгә житәкчелек итә, Казаннан язучылар, шагыйрьләр килсә, аларга багышлап әдәби очрашулар үткәрә. Мактауларга юмарт, матур һәм бөек сүзләргә бай Рахмай, халыкны яна килгән каләм ияләре белән таныштырганда, залга һәрвакыт бер үк мәдхияләрне яудыра:

— Әдәбиятыбызның иң якты, иң гүзәл йолдызларының берсе, илаһи шигърият остасы Фәлән Фәләнов безгә кунак булып килде...

Әдәбият сөюче, кайсы язучы килсә да очрашуларны калдырмаучы бер агай, икәүдән-икәү калгач:

— Син, Рахмай энем, барысын да йолдызга тиңлисең әле. Минемчә, гадел үк булып бетми син биргән бәяләр, — дигән.

— Ашыкма, абзый. Мин бит әлегә СССР Язучылар берлегенә кабул ителмәгән... Гадел бәя бирер көннәр житәр ул, житәр! — дигән көр тавышлы Рахмай.

### Гарьлегеннән үлгәндер

Әле беренче шигырьләре генә басылган яшь-яшь Нияз Акмал белән бер өлкән язучы сыраханәгә килеп керсәләр, анда артист Наил Әюпов чираттагы бокалны чөмерә. Хәл-әхвәл белешкәч, өлкән әдип артистны янындагы егет белән таныштыра:

— Нияз дигән егет бу. Сарманныкы. Киләчәктә көчле шагыйрь булачак...

— Сарманныкы булгач, киләчәгенә өмет юк инде, — ди жор телле Наил. — Сарманнарның казлары да йөзә белми аларның. — Шунда ук сөйләп тә бирә. — Минем әнкәй Сарманнан каз алып кайткан иде. Каз, мескен, Ыкка керү белән батып үлде.

— Беләм мин ул казның ни өчен батып үлгәнен, — дигән бишектән үк шома Нияз. — Сарман тикле Сарманда үскән каз Мөслим кебек пүчтәк якка эләккәч, хурлыгыннан батып үлгән ул.

### Гаҗәп

Танылган жырчы Гали Ильясовның жыйнак буйлы икәнен һәркем белә. Бервакыт шушы жырчыбыз гаражда машинасын ремонтлап мәш килә икән. Күрәмсең, онытылып киткән — гараж базына егылып төшкән. Икенче көнне сәнгать әһелләре арасында күңелсез хәбәр таралган:

— Гали Ильясов, базга егылып төшеп, аягын ике урыннан сындырган...

Барысы да ихлас күңелдән кайгырышкан. Бары тик виолончель остасы Лариса Маслова гына бу хәбәргә ышанмыйча утыра икән.

— Нәрсәсенә ышанмыйсың инде аның? Адәм башына төрле хәлләр килүе ихтимал бит, — диләр икән артистлар.

— Анысын беләм лә мин, — дигән Лариса. — Тик миңа шундый кыска аякның ике жирдән сынарлык урыны барлыкка гаҗәпләнәм.

### Икесе дә әзер

Равил Шәрәфинең кызы Равия тугач, тәпи йөри башлагач, боларга Илһам Шакиров кунакка килә. Равилнең аш-су әзерләүгә, кунакларны хөрмәтләп каршылауга, сыйлауга бик оста хатыны Рушания ханым бай итеп табын әзерли. Әлбәттә инде, «зәм-зәм сулары» да менеп кунаклый

өстәлгә. Шуларны да шактый авыз иткән кунакның күнеле күтәрелә. Аяк астында уралып йөргән кызчыкны күтәреп ала да:

– Кызың бик матур икән, Шәрәфи! Үсеп җиткәч, кияүгә чыгарлык булып өлгергәч, бу кызың үземнеке булыр! – ди дә, Равиянең колагын тешли.

Еллар уза, Равия үсеп җитә. Җорлык, үткен теллелек җәһәтеннәнәтисеннән әлләни калышмаучы чая кыз, Илһам Шакировны очраткач:

– Мин өлгердем, Илһам абый. Синең хәлләр ничек? – дип сорый.

Көтелмәгән сораудан каушап калган Илһам, һушына килеп:

– Мин дә өлгердем! Житмешкә җиттем менә! – ди. Аннары шуклык белән өстәп куя. – Колак тешләрлек кенә хәл һаман да бар әле, матурым.

## Караңгыда эшләп булмый

Элек Татарстан китап нәшриятында сукырлар өчен махсус китаплар чыгаручы Шәриф ага Еникеев эшли иде. Үзе дә тома сукыр иде мәрхүм. Беркөнне, кичке сәгатьтә, нәшриятта ут сүнә. Өйләренә кайту өчен сәбәп кенә көтеп йөрүче хезмәткәрләр:

— Утсыз эшләп булмый инде, кайтыйк, — диешеп, җыена башлыйлар.

— Нәрсә, ут сүнде дисезме? — ди Шәриф ага һәм үзе дә урыныннан кузгала. — Карангыда күз бозып булмас монда, кайтырга кирәк!

## Кайдан булуына карамастан

Җырчы Фердинанд Сәлахов бер авылга концерт белән килгәч, тамашага кадәр чыгыш ясаган колхоз рәисе залдагылар алдында болай дигән:

— Опера һәм балет театрында эшләвенә карамастан, Фердинанд Сәлахов матур җырлый...

## Кайсы кыйммәтрәк?

Җеннәр, иблисләр турындагы әсәрләре белән дан алган Заһид Мәхмүди өермә күтәрерлек тизлек белән Госман Садә бүлмәсенә килеп кергән дә тегенең өстәленә чалбар ташлаган.

— 80 сумга чалбар алдым, Госман абый, шәпме?

Әйләндереп-әйләндереп караган да Госман, мультфильмнардагы төлкедәй елмаеп:

— Кит инде... 5 тиенлек урыннарыңны томаларга 80 сумлык чалбар алмасаң! Менә мин бу бүрекне дә 60 сумга гына алдым.

Заһид тынып калган. Каты төрттерүенә куанган Госман:

— Нигә сүзсез калдың? — дип көлгән.

— Шуңа исем китте әле, — дигән Заһид. — Киясе әгъзага карап исәпләсәң, синең бүреген минем чалбардан да кыйммәтрәк икән бит.

## Кем кем беләндер бит...

Мәшһүр җырчы Фәхри Насретдинов, яшь җырчы Рафаил Җаббаров белән очрашкач, тиздән гастрольгә чыгачагы турында әйтә.

— Ә-ә, мин бу хакта ишеттем инде, — ди Рафаил. — Сара апа (Садыйкова) белән чыгасың икән, Фәхри абый.

Фәхринең хәтере кала. Авызын Рафаилнең колагына ук терәп:

— Юк, энем, ялгыш аңлагансың, Сара минем белән чыга, — дип, зәһәр пышылдый.

Нишлисең бит, сәнгать кешесе үзен икенче яки өченче итеп күз алдына да китерә алмый. Ул һәрвакыт беренче!

## Кешесенә карап

Тәмәкегә кытлык заманда Ләбиб Лерон белән Фәнзаман Баттал Китап нәшрияты янында очрашкан. Ләбиб Фәнзаманга «Опал» сигареты тәкъдим итә.

— Ничауа, юньле генә сигаретлар тартып йөрисең икән әле, — дип мактаган була Фәнзаман, сигаретны алгач.

— У-у, минем кесәләрдә әллә нинди сигаретлар бар ул! — дип очынып китә Ләбиб. — Мәсәлән, менә хаерчеләр дә тартмаска тырыша торган «Популярный». Анысын тәмәкене кешедән генә «атучы» Нияз Акмал кебекләр өчен йөртәм...

Икенче кесәсеннән «Идел» чыгара:

— Монысы көнаралаш үзләренекен тарта торган Госман Садә кебекләргә бирү өчен.

Фәнзаман сөенеп куя:

— Димәк, мин иң затлысына лаек икәнмен!

— Юк, — ди Ләбиб. — Тагын да затлырагы бар әле. Анысын үзем генә тартам. — Һәм ул күкрәк кесәсеннән әмриканский «Бонд» чыгара.

Фәнзаманның хәтере кала. Ләбибнең биргән сигаретын кире кайтара да, кесәсеннән ментоллысын, алтын язулысын алып кабыза.

## Киресенчә

Фәнзаман Баттал Минзәләгә кайткач, район газитенең баш мөхәррире Мөҗип Хәбриев кунагына озак кына карап, уйланып утырган да:

— Да-а, Фәнзаман абый, бу кадәр туры сүзле булуың аркасында дусларың да кыенны күп ашыйдыр, аларга да хакимият кешеләре кырын карыйдыр... — дип куйган.

— Киресенчә! — дигән Фәнзаман. — Максатымны, фикерләремне белеп бетергәч, аларны йә Кремльгә, йә КГБга эшкә алалар.

## Кыңгыраулы Гөлсем

Мәшһүр җырчы Гөлсем Сөләймановaның яшь чагы, халык мәхәббәтен яулап өлгергән чагы икән. Бер көндәше ана:

— Гөлсем, синең хакта гайбәтләр йөри. Имеш, бу ир белән йөрисең икән, тегесе белән чуаласың икән...

— Бер дә гаҗәпләнмә, ахирәт, — дигән Гөлсем тыныч кына. — Яхшы атка кыңгырау такмый калмыйлар ул.

## Культ бар ла ул...

Дүрт-биш язучы утыз ел буе Мәскәү Кремлендәутырган Сталинның шәхес культы турында сөйләшкән чакта, берсе капыл гына:

—Ул культ дигән нәрсә Кремльдә хәзер дә бардыр әле, егетләр? — дип куйган.

— Культ бар ла ул ... — дигән Фәнзаман Баттал төшенке тавыш белән. — Шәхес кенә юк...

## Имеш

Өч «Бат» — Салих Баттал, Батулла, Фәнзаман Баттал Идел өстендә көймәдән кармак салалар, имеш. Котмәгәндә көймәләре каплана һәм өчесе дә су төбенә китә. Водолазлар, ашыгыч ярдәм врачлары килеп җитә. Халык боларга әлеге өчәүнең кай турдарак батканнарын күрсәтә. Водолазлар агымның аскы

ягыннан эзли башлагач, яр читендә балык тотып утыручы Марс Шабаев:
— Дөрес эзләмисез, җәмәгать! Агымның югары ягыннан эзләргә кирәк аларны! — дип кычкырган.
Мондый киңәштән аптыраган водолазлар:
— Алай булмый инде ул. Логикага туры килми, — диешкәннәр.
— Була! — дигән Марс Шабаев. — Алар гомерләре буе агымга каршы барган кешеләр бит.

## Марсель һәм Жюше

Марсель Галиев чираттагы китабын чыгару өчен Татарстан китап нәшриятына кулъязмасын китергән. Беркадәр вакыттан кабат килеп житкән. Шунда мөхәррир булып эшләүче Фәнзаман Батталга:
— Роберт Батулла кебек, мин дә үз исемемне гарәпләштерәм әле. «Марсель»не «Марсил»га алыштырам, — дигән һәм кулъязмасындагы авторны Марсил Гали итеп үзгәртеп тә куйган. — Марсил — тау елгасы мәгънәсендә йөри икән...
— Ашыкма әле син, Марсель, — дигән Фәнзаман, чын-чынлап тегенең хәленә кергән сыман житди итеп. — Киләчәктә Татарстан Франция йогынтысында яшәячәк. Гонорарны да французлар түләячәк. Әнә, Франциянең Премьер-министры Ален Жюппе килеп тә житкән инде. Синең исем французлар исеме бит. Кадереңне бетермә...
Марсельнең сер бирәсе килмәгән:
— Ну бит... Марсил — тау елгасы... көчле елга!
— Анысы да дөрес түгел! — дип кырт кискән Фәнзаман Баттал. — Марсил — ул су еланы дигән сүз.
Марсель чыгып киткәч, Фәнзаман кулъязма тышына күз салган. Марсель «Марсил»ны яңадан «Марсель»гә әйләндереп куйган икән.
— Менә сиңа Жюппе! — дип куйган Фәнзаман.
... Шуннан соң инде Марсель ата-анасы кушкан исемне берчакта да үзгәртмәскә, ә инде бала һәм оныкларына саф мөселманча гына исемнәр кушып яшәргә  ант иткән, имеш...

## Микробны да күрә

Язучылар йорты янында берничә күзлекле әдип күзлекләрен тикшерешәләр икән. Ягъни кемнеке минуслы яки плюслы, ерактан күрү өченме, якыннанмы, диоптрияләре нинди?..
Шунда Фәнзаман Баттал сүз башлый:
— Мин күзлекне гомерем буе кызлар күзләү өчен генә кидем, егетләр. Якыннан мин микробны да күзлексез килеш күрәм...
Шулвакыт ишектән икенде күләгәседәй озын гәүдәле Ринат Мөхәммәдиев килеп чыга. Аңа карап ала да Баттал, әйтер сүзен түгәрәкләп куя:
— ... әгәр дә ул микроб Ринат хәтле булса.

## «Миңа язучы кирәкми...»

Нияз Акмал Сабан туенда чәчәктәй кызчык житәкләгән сабакташын очраткан. Сабакташы, исәнләшкәндә, кызына:
— Менә, кызым, мин сиңа хәзер тере язучы күрсәтәм, — дип тә әйтеп куйган.
Ә кызы елап жибәргән:
— Кирәкми миңа тере язучы. Син миңа морожный алып бирәм дигән идең. Миңа морожный кирәк.

## Нинди бүләк?

Сарман үзәгендә әкияттәгедәй матур, байларча затлы бала табу йорты салганнар. Сабан туенда тантаналы чыгыш ясаганда хакимият башлыгы әлеге яңалыкны дә искә алып үтә һәм болай дип өсти:

— Сарманыбыз да, киләсе елларда булачак сабан туйларыбыз да сабыйлар авазы белән күркәмләнсен! Ә бу йортта беренче булып бала тапкан хатынны затлы бүләк көтә.

Сабан туена кайткан язучы Нияз Акмал да шунда икән. Икәүдән-икәү сөйләшерлек форсат туган бер минутта ул Башлыктан сорап куя:

— Беренче булып бала табучыга «Ока» машинасы бирәсездер инде?..

— Их, Нияз туган, — ди хакимият башлыгы. — «Ока» машинасы бирсәләр, мин үзем бала табар идем әле!

## «Ничек белмәскә, ди...»

Илдар Юзеев Уфага баргач, башкорт шагыйре Гайнан Әмири белән икесен телевидениедән чыгыш ясарга чакырганнар. Экранга чыгаруның төп максаты — ике тугандаш халык шагыйрьләренең дуслыгын күрсәтү икән.

Беренче сүзне алган Гайнан, Илдарга таба борылып, әңгәмәне башлап җибәрә.

— Менә без, Илдар дустым, икебез ике халыкның шагыйрьләре. Башкорт әдәбияты үскән бер мәлдә татар әдәбияты да үсә. Бу хакта син дә, мин дә беләбез. Без икебез ике халыкның уллары булсак та, бер-беребезнең телен яхшы аңлыйбыз. Мин синең иҗатыңны да, үзеңне дә яхшы беләм. Син дә мине беләсеңдер дисәм, ялгышмамдыр...

Шулчак Илдар үзе дә сизмәстән:

— Һи, ничек белмәскә инде, Гайнан абый, икебез дә бер авыл кешеләре ләбаса! — дип ычкындыра.

Шулай итеп, Янавылның ике кешесе – ике татар – ике халыкның шагыйрьләре сурәтендә бик тә күңелле һәм җылы әңгәмә үткәреп, Башкортстанның шигырь сөючеләрен халыклар дуслыгы белән куандырганнар.

## Озак яшисе калмады

Минзәлә театрының бер бригадасы кайсыдыр авылда спектакль куя икән. Сәхнәдә саф мәхәббәт күренеше. Егет ролен уйнаучы Әхмәдиша Җиһаншин «сөйгәнен» назлап, тәмле-тәмле сүзләр сибеп утырганда, кинәт кенә сәхнә арты, дөресрәге, сәхнә түрендәге рәсем гөрселдәп төшкән. Әхмәдиша бу хәлгә күз салып ала да «сөйгәненә»:

— Әйттем мин сиңа дөнья бетә дип. Ә син һаман сузасың, туйны соңартасың, — дип куйган.

Кыз да аңлаган моны. Әхмәдишаның кочагына кереп:

— Булды, бүтән сузмыйм, — дигән.

Тамашачы әлеге җимерелүне режиссер табышы дип аңлаган.

**Фәнзаман БАТТАЛ**

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ УТЫРЫШЫ

7 февральдә «Татмедиа» ААҖнең конференцияләр залында ММЧ җитәкчеләре катнашында киңәйтелгән утырыш узды. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм РФ элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры урынбасары Алексей Волин да катнашкан утырышта Республика «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының узган елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре игълан ителде һәм 2013 елга бурычлар куелды.

Быелның гыйнвар аена республикада 788 көндәлек матбугат чарасы, федераль телевидение каналларының мәгълүмат агентлыклары һәм башка корреспондент пунктлары теркәлгән. Шулай ук халыкны көндәлек матбугатка яздыруда да күрсәткечләр әүвәлгечә калган, республика басмалары миллионнан артык укучы туплый алган, ә гомуми тираж 1 миллион 665 мең данәне тәшкил итә. Бу — һәр 1000 кешегә, уртача алганда, 438 данә газета-журнал туры килә дигән сүз. Болар хакында Республика «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов үзенең докладында белдерде.

Җыелыш барышында «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Рөстәм Бикмөхәммәтов, «Идел-Пресс» генераль директоры Ришат Хәсәнов, Татарстан журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров һ.б. чыгыш ясады.

Утырышта йомгаклау сүзе белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов чыкты. Ул шулай ук бер төркем гаммәви мәгълүмат чаралары хезмәткәрләренә Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды.

### ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ МУЗЫКА АНТОЛОГИЯСЕ

23 гыйнварда Казан шәһәренең Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Sony Music һәм RCA Red Seal Records ширкәтләре ярдәмендә дөнья күргән «Татарстан композиторларының музыка антологиясе» тәкъдим ителде. Диск-антологиядә Нәҗип Җиһанов, Салих Сәйдәшев, Фасил Әхмәтов, Алмаз Монасыйпов, Фәрит Яруллин, Рәшид Кәлимуллин, Шамил Тимербулатов, Анатолий Луппов, Ренат Еникеев, Мәсгудә Шәмсетдинова, Алёна Анисимова, Резедә Ахиярова, Зөлфия Рәупова, Александр Миргородский кебек танылган композиторларның әсәрләре урын алган. Бу җыентыктагы әсәрләрне Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры башкарды. Диск-антологияне тәкъдим итү тантанасында «B-Sharp» Берлин студиясенең продюсеры Филипп Нидель һәм Sony Music Russia мөдире Йэн Һендерсон катнашты.

### РӘССАМНАРЫБЫЗ ПАРИЖДА

Республикабыздан бертөркем рәссамнар — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рифкат Вахитов, Фәрит Вәлиуллин, Лада Аюдаг, Елена Габдрахманова, Татьяна Никишина, Татьяна Тэнч, Ирина Краснова-Волгина һәм яшь дизайнер Марат Әюпов Франция башкаласы Парижда «Татарстан күге астында» дип исемләнгән күргәзмәдә катнашып кайтты.

Әлеге күргәзмәдә «Казан — Россиянең сәнгать башкаласы» дип исемләнгән проектның йомгаклау чарасы да булды. Ул 2010 елда Прагада башланып, Вашингтонда дәвам иттерелгән иде. Париж исә Универсиада уты кабынган урын буларак сайлангандыр дип уйларга кирәк. Иң элек экспозиция Парижның борынгы китапханәләреннән берсе булган И.Тургенев исемендәге китапханәдә, аннары Россиянең фән һем мәдәният үзәгендә күрсәтелде. Аларда Париж мэриясенең халыкара бүлек җитәкчесе, барлык ассоциацияләр мөдире Пьер Шапиру, Россия үзәге директоры Игорь Шпынов, Парижда яшәүче рус зыялылары катнашты. Франция башкаласында сурәт осталары шунда гомер кичерүче һәм Франциянең иң яхшы 10 рәссамы исәбендә саналган Ринат Анимаев, «Сотби» аукционы арт-директоры Ленар Төрәев белән дә очрашты.

## МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында Татарстан һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Ренат Еникиевнең 70 яшьлегенә багышланган иҗат кичәсе булып узды.

Р.Еникиев – бүген иң күренекле татар композиторларының берсе. Аның музыкасы заманча яңгыравы, милли нигезле булуы белән аерылып тора. Россиякүләм, халыкара мәйданда композитор иҗатының нәкъ менә шул сыйфатлары бәяләнде. Р.Еникиев татар музыкасында ана кадәр булмаган жанрларда иҗат итә. Драматик соната, сатира юнәлеше, автор транскрипциясе, мәсәлән, шундыйлардан. Шулай да аның иң зур казанышлары – симфоник әсәрләре. Композиторның иң зур әсәрләре – фортепиано һәм оркестр өчен концерты, «Крыловка ияреп иҗат ителгән дүрт мәсәл» исемле миниатюралары, Рапсодия, виолончель һәм оркестр өчен диптих, скрипка һәм оркестр өчен триптих, Г.Тукайның «Дошманнар» шигыренә жырчы һәм оркестр өчен монологы, Б.Урманчега багышланган «Сагыш» пьесасы, романсы, гаҗәеп матур «Ариетта»сы һ.б. юбилей кичәсендә дә башкарылды. Ул кичтә Татарстан дәүләт симфоник оркестры белән дирижер Р.Агаронян житәкчелек итте. Солистлар – Татарстанның халык артистлары, музыкантлар Л.Маслова, М.Сиражетдинов, жырчы Р.Маликов, профессор Ш.Монасыйпов.

Иҗат кичәсендә Р.Еникиевне Республика житәкчелеге исеменнән мәдәният министры урынбасары И.Эюпова, Татарстан Композиторлар берлеге рәисе Р.Кәлимуллин тәбрикләде.

## ОЛУГ ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

11 гыйнварда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең актлар залында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, техник фәннәр докторы, профессор Әхмәт Мазһаровка 70 яшь тулу уңаеннан тантаналы чара үтте. Әхмәт Мазһаров – нефть һәм газны күкерт кушылмаларыннан арындыру белән шөгыльләнгән һәм бу өлкәдә шактый зур ачышлар ясаган галим, 165 гыйльми хезмәт, 130 патент иясе. Ул эшләгән технологияләр дөньяның төрле илләрендә кулланыла. Гомумән, ул –Татарстанны һәм Татарстан Фәннәр академиясен дөнья күләмендә таныткан шәхес. Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Әхмәт Мазһаровка «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды. Галимне котларга килгән Россия Фәннәр академиясенең Океанология институты директоры, РФА һәм ТФА академигы Роберт Нигъмәтуллин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, РФА академигы, РФ Дәүләт Думасы депутаты, география фәннәре докторы Михаил Залиханов, Башкортстан Фәннәр академиясе президенты Рамил Бәхтизин, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге рәисе Олег Синяшин кебек шәхесләр тарафыннан галимнең фәнни-оештыру эшчәнлегенә югары бәя бирелде. Чарада шулай ук язучылар, журналистлар һәм жәмәгать эшлеклеләре катнашты.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

11 февральдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында танылган шагыйрь, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мөхәммәт Мирзаның (Илфак Ибраһимов) 60 яшьлегенә багышланган «Сине эзләп килде жаным» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Ул М.Мирза шигырьләренә композитор Р.Мөхетдинова иҗат иткән «Идел-йорт» кантатасы белән башланды. Әсәрне М.Таминдарова житәкчелегендәге камера хоры һәм Р.Абязов житәкчелегендәге «La Primavera» оркестры башкарды. Аннары бәйрәмдарны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.Ратникова котлады. Ул М.Мирзага Президент Р. Миңнеханов һәм Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатларын, Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиевнең шәхси бүләген тапшырды.

Кичәдә шулай ук Татарстанның халык шагыйре Р.Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Р.Батулла чыгыш ясады. Камал театры артистлары башкаруында шагыйрьнең шигырьләре яңгырады. Шигъри мәжлес М.Мирзаның якташлары – актанышлыларның котлау-чыгышлары, аның шигырьләренә язылган жырлар белән үрелеп барды.

## ТАТАР ГАЛИМЕ СОРБОННАДА

Сорбоннада «Россиядә заманча федерализм һәм Татарстан Республикасы» дигән темага диссертация якланган. Аның авторы, жирле татар диаспорасы вәкиле Ришат Сабиров Россия федерализмы үсешендә Татарстанның өлешен өйрәнгән. Жюри әгъзасы, профессор һәм Россия буенча белгеч Жан-Робер Равио, бу эш гаять үзенчәлекле, чөнки ул Франциядә Россиянең заманча эчке сәясәтен өйрәнү буенча фәнни бушлыкны тулыландыра, дип белдергән. Әлеге гыйльми хезмәт Франция һәм Россия политологларының эшләренә таянып башкарылган. Диссертация милли мәдәниятне һәм телләрне саклауда Татарстанның ролен уңышлы ача, дип белдергән Франциянең Көнчыгыш телләре һәм цивилизация институты профессоры Жан Радвани.

## ИСКӘ АЛУ

Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында күренекле шагыйрь, прозаик, драматург һәм тәрҗемәче Равил Бохараевны искә алу кичәсе булып узды.

Р.Бохараев Казанда туып-үскән кеше. Шулай да гомеренең байтак өлешен туган ягыннан еракта, чит илләрдә яшәп үткәрде. Соңгы дистә елларда ул Лондонда яшәде, иҗат итте һәм вафаты да шунда булды.

Кичәдә ТР Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Рафис Корбан, шагыйрьләр Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Лилия Газизова, Равил Бохараевның энесе Наил, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, язучы белән аралашып яшәгән кешеләр, аның иҗатын яратучылар чыгыш ясады.

Искә алу кичәсендә Р.Бохараевка багышланган документаль фильм да күрсәтелде.

## ЯШЬ КОМПОЗИТОРНЫҢ УҢЫШЫ

Татар композиторы Эльмир Низамов «Композитор XXI века» дигән халыкара заманча музыка конкурсы лауреаты булды. Яшь композиторга «Ел премьерасы» номинациясендә III дәрәҗә премия бирелде. Ул бәйгедә Гомәр Хәйям шигыренә «Без кайдан килдек» вокал циклы белән катнашты. Моңа кадәр дә «Казан турында риваять» рок-операсы авторы төрле халыкара бәйгеләрдә лауреат булган иде инде. Хәзерге көндә Эльмир Казан дәүләт консерваториясендә композиция кафедрасы укытучысы булып эшли һәм аспирантурада укый.

## ТЕАТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕН ЯД ИТҮ

***

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында мәшһүр режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашеваның 110 еллыгына багышлап, К.Тинчурин пьесасы буенча куелган «Сакла, шартламасын» комедиясе күрсәтелде. 1956 елны режиссер К.Тумашева әлеге театрга эшкә килгәч тә, шушы спектакльне сәхнәләштергән булган.

***

Минзәлә Татар дәүләт драма театры бинасы каршында аның беренче режиссеры, директоры, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Сабир Өметбаевка бюст-һәйкәл ачу тантанасы булды. Әлеге чарада республика театрлары вәкилләре, мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина, район башлыгы Рәсим Садыйков, шәһәр җәмәгатьчелеге катнашты. Бюст-һәйкәлне сынчы Хәмит Миннегалиев эшләгән.

***

Күпьеллык намуслы хезмәте, Татарстан мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы «Мәдәни җомга» газетасы редакциясе» директоры – баш мөхәррире урынбасары, «Чын мирас» журналы баш мөхәррире **Ибраһимов Илфак Мирза улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

Уфада яшәүче татар шагыйре, Башкортстан Язучылар берлеге рәисенең татар әдәбияты буенча урынбасары, журналыбызның даими авторы **Марис Назиф улы Нәзиров** 64нче яшендә вафат булды.


2013 елның 12 февралендә язучы **Заһид Фәйзи** (Заһид Батыр улы Фәйзуллин) 80 яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Язгы ташу.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Ләйсән Фәтхетдинова**.

# Яңа китаплар




**Нурмөхәммәт Хисамов.** Татар шагыйрьләре: монографик мәкаләләр, иҗат портретлары һәм этюдлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. — 287 бит. Тиражы — 2500 данә.

Бу китап аша күп гасырлык татар шигъриятенең үсеш этапларын күз алдына китерергә мөмкин. Галим төрле чорларга караган утызга якын шагыйрь иҗаты турында фикерләре белән уртаклаша. Укучылар әлеге хезмәт белән танышканда тарихның өч дәвере: урта гасыр, XX йөз башы һәм совет чоры шигърияте турында байтак мәгълүмат алачак. «Мин шигъри иҗат белән яшәгәнгә һәм, асылда, шигърият белгече булганга, шагыйрьләр турында яздым» ди автор китапка бирелгән кереш сүзендә.

Җыентык шигърият белгечләренә, югары уку йорты мөгаллимнәренә, филолог студентларга, урта мәктәп укучыларына һәм югары сыйныф укучыларына адреслана.




**Равил Фәйзуллин:** шигырьләр = Вечность мгновения: стихотворения. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. — 287 б. Тиражы — 3500 данә.

Полиграфик яктан затлы итеп чыгарылган бу китапка Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның талантын һәм иҗат үзенчәлеген билгели алырлык, чагыштырмача кыскарак күләмдәге шигырьләре тупланган. Төрле елларда язылган бу шигырьләр ике телдә — татарча һәм русча тәрҗемәдә бирелгән. «Моңа кадәр оригиналның тәрҗемәсе белән янәшә урнаштырылган китап чыгарганым юк иде әле. Һәм шунадыр да аерым бер дулкынлану, уңышка өметләнү хисе белән әзерләдем мин аны» дип яза автор. Китапта шулай ук шагыйрь турында тәфсилле мәгълүмат һәм аның басылып чыккан китаплары турында библиографик белешмә дә бирелгән.



Ләйсән Фәтхетдинова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)